Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

# РУХИ МИРАС
## эзләнүләр һәм табышлар

2 нче чыгарылыш

Казан
2016

Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ
## поиски и открытия

Выпуск 2

Казань
2016

УДК 801.82(082)
ББК 63.2:80я43
Д 85

*Печатается решением Ученого совета*
*Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан*

Проект реализуется Центром письменного и музыкального наследия
Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук РТ – Мирасханэ

Издание осуществлено при финансовой поддержке
РФФИ и Правительства Республики Татарстан
в рамках научного проекта № № 16-46-161059

**Редколлегия:**
***И.Г. Гумеров*** *(руководитель проекта и ответственный редактор),*
***М.И. Ахметзянов, З.З. Рамеев, Ф.З. Яхин***

**Составители выпуска:**
***З.З. Рамеев, Л.Ш. Гарипова, А.Р. Мубаракшина, Л.Ш. Давлетшина***

**Д 85** **Духовное наследие: поиски и открытия** / под ред. И.Г. Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – Вып. 2. – 300 с.
ISBN 978-5-93091-201-2

Сборник продолжает традицию публикации малоизвестных письменных источников; изучения произведений, составляющих основу духовного наследия татарского народа; знакомства читателей с новейшими исследованиями в изучении татарских текстов.

Очередной выпуск серии посвящен жизни и творчеству писателя, публициста и общественного деятеля Ф. Амирхана. В сборнике впервые публикуются ранее не издававшиеся на кириллице публицистические статьи писателя, вводятся в научный оборот письма выдающихся деятелей татарской культуры и науки начала XX века, адресованные Фатиху Амирхану, их воспоминания. Особого внимания заслуживает уникальный дневник К. Сагиди, зафиксировавший последние дни и часы жизни классика.

ISBN 978-5-93091-201-2
© Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2016

## КЕРЕШ

«Үз миллəтеңне кирəгенчə сөяр өчен, аның рухын аңларга, аның халəте руханиясендəге бик нечкə мусика (музыка) тамырларын чиертеп, шуларның чыгарган тавышларын тыңлый белергə кирəктер. Шул вакытта гына кабык астына яшеренгəн куəи руханияне (эчке көчен), лəтафəт, матурлыкны күреп яратырга мөмкин буладыр», дип яза Ф. Əмирхан үзенең бер мəкалəсендə. Əйе, миллəте өчен җан атучы, аның килəчəге, язмышы өчен борчылган, гомумəн, миллəт тəрəккъыятенə көчен кызганмаган олуг язучыбыз, татар əдəбияты классигы, прозаик һəм драматург, журналист, ялкынлы публицист Ф. Əмирханның 130 еллыгы – мəдəниятебез өчен зур вакыйга. Чын мəгънəсендə олы талант, зыялы əдип булган Ф. Əмирхан иҗаты төрле чорда төрлечə бəялəнде, тарих томанында калып, билгесезлеккə дучар ителгəн вакытлары да бар иде. Лəкин галимнəребез тырышлыгы белəн мирасы, акрынлап булса да, халкына барып иреште, үзенə лаеклы урынын тапты, бу эш əле дə дəвамлы рəвештə алып барыла.

Ф. Əмирхан мирасын барлау юлында Г. Ибраһимов исем. Тел, əдəбият һəм сəнгать институты галимнəре дистə еллар дəвамында максатчан эш алып бара. Институтның текстология бүлеге хезмəткəрлəре тырышлыгы белəн язучының дүрттомлыгы дөнья күрде (1985–1989), əдəби чыганакларны өйрəнүгə багышланган һəм 1987 елдан аерым серия булып чыгып килгəн җыентыкларда, əдипнең юбилее уңаеннан чыккан басмаларда, истəлеклəр китабында да язучы иҗатын һəрьяклап яктырткан мəкалəлəр урын алды. Ф. Əмирханның олуг юбилее җəһəтеннəн быел башкарылган эшлəр, уздырылган чаралар дə байтак. Казанда Институт тарафыннан «Фатих Əмирхан: тормышы, иҗаты, мирасы» исемле Россиякүлəм фəнни-гамəли конференция оештырылу, максатчан рəвештə эзлəнүлəр нəтиҗəсендə «Хəят» əсəренең дəвамы табылып, беренче һəм икенче кисəклəренең бергə басылып чыгуы, бүгенгə кадəр сакланып калган оригинал фотосурəтлəре аша тормыш сəхифəсен

күз алдына бастырган «Фатих Әмирхан фотографияләрдә» альбомының дөнья күрүе, «Фәнни Татарстан» журналының 4 санында әдип иҗатын төрле аспектларда анализлаган мәкаләләр циклы нәшер ителү – шуның ачык мисалы. Дөрес, Ф. Әмирхан иҗатына мөнәсәбәтле материаллар болар белән генә дә чикләнми. Язучының, теге яки бу сәбәпләр аркасында, узган гасырда чыккан томлыкларына кермәгән һәм бүгенгә кадәр гарәп язулы чыганакларда гына сакланып килгән, яисә, гомумән, яңа табылган текстларын фәнни әйләнешкә тәкъдим итү максатыннан «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» җыентыгының әлеге II чыгарылышы тулысы белән Фатих Әмирхан иҗатына багышлана.

Китапта материаллар төп ике бүлеккә җыеп бирелә. Беренче бүлектә Ф. Әмирханның үз текстлары – язучының үткен каләменнән төшкән һәм моңа кадәр басылмаган яки гарәп графикасында XX гасыр башы газета-журнал битләрендә генә сакланып калган публицистик мәкаләләре – текстологик яктан эшкәртелеп, укучыларга тәкъдим ителә.

Икенче бүлек язучының тормыш һәм иҗат сәхифәләрен тулырак күзалларга ярдәм итә торган, язучының дуслары, каләмдәшләре тарафыннан язылган язмалардан гыйбарәт. Алар арасында моңа кадәр дөнья күрмәгән истәлекләр, хатлар һәм башка төр чыганаклар бар.

Ф. Әмирханның сакланып калган хатлары киң катлау укучыга мәгълүм. Ләкин аңа язылганнарның күбесе әле җәмәгатьчелеккә таныш түгел. Шушы җәһәттән бу бүлектә Ф. Әмирханга адресланган хатлар бирелә, алар язучының даирәсен, шәхсиятен ачыклау ягыннан да укучы өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз. Хатларның авторлары арасында татарның күренекле шәхесләре Р. Фәхретдин (1859–1936), В. Бәхтияров (1881–1960), К. Мотыйгый (1883–1941), И. Бикколов (1884–1938), К. Бәкер (1885–1944), Б. Шәрәф (1883–1942) һ.б. бар. Хатларда язучы тормышындагы кайбер фактлар ачыла, иҗат лабораториясен күз алдына китерердәй бай мәгълүмат табыла, шул чорның иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-мәдәни фонын тикшерү җәһәтеннән дә әһәмияте зур. Кайбер хатлар көнкүреш, хәл-әхвәл белешү характерында булсалар да, телнең үсешүзгәрешен өйрәнү ягыннан кыйммәтле чыганаклар булып тора.

Икенче төр материаллар – истәлекләр. Ф. Әмирхан хакындагы истәлекләр нәсел дәвамчылары, галимнәр тарафыннан өйрәнелеп, аерым китаплар булып басылып чыкты. Шулай да, алар

арасында мәгълүм елларда өлешчә генә тәкъдим ителгән, редакцияләнгән, «шомартылган» яки тикшерүчеләр күзеннән читтә калган, эзләнүләрнең уңышлы нәтиҗәсе булган кыйммәтле ядкәрләр дә бар. Мәсәлән, шагыйрь Миргазиз Укмасый (1884–1948), тарихчы галим, үткен каләмле журналист, җәмәгать эшлеклесе Габделбари Баттал Таймас (1880–1969), журналист һәм педагог В. Бәхтияровның хатыны Разия Бәхтиярова, укытучы Габдерахман Рәфыйковның улы Хәбибрахман Рәфыйков истәлекләре – әнә шундыйлардан. Татар һәм төрек халкына хезмәт иткән милләттәшебез Г. Баттал-Таймасның Ф. Әмирхан хакындагы истәлеге 1965 елда Төркиядә дөнья күрсә дә, татар телендә беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Истәлек шунысы белән дә кадерле: биредә Ф. Әмирханның 1922 елда Финляндиядәге мөселман оешмасының өлкән имамы Вәли-Әхмәт Абдул-Хәкимовка (1890–1962) язган хат тексты урын алган.

Ф. Әмирханның иҗат мирасын барлау, урынын тану һәм таныту максатыннан, аның үлем түшәгендә яткан көннәрендә булган вакыйгаларны бар төгәллеге белән теркәп барган якын дусты, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Кәрим Сәгыйтев (Кәрим Сәгыйд, 1888–1939) көндәлеге исә яңа табылган күләмле ядкәрләрнең берсе булып, язучыбызның күңел халәтен тирәнрәк аңларга, аерым бер бәхәсле мәсьәләләргә төгәллек кертергә ярдәм итә. Бу кыйммәтле чыганакны Кәрим Сәгыйтевнең оныгы, бүген Санкт-Петербург каласында гомер итүче, Г. Тукайның Казанда узган 130 еллык юбилей чараларында да актив катнашкан Эльмира Тисенко Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә тапшырды.

Мирасханәдә Ф. Әмирханның кулъязмаларын, фотоларын, шәхси документларын, аның турында хатирәләрне берләштергән фонд тасвирламасы да әлеге мирасның никадәр бай, кыйммәтле икәнен күрсәтә. Язучы вафатыннан соң якыннары, дуслары аның фатирында булган барлык язмалары, шәхси әйберләренең беренчел тасвирламасын төзиләр: «1926нчы ел июль аенда мәрхүм әдип Фатих Әмирханның әсәрләренең әдәби василары – без – Галимҗан Шәрәф, Ибраһим Бикколов мәрхүмнең фатирында табылган бөтен кулъязмаларын, хатларын, мәрхүмнең тәрҗемәи хәленә һәм исемен мәңгеләштерүгә бәйләнешле булган сәнәдләрне, китапларны, рәсемнәрне, кием вә бүтән материалларны барлап, һәммәсен язып алдык» диелә әлеге гакыднамә-килешүдә. Ләкин, кызганычка каршы, Г. Шәрәф, И. Бикколов, шулай ук Ф. Әмирханның энесе

И. Әмирханов имзалаган бу тасвирламадагы тәфсилләп саналган, ачык күрсәтелгән язмаларның күбесенең язмышы билгесез булып кала. Дөрес, кайберләре төрле елларда институт Мирасханәсенә тапшырылган. Мәсәлән, 1965 елда язучы, җәмәгать эшлеклесе А. Шамов (1901–1990) тасвирламада күрсәтелгән «Татар кызы» әсәренең кульязмасын бүләк итә.

Күргәнебезчә, соңгы вакытларда Ф. Әмирхан иҗат мирасына мөнәсәбәтле байтак чыганаклар киңкатлам укучылар игътибарына тәкъдим ителде. Инде күпме еллардан бирле хәбәрсез булып, җәмәгатьчелекне кызыксындырып килгән һәм югарыда әйтелгән тасвирламада урын алган «Хәят» әсәренең икенче өлеше дә табылды һәм аерым китап буларак нәшер ителде. Димәк, эш тукталмый, үзенең уңышлы нәтиҗәләре белән куандыра һәм язучының иҗади мирас фонды елдан-ел байый, эчтәлекле чыганаклар табыла тора. Гомумән, әдәбият тарихына, язучыларыбыз иҗатына бәйле яңа истәлекләрне барлау, фәнни-гамәли кулланышка кертү өзлексез дәвам итә, шуның чагылышы булган әлеге җыентык та укучыларыбыз өчен әһәмиятле булыр дип уйлыйбыз.

*Ләйлә Гарипова,*
*Илһам Гомәров*

# ӘДИП ПУБЛИЦИСТИКАСЫН БАРЛАГАНДА…

Моннан утыз биш еллар элек, тууына 100 ел тулу вакыты якынаюны истә тотып, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (хәзер: ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) текстологларының фәнни-тикшеренү планнарына Фатих Әмирхан «Әсәрләр»енең дүрт томлы басмасын әзерләү эше дә кертелгән иде. Әйтергә кирәк, моңа кадәр бу иҗади мирасны текстология җәһәтеннән өйрәнүдә башлангыч адымнар гына ясалган булу сәбәпле, томнарны төзүчеләр итеп билгеләнгән Фатыйма Ибраһимова, Нажия Садыйкова, Зөфәр Рәмиев, Марсель Әхмәтҗанов – басманың фәнни редакторлары – эш барышында төрле-төрле четерекле мәсьәләләрне хәл итәргә тиеш булдылар. Аерым алганда, болар – Ф. Әмирхан әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның җентекле библиографиясе төзелмәгән булу, атрибутив эзләнүләр уздыру кирәклеге, кайбер әсәрләрнең басма һәм кульязма вариантларында автор ирек-ихтыяры чагылышын ачыклау, текстларны укучыга якынайтуга хезмәт итәрдәй аңлатма-искәрмәләр язу. Билгеле, төзүчеләр аларның күбесе, бигрәк тә Ф. Әмирханның, башлыча, татар вакытлы матбугаты битләрендә чыккан мәкалә һәм фельетоннары, рецензияләре белән эш иткәндә «очраштылар». Бу мәсьәләләрнең кайберләре аеруча 3 нче томны төзегәндә кискен торды, чөнки анда Ф. Әмирханның публицистик язмаларын урнаштыру планлаштырылган иде. Әдипнең бик актив язышкан чоры аның, гамәлдә, үзе «тартып» барган «Әлислах» (1907–1909), шулай ук «Кояш» (1912–1918) газеталары нәшер ителгән елларга карый. Бу абруйлы матбугат органнарында ул шул чор татар дөньясы өчен актуаль мәсьәләләрне күтәргән мәкаләләрен күп вакыт төрле-төрле псевдонимнар (тәхәллүсләр) белән (бу турыда: З. Рәмиев. Дамелла, Марксист. Ташмөхәммәд // Мәдәни җомга. 1996. 2 фев.) тәкъдим итә, еш кына аноним рәвештә генә дә чыгыш ясаган.

Ф. Әмирханның дүрттомлы «Әсәрләр»е совет режимы елларында әзерләнде һәм нәшер ителде. Билгеле ки, моны төзүчеләр

һич тә онытмаска тиеш булдылар. Нәтиҗәдә, әдипнең кайбер текстлары басмадан читләштерелде, комментарийлар рухына да теге яки бу дәрәҗәдә тәэсир ясап торды. Ләкин бу гына төп сәбәп булмыйча, әдәби мирасыбызны барлау барышында да язучының әдәби хәрәкәткә, иҗтимагый-мәдәни яшәешкә кагылышлы җитди мәсьәләләрне күтәргән кыю мәкаләләре табылып тора. Шуны истә тотып, Ф. Әмирханның публицистик иҗатына караган бер төркем текстлар тупланып, текстологик яктан эшкәртелеп, әлеге җыентыкта укучыларга тәкъдим ителә. Күпчелек очракта әдипнең ачык («Фатих Әмирхан») имзасы белән «Әлислах» һәм «Кояш» газеталары битләрендә дөнья күргән бу мәкаләләрдә 1908–1917 елларда, башлыча, Казанда, Россия империясе башкаласы Петербургта булып торган иҗтимагый, мәдәни, дини вакыйгаларга мөнәсәбәт белдерелә (Дәүләт Думасы эшчәнлеге, Харитоновның Коръәнне бозып бастыруы, мәсҗедләр, Казан мәдрәсәләрен берләштерү мәсьәләсе һ.б.). Аеруча да әһәмиятлесе – 1917 елгы ике революция арасында, «Кояш» газетасының 13 санында басылып чыккан «Инкыйлаб вә без» мәкаләсе. Анда Ф. Әмирханның катлаулы иҗтимагый шартларда татар халкының милли мәнфәгатьләрен кайгыртып язуы, сыйнфый каршылыкларны алга чыгармаска өндәве ачык чагыла. 1911 елда әдип «Фәтхулла хәзрәт» повестен җиңелчә көлү, ирония белән сугарылган «Минем тәрҗемәи хәлем» дигән автобиографик язма белән кушып чыгара. Ул совет чорында беренче мәртәбә Ф. Әмирханның ике томлыгында булып та, дүрттомлыкка кертелми калган иде. Аны да бу тупланмада бирү мәслихәт күрелде. Бу мәкаләләр алдагы фәнни эзләнүләр өчен ныклы нигез булыр дип уйлыйбыз.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы З. Рәмиев*

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ПУБЛИЦИСТИК МӘКАЛӘЛӘРЕ

## Сәясәт галәмендә

Үткән номеруларның берсендә Думада бюджет (доход – расход) мәсьәләсе хакында малия назыйренең[1] Думада хотбә сөйләгәнен язган идек. Хәзер, гомумән, бюджет хакында бераз нәрсә язу файдадан хали булмас[2].

Гарби Яурупа мәмләкәтләрендәге парламентларның иң әһәмиятле имтиязлары – бюджетдыр. Вәкилләр хөкүмәт тарафындан ясалып гарыз ителгән[3] бюджет ляихасен[4] кабул итүдә һәм итмәүдә ихтыярлыдырлар.

Безнең Русия Думасы бюджет хакында биннисбә[5] бик аз хокукка малик[6] итдерелеп ясалганга күрә, әлбәттә, безнең вәкилләр бюджетка ул кадәр тәэсир итә алмыйлар, халык акчасындан расход тотыла торган нәрсәләрнең күп кыйсеме бөтенләй Дума нәзарәтенә гарыз ителмәстән, хөкүмәт тарафындан сарыф ителәдер.

Мәсәлән, гаскәр вә флотка тотыла торган акчалар Дума нәзарәтендән башка да сарыф ителенә аладырлар.

Менә шуңа күрә дә, Думаның оппозиционный партияләре малия нәзыйренә каршы сөйләгәндә, иң күп әһәмият биргән мәсьәләләре Думаның бюджет тугрысындагы хокукының артдырылырга тиешлеге иде. Хәзер хөкүмәт гарыз иткән 1908 нче сәнә өчен бюджет ляихасе күбрәк әгъзалары октябрист вә уңнардан сайланган бер комиссия нәзарәтендәдер.

–

Соңгы көнләрнең иң зур сәяси вакыйгасы – 12 нче декабрьдә Беренче Дума әгъзалары өстендән башланган суддыр. Беренче Дума үзе хакында шулкадәр онытылмаслык хатирәләр калдырган, бу парламентның 180 вәкиле, Выборг воззваниясенә кул куйган өчен, ягъни Русия гражданларын солдат бирмәскә вә

---

[1] Малия назыйренең – финанс министрының.
[2] Файдадан хали булмас – файдасыз булмас.
[3] Гарыз ителгән – тәкъдим ителгән.
[4] Ляихасен – проектын.
[5] Биннисбә – чагыштырмача.
[6] Малик – ия.

налог түләмәскә өндәп язылган хотбәнамәне тәэлиф өчен[1] хөкем ителәләр. Болар арасында Муромцев, Петрункевич, Аладин (ләкин ул читтә качып йөри) кеби кешеләр бардыр.

## Беренче Дума әгъзаларына хөкем

18 декабрьдә Русия мөхакамә[2] вә хокукый тарихы сәхифәләрендә иң мөһим урынны ишгаль итәчәк[3] хөкем тәмам булды. Мондан ел ярым әүвәл, Русиянең әүвәлге парламентка[1+] халык тарафындан сайланып барган бу депутатлар 12 декабрьдә Петербург палатасының мәхкүмнәре эскәмиясенә утыртылдылар.

Бу вәкилләргә 129 нчы статья буенча гаеп иснад кыйлынып[4], хөкемнәре бу көнгә калдырылуы сәбәпле, 2 нче, 3 нче Думаларга халык теләве белән дә болар сайлана алмадылар.

Палата хөкемнең әүвәлге көнендә горефчә, болардан нәрсә белән иштигаль иткәнлекләрене[5] сораганда, мәхкүмнәр[6] тарафыннан ошбу җаваплар биреләләр иде: профессор, ординарный профессор, приват-доцент (яшь профессор), мөхәррир, хаким, прокурор, халык хезмәте белән мәшгуль, табиб, мөһәндис, мөгаллим… идем.

Мәхкүмләр арасында хокук фәненә 35 ел хезмәт иткән Русиянең әүвәлге парламентының рәисе Муровцев, кырык ел гомум хезмәте белән мәшгуль булып, кырык еллык юбилей урынына мәхкүмләр эскәмиясенә утыртылган Петрункевич кеби затларның ак сачләре, нурлы йөзләре мөхакәмәләрнең залына моңар кадәр күренмәгән бер кыяфәт бирәләр иде.

Мәхкүмләр өч кыйсем: кадет, трудовик вә социалистларга бүленеп, һәр кыйсем тарафыннан берничә депутат үзләренең Выборг хитабнамәләренә мөнәсәбәтләре вә үзләрен гаепле саныйлармы икәнлекләренә даир бәянәт[7] бирделәр.

Кадетлар тарафыннан карт Петрункевич, Москва университетының приват-доценты Кокошкин вә исеме бөтен Русиягә мәгълүм гомум хезмәте белән иштигаль итүче Набоков сөйләделәр.

[1] Тәэлиф өчен – язган (чыгарган) өчен.
[2] Мөхакәмә – хөкем чыгару.
[3] Ишгаль итәчәк – биләячәк.
[4] Иснад кыйлынып – ягылып.
[5] Иштигаль иткәнлекләрене – шөгыльләнгәнлекләрен.
[6] Мәхкүмнәр – хөкемгә тартылучылар.
[7] Даир бәянәт – караган аңлатмалар.

Болар өчесе дә Выборг воззваниесенең тарихи мәҗбүрият белән вөҗүдкә килгәнлегене һәм мондый вакыйгалар Русия вә Англия парламентларында вакыйгъ булган идарәи мәшруталыкка мохалиф түгел[1] икәнлегене бәян итделәр. Тарихи мәҗбүрият белән вөҗүдкә килүне исбатта: «Русия халкының әүвәлге Думадан бик күп нәрсә – йир һәм ирек көткән вакытында хөкүмәтнең бу Думаны таратуына каршы, халыкка бер җавап бирергә тиеш булып, ул җавапта шушы хатибнамәдан башка нәрсә булырга мөмкин түгел иде», – диеп сөйләделәр.

Карт Петрункевич үзенең хотбәсен тәмам иткәндә, шушы сүзләрне әйтеп туктады: «Әгәр сез, хакимнәр, безгә төрмә ишекләрен ачасыз икән, вазифамызны үтәгән икәнемезне белгәнгә күрә, без аңар бик тыныч керермез».

Кокошкин речен шушы сүзләр белән тәмам итде: «Һәрбер зур вә мокатдәс фикер үзенә корбан таләп итә, диләр. Әгәр безгә шул мәшәкатьне җигәргә тиеш булса, без хәзер». Кокошкин да, бу речен бик куәтле вә гайрәт белән сөйләп, бөтен залны тетрәткән.

Трудовиклардән Галецкий, Лунин, Семеновлар сөйләделәр. Галецкий әүвәлге Думада никадәр өмид булып, шуларның һәммәсе бушка чыгарылдымы (дип); Лунин кызу, самими хотбәсендә вәкилләрнең халыкка биргән вәгъдә вә антлары тугрысында; Семенов халык алдындагы мәсьүлият вә вазифаны белү вә рус зыялылары фәкать үзләренең фидаилекләре белән генә халыкка якын булачакларын сөйләде. Болар тарафындан хөкемнең өченче көнендә социаль-демократлар исемендән Ишерский һәм Рамишвили сөйләделәр. Әүвәлгесе истигъбад ителгән фөкара[2] хакында һәм пролетариатның нинди лозунг өчен тартышуы хакында сөйләде. Хотбәсе арасында палата рәисе, Ишерскийны берничә җирдә туктатып, сүздән мәхрүм итәчәген белгертде.

Рамишвили үзенең сөйләгән речендә менә нәрсәләр ди: «Монда әүвәлге Дума әгъзалары гаепләнәләр дип ышанырга да читен. Без Ватанны яңартырга, ислах итәргә дип җыелган кешеләр, ел ярым үтүе белән мәгъюбләр[3] эскәмиясенә утыртылдык, без нишләдек соң? Нәрсә булды? Без үземезнең әсасларымызга, мәсләкемезгә хилаф эш эшләдекме? Әллә без 17 нче октябрь манифестыны

---

[1] Вакыйгъ булган идарәи мәшруталыкка мохалиф түгел – барлыкка килгән конституцияле идарәгә каршы түгел.

[2] Фөкара – фәкыйрьләр.

[3] Мәгъюбләр – гаепләнүчеләр.

бозып, тарих көпчәгене артка таба әйләндерергә телəдекме? Юк! Әүвәлге вә беренче халык вәкилләре бу эшләрдә гаепле түгел. Безгә икенче гаеп иснад итәләр[1], безне 129 нчы статья белән гаеплиләр. Ничек соң бу болай? Ничек соң Русиянең сайлап җибәрелгән кешеләре шундый, бик сирәк була торган иттихад белән сайланган вәкилләре бервакыт тотып халыкны налог түләмәскә, солдат бирмәскә өндиләр? Без әсаста[2] боларга хилафмы[3]? Менә болар хакында гаепләүче бик яхшы гына сөкүт итә[4]. Менә мин, болар арасында мөнәсәбәт ясар ичүн, Дума таратылу мәсьәләсенә күчәм». Палата рәисе аны туктата, хатиб яңадан сүзене башлый: «Граф Виттенең докладында "Русия үсеп йиткән" дип атала. Менә бу сүз бюрократия дә революциядән күзләрен йома алмаганлыгыны бик яхшы күрсәтә». Рамишвили сүзен бүлә, агара, һушы китеп эскәмиягә төшә, аны төрмә больницасына алып китәләр.

Мондан соң Шаповников сөйли. Ул иң әүвәл халыкның боларның хитабнамәгә кул куюларына ничек караганлыгыны сөйли. «Мин крестьянларга, бу хитабнамәнең мөфһүмене сөйләдем, алар мине Икенче Думага әгъза сайладылар, мәэмүрләре мине төшереп калдырганлар, халык мине икенче мәртәбә сайлады», – ди. Сүзене: «Мин халыкка хисап бирдем, башка нәрсә минем ичүн мөһим түгел», – дип тәмам итте. Андан таза гына, озын буйлы крестиян Врагов сөйли. Ул, үзене хибес итәргә килгән палисә кулындан крестьянларның котылдырып калдырганларыны сөйләп, сүзен болай дип тәмам итә: «Мине хөкем итеп гаеплисезме-юкмы, минем ичүн бар да бер». Андан соң биленә кызыл пута бәйләгән крестьян Зубченко сөйли: «Мин авылда старшина идем, мине вәкил итеп сайладылар, Дума таралгач, мине авылымдан хибес итәргә килгәнләр иде, крестьянләр сорадылар – ни өчен дип. Түрә аларга Выборг воззваниесен сөйләргә мәҗбүр булды».

«Сезнең 129 нче статьяңыздан мин курыкмыйм, – мондан соң нимес Дитц сөйләп, сүзен шулай тәмам итте. – Әгәр сез безне кабахәтләр дисәңез, беләңез ки, халык сезгә ышанмас!» Хөкемнең дүртенче көнене яңадан Рамишвили сөйләп, сүзенә шулай хитам бирде: «Безгә халык вә Яурупа хөкем иттеләр. Сез, әгәр теләсәңез,

---

[1] Иснад итәләр – ябалар.
[2] Әсаста – нигездә.
[3] Хилафмы – кашрымы.
[4] Сөкүт итә – дәшми тора.

җәза тәгаен итеңез!» Бу көнне гаепләүче сөйләп, Выборг воззваниесе Русиядә таратылыр өчен тәгаен ителгән низамга хилаф хитабнамә булмаганлыктан, 129 нчы статья буенча болар гаепле, диде. Мондан соң дәгъва вәкилләре сөйләп: «Әүвәлән, Выборгта тәртип ителгән нәрсә Русия мәхкәмәсенә мәхкүм түгел» диеп вә, саниян дә: «Бу хитабнәмә мәшрутият низамына мохалиф түгел», диеп нотыклар ирад иттеләр[1].

18 нче декабрьдә суд, киңәш итеп, депутатлардан Әхтәмев һәм Дьяченкодан башкаларын гаепле табып, һәммәсен өч ай төрмәгә хибес итәргә[2] хөкем итте.

Мәхкүмнәр чыкканда, алар өстенә чәчәкләр сиптеләр. Москвада болардан фәкыйрьләренең гаиләләренә һәдия[3] ичүн 20 мең сум акча җыйганлар.

## Гаспринский юбилее

Бу ел 11 нче апрельдә «Тәрҗеман»ның нәшер ителә башлавына 25 ел тула. (1883 сәнә 11 апрельдә нәшер ителә башлаган).

«Тәрҗеман» Русия мөселманлары арасында нәшер ителә башлаган гәзитәләрнең икенчесе вә бу вакытка кадәр, ягъни егерме биш ел дәвам иткән беренче гәзитәдер. «Тәрҗеман»га кадәр Кавказда «Игенче» исемле бер гәзитә нәшер ителә башласа да, озак дәвам итә алмыйча, хөкүмәт тарафыннан ябылган.

«Тәрҗеман» гәзитәсе чирек гасырлык дәвамында төрле репрессияләргә чорарга мөмкин булса да, Гаспринский җәнабләренең саклыгы, хәтта чамадан артык саклыгы сәбәпле бу көнгә кадәр дәвам итеп килә алгандыр.

Кыйсьмән[4] дә ул вакытның сәяси халәте вә бигрәк тә Гаспринский җәнәбләренең артык саклыгы аркасында «Тәрҗеман» Русия мөселманларына сәяси җәһәттән хезмәт итмәгән диярлек булса да, «Тәрҗеман»ның иткән хезмәтләре дә күп вә милләтемез тарафыннан тәкъдир вә тәшәккер ителерлектер.

«Тәрҗеман» гәзитәсенең милләтемезнең иң надан вә мөтәгассыйб вакытында мәктәпләремез ислахына иткән хезмәтләрен генә

---

[1] Ирад иттеләр – сөйләделәр.
[2] Хәбес итәргә – ябарга.
[3] Һәдия – бүләк.
[4] Кыйсьмән – өлешчә, берникадәр.

нәзаре дикъкатькә[1] алганда да: «Тәрҗеман» чирек гасыр үз йилкәсендә бик агыр йөк тартып килгән дияргә мәҗбүрмез.

Бөтен зыялыларымыз (бик аз истисна[2] белән) мөтәгассыйб[3] Русия мөселманларына аркалары белән әйләнеп, татар дигән надан халыкны күрәсе вә ишетәсе дә килмәгән вакытларда Гаспринский җәнабләре үзе муафыйк күргән юл белән хезмәт итәргә тырышып, вә бу надан халыкка арка бирер вакытта, алар өчен бөтен иҗтиһадын сарыф итеп газап чигүе милләтемез тарафындан тәкъдирсез узарга тиеш түгелдер.

Бүгенге шикелле хатеремдә тора: мондан ун ел элек мин яңа язу танып йиткән бала, «Тәрҗеман» гәзитәсенең почтадан алынганын дүрт күз белән көтеп, баштагы игъланларындан башлап, ахырдагы имзасына кадәр укып чыгып, үзем йөри торган мәктәпнең тышындагы дөньядан бәгъзе эшләр белән белешләнә вә татар мәгыйшәтенең ноксанлары[4] тугрысында, бик гайре мөгаен һәйәттә булса да, фикеремдә бер нәрсә калдыра идем. Минем белән бер партада утыручы балалардан мондыйлар күп иде. Вакытында зурлардан да мондый «Тәрҗемән» шәкердләренең булганлыгыны беремез дә инкяр итә алмыймыз.

Мин Гаспринскийның сәяси мәсләкен бик картайган, искергән вә вакытындан соңга калган дип ышанам, ләкин, әүвәлдә дидекемчә, «Тәрҗеман» безгә сәяси хезмәте белән түгел, бәлки милли вә педагогический хезмәтләре белән кадерле вә шул хатирәләре белә мөхтәрәмдер.

Әгәр «Тәрҗеман» аның сәяси мәсләкенә мөхалиф[5] мәсләк тотучылар белән дә артык тәгассыбсез[6] мөгамәлә вә мөнәсәбәттә булганын хәтергә алсак, Гаспринскийның миллияте, бәгъзе байлар тарафындан нәшер ителә торган гәзитәләр миллияте шикелле булмыйча, самими ышанырга мөмкиндер.

Мин – үз тарафымдан Гаспринский җәнәбләрен чирек гасырлык хезмәте белән тәбрик итүне бурычым саныйм.

---

[1] Нәзаре дикъкатькә – игътибарга.
[2] Истисна – чыгарма.
[3] Мөтәгассыб – иске фикерле.
[4] Ноксанлары – җитешсезлекләре.
[5] Мөхалиф – каршы.
[6] Тәгассыбсыз – монда: катлауландырылмаган (фикерләрдә каршылык алга чыгармыйча).

Бу турыда шәкердләр вә яшьләрнең дә бер кыйсеменең минем белән мөшарәкәт итүләренә[1] ышанам.

## Мәдрәсәләр берләштерү

Без 27 номеру «Әлислах»та мәдрәсәләр берләштерүнең ислах өчен файдасы булачагыны язган идек**[1+]**. Хәзер шул мөнәсәбәт белән Казан мәдрәсәләре тугрысында берничә сүз сөйләргә кирәк табамыз.

Монда берләштерүне иң әүвәл вөҗүдкә китерүләргә[2] уңгайлы йир булдыкындан, әүвәл Яңа бистә мәдрәсәләре тугрысында берничә сүз сөйләргә кирәк буладыр. Яңа бистәнең өч мәхәлләсендә өч мәдрәсә вә өч мәктәп бардыр. Иске игътибар белән игъдадия вә галия шәкерде игътибар ителерлек 30–40 шәкерд булып, өч йөз микъдарында мәктәп вә рөшдия шәкердләредер.

Әгәр мәгълүмат вә фөнүне җәдидә[3] белү игътибары белән карасак, бу 30–40 шәкерд дә, шөбһәсез, рөшдиянең беренче сыйныфындан укый башларга тиеш булачаклардыр. Шуңар күрә бу олуграк шәкердләрне киләчәк елда Яңа бистә мәдрәсәләренә кабул итмичә, өч мәхәлләдә өч мәктәп вә өчесенә бер рөшдия тәшкил итәргә тиеш буладыр. Киләчәк елга, бу рөшдиянең дүрт сыйныфын берьюлы ачарга мөмкин булса да (чөнки хәзердә дә Салихҗан хәзрәт мәдрәсәсендә рөшдия дигән нәрсә бар), әүвәлге сыйныфны ислах ителә башланган рөшдиядә асыл санап, бөтенләй яңа программа белән куярга тугры киләдер.

Аның киләсе елына өченче вә аның киләсенә дүртенче сыйныфларны шул әүвәлге сыйныфларда башланган рухта ислах ителергә тиеш буладыр. Болай тәдриҗ белән[4] ислах ителгәндә, табигый, матди вә мәгънәви агырлыкларның бик күбесе җиңеләядер (рөшдия вә дарелмөгаллим программалары нәмүнәт[5], киләчәктә «Әлислах» сәхифәләрендә күрсәтеләчәктер. Киләчәк дәрес ел башына кадәр, бәлки мөдәррис әфәнделәр дә мөзакәрә кыйлурлар[6]). Бу микъдар – ягъни өч мәктәп вә бер рөшдия Яңа бистә өчен бик җитә, вә әгәр шуларны яхшы программа белән алып баралса,

[1] Мөшарәкәт итүләренә – килешүләренә.
[2] Вөҗүдкә китерүләргә – тормышка ашыруларга.
[3] Фөнүне җәдидә – яңа фәнләр.
[4] Тәдриҗ белән – әкренләп (эволюция белән).
[5] Нәмүнәт – үрнәкләре.
[6] Мөзакәрә кыйлурлар – фикер алышырлар.

үзен бәхетле санарга хаклы буладыр. Монда Яңа бистә имамнарына программа төзешкәндә үз куәтләренә генә ышанмаска, читдән дә педагогиягә мөнәсәбәтле зыялыларымызны чакырырга вә аларның фикерләре белән файдаланырга һәм дә мөгаллим җәлеп иткәндә җөббә, тәвәккәл бүрек, пальто вә фуражкасындан катгы нәзар белән[1], истихкаклы[2] мөгаллим җәлеп итәргә тырышырга тәүсыя итми[3] китә алмыймыз. Башка мәдрәсәләргә даир[4] киләчәк номеруда язылыр.

– – – – – – – – – – – – – –

«Әхбар» гәзитәсе, «Әлислах»ның «Әхбар» бер кыйсем мөтәрәкъкый милләтчеләремезнең нәкыле әфкяре[5] булдыкындан җавап бирергә кирәк таптык» дигән сүзен гаеб итеп, «Гәзитәнең гәзитәлегендән бигрәк авторитетына игътибар итәләр», ди. Бу дөрест. Ләкин бер тарафындан тәфсилгә мохтаҗ: милләтнең бер кыйсеменең дә әфкярен нәкыль итмәдән бәгъзе бер гәзитәләр кеби, бер фамилиянең кирелеген химая[6] өчен вә «прежний величия»нең остаткасын кулларында тотар өчен генә чыгарылган гәзитәләрнең әфкяре[7] белән хисаплашуны без үземезгә кирәк тапмыймыз.

Әгәр «Әхбар»гә безнең ул сүземезне кире кайтартып алдыру максуд булса, табигый, без аңар мөтәгалликъ[8] тарафын кайтарып алырга мәҗбүр булырмыз. Ләкин ул вакытта: «Әхбар» милләтнең бер кыйсеменең дә нәкыль әфкяре түгел. Бәлки һәркемнең башына ни килсә, шуны яза торган җире», – дияргә тиеш буладыр.

Шул дөрестме-юкмы? Аны хәл[9] «әхбарче»ләргә раҗигъ[10].

## Мәдрәсәләр берләштерү

(28 номердагы мәкаләгә гыйлавә)

Без үткән номеруда Яңа бистә мәдрәсәләрен берләштерү хакында беркадәр язган идек. Хәзердә исә башка мәдрәсәләр

---

[1] Фуражкасындан катгы нәзар – фуражкасына карамастан.
[2] Истихкаклы – монда: бу эшкә лаеклы (хакы бар).
[3] Тәүсыя итми – киңәш итми.
[4] Даир – караган(ы).
[5] Нәкыле әфкяре – фикерләрен чагылдыру (урыны).
[6] Химая – саклау.
[7] Әфкяре – фикерләре.
[8] Мөтәгалликъ – караган, бәйләнешле.
[9] Аны хәл – аны хәл итү, чишү.
[10] Раҗигъ – кайта.

хакында берничә сүз димәкче буламыз. Бу мәдрәсәләрдән берләшүләре мөмкин булганлары: «Мәдрәсәи Мөхәммәдия», «Госмания» вә «Мәрҗания»ләрдер. Болар арасында «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» иң тәрәкъкый иткән вә иң күп хезмәт кертелгәнедер.

Моның галия вә игъдадия сыйныфлары, башка мәдрәсәләрнекендән ким булмау белән бергә, рөшдиясез калганларның һәммәсенә караганда мөкәммәлрәктер. Казанда иң әүвәл тәртипкә салынган бу – рөшди дүрт сыйныфлы, голүме җәдидә дә берникадәр дикъкать белән тә тәдрис ителенә[1] торган мәктәптер. Занымызча, «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» идарәсе бөтен көчен шуны тәкмил итеп яңа программа салырга сарыф итсә, бервакыт, шөбһәсез, бик гүзәл генә бер мәктәбе рөшди[2] булып чыгачактыр.

Моның өстенә дә, «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» дә рөшди бетергән шәкердләр өчен ике сыйныфлы дарелмөгаллимин кеби бернәрсә дә булындыруы башкаларның һәммәсенә караганда җиңелрәк вөҗүдкә китерелүе асатрактыр. Шуңар күрә дә, без мәзкүр идарәгә, киләчәк елдан игъдадия вә галия сыйныфын бөтенләй бетереп, рөшдиягә тәдриҗ белән (ягъни әүвәлге елда беренче вә икенче сыйныфларга вә киләчәкләрдә өченче вә дүртенчеләргә) яңа программа кертә башлап, шул ук елда бу ел рөшдия бетергәнләр өчен бер сыйныф вә аның киләсе елына икенче сыйныф итүне гарыз итәмез[3].

«Мәдрәсәи Госмания»дә дә киләчәк елдан рөшдиянең әүвәлге ике сыйныфларыны тәртипкә сала башланса, өч ел эчендә тәртипле бер рөшдия вөҗүдкә килә аладыр. Аның янында русча сыйныф та булуы – мәсьәләнең ул җәһәтен дә, биттабгъ[4], җиңеләйтәдер.

Болардагы игъдадия вә галия шәкертләре кайда китәләр дигән сөаль килә. Менә шуның өчен дә «Мәдрәсәи Мәрҗәния»не, хәзергә запаска саклап, аңар шул шәкердләрне урынлаштырырга вә хәзергә «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»нең игъдадия вә галия программасы белән укыта торырга муафикъ күреләдер. Боларның бер дә голуме җәдидә[5] күрмәгәнләре өчен махсус кичке сыйныфлар

---

[1] Тәдрис ителенә – укытыла, дәрес бирелә.

[2] Мәктәбе рөшди – башлангычтан югары сыйныфлар укытыла торган мәктәп.

[3] Гарыз итәмез – тәкъдим итәбез.

[4] Биттабгъ – әлбәттә.

[5] Голуме җәдидә – (укытуда) яңа фәннәр.

ясап, истигъдадлары[1] дәрәҗәсендә иштигаль итеп торырга тугры киләдер.

(Рөшдия вә дарелмөгаллимин программалары киләчәктә «Әлислах» сәхифәләрендә күрсәтеләчәктер)[1+].

**«Әлислах»тан ни көтәргә ярый?**

«Әлислах» гәзитәсе чыга башлаганга ун ай булды. Тиздән бер ел тула. (Җәнабе финанс гомерен озын кыйлсын да янә берничә еллар дәвам итсен!).

«Әлислах»ның мәсләке мәдрәсәләрне ислах, шәкердләрне химая[2] идеке укучыларга мәгълүм.

Ләкин «Әлислах»тан нинди ислах көтәргә кирәк? (Бу сөальне без «Әлислах»тан дарелфөнүн[3] салып бирүне өмид итеп авызын күтәреп торган «кечек башлар»га җавап бирер өчен куйган кебек, бик эре иттереп «Әлислах» моңа кадәр ни эшләгәне бар?» диюче зате мөбарәкләргә дә эшнең асылын аңлатыр өчен куямыз). «Ислах» дигән сүз әүвәлдән булып та бозылган, яхуд башта ук бозык эшләнгән нәрсәне төзәтү димәктер. Бездә исә дарелфөнүнләр юк. Бинаәи галәйһи[4], аны төзетәм дип, ислахчылар әйткәнләре түгел, уйлаганлары да юк. Мәдрәсәләргә килсәк, баягы сөаль килә: «Әлислах» мәдрәсәләрне ничек төзәтә? Андан нинди ислах көтәргә ярый? Бу сөальләргә җавап бирер өчен ниләр кирәк икәнене белү кифая итә[5]. Аңлаган кешеләргә мәгълүм: 1) ислах өчен хәзерге татар галәмендә улан, мәдрәсә исемен алып күз буяп торган «бозау абзарларыны» җир йөзендән очыртып, урынларына хифзы сыйххәт[6] кагыйдәләренә муаффикъ[7] биналар салырга кирәк; 2) аларның эчендәге өч-дүрт мендәр өстенә ултырып, замир мәрҗигъләр эзләүче эфьюнчыларны да үзләренең хәзерләнгән галәмнәренә куып, алар урынына икътидарлы, ысул тәгълим белгән мөгаллимнәр җитештерергә кирәк; 3) мөкәммәл дәрес китаплары кирәк. Соң боларны «Әлислах»тан көтәргә ярыймы?

---

[1] Истигъдадлары – сәләтлелекләре.
[2] Химая – яклау.
[3] Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет.
[4] Бинаәи галәйһи – шуңа күрә.
[5] Кифая итә – җитә.
[6] Хифзы сыйххәт – гигиена.
[7] Муаффикъ – туры килгән.

Юк. Чөнки «Әлислах» идарәсендә алтын базары юк – ул биек-биек биналар салдыра алмый. Шулай ук «Әлислах» дарелмөгаллимин дә түгел – ул үзе генә андый мөгаллимнәр дә хәзерли алмый.

«Әлислах»ның язучылары да – шул күз алдыңыздагы иске, тәртипсез мәдрәсәләр җитештергән яшьләр. (Фәкать рус шәкердләрендән алган мәгълүматлары илә аңны-туңны аерырлык булганлар). Бииаән галәйһи, алар мөкәммәл фәнни китаплар да хәзерләп бирә алмаслар.

Шуның шикелле үк, «Әлислах»тан матур-матур программалар да эзләмәңез! Ул программалар бераз булды инде. Соңгы елларда азмыни программалар чыкты, азмыни лафлар орылды, ләкин ни булды? Һаман шул иске мунча, иске таш, һаман җылынырлык эссе чыкмый. Оялмаганлар (автономистлар) һаман да язалар. Һаман «мәктәп-мәдрәсә идарәсене үземезгә алырга кирәк, фәләнләр тәгаен итәргә кирәк, төгәнләр эшләргә кирәк» дип, шул ук искереп беткән фикерләрне төрле-төрле буяулар илә буяп, төрле маскада кузгатып карыйлар. Вөҗүде имкян хариҗында улан[1] автономияләр илән хыяллананалар. Шул ук мөхальләргә тәгъликъ ителгән мөхаләтләрен[2] дә мөмкин итеп күрсәтмәкче булалар. Ләкин без, ул программаларның хәзер дөньяга чыкмавын хәкыйкатән[3] белгәнгә күрә, ул куәтләүне очырмыйча, фәкать халыкка бездә мәктәп-мәдрәсәләр юклыгын аңлатырга тырышамыз.

Мәктәп-мәдрәсәләремезнең эчен-тышын ачык иттереп күрсәтәбез. Халыкның хәзер мәктәбе ибтидаиларны[4] гына бертөрле тәрбияләргә вә, иң чиге дә, рөшдиләр[5], яхуд городскойлар образованиесе[6] бирерлек мәктәпләр генә ачарга кулындан килүен уйлаганга, мөгаллимнәр җитештерер өчен дарелмөгаллиминләр ачарга вә рөшдиләргә дәрес китаплары хәзерләргә иҗтиһад итүне вә шундан артыкка куәтемез җитмәүне ачык иттереп әйтәбез.

Менә «Әлислах»тан нәрсә көтәргә ярый.

---

[1] Вөҗүде имкян хариҗында улан – мөмкин булмаган.

[2] Мөхальләргә тәгъликъ ителгән мөхаләтләрен – үтәмәслек шартларга бәйләнешле (мөмкин булмаган) нәрсәләрне.

[3] Хәкыйкатән – чынлыкта.

[4] Мәктәбе ибтидаи – башлангыч мәктәп.

[5] Рөшди – башлангычтан югарырак мәктәп.

[6] Городскойлар образованиесе – шәһәрчә белем алу.

## Гыйбадәт

Күңелем бөтен нәрсәне: йирне, өстендәге вак-төяк шәйләрне, күкне, эчендәге зур-зур сәярәләрне[1] кечкенә күрә башлый.

Җаным бөтен уйларымны: истикъбальне[2], үткәнне, хәзергене, күңеллене, күңелсезне, шатлыкны, кайгыны, михнәтне, газапны юкка саный башлый.

Бөтен тәнем бу тормыштан, аның кирәк вә кирәкмәс гаризаларыннан, бөтен хәрәкәтләремдән, бөтен тик торышларыннан ара башлый.

Бөтен хыялым үземне, сөйгәнемне, башкаларны юк хисаплый башлый.

Күзләрем караңгылана, күңелем тәүсыйф ителмәслек[3] дәрәҗәдә бушлык хис итә, кайгырам, егълыйм, ләкин болар да буш, җансыз, хәрәкәтсез! Мин беткән, туйган, бөтен дөньяны, бөтен нәрсәдән туйган! Җаным әллә нәрсә эзли, әллә нәрсә тапмакчы була, йөрәгем ниндидер рәхәт сорый, тәнем ничектер җал итәсе килә, хыялым күз алдында барлык күрергә ашкына ...

Менә мин гыйбадәт кыйлырга тотынам, бөтен җаным, күңелем, хыялым белән каядыр, үзем дә белми торган гали галәмгә юнәләм. Укыйм – ул да ләззәтле, егълыйм – ул да ләззәтле, куанам – ул да мәхыз[4] ләззәт кенә ... Менә мин терелдем, мин әүвәлге күк кеше булып киттем. Җаным да, күңелем дә, тәнем дә үзләренең теләгәннәрен таптылар, тынычладылар, рәхәтләнделәр.

## Минем тәрҗемәи хәлем

Мин 188* ел гыйнварның таңында тудым[+1]. Туган вакытымның ел башы һәм ел башының да таң вакыты булуыны хәтерләренә төшерсәләр, укучы әфәнделәр үзләре дә минем буш кеше түгел икәнемә ышанырлар дип уйлыйм. Татарның һәр эше шикелле, минем тууым да алдан уйлап эшләнгән эш түгел иде. Тууымдан ярты гына сәгать элек мин әле аның хакында бернәрсә дә уйлап өлгермәгән идем. Һәрбер татар шикелле, мин дә тугач та: «Нәрсәгә дип тудым мин?» дип уйлап мәшәкатьләнмәдем, ата-баба эшләгәнне эшләргә кирәк дип, акырып еглый башладым, егладым-егладым

[1] Сәярәләрне – күк җисемнәрен (планеталарны).
[2] Истикъбальне – киләчәкне.
[3] Тәүсыйф ителмәслек – сыйфатлап бирә алмаслык.
[4] Мәхыз – саф, фәкать.

да, ничә минутлар еглаганмын, анысын белмим, мин әле ул вакытта сәгать танымый идем. Тәнемне этинең бер иске күлмәге белән төреп, авызыма ими каптыргач, туктадым. Татар баласы бит: тамак тук, өст бөтен булгач, артык нәрсәгә дип еглап торыйм, аның ары ягында нәрсәм йитмәгән тагын? Бервакыт тирә-ягымдагы хатынлар, җәннәткә кергән төсле, авызларын җырышып куандылар:

– Ир бала! Ир бала!

– Ә, – мин әйтәм эчдән генә, – ир бала булуның бу халык арасында почеты бар икән. Тукта, бунын кадерене белергә кирәк.

Үсә башлагач, бу фикернең бик күп файдасыны күргәнлегемне укучылардан яшерергә теләмим: юк-юк та, хатын кыз күргәндә:

– Әй, чүпрәк баш, мин сиңа әйтим, ирләрнең почетта икәнене белә торып, ир булып туа да алмагансың бит, бичара, – дип, зураеп карап куя торган булдым.

Бундан соң халык, тугач, үсә башлый, халык белми эшләмәс дип, мин дә үсәргә тотындым. Үсәм, үсәм, бер дә харап үсәм: ул тешләр чыгарумы кирәк, ул тәпи йөри башлаумы кирәк, ул сөйләшә башлаумы кирәк – әлхасил, һәммә кирәкле кирәгенчә.

Ләкин болай үсү үзем өчен бик файдалы булып чыкмады. Төрле-төрле бәлаләр бер-бер артлы башыма ява башладылар: ул аякларымны кычыткан чагумы кирәк, йиргә туп итеп, кулымны авырттырумы кирәк, инә карагы тотам дип йөри торгач, андан бармагымны тешләтүме кирәк, берәр малайны үчекләгән өчен әни «мәэмә» итүме кирәк – һәммәсе бу фәкыйреңезнең башына килеп үттеләр. Бәлаләр арасында минем өчен иң дәһшәте амиз[1] иң куркыныч һәм иң җанга үткече яз көнләрендә була торган иде: без тора торган йирнең зыярәте буендагы үләнлектә бәбкәләрене саклап йөри торган казлар, ни өчендер, мине әүвәл танышуымдук дошман күрә башладылар. Анлар миңа кайда гына тугры килсәләр дә «Пх-х-х-х...» – дигән бер төрле ямьсез вә минем өчен тарихи куркыныч тавыш чыгарып, куып йөри торган яман гадәткә өйрәнделәр. Кайда гына бәбкәле бер каз очрамасын, ул мотлак, муеныны сузып, минем артымдан кууны үзенең вазифаи казыясындан[2] хисаплый иде. Минем җан ачысы белән: «Әни, каз талый!» – дип кычкырган сүзләрем дә ул залимнарны куркытмый иде. Шулай

---

[1] Дәһшәте амиз – куркыныч тудыра торган.
[2] Вазифаи казыясындан – казлык бурычындан.

итеп, бу дошманлар якты һәм шатлыклы яз көнләрене минем өчен караңгы вә куркыныч ясыйлар иде.

Шушы вакытларда инде минем сәнаигы нәфисә хадиме булачакгым да тәмам билгеле булып йитте. Кариэләр[1] мактанып әйтә дип уйласалар уйларлар, мин тәрҗемәи хәлемне язгач, инде үземдәге хасыятьләрнең бик күзгә төртелеп тора торганларыны әйтми китә алмыйм: мин 5–6 яшьләргә йиткәндә инде таш тәти (чынаяк ватыклары) мөхибләрендән идем. Хәтта бик озак заман һәм тырышлык сарыф итеп, мөкәммәл бер таш тәтиләр коллекциясе дә җыярга муаффәкъ булган идем. Бу коллекциямнең никадәр мөкәммәл булганлыгыны күрсәтер өчен, мин бу урында шул гасырның таш тәти мөтәхәссыйсләрендән Габделбари әфәнденең фикерене әйтеп китүне урынсыз булмас дип уйлыйм. Габделбари әфәнде – 7 яшьлек гаюр[2] һәм фидаи бер таш тәтиче һәрвакыт:

– Синең таш тәтиләр шикелле һәйбәт таш тәтиләр бер йирдә дә булмас, – ди торган иде.

Кариэләр артык мактану дип уйласалар уйларлар инде, мин үземнең бик яшьдән мәсҗед сөючән булганлыгымны әйтми китә алмыйм. Мин 5 яшемдән намазга йөри башладым. Дөрест, ул вакытда мин тәһарәт алып, тәкәллефләнеп тормыйдыр идем, тәравих намазларында, тәрәзә төбендә яңлыш йоклап китеп, сәҗдәгә киткән абзыйларның өстләренә дә туп итеп төшкәли идем. Кыям вакытында[3], янымдагы малайларның берәрсе белән мәсҗедкә керер алдындан гына ясап тәмам иткән балчык күмәчләрем тугрысында сөйләшкәләп тә алгалый идем. Ләкин намазым, артык таза вә нык булуы аркасында, бундый эшләр белән генә бозылып азапланмый, һаман төп-төзек килеш кала иде. Минем намазымның шулай таза икәнене белмичә, бервакыт Вәли карт миңа: «Намаз эчендә сөйләшергә ярамый, мәхдүм», – дип әйтеп караган иде дә, мин аның үзенә, янындагы Сәгыйть карт белән сөйләшә-сөйләшә намаз укырга киңәш биреп, намазының бозылмаячак икәнене сөйләгәч, тавышы-тыны басылды.

Шушы елларда инде фәләкнең[4] золымлары мине төрле-төрле хәйләкәрлеккә дә өйрәтә башлады. Залим фәләкнең һәрбер зарба-

---

[1] Кариэләр – укучылар.
[2] Гаюр – тырыш.
[3] Кыям вакытында – аягүрә басып торганда.
[4] Фәләкнең – язмышның.

сына[1] каршы мин үз тарафымдан берәр химая итенү[2] коралы уйлап чыгара торган булдым: муеныны сузып, таларга каз киләме, мин аның өстенә янымдагы кечкенә, бик матур аппак этемне өстерәм дә, анлар сугыша торганда, үзем таям; өстемә үземдән көчлерәк берәр малай һөҗүм итәме, мин әүвәл бик мәһабәт кенә: «Кил, кил әле бундарак, эчеңне тибеп агызырмын менә!» – дип, бик гайрәт орам да, ул килеп йитә башлагач кына чабып качарга тотынам һәм ул көчле дошманның бер дә көтмәгән вакытында гына, кинәт борылып, яңагына берне әләктерәм дә, ул еглый кала, мин өемезгә кайтып йитәм; берәр нәрсә өчен анам кыйнарга телиме, мин, бик җитез генә берәр түбәгә менеп, намаз вакытыны көтеп утырам да мәсҗедкә кереп китәм. Андан әти белән бергә чыгып, бик акыллы гына өйгә керәм. Шул кадәр акыллы гына мәсҗеддән кайткан фәрештә шикелле баланы нинди сахибе вөҗдан[3] кыйный алсын!

2

Йиденче яшемдә мине мәктәпкә бирделәр. Безнең хәлфә җуан гына, ялкау гына бер мишәр иде. Ул миңа кәгазь өстенә ясалган таш тәтиләр шикелле нәрсәләрне күрсәтте дә, болар баш «ﺗ», урта «ـﺘـ» булалар, диде. Мин аның белән бәхәсләшеп тормадым, боларның таш тәти сурәтләре икәнлегене бик яхшы белсәм дә, урта «ـﺘـ», әллә нәрсәләр дип ышанып йөргән кыяфәт күрсәтә торган булдым. Акрын-акрын хәлфә миңа, табагач сурәтләре күрсәтеп, кечкенәсене «һәмзә», зуррагыны «гаен» дип йөрергә дә кушды. Башыңа төшкәч, бернәрсә эшләр хәл юк: табагачларны «һәмзә» һәм «гаен» исемнәре белән йөртә башладым. Хәлфәмнең иң ахыргы ялганы – шикәр ваткычы сурәтен «ләм-әлиф» дип ялганлавы булды. Шул ялганга ышанган көндән башлап, мине язу таный торган бала дип йөртә башладылар. Мин мулла баласы булганга, бик кечкенәдән үк муллалык дәрәҗәсенең, пәйгамбәр вә сахабәлекдән кала, иң зур дәрәҗә икәнене бик яхшы төшенә идем. Акрын-акрын кыйланышларым белән муллалыкка хәзерләнә башладым. Әтинең иске бикасәб казакиене сүттереп, үземә бер чапан текдертдем, аның ук иске чалмасындан кисдертдереп, үз гәүдәмә мөнасиб зурлыкта бер чалма хәзерләтдердем һәм, әнинең иске зонтигының сабыны суырып алып, үземә намаз таягы итеп тота башладым. Мин шулай

[1] Зарбасына – һөҗүменә, басымына.
[2] Химая итенү –саклану.
[3] Сахибе вөҗдан – вөҗдан иясе.

итеп намазга йөрим дә йөрим, ә мәхәлләмезнең сакаллы сабыйлары мине кечкенә клоун дип йөрисе урынына, «нәни мулла» дип йөриләр...

Шушы еллардук инде мин Фәтхулла хәзрәт (мәрхүм) белән дә таныша башладым. Ул мәрхүмне мин бик җыш һәм төрле вакытларда төрлечә итеп күрә идем. Ул яшь дә була, карт да була, юан да, нечкә дә була, кара күзле дә була, зәңгәр күзле дә була, озын буйлы да була, кыска буйлы да була иде.

Бу вакытта әле халык, Хуҗа Насретдиндан да гакыллырак, Кизләү мөридендән дә мөстәкыйльрәк, аю биетүче мишәрдән дә белдеклерәк булганга күрә, «галим-голәма»га бик ихласлы, Фәтхулла хәзрәткә мәхәббәтле вә тәгъзыймле[1] иде.

Мин дә акрын-акрын Фәтхулла хәзрәт дәрәҗәсенә ирешергә хәзерләнә башладым...

Мәктәпкә керүемнең икенче елында миңа хәез-нифаслар хакында да бик кыйммәтле мәгълүматлар бирделәр.

Мине иң әүвәл укыткан хәлфәмә Ходай дөньяда җәннәт, ахирәттә дәүләт бирсен, бичара һәрвакытта мине: «Кирәкле нәрсәләрне зурайгач та өйрәнә алырсың, кечкенә чагыңда кирәкмәсрәк нәрсәләрне белеп калырга тырыш!» – дип вәгазьли иде... Бүгенге шикелле хәтеремдә, бервакыт Фәтхулла хәзрәт безгә ак сакаллы карт булып килгән иде. Мин аңар сабакларымны тыңлатмакчы булдым. Ул миндән:

– Госелне ничә нәрсә фарыз итә, улым? – дип сорады. Мин бер дә төртелми җавап биргәч:

– Бәрәкәаллаһ, бәрәкәаллаһ, улым. Тырышып укыйсың икән; шулай укысаң, үскәч, минем шикелле зур хәзрәт булырсың, – диде. Шулай димәслек тә түгел шул: җиде яшьлек бала шундый, олуглар да сөйләшергә ояла торган нәрсәләрне шатырдатып әйтеп торса, ул баланың үсә төшкәч, Фәтхулла хәзрәт кенә түгел, «Дин вә мәгыйшәт»нең[2] даими мөхәррире булуына өмид баглау да читен түгел.

Икенче бер вакытта Фәтхулла хәзрәт безгә кап-кара сакаллы, гарәби җөббәле бер бәдәлче[3] сурәтендә килгән иде. Ул миндән:

[1] Тәгъзыймле – олылаучан.

[2] «Дин вә мәгыйшәт» – сәяси, дини, әдәби журнал (Оренбург, 1906–1917).

[3] Бәдәлче – ялланып хаҗга баручы.

– Тәһарәтнең сөннәтләре нәрсәләр? – дип сорады. Мин бераз лыбыр-лыбыр итеп торгандан соң:

– ...Өч мәртәбә борыныңны сеңгермәк, – дип җавабымны тәмам итдем. Фәтхулла хәзрәт болай белеклелегемдән бик куанганлыгыны күрсәтер өчен миңа ун тиен көмеш сәдака чыгарып бирде.

Бер-ике елдан мине Казанның иң мәшһүр мәдрәсәләрендән берсенә бирделәр. Бу мәдрәсәдә мин Әтәчетдин исемле бер казыйдан нәхве гарәби[1] башладым. Бу казый озын буйлы, калын җилкәле, кап-кара сакаллы, кара сипкел төшкән битле бер татар иде. Бу татар мәдрәсә хәлфәләре арасында гыйлем белән бик мөмтаз булмаса да, сәясәт вә тәрбиягә осталыгы белән мәшһүр иде. Бунын сәясәт вә тәрбия ысулы бик кыска иде: бер шәкерд кәләпүшен кыңгыр кияме, безнең Әтәчетдин казый аны алдына чакырып китерә:

– Малай! Ник кәләпүшеңне кыңгыр салдың?

– Яңлыш киелгәндер, хәлфә, мин үзем игътибар да иткәнем юк.

– Әле, малай, сөйләнеп торасың! Ят сузылып!

Шәкерд бичара ята да, Әтәчетдин казый чаж-чож суга.

Казый әфәнде мине дә яхшы әдәпкә өйрәтә иде: әгәр ул тәһарәткә чыкканда, комган вә кәвешләрене күтәреп тәкъдим итәргә өлгерә алмый калсам, ул көн көне буе борыныны сызгыртып, бик куркыныч һәм ямьсез тавыш белән тамагыны кырып йөри һәм миңа хитаб иткәндә тынкышрак кына, киберле[2] тавыш белән:

– Малай! – дип кенә хитаб итә һәм шул эш белән бу хәлфә әфәнде миңа бәбкәле казлардан да куркынычрак тоела иде.

Хәлфәмнең бу хәрәкәтләрене мин бервакыт ак сакаллы Фәтхулла хәзрәткә сөйләп карадым.

Фәтхулла хәзрәт аның ул хәрәкәтләрене урынлы күрде генә түгел, бәлки һәммәсене бик фәлсәфи тапты һәм «голәма» арасында бундый хәрәкәтләрнең һәммәсенә махсус фәхри[3] исемнәре барлыгын бәян итте.

Балалар куркытырлык итеп йөренә һәм тынкышланып сөйли белү – «вәкарь»[4] исемле, үзеңгә охшамаган һәр шәкердне кыйный белү – «тәэдиб»[5] исемле икән.

---

[1] Нәхве гарәби – гарәп теле синтаксисы.

[2] Киберле – горур.

[3] Фәхри – мактаулы.

[4] «Вәкарь» – «эрелек».

[5] «Тәэдип» – «әдәпкә өйрәтү».

Әтәчетдин хәлфә миңа нәхү белән бергә хәез вә нифас мәсьәләләрен гарәпчә язган бер китапны да укытып чыгарды.

Бундан соң мин «Исагуҗи» китабы башладым. Фәтхулла хәзрәтнең бу китапны бик тырышып укыганлыгыны ишетә идем, мин дә тырыштым һәм, шул тырышлыгым аркасында, бер ай укыгач та, үземнең «хайване натыйк»[1] икәнлегемне белдем.

Шулай мин хәзер «хайване натыйк»! Әтәчетдин хәлфә дә хайване натыйк! Фәтхулла хәзрәт тә хайване натыйк!

«Исагуҗи» башлауның минем өчен иң зур файдасы хәлфә алмашынуы булды: бу китапны мин Әтәчетдин казыйдан укымадым, риясыз, нифаксыз, дәрвиш табигатьле, йомшак холыклы, бик мәхәббәтле бер хәлфәдән укыдым. Бу хәлфә хәзер инде Хвалыйн өяздендә бер авылда мулла, мин аны хәер белән генә яд итәм.

Шушы елларда инде мин алдыма тугры килгән һәр шәкерт белән сүгешә башлау гадәтенә өйрәндем һәм үземнең шушы гадәтемне Фәтхулла хәзрәткә дә сөйләдем, хәтта, аны сүземнең дөрестлегенә ышандырыр өчен, үзе белән дә сүгешеп күрсәтдем. Фәтхулла хәзрәт минем сүгешкә осталыгымдан көтелмәгән рәвештә шатланды һәм, мине аркамдан сөеп, «моназыйр» исме галие белән ләкабләде[2]. Шушы елларда мин Сәгъди әфәнде (хәзер «Вакыт» мөхәррирләреннән) белән дустландым. Ул әдәбият гарәбия мөхибләреннән һәм мәдрәсәдәге схоластикага иң әүвәл каршы тора башлаган шәкердләрдән берсе иде. Шул ук рухда ул миңа да күп тәэсир итте һәм, шулай итеп, минем Фәтхулла хәзрәт була алмый калуымның иң әүвәлге визрене[3] үз өстенә йөкләде.

Бу елларда мин гарәп вә төрек әдәбияты белән шөгыльләнә һәм һәрбер яңа чыккан татар китапларыны укып чыга башладым. Горфи дәресләрем булган «Гакаид» вә «Тәһзиб»ләрне Фәтхулла хәзрәт белән очрашканда сүгешә алырга йитәр кадәр генә укый идем. Бу араларда инде шәкердләр хәрәкәтенең башлану дәвере керде. Мин бу хәрәкәткә кушылган шәкердләрнең иң әүвәлгеләреннән берсе идем.

Көнләрдән бер көндә без мөдәррис хәзрәтләреннән мәдрәсәгә фөнуне җәдидә һәм фәлсәфәи диния кертүне таләп кылдык.

---

[1] «Хайване натыйк» – «сөйләшә торган хайван».

[2] «Моназыйр» исме галие белән ләкабләде – «моназыйр» дигән бөек исемне бирде.

[3] Визрене – гаебен.

Мөдәррис әфәнде, безнең шушы таләпләремезне нәкъ кабул иткән бер сурәт белән, мәдрәсә өчен яңа низамнар төзеп кертде. Низамнамәнең иң әһәмиятле матдәләре түбәндәгеләр иде:

1) шәкерд биш вакыт намазны мәсҗеддә әда итәр[1];

2) кием, сач, сакал-мыекларыны шигаре исламга муафикъ йөртер: мыекларын үстермәс, сакалыны кырыкмас, голәма әлбисәсенә мөлазәмәт итәр[2];

3) Каһкаһә көлмәс[3], кычкырып сөйләшмәс...

Мөдәррис әфәнде шушы низамнамәне алып керде һәм үзе бик озын бер хотбә сөйләде, шушы низамнар тотылсалар, мәдрәсә һәм шәкерд ислах кылынган була икәнлегене, эш гыйлемдә түгел, бәлки аның бәрәкәсендә[4] икәнлегене бәян итте.

Бундан соң шәкердләрнең күбрәге дә: «Безгә «бәрәкәсе» булса йитәр, гыйлеме булмаса да ярар», – дип, мәдрәсә дәресләренә кул селекте.

Язга таба ихтилал көчәйде, мөдәррис әфәндегә тагы әүвәлге үк таләпләрне тәкрар иттеләр. Ул да, ихтилал зураймасын өчен, киләсе көздән мәдрәсәгә фөнуне җәдидә кертүне вәгъдә итте һәм үзе шул елдан ук фәлсәфәи диния укыта башламакчы булды.

Фәлсәфәи диния дәресләре бик кызык баралар иде. Иң әүвәл мөдәррис әфәнде гакылны ике төрлегә бүлеп куйды: гаклы сәлим[5] бар, вәһем[6] белән катыш була торган гаклы гайре сәлим бар. Фәтва китапларындагы сүзләрнең һәммәсенә ышанган гакыл – гаклы сәлим; ышанмаган гакыл – гаклы гайре сәлим. Андан соң һәммә хөкемләрнең фәлсәфәсен, шул таклы сәлимгә терәтдереп куеп, исбат итәргә кереште:

– Тәяммимдәге фәлсәфәләр ла йогатде вә ла йохса[7]. Боны гаклы сәлим инкарь итмәс. Дөрес, Европаның дәһри хөкәмалары[8] бу хөкемләргә игътикад итмәсләр. Ләкин, әүвәлдә бәян ителгәнчә, бу көнге Европа хөкәмасының гакыллары, мизаны шәргы[9] белән

---

[1] Әда итәр – үтәр, укыр.

[2] Голәма әлбисәсенә мөлазәмәт итәр – галимнәр киемен кияр.

[3] Каһкаһә көлмәс – кычкырып көлмәс.

[4] Бәрәкәсендә – бәрәкәтендә.

[5] Гаклы сәлим – сәламәт акыл.

[6] Вәһем – аң.

[7] Тәяммимдәге фәлсәфәләр ла йогатде вә ла йохса – тәяммимдәге (мөселманнарның тәһарәт урынына кыла торган гадәтләре) фәлсәфәләр санап бетергесез.

[8] Дәһри хөкәмалары – атеист философлар.

[9] Мизаны шәргы – шәригать үлчәве.

үлчәнмәгәнгә күрә, вәһем белән катыш фасиддыр[1], вә лиһаза мөгътәмәд[2] түгелдер.

– Сөтрә[3] мәсьәләсендәге хикмәт вә фәлсәфәләр хәд вә хисапдан хариждер[4]. Үз хатынының матур вә купшы йөзене нәмәхрәмләргә күрсәтергә һичбер гаклы сәлим сахибе риза булмас, фәкать дәюсьләр[5] бу эшкә ризалык күрсәтерләр!

Бу фәлсәфәләрне ишеткәч, мин дә «гаклы сәлим сахибе» булыр өчен хатын-кызны качыру кирәклек тарафына күчтем. Хәзер дә әле мин кешенең гаклы сәлимме, түгелме икәнене беләсем килсә, я тәяммим, я сөтрәгә мөнәсәбәте белән үлчәп беләм. Мәсәлән, шул мизан белән, доносчы Ишминең гаклы сәлим сахибе, Толстойның гаклы фасид сахибе икәнлегене белдем.

Гомеремнең бу дәверендә инде мин Фәтхулла хәзрәткә вә аның халык арасындагы ихтирамлы урынына кызыкмый башладым. Аның үзе белән очрашканда да, юк кына сәбәпләр белән бер-беребезгә бәйләнешеп китә торган булдык. Әүвәлдәрәк без аның белән галәмнең кадимме, хадисме[6] икәнлеге, яисә «Хәкаекы эшьяэ»ның сабитме, түгелме икәнлеге тугрысында гына моназара кыйлыша торган идек. Ләкин хәзер инде моназарамыз мәдрәсә программасы, Мисыр мөҗәддидләренең[7] дини фикерләре шикелле нәрсәләр тирәсендә әйләнә башлады. Моназараларда кирәк мин җиңим, кирәк Фәтхулла хәзрәт җиңсен, бә һәр тәкъдир[8] ахыры минем өчен начар чыга иде. Чөнки һәр моназараның ахырында Фәтхулла хәзрәт минем, җәннәткә кереп, хур кызлары кочу хакымны беткән дип игълан итә иде. Фәтхулла хәзрәт, төрле кыяфәтләргә кереп, мине бик вәгазьләп тә карады, җәһәннәм белән куркытып та карады, мулла булмый калып, ачдан үлү ихтималым белән дә каушатмакчы булып карады. Ләкин файда итә алмады. Шул вакыттан бирле инде ул мине «һәлак булган» санап йөри. Мин аны күргән саен берәр сүз әйтеп котыртам, ачуландырам. Кариэ әфәнделәр шундый берәр кешене котыртып караганлары булса, моның шактый күңелле бер эш икәнен икърар итсәләр кирәк!

---

[1] Фасид – бозык.
[2] Вә лиһаза мөгътәмәд – ышанычлы.
[3] Сөтрә – хатын-кызларның йөзләрен каплау, ирләрдән качу.
[4] Хәд вә хисапдан хариждер – иксез-чиксез.
[5] Фәкать дәюсьләр – әшәке кешеләр генә.
[6] Галәмнең кадимме, хадисме – дөнья мәңгелекме, әллә бетәчәкме?
[7] Мөҗәддидләренең – реформаторларының.
[8] Бә һәр тәкъдир – һәр икесендә дә.

Бара торгач, мин мәдрәсәдә «хәтме көтеб» иттем. Ягъни бик күп татар малайларының миләрене череткән «Мулла Җәләл», «Тәүзих» китапларыны укыдым да мәдрәсә курсыны тәмам иттем.

Әгәр «имам хатиб-мөдәррис» булмакчы булсам, миңа белгән кадәр нәрсәләрем җитәчәк иде, ләкин мин, «имам хатиб-мөдәррис» булмыйча, горфи[1] бер кеше булып калырга теләдем, шунлыктан миңа яңабашдан укырга тотынырга кирәк булды.

Русча укый башладым. Менә сезгә, кирәк булса, бер эш! Мөдәррис булырга теләмәсәң, яңадан укучы булып йөр! Үз кадеремне үзем белгән булсам, мин күпдән инде мөдәррис булып, әллә ничә Фәтхулла хәзрәт тәрбия итеп чыгарган булыр идем. Яки бөтен дөнья залаләткә[2] төшеп тә, үземнең генә һидаятьдә калганлыгыма ышанып, җәһле мөрәккәбләргә[3] генә махсус бер горур белән яшәүче бер «Дин вә мәгыйшәт» айгыры $^{2+}$ була алыр идем.

Язарга башлавым тарихына килсәк, ул бик иске эш инде. Өч яшемдә вакытдук мин атамның китап читләренә, үзем генә таный торган бер язу белән, диңгез тулкынларына охшашлы нәрсәләр яза башладым. Минем болай бик иртә мөхәррир булып китүем ата-аналарыма бик охшап йитмәде булырга кирәк: алар китапларны минем буем йитмәслек йиргә яшерә торган булдылар. Хәер, мин апдырап калмадым, китап читләре булмаса, миңа язарга башка нәрсә дә бетмәс әле дип, бармагымны карага манчып, энем (кечкенә бөрадәрем)нең йөзенә шул ук тулкынга охшашлы язуларымны яза торган булдым. Ләкин минем мөхәррирлегемнең бу дәвере хосусый сурәтдә анама охшамый иде. Ул минем шулкадәр сәнагать кертеп[4] язган язуларымны энемнең йөзендән сабын белән жуа-жуа бетерергә тырыша иде. Андан соң мәктәпдә укый башлап, кулыма камилән үз милкемә, үз тасрыйфыма тапшырылган кәгазь вә каләм эләккәч, мөхәррирлекнең канындан килә торган булдым. Ниндидер бер мәктәп китабындан: «Тәрбияле бала кеше алдында сөйләшмәс, кеше алдында көлмәс, кеше алдында йөткермәс, кеше алдында күз алмасын йөртмәс, кеше алдында баш бармагын калкытмас...» дигән бер мәкаләне 99 мәртәбә күчереп чыкдым. Ундүрт яшьләремдә инде мәдрәсәдә кульязма нәшер итеlә торган

---

[1] Горфи – гади.
[2] Залаләткә – азгынлыкка.
[3] Җәһле мөрәккәбләргә – чеп-чи наданларга.
[4] Сәнагать кертеп – монда: тырышып.

яшерен журналларга бик фәлсәфи, чикылдаган фәлсәфи мәкаләләр яза торган идем. Татарча гәзитә вә журналлар чыга башлагач, мин, әүвәл бер журналда язышучы булып, андан соң бер гәзитәдә баш мөхәррир булып тордым вә әлх, вә әлх...

«Тәрҗемәи хәл»не шушы урында кисәргә дә ярый инде. Чөнки бундан соңгы вакыйгалар – яңа вакыйгалар әле. Вакыйгаларны искерә төшкәч язуы күңеллерәк. Бәлки, укучылар арасындагы яшь туташлар һәм яшь егетләр:

– Әбәү, Ташмөхәммәд әфәнде гомерендә кызлар сөя дә белмәгән икән! Гыйшык тотканы булса, язмый узмас иде, – дип, үз артымда мине гаеп итеп сөйләрләр. Ләкин... «иннә бәгъзыль-занны исмен! Вә лә тәҗәссәсү вә лә ягътәбү бәгъзыкем бәгъзан»[1], әфәнделәрем. Андый мәсьәләләрне сер итеп, колакдан-колакка гына сөйләшергә яхшы.

1 август, 1911 сәнә.

## Балаларга бәйрәм

*(Мәүлүд мөнәсәбәте илә)*

Пәйгамбәремез балалык галәменә кергән көне хөрмәтенә ниндидер бик җылы, мәхәббәт вә самимият белән тулы сүзләр әйтәсе килә.

– Пәйгамбәремезнең балалык галәменә...

Мөтәмәддин[2] милләтләр ... үзләре мәнсүб булган[3] диннәрнең бундый көннәренә балаларына зур тантаналы бәйрәм ясап каршы алалар. Бундый көннәрдә бөтен кечкенә, мәгъсум йөзчекләрне көләч вә шад ясарга тырышалар.

Әмма безнең балаларымыз? Безнең балаларымыз андый бәйрәмләрне күрмиләр, белмиләр. Анларның бәйрәмләре юк! Боекдырылып, куркытылып, истикъляльсезләндерелеп үстереләторган безнең балаларымыз кызыксыз, эчпошыргыч үсәләр; гомерләренең башындан ук тормышның, фәкать, рухсыз (проза) ягыны күрергә гадәтләндерелеп тәрбия ителәләр. Әйтерсең лә. бөтен милләт балалары арасындан фәкать безнекеләр генә тормыш-

[1] «...иннә бәгъзыл-занны исмен! Вә лә тәҗәссәсү вә лә ягътәбү бәгъзыкем бәгъзан» – «кайбер шикләнеп караулар гөнаһ! Бер-берегез артыннан шпионлык итмәгез, бер-берегезне шелтәләмәгез».

[2] Мөтәмәддин – мәдәниятле, культуралы, алга киткән.

[3] Мәнсүб булган – монда: тоткан (караган).

ка үги бала булып дөньяга килгәнләр; әйтерсең лә, бу мескин балалар дөньяга чыгулары өчен җәзага мөстәхикъ[1] булганлар.

Бөтен тәрбия юлымыз катылыктан гыйбарәт, бөтен балалар тугърысында булган чараларымыз орышу вә хәтта кыйнаудан гыйбарәт, бөтен тәрбиямез балаларның шәхесене, истикълялене[2], хөрриятене кысу вә сытудан гыйбарәт булганлыкдан, безнең балалы йортларымыз бер дарелҗәзага[3] әйләнгән ки, анларны күрү генә дә күңелгә авырлык бирә. Әйтерсең лә, безнең балаларымыз, үзләренең татар балалары булып дөньяга килүләре белән җинаять эшләгәнләр...

– Пәйгамбәремезнең балалык галәменә кергән көне хөрмәтенә биреңез татар балаларына да рәхәт, тынычлык, шатлык! – дип кычкырасы килә.

Үземезнең балалык көнләремезгә кайтып карасак, без анда һичбер җуанырлык нәрсә таба алмыймыз, гомернең иң матур вакыты, бәхетнең иң мөмкин вакыты ниндидер бер дәһшәтле куркыныч төш (кошмар) булып үтеп киткән.

– Пәйгамбәремезнең туган көне, балалык дәверенә кергән көне хөрмәтенә инде бундан соң да татар балаларының сабавәте[4] алай үтмәсен лә! – дип кычкырасы килә.

Без дөньяда тора белмимез, без башкалар кадәр эшли алмаган шикелле, башкалар шикелле ду-у килеп бәйрәм дә итә белмимез; без сытылып гомер башлыймыз, иттифакый эш эшлимез; андан-бундан бәйрәм шикелле нәрсә итәмез дә – шуны тормыш дип атыймыз.

– Пәйгамбәремезнең балалык дәверенә кергән көне хөрмәтенә безнең балаларымызның да тормышы алай узмасын ла! – дип кычкырасы килә. Анлар сытылмыйчарак, хөррәк, күңеллерәк итеп гомер башласынлар да эшне дә иттифакый гына эшләмәсенләр, бәйрәмләрене дә андан-бундан итмәсенләр...

Балалык тормышыны бик кечкенә генә нәрсәләр каралта алган шикелле, бик садә генә нәрсәләр яктырта да алалар. Ләкин шул кечкенә нәрсәләр дә, бу садә нәрсәләр дә күңелдә җуылмый торган эз калдыралар. Күрсәтеңез балаларга диннең дә, милләтнең

---

[1] Мөстәхикъ – лаек.

[2] Истикълалене – иреклелеген, азатлыгын.

[3] Дарелҗәзага – җәза йортына.

[4] Сабавате – сабыйлыгы, балалыгы.

дә матур вә күңелле якларыны, биреңез балаларга дин вә миллиятләре белән баглы шатлыклар, дини вә милли бәйрәмнәр – анлар гомерләре буенча бунларны онытмасынлар. Бунлар айларның күңелләрендә юл күрсәтеп тора торган нурлы фонарьлар булырлар.

Безнең 7 яшьлек сабыйларымыздан башлап сакаллары агара башлаган ирләремезгә хәтле русларның «кызыл йомырка» һәм «масленица» бәйрәмләрене көтеп алалар...

Биреңез безнең балаларымызга үземезнең дини вә милли бәйрәмләремездә кызык, анлар шунларны көтеп ала башларлар.

Бөтен милләт хакимәләре[1] үз кул астларындагы башка милләтләргә үзләренең гадәт вә тормыш рәвешләрене йоктырганда, госманлы төрекләре ник үз кул астларындагы христиан милләтләргә шундый бер тәэсир итә алмадылар? Чөнки анларның тормышында кеше кызыкдырырлык бернәрсә дә булмады. Чөнки ул христиан милләтләрнең үз тормышлары төрекләрнекенә караганда кызыграк, рухлырак булды.

Балаларыңыз милләтләрене сакласынлар дисезме? Дисәңез, анларга милли тормышны кызыклы ясаңыз!

Күз алдымызда пәйгамбәремезнең туган көне.

– Биреңез шул көн хөрмәтенә балаларыңызга бәйрәм! Анларны сөеңез, анларны шатландырыңыз, анларга бу көнне гакыллы вә файдалы рәвештә куанырга, бәйрәм итәргә ихтыяр һәм имкян[2] биреңез!

## Муса әфәндегә җавап

161 нче номерлы «Вакыт» гәзитәсенең «Идарәгә мәктүбләр» кыйсемендә Муса әфәнденең «Инде әдәпсезлек үлде!» гонванлы[3] мәкаләсе дәреж ителгән. «Кояш»ка, аның баш мөхәрриренә һәм Ташмөхәммәд әфәндегә каршы язылган бу мәкаләгә, әгәр без беркадәр әһәмият бирергә кирәк тапсак, мөфассал[4] җавап бирер идек. Ләкин Муса әфәнденең моның шикелле кызулары, моның шикелле «нәсс»ләре[5] милли гәзитәләр күз алдындан моңар кадәр дә берничә мәртәбәләр үткән вә ул кызуларга матбугаты

---

[1] Хакимәләре – идарәчеләре.
[2] Имкян – мөмкинлек.
[3] Гонванлы – исемле.
[4] Мөфассал – җентекле.
[5] «Нәсс»ләре – «күрсәтмә»ләре.

мувәкъкатә[1] тарафыннан истихкакынча бәһа куелган булганлыктан, без кариэләремезгә[2] кызыгы бер дә булмаган бу мәсьәләдә Муса әфәнде белән мөнәзарага[3] керешә тормыймыз. Фәкать вакыйгаларны вә мәкаләләрне Муса әфәнде мизаны[4] белән үлчәүне үземезгә лазем тапмаганлыгымызны һәм халык алдында әдәб сакламаган кешеләрнең үзләре алдында башкалардан әдәп саклату юлында тартышып ятуларыннан гаҗәпләнгәнемезне генә әйтеп китүне үземезгә бурыч саныймыз.

Идарәгә мәктүпләр

Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде!

Мине шушы мәктүбемә гәзитәңездә урын бирүеңезне риҗа итәм.

82 нче номерлы «Кояш» гәзитәсендә Г. Әхмәдуллин әфәнденең бер мәктүбе дәреҗ ителгән[5]. Әхмәдуллин әфәнде мәктүбендә «Гостинный дууырда мәгълүм бер мөселман фирмасында зур бер урын тота торган бер мөселман»ның узган-барган хатын-кызга әдәпсез сүзләр белән бәйләнгәнлегеннән зарланып яза. Мин дә Гостинный дууырда зур бер мөселман фирмасында әһәмиятле бер урында торганлыгымнан, яңлыш аңлашылу булмасын өчен, Г. Әхмәдуллин әфәнденең мөзкүр әдәпсез шәхесне иseme белән матбугатта зикер итүен[6], вә шулай итеп, башка кешеләргә мондый әдәпсезлек сылтану ихтималын бетерүен таләп итәм.

*Хафиз Әхтәмов.*

**Идарә.** Мәзкүр әдәпсез кешенең исемене мәктүп иясе язган булса да, бәгъзе бер моталагага мөбани[7] исемене фаш итмәгән идек. Инде хәзер Хафиз әфәнде Әхтәмовны һәм башкаларны төһмәттән[8] коткару өчен ул кешенең исемен ачарга мәҗбүрмез; 82 номердагы мәктүпнең асыл нөсхәсендә ул кешене – «Гостинный дууырда Хәлил Галиев варисларының кибетендә доверенный Зыя Йосыпов булып чыкты» диелгән иде.

---

[1] Матбугаты мувәкъкатә – вакытлы матбугат.
[2] Кариэләремезгә – укучыларыбызга.
[3] Мөнәзарага – бәхәскә.
[4] Мизаны – улчәве.
[5] Дәреҗ ителгән – басылган.
[6] Зикер итүен – телгә алуын.
[7] Моталагага мөбани – укуга нигезләнгән.
[8] Төһмәттән – яла ягудан.

—

Муса әфәнде Бигиев үзенең «Вакыт» 161 нче номерында язган «Инде әдәпсезлек үлде» гонванлы мәкаләсендә миңа тәүҗиһ итеп[1] «Безә дустлык күрсәтер вә ихтирамларына тәнәззел итмәмеш[2] улсаңыз да ярар иде» ди. Бу сүз галиба[3] минем 63 нумерлы «Кояш»тагы «Питербург дустларыма ихтирам...» дигән җөмләм мөнәсәбәте белән әйтелгәндер. Муса әфәнде бу җөмләнең үз адресы белән әйтелмәгәненә әмин булсын! Питербургта Муса әфәндедән башка да кешеләр бар. Муса әфәнденең минем дустлыкка кызыкмас кадәр «гыйззәте» булса, минем Муса әфәнде дуслыгына кызыкмас кадәр аның белән танышлыгым бар.

## Мәхмүд Әсгадь әфәнде хәзрәтләре белән «Кояш» сайфиясендә мөсахәбә[4]

Өченче августда шәһәремезгә килгән Мәхмүд Әсгадь хәзрәтләре шул ук көнне «Кояш» сайфиясен тәшриф итте[5]. Бу вакытта инде сәгать дүртләр чамасы булганлыкдан, гәзитәнең көндәлек эше тәмам булган вә шунлыкдан һәйәте тәхририянең[6] бер кыйсеме таралып та өлгергән иде.

Олуг мосафир уртадан өстен буйлы, таза күренешле, 60 яшьләре чамасындагы мәһабәт бер карт икән. Ике сәгать микъдары сузылган мөсахәбәмездә ул яшьләргә махсус бер йитезлек белән бик күп мәсьәләләр тугрысында сөйләп вә безнең сөальләремезгә җаваплар биреп өлгерде.

Аның моңар кадәр Русиядә булганы юк икән. Русиядәге интизам[7], рус халкындагы әдәпле мөгамәлә һәм бездә шимал төрекләрендә күренгән галәмәте тәрәккый аның дикъкатен җәлеп иткән.

– Руслар бик яхшы мөгамәләле, гүзәл вә хәлим[8] холыклылар икән. Бу җәһәттән мин алар белән үземез – төрекләр арасында бер якынлык күрәм.

---

[1] Тәүҗиһ итеп – мөрәҗәгать итеп.
[2] Тәнәззел итмәмеш улсагыз – түбәнчелек итмәгән булсагыз
[3] Галибән – күбесенчә.
[4] Мөсахәбә – әңгәмә.
[5] Тәшриф итте – олылады.
[6] Һәйәте тәхрриянең – редакциянең.
[7] Интизам – тәртиплелек.
[8] Хәлим – йомшак, сабыр, ачусыз..

Шимал төрекләрендәге галәмәте тәрәкъкый[1] мәсьәләсенә килгәч, Мәхмүд Әсгадь әфәнде:

– Сезнең арада мөшаһәдә ителә[2] торган хәрәкәте мәдәниянең башы вә мәнбагысе[3] Казан икән. Мин Русиядә үзем булган йирләрнең һәммәсендә кирәк мөгаллимнәрнең, кирәк таҗирларның[4] Казан белән мөнәсәбәтле булганлыкларын күрдем, Казаныңыз бөтен шимал төрекләре тарафындан хөрмәт белән сөйләнә торган мәркәз икән, – ди.

Бу мәсьәләгә килгәч, безнең Гаспринский хәзрәтләрен һәм Кырымны хәтеремезгә алып күчеп, Мәхмүд Әсгадь әфәнде үзенең Кырымны бик улкадәр яратмаганлыгын, берничә сәбәпләр белән аларның истикъбале[5] безнекенә караганда карарак күренгәнлеген зикер итте.

– Кырымлылар Төркиягә һиҗрәт итәргә сөяләр; беркадәр мәдәниләшкән кырым төрке, үз йортын ташлап, Истамбулга урнашырга ярата – бу алар өчен бик зарарлы эш. Мин әгәр үзем бу көндә яшь кеше булсам, билгакес[6], Төркиядән Русиягә һиҗрәт итәр идем, һәм монда халкыма хезмәт итәргә тырышыр идем. Төркиянең башыннан бу көндә үтә торган тарихи бәлаләр Русия башыннан инде күптән үтеп киткән, шунлыктан мәдәни хәят өчен Русия Төркиягә караганда бик күп уңгайлырак. Кырымлылар үзләренең җәннәт шикелле ватанларын, йирләрен ташлап, Төркиядәге ут эченә керәләр. Моңар матбугат каршы торырга тиеш. Андан соң кырымлыларның хатын-кызларында, ябынып ятудан наши вәрем[7] хәстәсе, ирләрендә әхлаксызлыктан наши франк хәсталыгы бик таралган икән, бу эш милләтнең истикъбале өчен бик куркынычлы бер эш, – ди.

Без бу соңгы мәсьәлә мөнәсәбәте белән ислам хатын-кызларындагы сөтрәгә даир[8] сүз башлагач, Мәхмүд Әсгадь әфәнде: «Ул мәсьәләне сез дә – Казан төрекләрендә инде хәл кыйлынганга хисапларга ярый», – диде дә сугыш вакытында Истамбулга барган зыялы кызларымызны ихтирам белән хәтеренә төшерде.

---

[1] Галәмәте тәрәкъкый – прогресс билгеләре (күренешләре).

[2] Мөшаһәдә ителә – күренә.

[3] Мәнбагы – чыганагы.

[4] Таҗирларның – сәүдәгәрләрнең.

[5] Истикъбале – киләчәге.

[6] Билгакес – киресенчә.

[7] Наши вәрем – туган (барлыкка килгән) шешү.

[8] Сөтрәгә даир – битне ябып йөрүгә караган.

Гаспринский хәзрәтләре тугрысында Мәхмүд Әсгадь әфәнде:

– Ул, бер төрек галәменең генә түгел, бәлки бөтен ислам галәменең нурлы бер йолдызыдыр, – ди.

Мөзакәрә әснасында[1] без Мәхмүд Әсгадь хәзрәтләрендән Русия мәмләкәтенең 19–20 сәгать сузыла торган көнләрендә руза тоту мәсьәләсе хакындагы фикерен сорадык. Ул:

– Муса Бигиев бу мәсьәләдә хаклыдыр. Затән, «вәгалә әлләзинә йутыкунәһү фидйятү тәгамү мискин»[2] аяте кәримәсе бу тугрыда сарих[3] бит, – ди.

Бу мәсьәләдән Муса әфәнде Бигиев әсәрләре хакындагы шәйхелислам әмеренә күчеп, без үземезнең әмердән һәм тәгаҗҗеб, һәм тәэссеф иткәнлегемезне сөйләгәч, Мәхмүд Әсгадь әфәнде:

– Ислам галәменең һәр почмагында әле «Ишми»ләр хөкем сөрә бит, – дип җавапланды.

Безнең мәшһүр «Ишми»мезнең бер төрек галәме авызында зарбе мәсәл[4] урынында зикер ителүе безгә һәм гаҗәбрәк, һәм ятрак тоелды. Шөһрәт өчен зәмзәм коесын былчырату урынына хәзер башка юллар да бар икән.

Мәхмүд Әсгадь әфәнде, Казанга килгәнче, Уфа һәм Оренбургта булган. Уфада мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов хәзрәтләре белән дә күрешкән. Табигый, без Мәхмүд Әсгадь әфәнде хәзрәтләрендән мөфти белән булган мөсахәбәсен, вә ул мөсахәбәдә нинди мәсьәләләр мөзакәрә ителгәнлеген сорарга ашыктык. Ләкин Мәхмүд Әсгадь әфәнде бу тугрыда безгә көтелүе табигый булган кызыклы җавап бирә алмады:

– Мөфти карт вә иске кеше икән. Андый кешеләр белән мин сезнең белән сөйләшкән мәсьәләләрне сөйләшергә яратмыйм. Үз игътикадларына муафикъ булмаган сүзләрне сөйләп, аларны рәнҗетүдән мин сакланам.

Мәхмүд Әсгадь әфәнде хәзрәтләренә без төрек гәзитәләрендән зарланып, аларда милли төрек хәяты бик аз языла, шуңа күрә без татар гәзитәчеләренә күп вакытта госманлы төрекләре хәятына мөтагаллиакъ[5] нәрсәләрне дә төрек гәзитәләрендән түгел,

---

[1] Әснасында – вакытында.

[2] «Кемгә ураза тотарга авыр (тота алмый), ул фидия рәвешендә бер мескенне ашатырга тиеш».

[3] Сарих – ачык (әйтә).

[4] Зарбе мәсәл – гыйбрәтле сүз.

[5] Мөтагалликъ – караган.

бәлки рус гәзитәләрендән истифадә итәргә[1] тугры килә икәнен сөйләдек. Ул төрек гәзитәләренең үз милли хәятларына аз әһәмият бирүләрен ике сәбәптән күрә: 1) «бездә Яурупага тәкълид бик куәтле: үземез өчен әһәмияте булмаган мәсьәләләрне дә безнең гәзитәләр Яурупа гәзитләренә ияреп бик күпертәләр; үземез өчен бик әһәмиятле милли мәсьәләләрдә, фәкать, шул Яурупа гәзитәләре тарафындан игътибарсыз калдырылулары сәбәпле, үз гәзитәләремез тарафындан да игътибарсыз уздырылалар; 2) милли мәсьәләләр хакында уйлаганлык нәтиҗәсе уларак язылган мәкаләләр белән гәзитәне тутыруга караганда, Яурупа гәзитәләрендән тәрҗемә белән тутыру ансатрак. Затән, безнең йитешмәгән йиремез ул гына булса, тәшәккер итәр идек».

Мәхмүд Әсгадь әфәнде, киләчәк елда Бохара, Хива, Сәмәрканд тарафларында сәяхәт итеп, ул тараф мөселманларының тормышлары белән танышырга уйлый икән:

– Мин сәяхәт итүне сөям. Төркиядә мәшрутият игълан ителгәндән бирле һәр елны тәгътыйл[2] вакытында сәяхәт итми калмыйм. Бу ел бер Котбе шималидә[3] – боз диңгезләре арасында сәяхәт итәргә дә уйлаган идем, андан соң әүвәл Русиядә сәяхәт итүне яхшырак таптым, – ди.

Мәхмүд Әсгадь хәзрәтләре, сайфиямезгә килгәнче, Казанның тарихи манараларыннан Сөембикә манарасын зыярәт итеп өлгергән икән. Аның искергән вә игътибарсыз калдырылганлыгына ул тәэссеф иткәнлеген бәян итә.

Язу өстәлемездә тора торган Шиһаб әл-Мәрҗани һәйкәле (коеп ясалган сурәт) Мәхмүд Әсгадь хәзрәтләренең дикъкатен җәлеп итте:

– Мондый нәрсәләр милләтнең, үзенең олугларының кадерен белә башлаганын күрсәтә. Хәер, бездә Төркиядә моны ясатучы кешене тәкъфир итәрләр иде. Әмма мин тәкъдир итәм, – ди.

Мәхмүд Әсгадьь хәзрәтләре, Казандан Нижнийга вә андан Мәскәү аркылы Петербургка барып, андан Стокольмга китәчәк.

Бервакыт бөтен ислам голамәи руханиясенең башында булган зыялы бу галим бездә үзенең киң гыйлеме, гаять кечелекле мөгамәләсе һәм йинел вә хуш мөсахәбәсе белән якты бер тәэсир

---

[1] Истифадә итәргә – файдаланырга.
[2] Тәгътыйл – ял (каникул).
[3] Котбе шималидә – Төньяк котыбта.

калдырды. Юлында очраган һәрбер тәэссоратны үз милли тормышымызга үлчәп карарга өйрәнгән фикер ихтыярсыз төрле уйларга китте.

– Ни булыр иде, әгәр дә безнең голәмаи рухания атала торган сыйныфымыз арасындагы кешеләр дә шушындый киң мәгълүматлы булса вә шушылай мөсәхабә итә белсәләр?

Ләкин һәйһат, әйнә әс-сәмә вә әйнә әс-сүрайә![1]

## Хыял галәмендән

Төнләрдән бер төндә нәкъ сәфәр вакыты иде, Исрафил Галәйһиссәлам сулыш өрде. Шуның бәрәкәсендә бөтен Русия мөселманлары кояш чыгуы белән бергә йокыларыннан тордылар. Һәм ничек тордылар әле? Һәммәсе аңлы булып тордылар.

Менә шундан соң бөтен фитра сәдакалары, бөтен зәкятләр «милли фонд»ка җыела башладылар: 20 миллион гадәдле мөселманларның өчтән ике өлеше фитыр сәдакасы бирә иде. Шул сәдакалардан милли фондка әүвәлге гаед фитырдук ике миллион сумдан артык акча җыелды. Ул мөбарәк төндән соң Русия мөселманларының бөтен байлары да зәкятьләрен бер дә алдашмый гына, бик бөтен генә итеп бирә башлаганлар иде. Бу байларның миллиарддан арткан суммаларындан 25 миллион сумдан артык зәкят тә әүвәл елдук мәзкүр «милли фонд»ка барып керде.

Менә шулай итеп Русия мөселманларының бер еллык ваҗиб сәдакалары 27 миллион сумлы зур бер «милли фонд»ка әйләнде. Бу «милли фонд»тан ун мең мәхәллә, Русия мөселманлары мәхәлләсендәге ибтидаи мәктәпләр – ун мең мәктәп тәрбия ителде. Бу мәктәпләрнең һәм берәм-берәменә меңәр сум тотылгач да, әле «милли фонд»ның 17 миллион сум акчасы калган иде. Ул акчаның 10 миллион ятим балалар һәм эшдән калган картларны тәрбия итәргә сарыф ителде дә, калганына гадәдләре[2] 20 гә җиткән милли гимназияләр тәрбия ителделәр.

Бу «милли фонд»ның еллык доходы һәр сәнә арта бара, чөнки ишмаль төрегенең сәүдәгәр балалары кулындагы суммаларның җәмгысы сәүдәләре тәрәкъкые белән мотәнасыйб[3] бик тизлек белән зурая бара иде.

[1] «Кайда күк һәм кайда йолдыз!»

[2] Гадәдләре – санлары.

[3] Мотәнасыйб – мөнәсәбәттә (булып).

«Милли фонд» зурайгандан-зурайды, аның аркасында бөтен ибтидаи мәктәпләремез тәэмин ителделәр, ятим вә гаҗизләремез тәрбия ителделәр, милли урта мәктәпләр дәвам вә тәрәкъый ителделәр...

## Кызганыч бу тәнасеб[1]

– Петербург мәсҗеде өчен Баку мөселманлары утыз мең сумлык кадәр мөзәйян [2] кандильләр эшләргә биргәнләр!

Менә бу хәбәрне мин «Каспий» газетасында укыдым. Гәзитәнең тәгърифенә[3] караганда, электрик белән яктырачак бу кандильләр һәм матур вә мәһабәт һәм мөзәйян[4] булачаклар.

Дөньяның иң зур мәмләкәтенең мәһабәт пәйтәхәтендә вөҗүдкә китерелгән мөзәйян мәсҗеднең эченә бу мөзәйян кандильләр, шик юк, бик килешерләр. Алар мәсҗеднең эченә кергән кешеләрнең дикъкатьләрен иң әүвәл үзләренә җәлеп итәрлек булып, мөзәйян асылынып торырлар, кичке гыйбадәт вакытларында бөтен мәсҗеднең эчен ялт иттереп яктыртырлар, гыйбадәткә килгән мөселманнарны электрик белән коендырырлар.

– Шик юк, бу матур вә килешле булыр!

Мин ислам мәмләкәтләрендә булганым, аларның мөзәйян мәсҗедләрен күргәнем юк, ул мәсҗедләрне укыган нәрсәләрем, күргән рәсемнәрем аркылы гына хыялыма китерәм. Шуңар күрә ул мәсҗедләрнең гыйбадәт итүчеләргә нинди тәэссорат биргәнен белмим. Ләкин мин башка милләтләрнең иң мөзәйян гыйбадәтханәләрендә булганым вә аларның гыйбадәт итүчеләргә нинди тәэссорат биргәнен күргәнем бар. Ул гыйбадәтханәләрнең мөзәйян эчләрен күргәндә, һәрвакыт минем – зинәтел-хәйәте әддөнья![5] – дип әйтәсем килә иде. Мин бу мөзәйянлекне үземезнең мәсҗедләремезнең зиннәтсезлеге белән чагыштырып карый идем, гыйбадәт йортының садәлеген, зиннәтсезлеген фазлыяткә[6] саный идем: – зинәтел-хәйәте әддөньядан туйган дәкыйкаләрдә[7] адәм баласы гыйбадәт йортына качсын!

---

[1] Тәнасеб – гармония, пропорция.
[2] Мөзәйян – бизәлгән, матур.
[3] Тәгърифенә – белдерүенә, аңлатуына.
[4] Мөзәйян – зиннәтләнгән, матур, бизәкле.
[5] Зинәтел-хәйвате әддөнья – дөньяда яшәү матурлыгы.
[6] Фазлыяткә – өстенлеккә.
[7] Дәкыйкаләрдә – минутларда.

Мин гомеремдә онытмам бер авыл мәсҗеден. Ул эшкә күптән инде: мин кечерәк вакытымда хәзер инде исемен онытканым бер мөселман авылында булдым. Фәкыйрь бу авылның искерә төшкән, бик садә бер мәсҗеде вә ул мәсҗеднең нәкъ үзе шикелле, бик садә, аппак чәчле, аппак сакаллы карт бер имамы вә ул имамның карылган гына серле карт тавышы бар иде. Бу мәсҗеднең бик тупас такталардан оештырылган идәненең кайбер йирләренә соң дәрәҗәдә садә камыш намазлыклар җәелгән, ул намазлыкларның өстенә анда да монда бик садә итеп ясалган утыз өчлы тәсбихләр ыргытылган иде. Күптән инде шул мәсҗедтә мин, мәсҗеднең үзе шикелле садә картлар белән рәттән торып намаз укыган аппак имамның карылган карт тавыш белән:

– Изә зүлзиләт әл-арду зилзәләһә, вә әхраҗәт әл-әрду әскаләһә, вә калә әл-инсәнү мә ләһә... йәүмә йәсдуру ан-нәсү әштәтәл лийурау әгмәләһүм...,[1] –дип укыганын ишеткән вә бөтен бу садәлектән гомеремдә дә онытмаслык мәхзуз[2] булган идем. Ул садә мәсҗеднең эчендә торып, чынлап та йирнең тәзәлзел итеп, бөтен хәзинәләрен, бөтен «әскален»[3] ыргыткан көне тугърысында уйланырга һәм йирнең шул тәзәлзеле[4] вә шул әскален чыгарып атуы өчен бер дә хафаланмый, бер дә борчылмый уйланырга мөмкин иде. Ул тупас тактaлы идәннең камыш намазлыгы өстенә басып хәзрәткә йирнең тәзәлзеленә хафаланырга, анда һәлак була торган «зинәтел-хәйәте әддөнья» өчен борчылырга һич сәбәп юк иде.

– Петербург мәсҗедендә утыз мең сумлык кандильләр! Менә хәзер инде бу гармония (тәнасеб) бозылды. Мәсҗеднең садәлеге аның бөтен зинәтел-хәйәте әддөньядан гарилеге[5] бетте. Хәзер инде «Зәлзәлә» сүрәсе бу мәсҗед эчендә алай яңгырамас, ул мөзәйян кандильләр астында гыйбадәт итүчеләр йирнең тәзәлзелләрен, бу матур нәрсәләрнең йимерелеп төшүләрен хафаланмый гына, тыныч кына гыйбадәт вә хөсне риза[6] белән генә уйлана алмаслар!

– Шик юк, екерме миллион мөселманы булган бер мәмләкәтнең пайтәхетендә утыз мең сумлык кандильле матур мәсҗед бик матур булып торыр. Ләкин... тәнасеб бозылды, мәсҗедкә күп,

[1] Коръәннең «Зәлзәлә» сүрәсе шушы аятьләр белән башлана.
[2] Мәхзуз – шат.
[3] Әскален – йөген (багажын).
[4] Тәзәлзеле – тетрәнүе, селкенүе.
[5] Гарилеге – бушлыгы, сафлыгы.
[6] Хөсне риза – разыйлык матурлыгы.

зинәтел-хәйәте әддөньядан кача алу имкяне[1] бетте. Кызганыч бу тәнасеб!

### Дини мәктәп һәм мәдрәсәләр хакындагы истифсарга даир[2]

Рухани эшләр департаменты директоры тарафыннан мөфти хәзрәтләренә җибәрелгән истифсарнамә гәзитәмезнең 237 нче номерында дәреҗ ителгән иде [+1]. Истифсарнамәдә күрсәтелүенә караганда, нәзарәт тарафыннан мөселман мәктәп вә мәдрәсәләре хакында мәгълүмат җыелып тәртипкә салына башлаганлыгы аңлашыла. Димәк, озакламый мәктәп вә мәдрәсәләремезнең хәлләренә даир хөкүмәт тарафыннан нинди дә булса адымнар булачак. Боларда нәрсәләр укытылу, кемнәр укыта алу, нинди максат тәгъкыйб ителү[3] мәсьәләләре кузгатылачак.

Истифсарнамәдә сорала торган нәрсәләрне менә шушы рәвешчә тәхлил итәргә мөмкин:

Шәригать тәгълиматы буенча:

1) дини мәктәп вә мәдрәсәләрнең вазифалары нәрсә?

2) дини мәктәп вә мәдрәсәләрдә нинди максад тәгъкыйб ителә?

3) ул мәктәп вә мәдрәсәләрдә тәгълим ысулы нинди булырга тиеш?

4) нинди программа булырга тиеш?

5) мөгаллимләр кемләрдән гыйбарәт булырга тиешләр?

6) дин өйрәтүче мөгаллимләр нинди кешеләр булырга тиешләр?

Коръән, әхадис, тәгълиме фикъһә һәм сөннәте сәләф һәммәсе бергә алынган хәлдә шәригать аталалар. Без Коръән вә әхадистә тугрыдан-тугры мәктәп вә мәдрәсә исемләрен очратмасак та, боларда мөселманларны тәгълим[4] мәсьәләсенә даир шактый нәрсә очрата аламыз. Сөннәте сәләф вә тәгълиме фикъһә тугрыдан-тугры безгә «мәктәп вә мәдрәсә» исемнәре белән мәгъруф тәгълимханәләргә даир инде ачыктан-ачык юл да күрсәтәләр.

Без шәригать ноктаи нәзарендән[5] югарыдагы сөальләргә бик ачык җавап бирә алабыз:

---

[1] Имкяне – мөмкинлеге.
[2] Истифсарга даир – аңлатмага караган .
[3] Тәгъкыйб ителү – күзәтелү.
[4] Тәгълим – укыту, белемле итү.
[5] Ноктаи нәзарендән – карашыннан.

1–2. Мәктәп вә мәдрәсәләрнең вазифалары – дин вә фөнүнгә ашна[1] адәмнәр йитештерүдер. Монда шуны дикъкатькә алырга кирәк ки, ислам голамасы бервакытта да мәктәп вә мәдрәсәләрне дини вә дөньяви исемнәре белән ике сыйфатка бүлмәгәнләр. Дин тәгълименә бик зур әһәмият биргән бу мәктәп вә мәдрәсәләрдә фөнүнгә дә бик зур урын бирелгән: сәләфе рәхимумаллаһ[2] үзләренең тәгълим йортларында риязыят[3], мантыйк, тарих шикелле фәнләрне бик зур әһәмият биреп укытканлар. Бу мәктәп вә мәдрәсәләрне бәлки хәзерге заман христианларының рухани семинария вә академияләре шикелле, дин белән бергә, фән дә укытыла торган мәктәпләренә охшатырга мөмкин булыр.

3. Хосусый тәгълим ысулына даир шәригатьтә һичбер тәгълимат юк, фәкать, боларда һәрвакыт тәгълим ана телендә була килгән. Менә бу матдәгә даир инде сөннәте рәсүлдә[4] туп-тугры тәгълим бар. Ул, гарәпчә сөйләшми торган кавемнәргә дин мөгаллиме җибәргәндә, шул кавемнең телен белә торган сәхәбәне җибәрә торган булган. Сәләфе салихин[5] вә фикъһа үзләренең тәгълим йортларында һәр милләткә үз ана телендә өйрәтә торган булганлар.

4. Сәләфе салихин рәхимуллаһның мәктәп вә мәдрәсәләрендә программа бик киң булган, ул программа дин дәресләре белән бергә, әллә никадәр фән дәресләре дә керә булганлар.

5. Мөгаллимләр әһле диянәт вә әһле гыйлем кешеләр булырга тиешләр.

6. Дин өйрәтүче кешеләр дин галимләрендән вә җәмәгате мөслимин тарафындан[6] ышаныч казанган кешеләр булырга тиешләр.

Менә бу соңгы матдә хөкүмәт мәктәпләрендә укучы мөселман балаларына дин мөгаллимнәре тәгаен ителгәндә, бик күп вакытта иһмаль ителә[7] килә. Мондый мәктәпләргә дин белми торган гына түгел, яхшы язу да танымый торган наданлар куелгалыйлар.

Шәригать тәгълиматы буенча, укытучыларга уку вә укыту эшендә бик зур хөррият бирелүе дә шаян дикъкать[8] мәсьәләдер.

---

[1] Фөнүнгә ашна – фәнләргә мәгълуматлы..
[2] Сәләфе рәхимуллаһ – Аллаһы Тәгалә мәрхәмәт кылсын.
[3] Риязыят – математика.
[4] Сөннәте рәсүлдә – Пәйгамбәребез практикасында (эшләгән гамәлләрендә).
[5] Сәләфе салихин – үткән замандагы изге кешеләр.
[6] Җәмәгате мөслимин тарафындан – мөселман җәмәгате алдында.
[7] Иһмаль ителә – әһәмият ителми.
[8] Шаян дикъкать – тиешле дәрәҗәдә игътибар (сорый торган).

Без мөфти хәзрәтнең мәзкүр сөальләргә нинди җаваплар бирәсен, нинди тәфсилат вә бәянәт белән ул җавапларына изах итәсен, табигый, белә алмыймыз. Ләкин ул җавапларның күрсәтелгән җавапларга мөхалиф[1] булмасыннан һәм кирәк кадәр дәлилләр белән беркетелгән буласыннан әминмез. Бу мәсьәләгә яңадан кайтырмыз әле.

## Коръән бозу

Үткән көн минем кулыма Харитонов матбагасында басылган бер мосхәф төште. Мосхәфнең кайсы фирма тарафыннан нәшер ителгәнлеге күрсәтелмәгәнгә күрә, мин аның Харитоновның үз тарафыннан нәшер ителгән булучылыгын уйладым. Һәм ахырдан, тәфтиш итеп, шул фикеремдә яңлышмаган икәнемне, ул мосхәф мөселманлар арасында сатылыр өчен Харитонов тарафыннан нәшер ителгән икәнен белдем.

Әһле булмаган кеше тарафыннан нәшер ителгән бу мосхәфнең дөрест басылганмы, дикъкать белән вә кирәгенчә иһтимам итеп[2] эшләнгәнме икәнчелеген беләсем килде, мосхәфне укый башладым һәм, үземнең тәәссефемә каршы, мин бу мосхәфтә шундый фәхши хаталар һәм тәхрифләр[3] тапдым ки, Харитоновның шушындый мосхәфне татар китап базарына чыгарырга җөрьәт итә алуына тәгаҗҗеб итдем. Бу мосхәфтә сүзләрне генә бозып канәгатьләнмәгән, бөтен-бөтен аятьләр тәхриф ителгән, бөтен-бөтен аятьләр төшереп калдырылган. Мин бу мосхәфнең фәкать әүвәлге табагын карап чыкдым вә шул аз гына йирдә дә менә нинди хатаи фәхешләр очратдым:

І7–18 нче битдә: «Әлләзиинә әәтәйнәәһүмүл-китәәбә фә’ ү икә һүмүл-хаасируун» диеп, «Китап индерелгән бөтен өметләр бәхетсез вә көенечтәдер» мәфһүмендә, бөтен Коръәннең рухына хилаф булган аять ясап чыгарылган. Асыл аять исә болай: «Әлләзиинә әәтәйнәәһүмүл-китәәбә йәтлүүнәһү хәкка тиләәүәтиһи үләә’икә йү’минүүнә биһии үә мәй йәкфүръ биһии фә’үләә’икә һүмүл-хаасируун»[4].

[1] Мөхалиф – каршы.
[2] Иһтимам итеп – кайгыртып, карап.
[3] Тәхрифләр – язылган сүзләрне үзгәртүләр; сүзнең хәрефләрен үзгәртүләр.
[4] «Бәкара» сүрәсе, 121 аять.

19 нчы биттә бер бөтен аять һәм бер кәлимә тәкрар басылган. 21–22 нче биттә ике аятьне бүлгәләп ташлап калдырыла да: «Үә мин хәйсү харәҗтә фәүәллии үәҗһәкә шәтраль-мәсҗидил-хәраами үә хәйсү мәә күңтүм фә-үәллүү мәә ләм тәкүүнүүтәгъләмүүн» диеп тәхриф итеп, һичбер мәгънәгә дәлаләт итми торган яңа аять ясап чыгарыла. Асыл аять булырга тиеш: «фәүәллүү вүҗүүһәкүм шәтраһү...»[1].

23 нче биттә өч аятьтән артык басып куя да, ахырында мондый аять ясап чыгара: «Үә изәә кыйлә ләһүмү-ттәбигүү мәә әңзәләллаһү каалүү бәл нәттәбигү мәә әлфәйнәә гәләйһи әәбәә’әнәә үә ләү кәәнә кәмәә тәбәррaүү миннәә».

Менә шул җөмләне теләсәң ничек аңла! ..

25–26 битләрдә 5 аять кадәр арадан ташлап калдыра да: «Китабин гәләйкүм изәә хәдара әхәдәкүм әл-мәүтү ин тәракә хайран үлвәссыййәтү хайран ләһү. Вә ән тәсуумуу хайран ләкүм ин күнтүм тәгләмүүн»[2] дигән мәгънәсез вә мантыйксыз бер сүз тезмәсе ясала.

27–28 битләрдә 4 аять төшереп калдыра да: «Фәмән кәәнә минкүм мәриидан әл-кәәфириин»[3] дигән рабытсыз[4] җөмлә төзеп куела.

29–30 нчы битләр арасында 7 аять микъдары төшереп калдырып: Үә изәә кыилә ләһү-ттәкы-лләәһә үә-ллааһү йәръзүкү мәй йәшәә’ү бигайри хисәәб»[5] дигән сурәтдә хата чыгарыла.

31–32 нче битләрдә 3 аятьдән артык (унбер юл) ташлап калдырып: «Үә йәс’әлүүнәкә фии сәбилләәһи үләәикә йәрҗүүнә рахмәтәллааһү үә-ллааһү гафүүру-ррахиим»[6] дигән яңа аять ясап чыгарыла.

Харитонов безнең әлифбамызга, сарыф[7] вә нәхүемезгә[8] тотынып, алар белән шаярды. Матбугаты миллия ул эшкә сабыр итте. Хәтта бәгъзе бер шәхесләр бу мөнәсәбәтсезлекне тәрвиҗ итүдән[9] дә кире тормадылар.

Иван Николаевичның инде мосхәфкә кадәр барып тотынуын, мөселманнарның мөкатдәс китаплары белән болай игътибарсыз

[1] «Бәкара» сүрәсе, 150–151 аятьләр.
[2] «Бәкара» сүрәсе, 180–184 аятьләр.
[3] «Бәкара» сүрәсе, 196 аять.
[4] Рабытсыз – бәйләнешсез.
[5] «Бәкара» сүрәсе, 206–212 аятьләр.
[6] «Бәкара» сүрәсе, 222 аять.
[7] Сарыф – морфология.
[8] Нәхүемезгә – синтаксисыбызга
[9] Тәрвиҗ итүдән – таратудан.

мөгамәлә итүен тавыш-тынсыз гына уздырырга мөмкин түгел. Һичбер мөселман бу эшкә тәхәммел итә[1] алмас. Харитоновка мосхәф бер сатлык товар гына булса да, мөселманларга ул – динләренең әсасы һәм дөньядагы мөкаддәсе.

Бу мосхәфтә минем иң зур дикъкатемне җәлеп иткән нәрсә аның кем тәсхихы белән нәшер ителгәнлеге мәсьәләсе булды. Мөсаххихнең имзасын эзләп, мосхәфның ахырын ачып карадым. Монда мосхәфның «Мулла Сафиулла бән Габдулланың иҗтиһад кыйлып тәсхих итүе белән 1329 нчы сәнә шәгъбанында» басылып тәмам булганлыгы күрсәтелгән вә Сафый хәзрәтнең имзасы белән тәэкид ителгән[2].

Мин хәзер Сафый хәзрәтдән сорыйм: бу мосхәф чынлап та сезнең тәсхих белән нәшер ителгәнме? Әгәр сезнең тәсхих белән булмаса, Харитоновны сезнең имзаны куйган өчен мөхакәмәгә чакырырга үзеңезне мәҗбүр күрмисезме?

Һәрбер гарәпчә белә торган кеше аңларлык мондый фәхеш хаталарны, Сафый хәзрәтнең төзәтми узуын мин мөмкин күрмим, шуңар күрә мосхәфкә күрсәтелгән мондый игътибарсызлыкка мин аны гаепләүдән ерак торам. Шулай да Сафый хәзрәт бу хакта матбугатта үз тарафыннан бер бәян бирергә мәҗбүрдер.

Мондан соң мосхәф шәриф ала торган мөселманларның, үзләре ала торган мосхәфнең, мөселман каширләр тарафыннан нәшер ителеп, наширләре күрсәтелгән булучылыкка игътина[3] итүләре тиештер.

Без чыдам халык. Безнең һәммә нәрсәләремез белән игътибарсыз мөгамәлә итәргә мөмкин, ләкин мосхәфемезне генә булса да үземезгә калдырсалар иде. Гакълән[4] аның белән генә болай мөгамәлә итмәсенләр иде. Чыдамлык-чыдамлык, әмма анңың бер чиге дә бар бит!

### Харитонов җавабы мөнәсәбәте белән

Цензор һәм матбугат кануннарының 114 нче статьясындагы 12 нче матдә буенча, без Харитоновның җавабын гәзитәмезнең үткән номерында гайнан[5] дәреҗ иткән идек. Мәзкүр статьяның

[1] Тәхәммел итә – түзеп тора.
[2] Тәэкид ителгән – расланган.
[3] Игътина – игътибар.
[4] Гакълән – акыл белән
[5] Гайнан – үзгәртмичә.

мәзкүр пункты гәзитәдә чыккан бернәрсәгә рәддия[1] яхуд шуны тәхсыйс[2] булса гына «рәддия»не дәреҗ итәргә мәҗбүр итә. Харитоновның мәктүбендә безнең гәзитәмездә аның хакында чыккан нәрсәгә рәд дә юк, тәхсыйс тә юк, булса да, без аны гәзитәмездә дәреҗ итәргә мәҗбүр булдык.

– Була бит шундый вакыйгалар!

Мәҗбүр булганда да ничек мәҗбүр булдык әле. Әнә шул югарыда күрсәтелгән статья «буенча» мәҗбүр булдык. Ул статьяның мәфһүме[3] буенча, без Харитоновның ул мәктүбенә шул җавап та дәреҗ итмәскә мәҗбүр идек.

Җавап димәктән, ул мәктүпкә нәрсә җавап бирергә кирәк?

Харитонов Алла исеме белән имин итә-итә, үз табгысы мосхәфләрдә[4] хата табылганлыгын тәсдикъ итә[5] дә: «Бу вакыйгада эшчеләр гаепле», – ди. Матбага эшчеләре Коръән мосаххихләре[6] түгелләр, алардан: баса торган нәрсәләрен тәсхих итүне таләп итеп булмый. Бу эш өчен идарәи рухания тарафындан куелган махсус мосаххих бар. Ул мосаххихнең матбугат сәхифәләрендә биргән бәянына караганда, Харитонов бу хаталы мосхәфләрдә аның имзасы белән сүи истигъмаль иткән[7]. Бу эш аның Коръән табгысы[8] белән никадәр игътибарсыз кыйланганлыгын күрсәтергә йитәдер. Мөкатдәс китаплар түгел, иң гади бер китапны дә һичбер инсафлы нашир, мосаххихдән төзәттермичә нәшер итмидер. Харитонов бөтен әһле исламның иң газиз булган нәрсәләре белән сәүдә итәргә тотынып вә шундан зур сәрмаялар хасил итеп тә, иң горфи[9] бер китапка бирелә торган әһәмиятне дә бирмәве белән, үзенең Коръән табгысына кямилән әһалиятсез[10] бер кеше вә инсафсыз бер мәтбагачы икенчелеген аерымачык күрсәтте:

– Харитонов, бу халыкка ничек булса да ярар әле! – дип уйлады булырга кирәк.

---

[1] Рәддия – кире кагу.
[2] Тәхсыйс – билгесе.
[3] Мәфһүме – аңланган нәрсә.
[4] Мосхәфләрдә – Коръәнләрдә.
[5] Тәсдикъ итә – раслый, таный.
[6] Мосаххихләре – төзәтүчеләре (корректорлары).
[7] Сүи истигмаль иткән – урынсыз файдаланган.
[8] Табгысы – басмасы (бастыру).
[9] Горфи – гади, гадәти.
[10] Кямилән әһалиятсез – бөтенләй туры килмәгән (бу эшкә яраксыз, ярамаган).

Харитонов бозык мосхәфләрнең гадәден 200 генә дип күрсәтмәкче була. Без, табигый, бу көндә аның микъдарын катгый сурәттә күрсәтә алмыймыз. Ләкин «Вакыт» гәзитәсе Оренбург шәһәренең бер складында гына да бозык мосхәфләрнең ничә меңләргә йитә икәнен хәбәр бирде.

Харитонов бу эштә конкуренция гаепле димәкче була. Мөселманларның иң газиз нәрсәләре белән шулкадәр кабахәт мөгамәлә итеп, шул кабәхәтең дөньяга чыгарылгач та, «конкуренция гаепле» дип әйтергә никадәр оятсызлык кирәк икәнен укучылар үзләре тәхмин итсенләр.

Харитонов Коръән сатлык товар гына булганга күрә, ул Коръәннең дөрест вә бозык басылуына да «конкуренция» ноктаи нәзарендән гына карый алса да, без мөселманларга Коръән сатлык товар гына түгел, ул безгә мөкатдәс нәрсә, безнең мөселманның Коръәнгә булган ихтирамнары Харитоновка аңлашылмаслык дәрәҗәдә югары тора.

Коръән Харитоновка сатлык товар, шуңар күрә ул аның һәммә нәрсәсенә конкуренция ноктаи нәзарендан карый ала, әмма без мөселманларга ул – мокатдәс китап. Иван Николаевич Коръәнгә булган үз карашын мөселманлар өстенә йөкләтмәсен.

Гайре дингә мәнсуб булган[1] бер мәтбагачы, Инҗилне шушы дәрәҗәдә бозып караса, бөтен христианлар, бик хаклы уларак, шул вакыйгадә гаепле кешедән нәфрәт итмәсләр идемени?

Харитонов үзенең мәктүбендә мөселманларга бик зур сөенеч ясамакчы була: «Мондан соң Коръәнне мин үзем карап бастырырмын», – ди.

– Ишетәмсез, Иван Николаевич Коръәнне үзе карап бастырачак!

– Нинди мөтәхәссис! Нинди Коръән галиме!

Бер мәртәбә мосхәфне эштән чыгарып тәхфиф иттергән бер хәриф[2], әле яңадан Коръән бастырырга җөрьәт итә генә түгел, бәлки бөтен мөселманларга хитабән, үзе карап бастырачаклыгын сөенеч биреп куя.

Мондан инсафсыз игъланга ни дип җавап бирмәк кирәк инде?

Бөтен мөселманларны һәйҗанга китерерлек скандал ясаган бер шәхес, әле һаман шул эшен куярга исәпләп тә карамый, әле

[1] Гайре дингә мәнсүб булган – башка дингә караган (диндә булган).

[2] Хәриф – түбән кеше.

һаман мосхәфләр нәшер итәргә уйлый, аның өстенә әле: «Үзе карап нәшер итәчәген сөенеч бирә».

– Юк, Иван Николаевич, рәхим итеп сез инде мөселманларны үз башларына гына калдырыңыз! Алар Коръәнләрен карап нәшер иттерергә сездән башка да кеше табалар.

Харитонов, мәктүбенең ахырында үзе бастырган мосхәфләр бик шәп булганлыгын бәян итә.

Моны без оятсыз реклама дип кабул итмәсәк иде, хосусый җавап биреп торган булыр идек бәлки. Шулай да «Вакыт» гәзитәсендә Харитонов табгысы мосхәфләр тугрысында чыккан нәрсәне Харитоновның хәтеренә төшереп китик.

Харитонов мосхәфләре соң дәрәҗә игътибарсыз басылганлар. Бер мосхәф эчендә әллә ничә сурәттә, әллә ничә төрле кягадләр[1] очрыйлар.

Харитонов мәктүбенең иң соң юлларын мөселманларны, үз мосхәфен алырга димләп тәмам итә.

Әгәр Харитонов, бу рекламасын, рәддия мәктүбендә түгел, бәлки игъланлар арасында дәреҗ итсә, без моңар:

– Шушы кадәр скандалдан соң да нинди йөз белән мөселманларга үз мосхәфен гарыз итә? – дип уйлар идек тә узар идек. Ләкин бу реклама, аның рәддия мәктүбендә дәреҗ ителгәнгә күрә, безгә бары гаҗәпләнеп, тәхкыйрьле җылмаеп калырга гына тугры килә.

– Юк инде Иван Николаевич, бу тугрыда тагы рәхим итеп, сез мөселманларга үз нәшереңез мосхәфләрне алу-алмау тугрысында ирек калдырыңыз инде. Мөселманларны сез сарыклар гына дип уйлый торгансыздыр бәлки. Ләкин киләчәк күрсәтер, мөселманлар нинди мосхәфләрне алырга ярый, нindиләрне ярамый икәнен үзләре белеп эш күрерләр.

### Мөфти хәзрәткә бердәнбер юл

Кичәге телеграм мөфти хәзрәтнең 10 нчы декабрьгә тәгъйин кыйлынган киңәш мәҗлесен билгесез вакытка кичектергәнлеге хәбәрен китерде.

– Билгесез вакытка кичектерү!

Рәсми даирәләрнең телен белгән кешегә бу сүзнең мәгънәсе бик ачык.

---

[1] Кягадләр – кәгазьләр.

– Билгесез вакытка кичектерелгән, ягъни бөтенләй ясамаска, киңәш мәҗлесе җыелмаска карар бирелгән.

Дахилия нәзараты, мәктәп вә мәдрәсәләр хакында һәм идарәи руханияне ислах тугрысында мөфти вә казый хәзрәтләренең фикерләрен белергә теләп, аларга мөрәҗәгать итте. Бу соңгылар исә милләтнең хәят вә мәмат[1] мәсьәләсендә үзләре генә җавап бирүне авырсынып, таулардан зур мәсьүлиятне[2] күтәрүдән куркып, бу мәсьәләдә голамаи руханиянең фикерен белергә теләделәр: киңәш мәҗлесе җыймакчы булдылар. Хәтта дәгъватнамәләр дә таратып өлгерделәр... Милләт Уфага күзен текте. Анда чакырылган кешеләрнең шул олуг мәсьәләләр тугрысында татар рухында кайнаган ихтыяҗларны, татар күңелен сикертеп торган кирәкләрне әйтүләрен көтеп тора башлады:

– Менә киңәш мәҗлесе була, менә анда җыелган голамаи милләтнең үз мәдрәсәи руханиясе тугрысындагы фикерен әйтә дә, менә хөкүмәт шул хакта низам ляихасе[3] тәртип иткәндә шул фикерне игътибарга ала...

Милли матбугат инде бөтен дикъкатен сарыф итеп, Уфадагы хәрәкәтне тәгъкыйб итә башлаган иде. Ул үзенең вазифасын хакы белән әда итәр[4] өчен мәсьәләгә әһәмияте микъдарында үз сәхифәләрен ачарга хәзерләнә иде («Кояш»ның хосусый мөхбире инде бүгенле-иртәле Казандан Уфага китәр өчен, җыенып, кирәкле тәгълиматны алып та куйган иде).

Менә шул хәрәкәтләр арасында без кичәге тәәссефле телеграмны алдык:

– Киңәш мәҗлесе булмаячак!

– Мөфти хәзрәт тарафыннан киңәш мәҗлесен җыймаска карар бирелгән!

Дөрестен әйтергә кирәк, без, мөфти хәзрәтнең киңәш мәҗлесе җыярга карар биргәнлеген әүвәл мәртәбә ишеткәч тә, бик көчлек белән генә ышана алган идек:

– Харикылгадә[5] эш! Фәүкылгадә[6] эш! Мөфти Солтанов хәзрәтләре милләт фикеренә колак салсын имеш? – дип уйлаган,

---

[1] Мәмат – үлем.
[2] Мәсьүлиятне – җаваплылыкны.
[3] Ляихасы – проекты.
[4] Әда итәр – үтәр.
[5] Харикылгадә – гадәттән тыш.
[6] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

ләкин милләтне мәэюсияткә[1] төшермәс өчен, шул уемызны йөземезгә чыгармастан гына хәрәкәт итә биргән идек:

– Ходай кушса, белмәссең тагы! – дип тора идек без.

Декабрьнең 3 ндә һәм 4 ндә мин собрания даирәсенә якын тора торган ике заттан бик мәэюсият белән язылган хосусый хатлар алган булсам да, ияләренең тәнбиһләре[2] белән матбугатка чыгармый калдырган идем. Хәзер инде: «Кад кәнә әл-ләзи мә хыфтү ән йәкүнә»[3]. Хат сахибләренең гафуларына таянып, шундагы бәгъзе мәгълүматны укучыларга гарыз итәм.

Киңәш мәҗлесе өчен мөфти хәзрәт, кирәк урыныннан рөхсәт-фәлән алып тору мәшәкатенә иртикаб итмичә[4] генә, сахибе мәктүб[5] тәгъбиренчә, бер приставның стражникларны җыюы кабиләндән генә итеп, муллаларга дәгъват тараткан булган икән.

Съездга имамнар гына чакырылып, зыялыларның чакырылмавы да шул ук сәбәптән булган икән.

Дәгъват таратылган, ниндидер тәэсират астында мөфти хәзрәт бу эшне эшләп ташлаган, ләкин үзе бу киңәш мәҗлесенә һич тә генә бер игътибар вә игътимад итмәвендә[6] дәвам итеп килгән, әтрафтан килгән җавапларны казыйлар вә Уфа голәмасы һәр көнне собраниягә җыелып тәфтиш итеп торган вакытта, мөфти хәзрәт шул мәҗлескә нә бер мәртәбә килеп караган вә нә дә аның эшләре тугрысында истифсарат вә мөзакәрәдә булынган.

Шулай итеп, мөфти хәзрәт бөтен бу мөһим мәсьәләгә мотагалликъ булган бөтен бу хәрәкәтләрне иң вак бернәрсә сыман итеп карап килгән нәтиҗәсендә инде кичәге телеграм!

– Киңәш мәҗлесе булмаячак!

Бөтен бу мәҗлескә, хәтта милләт өчен хәят вә мәмат мәсьәләсе булган бөтен бу мәсьәләгә мөфти хәзрәтнең карашы шулай булгач, ул мәҗлеснең мөфти хәзрәт тарафыннан туктатылуында бер дә гаҗәпләнерлек эш калмый:

– Билгесез вакытка кадәр кичексен!

Мөфти хәзрәткә бу әмерне бирү бер дә читен түгел:

---

[1] Мәэюсияткә – өметсезлеккә.

[2] Тәнбиһләре – искәртүләре, кисәтүләре.

[3] «Була калса дип курыкмаган әйбер булды».

[4] Иртикаб итмичә – гөнаһына төшмичә, бу очракта карамыйча.

[5] Сахибе мәктүб – хат иясе.

[6] Игътимад итмәвендә – ышанмавында

– Кичексен дә вәссәлам!

Мөфти хәзрәтнең бу эше коры бер каприз гына булыр дип уйлаудан без ерак торамыз. Бу әмернең сәбәпләре бардыр, бәлки аңа шул әмерне бирергә кушканлардыр, без бер генә дәкыйкагә дә ул ихтималны күңелемездән чыгармыймыз, ләкин эшнең алай булучылыгы безгә җуаныч була алмый.

Мөфти хәзрәт әгәр дә ул мәҗлесне җыярга чынлап касд иткән булса, мөфти хәзрәт әгәр дә бу милли хәят вә мохат мәсьәләсенә кирәгенчә әһәмият бирә торып та, үзе игътикад иткән вә үзе кирәксенгәнчә эшләүдән гаҗиз булса, ягъни хариҗи манигълар[1] сәбәпле, милли матлабларны[2] югары даирәләргә аңлату аның кулыңдан килми торган булса, аңар, милләт вә тарих алдында үзен мәсьүлияттән[3] котылдыра торган юл ачык бит:

– Ул уңгайсыз вә мәсьүлиятле урынны башкаларга калдырып, үзе ял итәргә, ханәи сәгадәтенә[4] чигелә!

Чынлап та, мондый вакытларда мәнсаб иясен[5] халык алдында аклый торган бердәнбер юл шул гына бит.

– Әгәр миңа үзем лазем тапкан рәвешчә хәрәкәт итәргә ихтыяр икән: мин хезмәтче! Әгәр ул ихтыяр юк икән, гафу итеңез, мин бу мәсьүлиятне мәнсабта торып, өстемә зур мәсьүлият күтәреп калудан куркам!

Хәер, бу мәсьәләне озак-озак исбат итәргә нинди ихтыяҗ бар?

– Бу һәркайда шулай инде: сүзләрен үткәрә алмаган мәнсаб ияләре һәркайда отставкага чыгалар!

Мин алган хатларның берсендә, Уфа могътәбәране[6] арасында шушындый бер хәбәр чыкканлыгы язылган:

– Киңәш мәҗлесенә рөхсәт ителмәсә, мөфти Солтанов хәзрәтләре дәрхаль отставка гаризасы бирәчәк имеш!

Ләкин сахибе мәктүб үзе бу хәбәргә игътимад итми:

– Моңар охшашлы эшләр булгалап узгалады, ләкин мөфти хәзрәт бу вакыйгаларның һичберсендә дә отставкага чыгарга уйлап та карамады, – ди.

---

[1] Хариҗи манигълар – тышкы каршылыклар.
[2] Матлабларны – ихтыяҗларны.
[3] Мәсьүлияттән – җаваплылыктан.
[4] Ханәи сәгадәтенә – бәхетле (рәхәт) яшәү йортына.
[5] Мәнсаб иясен – (рәсми) урында хезмәт иткән кешене.
[6] Могътәбәране – хөрмәткә лаек кешеләре.

– Киләчәк күрсәтер, «Күллү этин кариб»[1] диюдән башка, ни әйтә аламыз?

## Бездә вә кардәшләремездә сөтрә мәсьәләсе

Кавказ мөселман гәзитәләренең соңгы номерларында мөселман хатынларының качулары (сөтрә) мәсьәләсе мөзакәрә ителмәктәдер[2]. Матбугаты мувәкъкатьның[3] бер кыйсеме[4], Кавказ мөслимәләре[5] арасында бу көндә хөкем сөрә торган сөтрәдән тарсынып, аның милли хәятыны хатын-кызны изгәнлеген, аналарны ваксыл вә тәрбиясез итеп калдырганлыгын хәтергә алып, бик сак кына җөмләләр, йомшак кына сүзләр белән сөтрәгә каршы каләм тибрәтәләр...

Шул йомшак сүзләр, шул сак җөмләләрне дә Кавказның гавам вә бер кыйсем руханилары күтәрә алмыйча, хәзер зур шау-шу кузгаттылар; сөтрәгә каршы язган кешеләр тәкфир ителүләр[6], мөнбәрләр өстендән гавамны алар өстенә өстерәләр, кызган гавам аларга һөҗүм итәргә хәзер тора.

Кавказ мөселман гәзитәләрен тәгъкыйб итеп[7] киләсең-киләсең дә, бөтен бу вакыйгалардагы серләрне вә мантыйкны аңлый алмыйча гаҗиз каласың:

– Йаһу, Кавказ мөселманлары арасында шушы кадәр зыялылар бар. Аларның балалары хөкүмәт мәктәпләрендә тулып яталар. Менә шул халык арасында әле кызышмыйча гына, җитди мәсьәләләрдә лязем булган салкын канлылыкны саклап кына, милли мәсьәләләр тугрысында моназарә[8] ачарга мөмкин түгел!

Без, өстерелгән, каны кыздырылган, надан, тәрбиясез гавамның мәсьәләне аңлый алмавына, салкын канлылык саклый алмавына гаҗәпләнмимез, әмма ... голәма аталган кешеләрнең милли мәсьәләләрне аңламавының сәбәбенә һичничек төшенә алмыймыз. Шактый күп гадәдле[9] зыялыларның халык арасына акрын-

[1] «Һәр була торган нәрсә – якында».
[2] Мөзакәрә ителмәк – тикшерелмәк.
[3] Матбугаты мувәкъкать – вакытлы матбугат.
[4] Кыйсеме – өлеше.
[5] Мөслимә – мөселман хатын-кыз.
[6] Тәкфир ителә – динсезлектә гаепләнә.
[7] Тәгъкыйб итеп – күзәтеп.
[8] Моназарә – дискуссия.
[9] Гадәдле – санлы.

лап кына булса да үз фикерен кертә алмавына соң дәрәҗә гаҗәпләнәмез.

Кавказ мөселманларының күз алдында Кавказның зыялылары, зур миллионерлары әҗнәби[1] милләт кызлары кочагына атылып торалар. Бер яктан, Кавказ мөслимәләре җәһаләт[2], тәрбиясезлек вә кояш күрмәүдән туган [...] белән инкыйразга йөз тотып, икенче яктан, мөселман ирләр христиан хатынлары белән бөтен миллиятенә вә каумиятенә ят булган гаиләләр тәшкил итеп яталар... Менә шул эшләр бөтен Кавказ голамаи руханиясенең күз алдында эшләнеп тора... Шундый миллият өчен тәһликәле[3] бер хәл җәелеп вә милләтнең әфрадын каплап яткан тәһликәле бер дәкыйкадә голәмаи рухания шуңар каршы торуның бердәнбер чарасы булган үз хатын-кызларына хәрәкәткә килергә ирек бирми, ул хатын-кызларны бикләп куярга тырыша, ул хатын-кызларга аларның урынына һөҗүм иткән әрмән, грузин, рус кызлары белән тартышырга ирек бирми!

– Йаһу, бу эш – үз тамырымызга балта чабу бит! Бу эш үз аналарымыз, сеңелләремез, хатынларымыз, кызларымыз, сөеклеләремезгә каршы сугышу; әҗнәби милләт хатын-кызы сафында торып, үз милләтемез белән сугышу бит!

Мондан җиде ел мөкаддәм мин Кавказ милләт хадимнәрендән Галимәрдан бәк Тупчыбашев хәзрәтләре белән очрашып, андан:

– Ник Кавказ зыялылары үз ватанларындан качып, дарелфөнүн тәмам иткәч, башка шәһәрләрдә калырга тырышалар? – дип сораган идем.

– Кавказ мөселманлары арасында торып, гаилә тормышы тәшкил итү мөмкин булмаганлыктан булса кирәк, – дигән җавап алдым. Гали Мәрдан бәк әфәнде шул фикерен тәэкид итеп, миңа үз башындан узган бер вакыйганы хикәят итде.

– Көнләрнең берендә миңа икенче шәһәрдә тора торган бик якын бер иптәшем кунакка килде. Квартирамның түбән катына хәзерләнгән чәй сөтрәсе янына мин, хатыным һәм кунагымыз өчәү җыелдык, бер мәҗлес кордык. Бер сәгать узмады, бер вакыт тәрәзәне чәлпәмәрә итеп ватып, безнең өстәл янына зур бер таш килеп төште. Аның артындан икенче вә өченчеләре ява башлады. Тәрәзә алдына җыелган [...]  төркемендән мине вә хатынымны

[1] Әҗнәби – чит.

[2] Җәһаләт – наданлык.

[3] Тәһликәле – куркыныч хәл, һәлакәт

иң кабахәт сүзләр белән сүккән тавышлар ишетелә иде вә мондан соң да минем хатыным шундый «нәмәхрәм» алдына чыгарга җөрьәт итсә, үтереләчәк икәне тәһдид тарикынча[1] кычкырыла иде. Гаиләсе өчен шушындый хөрриятсезлек булган бер йирдә торырга һәркем риза була алмый икән, тәгаҗҗеб ителәчәк эш түгелдер ...

Халык өчен әллә никадәр файдалы эшләр эшләгән, зур вә ихтирамлы исем казанган бер милләт хадименә шушылай мөгамәлә иткән гавамны, яңадан бу сөтрә мәсьәләсе белән кыздыру юлында голама вәгазьләр сөйләсә, [...] кыйла торган вә кыйлачак җинаятьнең мәсьүлияте, шиксез, шул голяма өстенә төшәчәктер.

Сөтрә мәсьәләсе без Казан татарлары арасында да бервакыт зур низаглы бер мәсьәлә булып тора иде. Ләкин тугры вә куәтле миллият тойгысы уяну, халыкта милли аң арту белән хәзер инде ул мәсьәлә үз-үзендән хәл ителү юлында бара. Бу мәсьәләнең иң низагълы көнләрендә халкымызның бер дәрәҗә игътидал[2] саклап вә фикер йөртеп хәрәкәт иткәнен хәтеремезгә алып, без бу акыллы халыкны яхшырак аңларга вә аның гакыллылыгы алдында ихтирам итәргә мәҗбүрмез.

## Мәгънәсез тәкълид[3]

Өченче көн, фаҗигале рәвештә вафат булган печатник Ризван Шәриповны дәфен итделәр. Дәфен мәрасимендә мөтәвәффаның[4] иптәшләре мөселман мәтбагаларындагы хадимләр хазир булганлар, алар җеназаны тантаналы сурәттә озатырга тырышканлар, иптәшләренең мәете өстенә чәчәкләрдән венок та куйганлар.

Үз араларындан вафат иткән бер иптәшләрен хөрмәтләп дәфен иткән өчен мәтбага эшчеләренә тәхсиндән[5] башка сүз әйтергә тугры килмидер.

Мин ул тугрыда язарга теләмим. Мин, фәкать, шушы мөнәсәбәт белән, соңгы вакытларда гадәткә кертелеп бара торган «чәчәк кую» мәсьәләсенә даир генә берничә сүз әйтеп китмәкче булам.

---

[1] Тәһдид тарикынча – куркыту юлы белән.
[2] Игътидал – уртачалык.
[3] Тәкълид – ияру.
[4] Мөтәваффаның – вафат булганның.
[5] Тәһсиннән – хуплаудан, мактаудан.

Менә инде икенче ел, мәрхүм Хөсәен Ямашевның вафатыннан бирле, яшьләр җеназа өстенә чәчәк кую рәсемен[1] гадәткә әйләндереп баралар: Тукайга, Исхак Бичуринга чәчәкләр куелды...

Үлгәнләрне ихтирам итүнең яхшылыгы, чәчәкләрнең матурлыгы үзләрендән генә каралганда шөбһә ителмәслек ачык нәрсәләр, ләкин шулар белән бергә, татар тормышына кертелә башлаган бу бидгатьнең нинди максад белән кертелә икәнен мин бер дә аңлый алмыйм.

Милләтемезнең тормышына мөнасыйб булмаган[2], халкымызның үлем һәм үлекләр тугрысындагы аң вә игътикадларына[3] муаффәкыять итмәгән мондый бидгатьне гадәткә кертүне мин соң дәрәҗәдә мәгънәсез саныйм. Яурупалылардан, хосусан, руслардан безгә шактый гореф вә гадәтләр җогалар. Боларның кайсыларын без үземез теләп, кирәксенеп җоктырамыз, кайсыларын безнең теләвемезгә каршы буларак, кәрһән[4] җогалар. Кәрһән җоккан гадәтләрнең безнең өчен файдалы вә зарарлы булулары тугрысында сөйләп торуда мәгънә булмаса да, үз ихтыярымыз белән җоктыра торган нәрсәләрне без уйлап вә аңлап җоктырырга тиешле икәнен дә хәтердән чыгармаска ляземдер. Менә бу чәчәк кую мәсьәләсен алганда, занымча, бу бидгать безнең тормышка һич мәгънәсезгә сукыр тәкълид буларак кертеләдер.

Милләтемезнең ислам тарафыннан тәлкыйн ителгән[5] үлемгә карашы – чын кайгылы карашдыр. Чәчәкләр, дөнья зиннәтләре бу карашка муаффәкать итми генә түгел, бәлки капма-каршы килә. Үлемгә серле, тәрәддедле[6] вә тәүсыйф итәлмәслек[7] кайгылы караш бездән мәетләремез өстендә чәчәкләр куйдыртырга түгел, бәлки ул тәәссефле эшләрне мөмкин кадәр садә эшләтергә тиештер. Безнең үлемгә каршы булган милли карашымызга фәкать гыйбадәт рәвеше; зур моңлы гыйбадәт рәвеше генә муаффәкъ төшә аладыр. Безнең җеназа мәрасимендә шул зур, моңлы гадәт халисен[8] җуарлык зиннәтләр бөтенләй урынсызлар, мәгънәсез тәкълидтән гыйбарәтләрдер.

---

[1] Рәсемен – йоласын.
[2] Мөнасыйб булмаган – туры килмәгән.
[3] Игътикадларына – ышануларына.
[4] Кәрһән – көчләнеп, теләмичә, ихтыярсыз.
[5] Тәлкыйн ителгән – инандырылган.
[6] Тәрәддедле – шикле,
[7] Тәүсыйф итәлмәслек – сыйфатлап булмаслык.
[1] Халисен – эчкерсезлеген, сафлыгын.

Яурупаларның хәятемез өчен һич кирәге булмаган гадәтләрне тәкълид иткәндә, минемчә, иң әүвәл ул гадәтнең милли рух белән тәнасиб итә аламы, юкмы икәнен үлчәргә вә шундан соң гына аны алырга мөмкиндер. Шулай булмаганда, ул тәкълид сукыр вә мәгънәсез тәкълид булып чыгадыр.

## Наилбәк һәм иптәше белән мөсахәбә

Төркия хөкүмәте тарафындан профессор Катанов көтебханәсен карарга йибәрелгән Наилбәк әфәнденең Русия татарлары арасында әүвәл мәртәбә булуы икән.

Шимал төрекләре арасында күренгән әсаре тәрәккъкый[1], сәүдәгәрлек һәм гомуми хәятның госманлы төрекләрнекенә караганда күп рухлы булуы Босфор буендан килгән бу кардәшемезгә бик зур тәэсир иткән. Гарби Яурупадагы мәгъмүр[2] мәмләкәтләрне күргән кеше булуына карамыйча, Наилбәк Русия мәмләкәтенең мәгъмүрлегендә дикъкать итәрлек дәрәҗәдә күрә. Минем:

– Русия мәмләкәтен ничек табдыңыз? – дигән сөалемә ул:

– Русиянең мәгъмүрияте дикъкатьне җәлеп итәрлек, мин юлда каранып килдем, бер карыш булсын эшләнмәгән йир күрмәдем. Крестьянларның күренешләре, өст-башлары аларның тук булдыкча рәхәт яшәдекләрен күрсәтеп тора. Бу хәл безнең Анатолия белән чагышдырганда бигрәк күзгә бәреләә. Анатолиядә әле соңгы елларга кадәр йирнең кырыкдан бере эшләнгән вә калганы ташланган хәлдә ята иде. Шуңар күрә безнең Анатолия крестьяннары арасында өсте-башы ертыксыз кешеләрне бик сирәк күрергә тугры киләдер, – дип җавап бирә.

Наилбәк әфәнденең юлдашы – асылда, шимал төрке булып, яшьлегендән Истанбулда урнашкан Гомәр әфәндедер.

Болар һәр икесе Казанда татарча спектакльдә һәм Шәрекъ клубы залында укылган лекциядә хазир булганлар. Наилбәк кирәк спектакльдән, кирәк лекциядән бик яхшы тәэсир алган, хосусән, боларда хатын-кызларыбызның сәрбәст[3] йөрүләре аңар зур тәэсир калдырган,

– Шимал төрек хатынының тәрбияле, гыйффәт вә нәзакәтле рәвештә гомуми хәятка катышуын мин зур шатлык вә ифтихар

[1] Әсаре тәрәккъкый – тәрәккъкый күренешләре, галәмәтләре.
[2] Мәгъмүр – төзек, цивилизацияле.
[3] Сәрбәст – азат, иректле.

белән[1] күрдем. Тәрәкъкыеңез шаян мәмнүният[2]; безем госманлыларга гомуми хәятларын сезнеке дәрәҗәсенә йиткерү өчен «Дәһа кач[3] сәнәләр ляземдер», – дип, Наилбәк үзләренең кечек бөрадәрләре – шимал төрекләре өчен шатлык изһар итә[4].

Утыз елдан артык Истанбулда торып, Русия төрекләре арасындагы тарихи тәрәкъкыйне биззат тәгъкыйб итеп[5] килмәгән Гомәр әфәнде дә шимал төрекләренең тәрәкъкыйләрен тәэмин ителгән вә җәнүб төрекләренекенә караганда күп өмидле күрә.

Босфор буендан килгән төрекләр Русия мөселманларының Төркия вә Русия сәүдәсенә васита[6] булырга тиешлеге фикерен гарыз итәдер[7].

– Төркиянең бөтен сәүдәсе грек вә әрмәнләр кулында. Төрек милләтенең акчасына баеган бу сәүдәгәрләр – ватанның иң сәдакатьсез[8] балалары вә төрекләрне иң дошман күрә торган элементлардыр. Төркияле греклар төрек милләтендән җыеп алган акчаларына Юнанстанга сугыш кимәләре хәзерләп бирәләр. Менә шул эш, табигый уларак, төрекләрне ул сәүдәгәрләрдән нәрсә алмаска вә мөмкин вакытта аларга акча бирмәскә тырышырга мәҗбүр итәдер. Хәзерге вакыт Русия мөселманлары өчен Төркиядә сәүдә ачарга иң муаффәкъ[9] вакытдыр ки, тырышканда, шимал төрекләре Русия вә Төркия сәүдәсендә бик яхшы васита булырлар иде, диләр.

Гомәр әфәнде хосусый сурәттә балык вә икра сәүдәләренә дикъкатьне җәлеп итә. Бу нәрсәләрне төрекләр бик яратып истигъмал итәләр икән. Ләкин греклар кулына кереп беткән бу нәрсәләр бер вакытта да төрекләргә саф килешчә сатылмыйча, төрле кушымталар белән бозылып вә хакыйкый бәһәсендән өч-дүрт мәртәбә кыйммәт бәһага ыслана икән.

Әстерхан шикелле йирләрдә балык вә икра сәүдәсе белән шөгыльләнә торган мөселманлар бардыр. Гомәр әфәнденең сүзләренә болар дикъкать итсәләр, үзләре өчен яхшы бер базар казанулары мөмкиндер.

---

[1] Ифтихар белән – горурлык белән
[2] Шаян мәмнүният – канәгатьләнерлек.
[3] Дәһа кач – әле күп.
[4] Изһар итә – белдерә.
[5] Биззат тәгъкыйб итеп – турыдан-туры үзе
[6] Васита – арадашчы.
[7] Гарыз итәдер – тәкъдим итәләр, әйтәләр.
[8] Сәдакатьсез – тугрылыклы булмаган
[9] Муаффәкъ – уңайлы, җайлы.

Соңгы елларда Русия мөселманлары арасында күренгән интибаһ[1] милли төрек әфкяре гомумиясендә Русия мәдәниятына каршы зур бер ихтирам тудырган.

Кунаклар төрекләр арасында балаларын Русия мөкятибе галиясенә[2] йибәрергә теләүчеләрнең күбәйгәнлеген сөйлиләр.

Гомәр әфәнде үзенең бу ел Истанбулда франсуз телендә тәдрис ителә[3] торган урта тиҗарәт мәктәбен тәмам итә торган угылын Русия мөкятибе галиясендән берәрсенә йибәрергә теләгәнлеген бәян итә: Русия мөселманлары арасында интибаһны биззат күрү аның бу касдын[4] тагы да куәтләндергән.

* * *

Безнең белән мөзакәрә иткәндә, әле кунаклар Катанов әфәнденең көтебханәсен тәмамән карап чыкмаганлар иде. Шулай да алар безгә бу хакта мәгълүмат бирделәр. Көтебханәнең бер кыйсеме генә Төркиядә Укаф нәзарәте тарафындан тәэсис ителәчәк көтебханә өчен әһәмиятле булачак икән. Көтебханәдәге Истанбулда табыгъ ителгән китаплар вә кайбер китаплардан булган мөтәгаддид[5] нөсхәләр (мәсәлән, төрле шәрекъ телләрендәге Инҗилләрдән бишәр-унар нөсхә) төрекләр өчен кирәксез нәрсәләр булганлыктан, Истанбулга ташып йөрерлек түгелләр икән.

Төрекләр, китаплар караганда, көтебханәнең тәртипсезлегендән, фиһристсезлегендән[6] күп мәшәкать чиккәнлекләрен сөйлиләр.

Төркиянең Укаф нәзарәте исламга мөтәгалликъ[7] әсәрне бер көтебханәгә җыярга карар биргәч, хәзер Франция, Германия һәм Англиягә дә китаплар карарга һәйәтләр йибәргән вә ул мәмләкәтләрдән дә исламга мөтәгалликъ төрле әсәрне җыярга тырышачак икән.

Шәһәремезнең кунаклары шушы көннәрдә Казандан Петербургка сәфәр итәчәкләр вә анда да китаплар тәфтиш итәчәкләрдер[8].

---

[1] Интибаһ – уяну
[2] Мөкятибе галиясенә – югары уку йортларына.
[3] Тәдрис ителә – дәрес бирелә, укытыла.
[4] Касдын –теләген.
[5] Мөтәгаддид – күп санлы.
[6] Фиһристсезлегендән – каталог булмаудан.
[7] Мөтәгалликъ – бәйле, караган.
[8] Тәфтиш итәчәкләрдер – эзләячәкләр.

Безгә анларның мәсъүлиятле хезмәтләренә муаффәкыять[1] теләргә кала.

**Беренче шәүвәл, шинбә көн**

Җомга көн көндезге сәгать өчдән башлап көсүф, ягъни кояш тотылу булачагыннан бу елгы ай мәсьәләсе хосусый сурәтдә катгыять кәсеб итәдер. Мәгълүм ки, айның тууы кояш белән айның иҗтимагъларындан[2] башланадыр. Иҗтимаг ноктасындан узу белән яңа ай башлана. Бу бер фәнни хакыйкать ки, бөтен дөньяның һәм борынгы һәм бу көнге әһле һәйәте моны шулай игътикад итә[3] вә шулай хисаб итә.

Бу көн, ягъни 8 нче август, җомга көн сәгать өчдән бишкә кадәр көсуф булачагыннан сәгать бишдән соң инде айның кояш белән иҗтимаг ноктасындан узганлыгы, риязият катгыяте дәрәҗәсендәге бер катгыять белән сабит[4] буладыр ки, бөтен дөньяның әһле һәйәте 9 нчы август, шинбә көнне яңа айның, ягъни шәүвәлнең беренче көне саныйдыр. Җомга көннең кояшы баеганчук теләсә нинди кеше, теләсә нинди бер обсерваториядән караб, шәүвәл аеның туган икәнен үз күзе белән күрә ала вә шунлыкдан «Әшһәд» ләфазы белән генә түгел, бәлки Аллаһ исеме белән ант итеп, айның туганлыгыннан шәһадәт бирә аладыр. Әгәр мөмкин булып бөтен төрек – вә татар милләтен җомга көн сәгать алтыда дөньяның обсерваторияләрендә җыеп да, боларга кораллар белән айның туганлыгын мөшаһәдә[5] итдерелсә, табигый, бөтен төрек-татар милләте Аллаһ исеме белән ант итеп, яңа айның туганлыгына шәһадәт бирәчәкдер.

Шәүвәл аеның әүвәл көне шинбә көн булучылыгы шушы дәрәҗәдә катгыятькә ирешкәч дә, Казан имамларының бер кыйсеме җаһиләнә тәгассыбда[6] дәвам итеп, гаедне якшәнбә көн укырга, ягъни шәүвәлнең беренче көнендә халыкга руза тотдырырга карар бирәләр. Шәүвәлнең беренче көнендә руза тоту шәригать

---

[1] Муаффәкыять – уңыш.

[2] Иҗтимагъларындан – бер урынга килеп туплануларыннан (җирдән шулай булып күренә).

[3] Игътикад – ышану, инану.

[4] Сабит – кузгалмаучы, бер урында торучы.

[5] Мөшаһәдә – күрү.

[6] Тәгассыбда – фанатизмда (кирелектә).

каршында хәрам эшдер. Казан имамнарының бер кыйсеме шул хәрам эшне бөтен Казан мөселманларындан эшләтмәкче булалар.

Гаҗәбә, аларны мондый зур дини бер җинаятькә иртикяб[1] итдерә торган нәрсә ни? Нинди дәлилгә истинада алар сөбүти катгый булган бер нәрсәгә каршы барырга җөрьәт итәләр.

Кояш вә айның хәрәкәтләре сөннәте Аллаһ буларак дөнья яратылгандан бирле инде гаҗәеб бер тәртип, хисабе катгыяте дәрәҗәсендә катгый бер нәүбәт белән дәвам итеп киләдер. Сөннәте Аллаһ да бер тәбдил[2] булмаган моддәтдә бу тәртибнең алмашыну вә тәхлиф итү[3] ихтималы катгыян юкдыр. Шулай булгач, Казан имамнарының бәгъзесен бу тәртибне икърар итмәскә[4] нәрсә батырчылык итәдер? – Заһирпәрәстлек! Динне вә пәйгамбәр сүзләрен мәгънәдән бигрәк ләфыздә дип игътикад итү? Динне катгыяте аб-ачык булган фәнни хакыйкатьләргә хилаф була[5] ала дип уйлау шикелле фәхеш вә динне тәхкыйрь итә торган игътикад!

Менә нәрсәләр аларны мондый эшкә батырчылык итдерә.

Без аларның дәлилләренә бер мәртәбә күз салыйк:

– Ай үзенең тууыннан 12 сәгать үтмичә күренә алмый, шулай булгач, җомга көн горубе шәмскә[6] кадәр ай күренмәскә тиеш; филвакыйг[7] ай туган булса да, күренмәгәч, шәригать аны игътибарга алмый, бәс шинбә көнне (вакыйгда шәүвәл ае туганлыгы катгый булса да) руза тотамыз! – диләр алар. Бу көндә дөньяның нокталарында айның туганлыгын һәркемнең күзенә күрсәтә алырлык мөкәммәл[8] обсерваторияләр тулып яткан бер гасырда «Ай үзенең тууыннан 12 сәгать үтмичә күренә алмый» дип дәгъва итү, азында сәдадиллек, бөтен дөнья мәдәниятен, бөтен фәнни вә хәтта мөшаһәдне инкяр итүдер. Фараз итеңез, бу көн сәгать йидедә обсерваториядән карап айның туганлыгын үз күзләре белән күргән йөз мөселман айның туганлыгыннан, бөтен шәһадәт шартларын үтәп, шәһадәт бирделәр. Бу имамлар шул шәһадәтне кабул итәчәкләрме,

---

[1] Иртикяб – начар һәм тыелган эшне эшләү.

[2] Тәбдил – үзгәртү, алмаштыру, икенче хәлгә кертү.

[3] Тәхлиф итү – берсе артыннан икенчесен булдыру, бәрәр нәрсәне үзеңнән соң калдыру.

[4] Икърар итү – урнаштыру.

[5] Хилаф булу – каршы булу.

[6] Горубе шәмс – кояш баю, бату.

[7] Филвакыйг – нигездә, асылда, дөрестән дә.

[8] Мөкәммәл – тулыландырылган, камилләшкән, җитешкән.

яхуд аларны, сөбүти[1] катгый булган бер эшдә шәһадәт биргән йөз мөселманны тәгъзиб итеп[2], аларның шәһадәтләрен рәд итәчәкләрме? Әгәр шушы соңгы шәкъне[3] ихтияр итсәләр, аны нинди дәлил белән эшләячәкләр? Ике йирдә ике дүрт була дип шәһадәт бирә торган йөз мөселманның шәһадәтен рәд итү[4] белән бәрабәр булган бу эшдән алар фән, хакыйкать һәм бөтен дөнья алдында ничек оялмаяклар?

Бу әфәнделәр шәригать риваятенә игътибар итә диләр. Пәйгамбәрләремез заманында бу көнге шикелле мөкәммәл обсерваторияләрнең юклыгы сәбәбле, ул рөэять[5] фәкать күз белән була иде. Бу көн инде рөэять икенче тарикълар[6] белән һәм мөмкин, һәм асат, һәм катгыйрак булды. Шулай булгач, бу рөэятьне инкяр итәргә бу әфәнделәр ничек батырчылык итә алалар? Бу җөзафи эш шәригатьне соң дәрәҗәдә заһирпәрәстлекдә гаепләүдән башка нәрсә түгел бит!

Мондан ярты гасырлар мөкаддәм үк инде голәмаи исламиядән Әбү әл-Насыйр әл-Курсави хәзрәтләре бу ап-ачык хакыйкатьне мөтәгассыйбләргә сөйләп вә исбат итеп киткән. Шиһаб әл-Мәрҗани хәзрәтләре һәм вакытның фән белән мөнәсәбәтсез голяма исемдәгеләре белән хисапны игътибар итдерү юлында әллә никадәр моназарә иткән. Ләкин ул вакытларда әле татар голямасы арасында аларны аңларлык башкалар йә булмаган, йә аз булган. Бу көн инде милләтдә азмы-күпме фәнгә ышану, катгый нәрсәләргә инкяр итмәү табигате туа башламаг көндә дә бу хакыйкатьне инкяр итүчеләрнең булучылыгы бер милли хурлыкдан башка нәрсә түгелдер.

Имеш дә «шәргый ай» сөннәте Аллаһ белән туу вакыты катгый забыт ителгән[7] хакыйкый айдан унике сәгать соң башлана имеш!

Бу сүз бит «шәргый кояш» хакыйкый кояшдан 12 сәгать туа дигән сүз шикеллүк җөзафи вә көлке сүздер!

---

[1] Сөбүти – чынлык, ышанычлылык.
[2] Тәгъзиб итү – газап күрсәтү, газаплау.
[3] Шәкъ – ярык, тишек.
[4] Рәд итү – кире кагу.
[5] Рөэять – яңа айны күрү.
[6] Тарикъ – юл, тоткан юл.
[7] Забыт ителү – язып кую.

Бу сүз бик шәригать фәнни хакыйкатьләрне игътибар итми, ул риязыятькә дә игътибар итмәс дәрәҗәдә бер нәрсә дигән сүз бит!

Шәригать йиңеллек өчен күз белән күренүне дәлил итеп санаса, аның корал белән күренүне, яхуд катгый әсасларга мөстәнид[1] хисап белән белүне билтарикъ әл-әвәли дәлил итеп игътибар итәчәге бәдаһәт дәрәҗәсендә ачык бит.

Безнең мәмнүниятемезгә каршы Уфа идарәи руханиясе быел бу фәнни ноктаны игътибарга алып, гаедне шинбә көн укырга карар бирде вә шулайтеп катгый мәсьәләдә фәнни вә катгый бер ноктаи нәзардә торды вә моның белән бөтен Русия мөселманларына тугры вә ачык бер юл күрсәтте.

Фәнни хакыйкатьләрне аңлаудан түбән тора торган бер такым имамларны үз башларына хәрәкәт итүдән тыю өчен мондан соң идарәи руханиямез бер чара күрсә, юк ихтиляфлар, көлке игътикадларның юлын кисүдә зур ярдәм иткән булыр иде.

Без идарәи руханиямыздан шуны көтәмез!

*Ф. Әмирхан: Бу имамларның иттифагына кадәр язылган иде.*

## «Йолдыз»га җавап

«Йолдыз» гәзитәсе, «Гомуми эшләргә ничек карыйлар?» дигән бер мәкалә язып, «Кояш»ның мәҗрухларга[2] иганә мәсьәләсендә бер мәсләктән икенче мәсләккә күчеп йөрүен дәгъва итә вә шул мөнәсәбәт белән «Кояш» исеменә сүгенеп алудан үз-үзен тыя алмый.

«Йолдыз»ның бу мәкаләсендә, башка мәкаләләрендә булгалаган шикелле, минем исемем дә чәйнәлеп йөртелгәнлектән, мин үз тарафымдан бу тугрыда бер изах[3] бирергә мәҗбүр булам.

«Йолдыз»да мөселман комитеты ясалу хакында игълан чыккач да, «Кояш» үз тарафыннан бу тәшәббескә[4] ярдәм рәвешендә баш мәкалә язды. Бу вакытта әле «Кояш» идарәсенә бу тәшәббеснең әһале белән киңәш итешми-нитми генә, коры кул белән, күре-

[1] Мөстәнид – таянычлы.
[2] Мәҗрухларга – яралыларга.
[3] Изах – аңлатма.
[4] Тәшәббескә – инициативага.

неп калу касды[1] белән генә ясалган тәшәббес икәнлеге мәгълүм түгел иде.

Шул көннүк «Кояш» идарәсе, үзенең мөхбирен йөртеп, мондый эшләрдә файдалы булулары өмид ителгән Казан могътәбарәнләрендән бу эшнең асылын тикшертде. Бу тикшерүләр нәтиҗәсе буларак, ул затларның бу комитет хакында бер нәрсә дә белмәгәнлекләрен һәм аптырабрак калганлыкларын аңлагач, инде бу тәшәббеснең асылы бер тәшәббес түгел икәнен хатергә алып, минем үз имзам астында язган «Бергәме, аерыммы?» гонванлы мәкаләмә «Кояш» урын бирде. Моның шулай булучылыгы табигый дә иде. Чөнки Казанның могътәбарәны читтә калдырылып, күренеп калу максадын тәгъкыйб итүче[2] берәр кешеләр тарафыннан гына башланган мондый эшнең гомуми Казан мөселманларын руслар алдында оятлы итеп калдыру ихтималы бик якын иде. Менә шуңар күрә «Кояш» минем мәкаләмә урын бирде. Мин исә, фикеремнең гаммә тарафыннан кабул ителү-ителмәү мәсьәләсенә бер дә игътибар итмичә генә, бу көнгә кадәр үземнең хосусый карашымда сәбат итәм[3]. Мин әле бу көндә дә гомуми Русия мөселманлары өчен зур бер мөәссәсә вөҗүдкә китерергә мөмкин булмаса, руслар белән бергә эш күрергә тиеш, вак тәшәббесләрнең әһәмиятләре юк дип ышанам. Бу караш – хосусый минем карашым. «Кояш» һәйәте тәхририясенең күпчелеге исә, беркадәр башкаракioктаи нәзар тотып, беркадәр эш күрсәтүе ышанычлы булганда, аерым эш күрүнең файдасыз булмавын уйлый. «Кояш» исә һәйьәте тәхририясенең күпчелеге ноктаи нәзары булган шул карашны тәгъкыйб итеп килә. Мәсьәлә башлангандан бирле мәсләкендән һичбер төрле годул иткәне[4] юк. «Йолдыз»ның минем хосусый фикерем белән «Кояш»ның тәгъкыйб итә торган юлын бутап йөртүе, ябылып-ябылмый ясаган яңлыштыру – укучыларын хатага төшерүдер. Мондый олуг мәсьәлә өстендә, мондый олуг көнләрдә мондый ваклыкларга җавап биреп торырга мәҗбүр булуым өчен тәэссефемне әйтми уза алмыйм.

---

[1] Касды – теләге.
[2] Тәгъкыйб итүче – күзәтүче.
[3] Сәбат итәм – нык торам.
[4] Годул иткәне – чигенгәне.

## Олуг милләтче тугрысында кечкенә бер хатирә

Гаспринский хәзрәтләрен мин мондан сикез ел мөкаддәм Петербургта мөселман съезды вакытында күргән идем. Минем хәтеремдә ул менә ничек булып калган: уртачадан бераз биегрәк буйлы, чандыр гына гәүдәле, йөргәндә вә утырганда буен бераз алгарак бөкрәебрәк йөри вә утыра торган, шактый озын, чандыр муенлы, гасабилек күрсәтер дәрәҗәдә чандыр, озынчарак йөзле, сакалсыз, зур, чал мыеклы, кыска гына агарган чәчле, киңрәк кенә, бик беленеп тора торган кашлы, йомшак, ләкин ниһаять дәрәҗәдә зәкявәтле[1] карый торган матур каргылт күзле бер зат. Моның өстенә, аның карлыгансыманрак бер тавыш белән саф төрек аһәңдәге сөйләшен кушарга кирәк. Аның тавышындагы бу карлыгансыманлык, бәлки, Петроград һавасының вакытлы тәэсирендән килгән булгандыр. Ләкин нидән булса булсын, минем хатирәмдәге Гаспринский хәзрәтләре сурәтендән бу тавышы да бер җөзә.

Ул еллар минем иске караш вә иске игътикадларымның[2] җимерелгән, хәяткә карашымда бер [...] вөҗдан хасил булган еллар булуына карамыйча, Гаспринскийны күрү миңа тирән бер тәэсир калдырган иде: үземне тудырган гаиләдә вә үзем укый торган яңа китапларда исеменең зур ихтирам белән зикер ителгәнен ишетеп вә күреп килгәнем бу затны үзем күзем белән күрә алу миңа бер яктан төш сыман вә бер яктан да кәефле тоела иде:

– Имам әбү Хәнифә, имам Бохари... Карл Маркс шикелле «китаптан укып кына» беленә торган кешеләрне күз белән күрү шикелле иде.

Бу көнге шикелле хәтеремдә, бабаның съезд бюросындагы утырышы: кечерәк бер нумир (хәтеремдә яңлыш калмаган булса, бабаның үз нумиры) 12–15 кешенең утырышындан тыгызлык, нумир түрендәге хәтфә тышлы диванның югары башына баба утыра (түбән башында дамелла Галимҗан әл-Баруди). Ул халык сөйләгәнне тыңлый, шау-шу басылгач кына, кыска гына берничә сүз әйтә, шул сүзләр белән үзенә кадәр сөйләп уздырганларның фикерләрендән бер хасыйл ясый да аның өстенә катгый гына бер тарызда үз фикерен бәян итә. Карар бик күп вакытта шул фи-

---

[1] Зәкявәтле – зирәк.

[2] Игътикадларымның – ышануларымның.

кер тирәсенә оеша. Бу мәҗлесләрдә мин аның һичбер озын нотык сөйләгәнен хәтерли алмыйм. Ул әйтә торган сүзләрен бик садә генә бер тарызда, кыска гына итеп әйтә иде. Ул партия низагълары белән чыккан мөназарәләрдә үзенең кызу табигатенә, чандыр йөзе күрсәтә торган гасабилигенә капма-каршы буларак, гаҗәп бер салкын канлылык саклый ала, вә бу эш аңар бик килешә, аның ул низагълардан өстә торганлыгын ачык күрсәтә иде. Шундый бер вакыйга хәтеремдә калган: без съездга оппозициядә тора торган берничә яшь җилбәзәкләр (шулар арасында мин дә) бюро мәҗлесләренең бер-икесендә үземезнең ноктаи нәзарларны[1] әйтеп калырга теләдек. Минем иптәшләрдән берсе, бик озын вә ачы бер нотык сөйләп, съездны демократиягә каршы ясалган бер нәрсә булуда гаепләде. Аның ачы сүзләре бөтен мәҗлестә безгә каршы протест тудырганда, фәкать өч кеше: баба, дамелла Галимҗан һәм Галимәрдән бәк Тупчыбашев салкын канлылык саклап калдылар, баба исә, хатибка сөйләп бетерергә ихтыяр бирүнең тиешлеген изһар итде[2]. Безнең хатибымыз үзенең озын вә шактый тәртипсез ачы сүзләр белән вә, шул җөмләдән, хосусән, бабаның үзенә дә тәүҗиһ ителгән[3] ихтирамсызлыклар белән тулы нотыгын тәмам иткәч инде, Гаспринский, тәхминән[4], шушы маилдә җавап бирде:

– Углым, сез яшьсез, тәҗрибәсезсез, шунлыкдан кирәгендән артык каты гыйбарәләр истигъмаль итәсез[5]... Сезнең кеби кызу рухлы яшьләремез милләткә хезмәт итеп, аның мәдәни дәрәҗәсен үстерсәләр, ул вакытта бездә сыйнфый ихтиляфлар[6] тугрысында сөйләшермез, фикер йөртешермез. Мәдәнияте юк бер милләтнең промышленносте була алмый, мадам ки, ул юк, сыйнфый низагъларга да иртә. Безнең бу көнге вазифамыз әле мәдәни үсүдән вә шуңар юллар хәзерләүдән генә гыйбарәт... Андан соңгысын бездән соңгылар карарлар...

Милләт мәдәниятенең бабасы агызындан бу сүзләр һәм ышанычлы, һәм олуг яңгырыйлар иде.

---

[1] Ноктаи нәзарларны – карашларны.
[2] Изһар итте – белдерде.
[3] Тәүҗиһ ителгән – юнәлтелгән.
[4] Тәхминән – якынча.
[5] Истигъмаль итәсез – кулланасыз.
[6] Ихтиляфлар – каршылыклар.

**Хурлык сәнәде**[1]

12 нче июльдә Нижний шәһәрендә минем адреска язылып, почта ящигына салынган бер хат эчендән кызыклы бер сәнәд килеп чыкты. Бу сәнәд белән бергә йибәрелгән, Урбар карьялек Ибраһим әфәнде Вәлиев тарафындан имзаланган мәктүб бу сәнәдкә беркадәр изах[2] да бирә. Бу сәнәд вә аның янындагы мәктүб мәшһүр Ишми ишанның донослары тугрысында булганлыкдан, мин аларның һәр икесен матбугатка чыгарам.

Ибраһим әфәнде яза:

«Мин кызыклы бер мәктүб күндереп, шуның матбугатка чыгарылуын сездән үтенәм. Мин йибәрә торган бу хат Әтнә Әхмәтҗан дигән кешедән Малмыжда русско-татарский училище дин хәлфәсе булган Закир Йосыфовка язылган.

Хатта исемнәре зикер ителә[3] торган Мотыйгулла хәлфә һәм Зәйнулла дигән кеше вә Әтнә Әхмәджан үзе – Түнтәр Ишминең якын мөридләредер.

Бу хат, Малмыж тирәсендәге өч сыйныфлы мәктәптә тәртип белән укыта торган хәзрәтнең өстендән биреләчәк доноска хәзерлек күрү тугрысында язылгандыр».

Ибраһим әфәнде тарафындан йибәрелгән «Әхмәджан» имзасы сәнәд чирек табак кәгадьгә иске ысул белән, тарихы куелмыйча гына язылган. Язылу рәвеше вә гыйбарә тәртибе һәм һичбер төрле вәкыф[4] галәмәтләре куелмау бу хатның «подлинный» бер хат булучылыгын тәэмин итәр дәрәҗәдәдер. Милли мәктәпләр өстендән ясала торган донослар хакында хәясез[5] бер ачыклык, оятсызлыкның чигенә йиткән бер тәкәллефсезлек белән язылган бу хатны Ишми партиясенең хурлык сәнәде дип атарга бик мөмкиндер.

Менә ул мәктүб гайнән[6]:

Бисмилләһи әлә галә вә бә әлә фәттах бисмилләһи әл-әглә вә биһи әл-ифтитәх.

---

[1] Сәнәде – документы.
[2] Изах – аңлатма.
[3] Зикер ителә – искә алына.
[4] Вәкыф – пауза (укыганда тын алу).
[5] Хәясез – оятсыз.
[6] Гайнән – үзгәртелмәгән рәвешендә.

Сезки газиз вә мөкәррәм[1] мулла Закир хәзрәткә сәлам, сөннәтел-ислам әһдә вә тәблигъ әйләдүкүм бәгъдендә[2] хәер дога үтендек, ма бәгыд[3] бу көн, ягъни якшәнбә көн Түнтәрдә хәзрәт хозурында булдым, сезнең миңа әманәт сүзеңезне сөйләп, ике игъламнамә[4] язып, берсе жандармский помощникка вә берсе инспектор хәзрәтләре исеменә әл-имза вә мөһер кыйд кыйлдырып сезеңә җибәрәмен шушы хат берлән, үзенең тиешле урынга бирерсен, ләкин истә тот: игъламнарның икесенең дә юкары йулын ачык урынга, икенчеме йа өченчеме [...] белмәдем, озынның яз урысча, менә (двухъ-трехъ) башка урынлары ярардай күк тиде. Әгәр дә башка формада язылырга тиешле булса, формасын язып кул куярга кайтарырсыз, вәс-сәлам Мотыйгулла хәлфәңә, сәлам вә Зәйнулла әфәндеңә һәм сәлам диясез инспекторыңа хәзрәтдән һәм үзеңезеңә сәлам вә хәер дога.

Әхмәджан.

Доносчылар фиркасының бу доносларындан нинди нәтиҗә чыкканлыгын белүчеләр булып идарәгә хәбәр итсәләр, Ишмиләр «милли хезмәтенең» мәңгелек хатирәсе буларак, без дә укучыларымызга игълам итәр идек.

### Хәррәфуль кәлям ган мәвазыйгиһи[5]

«Вакыт» гәзитәсенең мөфтилек мәсьләсендә тоткан «мәзахчылык» юлы, «Кояш», «Тормыш» һәм «Йолдыз» гәзитәләренең һәммәсендә бертөрле тәкъдир ителеп, вакытында күрсәтелеп уздырылган иде.

Мөфти тәгаен ителеп беткәч, дахилия назыйре[6] хәзрәтләре дигәнчә эш узгач, «Вакыт» гәзитәсе Ф.К. әфәнде тарафындан имзаланган бер мәкалә белән «Кояш», «Тормыш» һәм «Йолдыз» гәзитәләренең бу карашларына нәсыйханә вә вәгазәнә бер газамәт[7] белән җавап бирә.

---

[1] Мөкәррәм – хөрмәтле.

[2] Бәгъдендә – соңында.

[3] Ма бәгыд – соңгысы.

[4] Игъламнамә – белдермә.

[5] Алар сүзләрнең мәгънәсен бозып, үзләренчә тәгъбирлиләр». Коръәннең «Ниса» сүрәсенең 46 нчы аяте.

[6] Дахилия назыйре – эчке эшләр министры.

[7] Газамәт – горурлык.

Укучыда көлү тойгысы тудыруга тиешле бер газамәт белән язылган бу мәкаләнең башка рәфикъларымыз хиссасенә[1] төшкән кадәрлесенә кагылмыйча гына, мин «Кояш»тагы үз мәкаләм хиссасына төшкән кадәрлесенә берничә сүз әйтеп китәргә үземне мәҗбүр күрәм.

Гаед номерындагы мәкаләмдә мин «Вакыт»ның мөфтилек мәсьәләсендә тоткан юлы хакында түбәндәге сүзләрне әйткән идем: «Вакыт», ни өчендер, «угодно было» иң җитди милли мәсьәләләрдән берсен үзенең укучылары күзе алдында әһәмияттән төшерергә вә, шулай итеп, әфкяре гомумия[2] белә шаярырга – гаять урынлы вә гаять вакытлы эшдер... бәлки!

Ләкин шул кадәрлесе бар ганганәи мәдәниясе[3] булган бер милләтнең әфкяре гомумиясе моны тәхәммел итә[4] алмас, җитди вә вә милли бер мәсьәләгә мондый төс бирүчене мәзахчылык итә дип түгел, клоунлык итә дип каршы алыр иде».

Минем бу сүзләремә Ф.К. әфәнде менә ничек дип мокабәлә итә[5]: «Инде «Кояш» рәфикымызга килгәндә, аның бәйрәм номерында Фатих әфәнде Әмирханов, «Ганганәсезлек хурлыгы» гонванлы озын бер мәкалә язып, «Вакыт»та Камил әл-Мотыйгый фельетоны язылуга кагылып үтә вә аны басу ни өчендер «угодно было» ди.

Югарыдан бирле язып килүләремездән аңлашылса кирәк ки, бездә һич нәрсә берәүнең күңеле, хәтере өчен басылмый, һич мөнәсәбәтсез уларак бер гәзитә мөхәрриренең фикерендә шундый нәрсә эзләү матбугат әдәбенә хилаф була, өстенә «ул кешенең үзенең шул «угодно было»лар өчен язу гадәте барлыгын күрсәтмәктәдер», – ди.

Олуг кеше алдында әдәпсезлек булса да, мин шуны әйтергә мәҗбүрмен ки, Ф.К. әфәнде, мин язган җөмләне аңламасдан, аңар җавап бирергә тотынган. Ф.К. әфәндегә мәгълүм булсын ки, «угодно было» дигән сүзне ул бөтенләй хата уларак «выгодно было» мәгънәсендәрәк аңлаган. Ф.К. әфәндегә билгеле булсын ки, «угодно было» дигән сүздән «берәүнең күңеле хәтере өчен» дигән

---

[1] Рәфикъларымыз хиссасенә – иптәшләребез өлешенә.
[2] Әфкяре гомумия – җәмәгатьчелек фикерләре.
[3] Ганганәи мәдәниясе – мәдәни традициясе.
[4] Тәхәммел итә – күтәрә.
[5] Мокабәлә итә – каршы кылә.

мәгънәне аңлау русча белмәгәндән генә килеп чыккан бер хатадыр. Ф.К. әфәнде тыныч булсын ки, минем җөмләләремдән «Вакыт»ны Камил әл-Мотыйгый фельетонын берәүнең хәтере өчен баскан дип гаепләү һичбер чыкмый, шуңар күрә аның «Бездә һичнәрсә берәүнең күңеле, хәтере өчен басылмый» дип миңа җавап бирүе урынсыз, мантыйксыз, иске мәдрәсәләрдәге тәгъбир белән әйткәндә, «мөтәгалликъ[1] – бер пич» булган җавап.

Ф.К. әфәнде «Бер гәзитә мөхәрриренең фикерендә шундый нәрсә эзләү матбугат әдәбенә хилаф», – ди. Мин бу кешедән (Ф.К. әфәнде үзе әйткәнчә) сорыйм:

– Нәрсә эзләү хата?

Ф.К. әфәндене мин татарча яза белүче булу сәләтем белән тәэмин итәм[2] ки, минем сүзләремдән «Вакыт»ның ул хәрәкәтендән, яхуд «Вакыт» мөхәрриренең фикерендән берәр нәрсә эзләп тору бер дә чыкмый, болай дип җавап бирү – һаман шул «угодно было» дигән рус сүзен аңлап йитә алмаудан гына чыккан икенче хата.

Ф.К. әфәндене тәэмин итәм ки, мин «Вакыт»ның бу хәрәкәте мөнәсәбәте белән Ф.К. әфәнде фикерендән бернәрсә дә эзләмәдем. Мин бу хәрәкәткә бик мөгаен бер диагноз куйдым да:

– Клоунлык! – дидем.

Шуңар күрә, мин бу кешедән (ягъни Ф.К. әфәнде җәнабләрендән) тагын бер мәртәбә сорыйм:

– Мөхәррир фикерендән нәрсә эзләү матбугат әдәбенә хилаф?

Менә шуңар күрә дә Кытай хәкимнәре әйтәләр икән:

– Бер гәзитәнең мәсьүл мөхәррире икенче гәзитәдә чыккан нәрсәгә җавап бирмәкче булса, әүвәл шул җавап бирәчәк нәрсәсен аңлап йитәргә, үзе генә аңлап йитә алмаса, кешеләр белән моталәгә итеп[3] аңларга вә фәкать шундан соң гына җавап язарга тиешдер! – диләр икән. Мин уйлыйм, Кытай хәкимләренең бу кәшефләрендән истифадә иткән[4] булса, Ф.К. әфәнде мондый мантыйксыз җавап бирү хурлыгына төшмәс, яхуд инде шундый җавап бирергә үзен мәҗбүр күрсә, мондый газамәтле[5] бер аһәң тотудан ваз кичеп, гади язучыларча гына кыйланыр иде.

---

[1] Мөтәгалликъ – бәйлелек.
[2] Тәэмин итәм – тынычландырам.
[3] Моталәгә итеп – фикерләшеп, өйрәнеп
[4] Кәшефләрендән истифадә иткән – ачышларындан файдаланган.
[5] Газамәтле – горурланулы.

Инде соңрак булса да, мин Ф.К. әфәндегә белдерергә тиеш күрәм ки, минем «Вакыт» гәзитәсенә ничөндер «угодно было» дигән сүземнең ләгуе[1] вә вә истыйляхи[2] мәгънәсе:

– «Вакыт» гәзитәсе, ничөндер, ихтыяр боердылар! – дигән сүздән гыйбарәтдер. Бу сүзне минем бертөрле истихфаф[3] аһәңе белән язуым да аның ләгуе вә истиляхи мәгънәсен үзгәртмичә, фәкать «Вакыт»ның мондый урынларда гадәт итенгәне газамәт аһаңындан көлүне генә күрсәтәдер. Менә шуңар күрә дә мин тагы бер кат әйтәм ки:

– Ф.К. әфәнденең миңа каршы язган җавабы – җавап түгел. Ул – мантыйксыз, урынсыз, кыек атылып җилгә очкан «җавап»!

Ф.К. әфәнденең «Ул кешенең үзенең шул «угодно было»лар өчен язу гадәте барлыгын күрсәтмәктәдер» дигән сүзе, үзенең мәгънәгә дәляләт итә[4] алмавы сәбәпле, урынсыз, хәтта көлкедер.

– Бу ни дигән сүз?

– Бу бит: «Ул кешенең үзенең шул «ихтыяр итделәр» өчен язу гадәте барлыгын күрсәтмәктәдер» дигән сүз була.

Мин бу кешенең үзендән сорыйм:

– Бу сүздән максад нәрсә? Бу кеше мине нәрсәдә гаепләмәкче була?

Ф.К. әфәнде мәкаләсенең ахырында «Тормыш», «Йолдыз» һәм «Кояш» гәзитәләрендә карап болай ди: «Без аларның да хөррияте фикриягә вә, хосусән, гәзитә башындагы мәсьүл мөхәррирнең иҗтиһад фикересенә тәсәллыт итмәүләрен[5], әгәр хата фикер нәшер ителсә, каләм вә матбугат әдәбе даирәсендә язып, мөхакәмә вә тәсхыйх итүләрен үтенер идек».

Мин үз тарафымдан нәкъ шул ук үтенеч белән «Вакыт» гәзитәсенә мөрәҗәгать итәм:

– «Вакыт»ның бу мөфтилек мәсьәләсендәге хәрәкәтен без клоунлык дип тапдык икән, хөррияте фикриянең бик кызу «тарафдары» булган «Вакыт» безгә шул фикеремезне әйткән Ф.К. әфәнденең ул кешенең үзенең шул угодно былолар өчен язу гадәте барлыгын күрсәтмәктәдер» дигән сүзе үзенең мәгънәгә дәлаләт итә алмавы сәбәпле урынсыз, хәтта көлкедер.

[1] Ләгуе – мәзәге.
[2] Истыйляхи – атама булу ягыннан.
[3] Истихфаф – мыскыллау.
[4] Дәляләт итә – дәлиллек итә, дәлил була.
[5] Тәсәллыт итмәүләрен – буйсынмауларын.

– Бу ни дигән сүз?

– Бу бит: «Ул кешенең үзенең шул «ихтыяр итделәр» өчен язу гадәте барлыгын күрсәтмәктәдер» дигән сүз була.

Мин бу кешенең үзендән сорыйм:

– Бу сүздән максад нәрсә? Бу кеше мине нәрсәдә гаепләмәкче була?

Ф.К. әфәнде мәкаләсенең ахырында «Тормыш», «Йолдыз» һәм «Кояш» гәзитәләренә карап, болай ди: «Без аларның да хөррияте фикриягә вә, хосусән, гәзитә башындагы мәсьүл мөхәррирнең иҗтиһад фикеррисенә тәсәллыт итмәүләрен[1] әгәр хата фикер нәшер ителсә, каләм вә матбугат әдәбе даирәсендә язып, мөхакәмә вә тәсхыйх итүләрен үтенер идек».

Мин үз тарафымдан, нәкъ шул ук үтенеч белән «Вакыт» гәзитәсенә мөрәҗәгать итәм:

– «Вакыт»ның бу мөфтилек мәсьәләсендәге хәрәкәтен без клоунлык дип тапдык икән, хөррияте фикериянең бик кызу «тарафдары» булган «Вакыт» безгә шул фикеремезне әйткән өчен ачуланмасын иде, бәлки каләм вә матбугат әдәбе даирәсендә язып, шул эшнең клоунлык түгел, бәлки бик мөнасыйб[2] бер эш икәнен безгә исбат итсен иде.

Хосусан, мин үземнең «Вакыт»ның бер хәрәкәте хакында язган сүзләремдә матбугат әдәбендән хариҗ[3] бер нәрсә дә күрмим генә түгел, бәлки бөтен уйланган нәрсәне әйтеп бетермәгәнлекдән, әле анда «Вакыт»ның вә аның газәмәтле мөхәррире Ф.К. әфәндедәнең хәтере саклангaн табам.

Ф.К. әфәнде: «Төрле фикерләр мәйданга чыксын, ишетелсен, мөхакәмә ителсен, ни зарар бар. Фикер хөрриятенә киң күз белән карамаганда, мәдәнилекнең мәгънәсе кайда кала», – ди.

– Өр-яңа сүз! Ләкин шуның белән бергә бу сүзләр инде башка гәзитәләргә дә мәгълүм сүзләр иде. Шуңар күрә дә «Тормыш»дә мөхтәрәм Гаяз әфәнде «Вакыт»ның мөфтилек тугрысында тоткан юлын «Атабыз сакалы белән уйнау»дип атады.

«Йолдыз» исә «Вакыт»ка бу мәзахы өчен тәшәккерләр итде. «Кояш» да, булса, бу эш – клоунлык, диеп атады.

---

[1] Тәсәллыт итмәүләре – буйсынмаулары.

[2] Мөнасыйб – урынлы.

[3] Хариҗ – чыккан.

Төрле фикерләр мәйданга чыкты, ишетелде, мөхакәмә ителде, ни зарар бар? Фикер хөрриятенә, үз зарарыңа булганда да, киң күз белән карамаганда мәдәнилекнең мәгънәсе кайда кала.

Ф.К. әфәнденең җавабындан соң да мин, хөррияте фикериягә таянып, үз фикеремдә калудан үз-үземне тыя алмадым.

«Вакыт»ның мөфтилек мәсьәләсендә тоткан юлы клоунлык булып чыкты. Ф.К. әфәнденең «Мөкабәлә» мәкаләсе дә бу клоунлыкны тарата алмады гына түгел, бәлки аның төсен куертып, аны ныгытды гына.

«Җавабым»ның ахырында шуны да әйтеп китәргә кирәк ки, минем гаед фельетоным башка имзалы мәкаләләрем шикеллүк «Фатих Әмирхан» дигән имза белән имзаланган булса да, Ф.К. әфәндегә ничекдер, «угодно было» аны «Фатих Әмирханов» дип бозарга. Олуг кешенең минем матбугат мәйданындагы фамилиямне белмәвенә мин гаҗәпләнмәсәм дә, аның минем мәкаләмә җавап бирергә «тәнәззел» итә[1] торып та шул мәкаләнең ахырындагы имзага да дикъкать итмәве миңа кызыклы тоелды.

Бәлки, бу да – үзенчә бер газамәтдән чыккан эшдер.

## Инкыйлаб вә без

I

Без, сугыш башланып, аның йөзе ачык күренә башлаган көннән бирле Русия мөселманнары өчен бер гомуми мөәссәсә вөҗүдкә китерү[2] вә шуны хәятлы сурәттә эшләп тора торган җанлы бер организация уларак дәвам итдерергә халыкны кызу-кызу өндәп карадык: мәҗрухларга[3] ярдәм өчен мәркәз комитет, мөселман фракциясе хозурында бюро ясау мәсьәләләренең куптарылулары, шаулатылулары, алар хакында әллә никадәр гасаби[4] нәрсәләр язып караулар – болар һәммәсе дә менә шундый бер организациягә оеткы ясап йибәрергә тырышу иде. Ул мөәссәсәләрне шаулатканда, ул мәсьәләләргә шулкадәр гасаби бер аһәң кертеп халыкны өндәгәндә, алардан асыл максад булган менә шул фикерне аб-ачык әйтергә мөмкин түгел, аны әйткән кеше әле ул вакытта үлем җә-

[1] «Тәнәззел» итә – түбәнчелек итә, кече күңеллелек күрсәтә.
[2] Мөәссәсә вөҗүдкә китерү – оешма төзү (булдыру).
[3] Мәҗрухларга – яралыларга.
[4] Гасаби – көчле.

засына хөкемителә иде. Шул әйтелеп йитә алмауның кәсафәте[1] булырга кирәк, халык безнең бу өндәүләремезгә каршы чукрак калды, кирәк мәркәз комитетка вә кирәк бюрога җанлы вә һәрбер төрле хәятка мөстәгыйд[2] бер организация хәленә килергә ярдәм итмәде, бары матбугат вә җәмәгать хадимләремезнең[3] кыставыннан гына туеп, боларны ясый башларга теләгән сыйфат күрсәтде дә андан соң алар белән эше булмады; менә шуның нәтиҗәсендә без ватанымыз хәятының[4] иң куркынычлы, иң тантаналы вә иң олуг дәкыйкасендә[5] үземезнең башымызда тора торган, үземезнең кирәк дәкыйкадә хәрәкәткә кушылып китәргә мөстәгыйд булуымызны тәэмин итә торган мөәссәсәдән мәхрүм булдык.

– Мең вә мең тәәссефләр[6]...

Бу көн инде халыкның милли истикъбалемез[7] тугрысында уй уйларга мөстәгыйд[8] булган кыйсеме[9] үзенең нинди зур гафләттә[10] икәнлеген аңлый торгандыр, яхуд аңлап йитмәгән хәлдә хис итә торгандыр. Әгәр безнең мәркәз комитетымыз халык тарафындан чын ярдәм күреп, хәятлы бер организация хәленә килеп өлгергән вә шулай дәвам итеп килә алган булса, яхуд мөселман фракциясендәге бюромызга кирәгенчә җан өрелеп дәвам иттерелгән булса иде, бу көн ул мөәссәсәләр безнең Петроградтагы күземез, колагымыз булырлар иде, бу көн инде алар милләтне шушы көнгә муафикъ[11] оешдыру юлында иң зур, иң мөәссир[12] вә иң уңгайлы гамәлләр булырлар иде.

– Ләкин мең вә мең тәәссефләр...

Халык аңлый белмәде, халыкның зыялысы һәм матбугаты да аны аңлатырлык, иске бюрократия телендән яшерен бер тел таба алмады.

– Үткәнемезгә мең вә мең тәәссефләр...

---

[1] Кәсафәте – зыяны.
[2] Мөстәгыйд – сәләтле.
[3] Хадимнәремезнең – хезмәткәребезнең.
[4] Хәятының – яшәешенең.
[5] Дәкыйкасында – фикерендә.
[6] Тәәссефләр – үкенечләр.
[7] Истикъбалемез – киләчәгебез.
[8] Мөстәгыйд – сәләтле.
[9] Кыйсеме – төркем.
[10] Гафләттә – саксызлык.
[11] Муафикъ – туры килгән.
[12] Мөәссир – эффкетлы.

Киләчәгемездә безне нәрсә көтә? Эшли алсак, көч табалсак, торып уздыра торган олуг тарихи дәкыйкаләремезнең әһәмиятен, хәтта кыйсьмән генә булса да аңлый алсак...

– Әйе, аңлый алсак, безне киләчәкемездә бәлки хөрриятле, якты көннәр көтәрләр иде.

Хыялга китерергә курыкканымыз олуг вакыйгалар бу көн инде чын тереклекнең чын вакыйгалары булып китделәр. Шул олуг вакыйганы рус милләте вә, андан да бигрәк, яһүд милләте тәмам оешып йитеп каршы алдылар вә вакыйгаларның әүвәлге көнендән үк хәрәкәткә кушылып өлгерделәр генә түгел, бәлки шундан инде истифадә[1] дә итә башладылар.

Бу революцияне эшләп чыгаручы элемент башлыча рус демократиясе булса, Петроград гарнизоны арасында, иске идарә белән көрәшкән солдатларның йөз мең кадәрлесе татар һәм чирмеш вә чуаш милләтләренә мәнсүб[2] солдатлар булган икәнлеге дә хәзер инде мәгълүм. Каны белән иң аз вә иң әһәмиятсез микъдарда бу инкыйлабка мөшарәкәт иткән[3] яһүд милләте үзенең оешкан хәлдә булучылыгы белән бөтен гайре рус милләтләргә караганда йөз өлеш артык файда итеп өлгергән хәлдә, без әле бу көнгә кадәр үземезне төш күрүче хәлендә хис итеп ятудан айный алмадык.

II

Үткән гафләткә пошаман булуымызның зурлыгы нисбәтендә акыл хәзер, вакыйгалар билфигыйль булып[4] өлгергәч, инде оешу, укмашу эшенә керешергә бурычлылармыз.

Мәгълүм, ки 1905 нче еллардин соң милләтемезнең әүвәлге интизамлы[5] оешуы «Мөселман иттифакы[6]» партиясе тирәсенә булган иде. Бу «Иттифак»ның уйланган вә мөзакәрә ителеп[7], аңлашышып кабул ителгән бер программасы бар иде ки, әнә шул партия тирәсенә инде халкымызның җитди зыялылары, җитди вә олы әл-фикер буржуазиясе, аңлы имамлары, һәммәсенең башында бабамыз Гаспринский хәзрәтләре булган хәлдә оешырга теләгәннәр иде.

[1] Истифадә – файдалана.
[2] Мәнсүб – караган.
[3] Мөшарәкәт иткән – катнашкан.
[4] Билфигыйль булып – чынлыкта.
[5] Интизамлы – тәртипле.
[6] Иттифак – союз.
[7] Мөзакәрә ителеп – тикшерелеп, фикерләшеп.

Реакция көнләрендә сүнеп киткән бу партия үзенең ганганәле[1] бер мөәссәсә булучылыгы хәзерге көндә тергезелергә тиеш вә, аннан да бигрәк, тергезелергә иң мөстәгыйд вә иң уңгайлы бердәнбер организация булучылыгы белән хәзерге абдыраш көнемездә иң әүвәл телгә алына торган нәрсә булырга кирәк.

– Ул тергезелергә тиеш! Русиянең төрле якларына таркалып утырган мөселманнар арасында бервакытта аның шөгъбәләре[2] буларак бу организацияләр дәвам иткән булсалар, шулар бу көннән башлап эшкә тотындырылырга вә шул ганганә вә тарихлы оеткы тирәсенә халыкны җыярга кирәкдер.

Дөрест, хәзерге тәмам алмашынып киткән әхваль аның сәяси, икътисади вә хәтта милли мәсьәләләргә даир[3] төрле матдәләрне дә төрлечә үзгәрешләр кертүне таләп итәр, ләкин бу эш яңа бер партия торгызуга караганда, бик күп йиңелрәк вә бик күп-күп уңайлырактыр.

Мәзкүр[4] мөселман партиясенең ганганәсе аңар халыкны үз тирәсенә җыярга көч бирер, әүвәлдә аның тирәсенә оешкан кешеләрнең бер-берсе белән сакланган галякәләре[5] ул организацияне тергезеп йибәрер өчен мая булып хезмәт итәр вә билахирәдә[6] анда эшләгән кешеләрнең сәяси тәҗрибәләре бу көндә истифадә ителер өчен олуг вә яхшы бер мәнбәгъ[7] булыр.

Шулай «Мөселман иттифакы» тергезелергә тиеш!

Безнеңчә, моның иң уңгайлы юлы түбәндәге рәвешчә булырга мөмкиндер. Нинди генә бер шәһәрдәме, шәһәрчекдәме, хәтта авыллардамы бу партиянең төпләшеп өлгерепме, яхуд өлгереп йитмичәме, сүнгән бер шөгъбә сымак нәрсәсе булып та шуңар мөнтәсиб[8] кешеләр булган булсалар, һичбер сәгать уздырмыйча шул кешеләр үзара бер җыелыш ясап берегергә вә шундан соң ук, шул берегүләрен Дума хозурындагы мөселман фракциясенә хәбәр итәргә тиешләрдер. Мондый ясалып сүнгән шөгъбәләр булмаган

---

[1] Ганганәле – традицияле.
[2] Шөгъбәләре – бүлекләре.
[3] Даир – караган.
[4] Мәзкүр – югарыда әйтелгән.
[5] Галякәләре – бәйләнеше, мөнәсәбәте.
[6] Билахирәдә – ахырда.
[7] Мәнбагъ – чыганак.
[8] Мөнтәсиб – бәйләнешле.

йирдә «Мөселман иттифакы»на интисаб иткән[1] кешеләр булса, шулар үзара берегешеп, үзләренең щундый бер шөгъбә ясарга икәнлекләрен мөселман фракциясенә хәбәр итәргә тиешләрдер.

Бер яктан, вилаятьләрдә[2] шушы берегешү барганда, икенче яктан, мөселман фракциясе «Мөселман иттифакы» партиясенең съездын хәзергә мөмкин кадәр тизлектә шул съездны җыярга вә аның программасын һәм хаттыл-хәрәкәсен мөзакәрәгә[3] куярга тиешдер.

Өченче яктан исә, шундан бер шөгъбәләргә оешкан бу кешеләр, оешкан көннәрендән үк башлап, гомуми хәрәкәтләрнең һәммәсендә корпорация исеменнән катыша торып, гавам, насымыз арасына хәзерге олуг көннәремезнең мәгънәсен тәшһир итү[4] вә аңлату өчен лекцияләр ясау, җыелыш ясау белән шөгыльләнә башларга тиешдер. Зуррак шәһәрләрдәге шөгъбәләр бу көннән үк «Мөселман иттифакы» организациясен терелтү өчен хәзердән үк бер фонд тәшкил итәргә дә керешүгә тиешдер ки, бу фондның һәр көнне кирәк булып торачагы әйтеп тормыйчук мәгълүм нәрсәләрдер.

Безнең уйлавымызча, башларымызның хәзерге вакыйгалардан алган әүвәлге исереклекләре тарала башлау белән үк ясарга тиешле әүвәлге адымыбыз – ушбудыр.

III

Ватанымыздагы соңгы ихтиляль үзенең тибы белән гаҗәеб, моңар кадәр тарихта мисалы күрелмәгән бер ихтилал булып чыкды: бу – бер сыйныфка гаид ихтиляль[5] түгел. Бу аристократия ихтиляле булмаган шикелле, демократия ихтиляле гына да түгел, хәрби ихтиляль гына да түгел, бәлки бөтен Русия гражданнарының, игътикадларда[6], фикерләрдә, төп максадларда бер-берсеннән гаять ерак тора торган бөтен сыйныфларның ихтиляле иде.

Чхеидзе һәм Керенскийлар бу ихтиляльнең рухлары вә ышанычлы фидаиләре[7] булсалар, Гучков һәм Шульгиннар да бу ихтиляльгә галәбә[8] теләүчеләрдән вә шул юлда хезмәт итүчеләрдән иде.

---

[1] Интисаб иткән – бәйләнеше булган.
[2] Вилаятьләрдә – өлкәләрдә.
[3] Хаттыл-хәрәкәсен мөзәкәрәгә – тактикасын тикшерүгә.
[4] Тәшһир итү – тарату.
[5] Ихтиляль – баш күтәрү.
[6] Игътикадларда – ышануларда.
[7] Фидаиләре – фидакарьләре.
[8] Галәбә – җиңү, өстенлек.

Менә шуңар күрә дә бу ихтиляльнең башына менгән Думаның Исполнительный комитетында социал-демократлар башлыгы Чхеидзе белән моннан берничә айлар гына мөкаддәм Короленконы ихтиляльчелеге өчен үлем җәзасына бирергә кирәк дип матбугатта агитация ясап торган Шульгин беррәттән утырып эшләделәр вә кулга-кул тотынышып ихтиляльчеләрне идарә итделәр, үзара бер дә килешә алмаслык дошман булуларына рәгъмән[1], ватан фаидәсе өчен эш вакытында бер-берсенә иң ышанычлы иптәшләр булып тордылар.

– Менә шул берлек, ихтиляльнең менә шул сыйныфлар дәгъвасыннан[2] өстен булучылыгы аңар шундый гаҗәеб галәбә бирде, шундый асатлык вә нисбәтән шундый бер кан агызылмау белән ул үзенең иң авыр адымын муаффәкыятьле[3] сурәттә эшләп очына чыгарды.

Шундый бер иттифак белән башланган ихтиляль икенче адымында да шундый берләшү белән алып барылды, шул берлекнең иң ачык мисалы вакытлы хөкүмәт тәшкил ителү мәсьәләсендә ялтырап күренде:

Бөтен хөрриятләрнең тарафдары, бөтен золым вә кансызлыкларның дошманы булган Керенский гадлия[4] вәзире булган бер хөкүмәтнең Хәрбия[5] вә бәхрия[6] вәзарәтенә[7] Гучков, моннан 6–7 генә ел мөкаддәм[8] Столыпинның сәясәтен мәгъкулләп[9] торган Гучков тәгаен әйтелгән иде.

Менә шул бер-берсенә капма-каршы ике Котыб гомуми эш өчен, ватанның сәгадәте[10] өчен берләшкән вә бер хөкүмәт эчендә җыелганнар иде.

– Чөнки бу ихтиляльнең рухы шуны таләп итә; чөнки бу ихтиляль шулай барганда гына максадка ирешдерә ала икәнен Русиянең бөтен әһел фикере инде аңлап кына түгел, бәлки хис итеп киткән иде.

---

[1] Рәгъмән – карамастан.
[2] Дәгъвасыннан – низагыннан.
[3] Муаффәкыятьле – уңышлы.
[4] Гадлия – юстиция.
[5] Хәрбия – хәрби..
[6] Бәхрия – диңгез.
[7] Вәзарәтенә – вәзирлегенә, министрлыгына.
[8] Мөкаддәм – элек, әүвәл.
[9] Мәгъкулләп – яклап.
[10] Сәгадәте – бәхете.

Менә шул көннәрдә, менә Русиянең бөтен гражданнары гомуми фикер, гомуми максад өчен шушы кадәр берләшкән вакытта...

Әйтергә оят, безнең гадәдләре бер учдан артмаган бер даирәмез[1] гомуми хәрәкәткә кушыла башлавымызның әүвәлге дәкыйкасендә халкымыз арасында ихтиляф чыгарлык мәсьәләләр кузгатырга омтылды. Әйтергә оят, шул даирә үзенең шушы вак, мәгънәсез вә соң дәрәҗәдә черкен хәрәкәтенә әллә нинди гомуми, милли төс бирергә азапланды.

Мин бер даирә тарафыннан Галимҗан хәзрәт әл-Барудиның шәхесенә каршы күтәрелгән һөҗүмне әйтәм.

Артында 35 еллык хезмәте миллиясе тора торган, бөтен Идел буе татарларын укыр вә язар халәткә китерүдәге хезмәтнең иң авыр кыйсемен[2] үз йилкәсендә күтәреп барып, чәч-сакалын агарткан бу затны сәяси сул игътикадта[3] булмаганлыгы өчен генә тәхкыйрь итәргә[4] һичберәүнең хакы булмаудан катгы нәзар[5], әле ул эшнең халкымыз арасына ихтиляф төшерүдән башка һичбер максадка илтеп чыгармаячак икәне, тора торган дәкыйкаләрнең әһәмиятен аңлаган һәркемгә ачык булырга тиеш иде.

Галимҗан хәзрәт иске хөкүмәт вакытында указын кире кайтарып алган икән, бик яхшы эшләгән, шуның белән, андан башка да һәрвакыт мәэмүрият[6] тарафындан кысынкылыклар күреп тора торган мәдрәсәсен иң авыр көнләрдә дә ябтырмый алып килә алган.

Һәрбер дәкыйка мең сәгать кадәр әһәмияткә малик вакытта бөтен Русия халкы, хәтта сыйнфый дәгъваләрдән югары күтәреләп берләшкән вә шул хәлдә яңа тарзе идарәне сакларга йәмин иткән[7] хәлдә, шундый мөһим тарихи вакыйгалар көннәрендә никадәр вакыт вә никадәр гайрәт сарыф итеп бер карт имамны тәхкыйрь итүгә[8], без, иң азында, сәяси тәрбиядән мәхрүмлек, вакытның әһәмиятен аңламау, халкымызның рухын акламау, халкымызның ышанычын сүи истигъмаль итү[9] дип карыймыз.

---

[1] Даирәмез – төркемебез.
[2] Кыйсемен – өлешен.
[3] Игътикадта – монда: фикерлелектә, карашларда.
[4] Тәхкыйрь итәргә – хур итәргә.
[5] Булмаудан катгы нәзар – булмауга карамастан.
[6] Мәэмүрият – чиновниклар (дәүләт эшендәгеләр).
[7] Йәмин иткән – ант иткән.
[8] Тәхкыйрь итүгә – хур итүгә.
[9] Сүи истигъмаль итү – урынсыз файдалану.

Алдымызда, милләтнең бер уч кадәр зыялы сыйныфы алдында, зурлыклары белән коточыргыч мәсьәләләр торган вакытта, бу мәсьәләрнең һәрберсе иҗаби[1] эш таләп итеп торган дәкыйкадә, халыкның вакытын бушка сарыф итдерү, аның фикерен вак мәсьәләләргә бору җинаятьдер. Бу эш бәлки 1905 нче елда, бәлки, җимерү максады өчен файдалы булгандыр. Ләкин бу көн инде, җимерелгәннәр урынына яңаларны иҗад итү тиеш булган көндә, һәрбер төрле ихтиляф, һәрбер төрле сүгенү вә сүгешү – җинаятьдер.

Без өмид итәмез, мондан соң ихтиляф төшерергә омтыла торган даирәләр халык тарафыннан тиешле рәдне алырлар вә шуның белән башланып китәргә тиешле иҗаби эшләрне кичекдерү тукталыр.

IV

Ихтиляльның галәбә итеп[2] чыгуы нинди тизлек ва нинди асатлык белән булса да, аның галәбәсенең ныгуы, аның сугышып алган хөрриятенең, ганимәтенең халык кулында мәңгелеккә ныгып кала алуы гаять күп тырышлык вә халык тарафындан гаять зур аңлылык вә фидаилек таләп итәдер. Хөрриятләрнең мәмләкәттә ныгып калуы өчен иң зур чара шул хөрриятләрне вә ул хөрриятләрнең халык өчен булган кирәкләрен вә ул хөрриятләрне гакселхәрәкәгә[3] каршы саклауның чараларын халыкка, халыкның иң төп сыйныфы булган авыл халкына аңлатып йиткерергә кирәкдер.

Без татарлар өчен бу мәсьәлә бигрәк мөһим һәм бигрәк үткендер. Безнең халкымыз – авыл халкыбыз хәзергә кадәр сәясәтдән гаять ерак торып килгән, аның арасында хәзергә кадәр бу бабта һичбер зыялы куәт эшләмәгән, шуңар күрә, бу бабда безнең авыл халкымыз бигрәк гафил вә бигрәк мөбтәди[4] хәлендәдер.

Вә әлхаль, бу хөрриятләр, бу яңа тарзе идарә[5] безнең өчен, безнең халкымыз өчен бигрәк тә кирәкле: болар безгә бигрәк тә газиз вә бигрәк тә лябед[6] менә нәрсәләрдер.

Шуңар күрә, шәһәрләрдә оешып йиткән мөселман организацияләренең һәрберсе иң әүвәлге адымындан ук авыл халкымыз

---

[1] Иҗаби – уңышлы.
[2] Ихтиляльнең галәбә итеп – баш күтәрүнең (революциянең) җиңеп.
[3] Гакселхәрәкәгә – реакциягә.
[4] Мөбтәди – примитив, гади.
[5] Тарзе идарә – идарә ысулы.
[6] Лябед – бик кирәкле.

арасында бу яңа тарзе идарә вә хөрриятләрне аңлату юлында эш күрергә вә шуңар иң зур әһәмиятне бирергә тиешдер.

Безгә бер нәрсәне онытмаска кирәк: әгәр иске тарзе идарә кайчан да булса бер баш күтәрергә омтылса, аның вәкилләре иң әүвәл вә иң башлап, авылларда, надан вә гафил почмакларда үзләренә корал булырлык халыкларны эзләячәкләр вә үзләренең максадларына шуларны корал итәргә тырышачаклардыр. Безгә иң әүвәл вә иң башлап, үз авыл халкымызны гакселхәрәкәгә корал була алмас дәрәҗә аңландырырга кирәк буладыр. Моның өчен, табигый, иң беренче вә куәтле чара мәсҗед мөнбәрәләрендән вә мәктәп йортларындан халыкка яңа тарзе идарәнең безнең өчен, безнең дин вә милләтемез өчен булган әһәмиятен аңлату вә аны яңа тарзе идарәнең аңлы тарафдары, яңа тарзе идарәнең хәмиясе[1] вә фидаисе ясаудыр. Бу эшдәге баш тәшәббес[2] шәһәрләрдә оешып өлгергән мөселман организацияләрендән чыгарга тиешдер. Бу организацияләр хәзердән үк авылларга хатиблар вә дагыйлар[3] йибәреп һәм шул мәсьәләгә даир хитабнамә вә рисаләчекләр таратып эшкә тотынырга тиешләрдер.

Казанга бу көн бик вә бик тәэссефле бер хәбәр иреште: Арча шәһәрендә бер гөруһ халык сәүдәгәрләрне талап йөргән вә шул гөруһ эчендә шактый бер микъдарда мөселманлар да бу кабахәт эштә мөшарәкәт иткәнләр имеш. Әгәр бу хәбәр чынлап та дөрест булса, бу мөселманлар дине-исламга вә бөтен мөселманларга йөз карасы яккан халык булып, бөтен мөселманларның зарарларына тырышкан ахмаклар булалар. Бөтен мөселманлар мондый эшкә катышырга теләгән ахмакларны бик тизлектә бу эшдән тыярга тиешләрдер. Хәзерге вакытта чыгарылган һәрбер фетнә – яңа ирекләргә, яңа вә безнең өчен дә гаять кирәкле хөкүмәткә каршы чыгарылган фетнә булып, болар иске хөкүмәт кешеләренә, безнең дин вә миллиятемезгә каршы кысынкылыклар ясап торган әүвәлге хөкүмәт кешеләренә, карагруһларга гына файдә булачакдыр.

Шуңар күрә дә, дине-исламны сөйгән һәрбер кеше вә һәрбер мөселман, бу көнләрдә фетнәләргә, талауларга кушылудан бик сак булып, хәзерге хөкүмәтнең әмерләренә бик итагать итәргә вә тынычлык вә тәртипне һәр йирдә бик нык сакларга тиешләрдер.

---

[1] Хәмиясе – яклаучысы.

[2] Тәшәббес – инициатива.

[3] Дагыйлар – аңлатучылар (агитаторлар).

Менә шул хакыйкатьне хәзер имамнар вә җәмгы аңлы мөселманнар үзләренең мөселман кардәшләренә бик тырышып аңлатырга тиешләр вә һәрбер хәрәкәтләрендә шәһәр мөселманлары белән бер җан вә бер тән булып хәрәкәт итәргә бурычлылардыр.

Шәһәрләрдәге мөселман мөәссәсәләре әнә шул Арча вакыйгасе шикелле вакыйгаләрне булдырмас өчен дә һичбер вакыт уздырмыйча, авыл халкы арасына хатиблар вә аңлатучылар чыгарырга тиешләрдер.

Халкымызның олуг вә кечеге бер нәрсәне аңлап йитәргә тиеш:

– Безнең бөтен истикъбалемез, бөтен бәхетемез – хәзерге яңа тарзе идарәнең ныгып калуындадыр.

## V

Русиядә иске идарәи мөстәбидә дәвам итеп торганда, ул империализм юлы белән баручы үзенең чит-читендәге кечкенә милләтләрне йотып, аларны славянлык колы ясарга тырышучы, Ауропа гаксел-хәрәкәсенә[1] рух өрүче бер мәдһиш[2] мәмләкәт иде.

Шуңар күрә, бу сугыш башланып, Русия зыялылары «сугыштан максад кечкенә милләтләргә хөррият бирү» дип шаулый башлагач та, без мөхалифләремез мәйданында гына түгел, бәлки чын-чын битарафлык саклаучы битараф мәмләкәтләрдә дә шаулауларны мөстәхыйранә[3] бер елмаю белән каршы алганлар иде.

– Чынлап та, үз эчендәге бөтен гайре рус милләтләрен сытып вә изеп кенә тора торган бер мәмләкәтнең нindидер башка вак милләтләргә хөррият бирер өчен сугышам дип игълам итүе, ышанырга мөмкин булмаган бер игълам вә ачыктан-ачыкка мәгънәсезлек белән яңгырый торган бер шаулау иде.

Русия эчендә яшәүче без, гайре рус милләтләр дә, ул вакытта Русия буржуазный зыялы таифәләренең[4] бу игъламнарына мәгънәсез бер игълам дип карамый кала алмыйдыр идек, бер яктан, Төркестандагы халыкны атдырып, хәрби мәхкәмәләр белән астырып тора торган бер мәмләкәтнең, икенче яктан, нindидер милләтләргә хөрриятләр алып бирү өчен сугышуы ышаналмаслык елмаеп каршы алынырлык кына бер нәрсә иде.

---

[1] Гаксел-хәрәкәсенә – реакциясенә.

[2] Мәдһиш – куркыныч.

[3] Мөстәхыйранә – мыскыллы.

[4] Таифәләренең – төркемнәренең.

Германия солых гарыз иткәндән соң, мөттәфикъләрнең[1] аңар каршы куйган шартлары, мөстәкыйль Иранстанның Англия вә Русия арасында тәкъсим ителеп[2], истикълале бетерелүе һәм йөздән сиксәне төрек милләтенә мәнсүб булган[3] Истанбулның Русиягә кушылуын солых шартларындан берсе итеп игълан итү – болар һәммәсе «бу сугыш кечкенә милләтләргә истикълаль бирү сугышы» дигән матур сүзне бөтенләй мәгънәсез вә хәтта ачыктан мыскыллаш сүзе генә ясап калдыралар иде.

– Без моны теләсәк тә, теләмәсәк тә, хис итә идек.

Хәл шулай булгач, ягъни матур сүз вә матур лозунг куеп та, шул сүзне бөтен хәрәкәтләр белән тәкъзиб итеп[4] торгач, без, бик табигый, бу сугышдан бер милләт буларак, һичбер файдә көтә алмыйдыр идек, бу сугыш безгә ят вә мәгънәсез иде. Шуңар күрә безнең бу сугыштагы ватанпәрвәрлегемез бер хистән, бер аңдан чыккан ватанпәрвәрлек түгел, бәлки мәмләкәт хаине булмас өчен, рус милләтенең тарихи көнендә аңар каршы тормас өчен көчләнеп вә хиссиятемезгә хилаф килеп булган ватанпәрвәрлек иде. Ул көнләрдә без сугышсак вә кан түксәк, үземез өчен түгел, бәлки рус милләтенең теләве өчен сугыша вә канымызны түгә идек.

Бу – иске идарә вакытында, бу хариҗи сәясәтемезнең Сазонов [...] тарафыннан әбҗәд ителә торган көнләрендә иде.

Әмма хәзер, хәзер инде әхваль бөтенләй тикшеде, бөтенләй икенчегә әйләнде. Бу көн инде ватанымызның мөдәфәга ителүе, немесләрнең артык җиңә алмаулары ихтимал белән сугышып алынган хөрриятләрнең дәвам итә алулары, ныгулары өчен беренче шарт булып китде. Русиянең бөтен милләтләренә хокукда мөсавәт[5] һәм мәдәни автономия вәгъдә итә торган яңа тарзе идарәнең бөтен истикъбале немесләрнең Петроградка керә алмауларында, аларның безнең өчен мәкъбуль булырлык шартлар белән солых ясарга хәзер булулары белән мәшрүт булып[6] калды. Ягъни мәмләкәтнең яхшы мөдафәга ителүе мәсьәләсе инде туп-турыдан безнең үземезнең дә мөнафәгамез белән бик нык бағланды, ягъни безнең үз мәмләкәтемез эчендә мәсгуд яши алуымыз өчен дә иң

---

[1] Мөттәфикъләрнең – союздаш илләрнең (монда: Антанта илләре).

[2] Тәкъсим ителеп – бүленеп.

[3] Мәнсүб булган – караган.

[4] Тәкзиб итеп – ялганга чыгарып.

[5] Мөсавәт – тигезлек, бердәйлек.

[6] Мәшрут булып – шарт ителгән.

самими мөдафәга тиеш булып чыкды, шулай булгач, табигый, безнең сугышка мөнәсәбәтемез дә үзгәрми хәл юк, әүвәлдәге көчлек белән үзләшдергәнемез ватанпәрвәрлек мондан соң инде самими бер хистән чыккан, хәят әхвален яхшы аңлаудан килеп чыккан кызу ватанпәрвәрлек хисенә урын бирде ки, мондан соң инде без дә чын-чынлап, фикрән сугышка мөшәрәкәт итә торган бер милләт булып киттек.

– Ватанның җиңелмәвендә рус милләте никадәр мәнфәгатьдар булса, бу көндә без дә инде шулкадәр ук мәнфәгатьдар булып киттек!

Шуның белен бергә без, бик табигый, кадет вә аның уң тарафындагы бер-ике партияләрнең сугышка карашларын бер дә уртаклаша алмаганлыгымызны да әйтеп китәргә мәҗбүрмез. Панславянизм фикере белән хәрәкәтләнә торган бу партияләрнең сугышка булган мөнәсәбәтләрен без мәмләкәт вә, ватан мәнафәгыннан бигрәк, тар милләтчелек нәзариятындан чыккан вә бу көндә мәмләкәтемездән фаидәсез корбаннар таләп итүе ихтимал булган мөнәсәбәт дип игътикад итәмез.

Әмма демократия, олуг рус демократиясенең сугышка булган мөнәсәбәте бу инде – бөтенләй башка. Боларның сугышка булган мөнәсәбәтләренең төбендә чын-чын хөррият әсаслары вә чын-чын мәмләкәт вә аның халкы мөнафәгы торадыр. «Эшчеләр вә солдат вәкилләренең шурасы» бу көнләрдә бөтен дөньяга бер хитабнамә белән мөрәҗәгать итеп, сугышучы мәхләкәтләрнең йир киңәйтүләренә каршы торып, солыхны тизлектә вөҗүдкә чыгару өчен бөтен милләтләрнең бергәләшеп хәрәкәт итүләре тиеш икәнлеген игълан итәдер.

Демократия Германиянең галәбә[1] казануына каршы бөтен куәте белән сугышачагын игълан итү белән бергә, бу сугышның нәтиҗәсендә Европаның бөтен милләтләренә чын мөсават вә чын тигезлек булуны үзенең шигаре итеп куядыр.

Менә шул шигарь, безнең самими игътикадымызча, бөтен кечкенә милләтләр вә, шулар җөмләсендән, безләр өчен дә шигарь булырга тиешдер.

Тигез хокуклы, хөр милләтләрнең ватаны булган Русия бу сугышдан империализм юлына керми чыгарга тиеш булган шикелле, мәгълүб булмыйча, икътисади изелмичә чыгарга тиешдер.

---

[1] Галәбә – җиңү.

Моның өчен бер генә чара бар ки, Русиянең бөтен гражданлары аны мөкаддәс бурычлары дип танырга тиешләрдер.

VI

Ихтилалның сәлби[1] максады иске тарзе идарәне җимерү булса, аның иҗаби вә төп максаты – Учредительный собрания җыеп, мәмләкәтнең халкы теләгән рәвештә ясауның нигезен салудыр.

Шуңар күрә, хәзер бөтен Русия халкының төп омтылган максады, төбәп бара торган Тимер казык йолдызы – шул Учредительный собраниядер.

Бу Учредительный собраниянең никадәр әһәмиятле вә никадәр газамәтле бер нәрсә булучылыгын аңлар өчен, ул җыелгач та, бөтен мәмләкәтнең хуҗалыгы аңар күчәчәк икәнен, калган бөтен мөәссәсәләрнең[2] фәкать аның теләгән генә иҗра итеп[3] тора торган ихтыярсыз кораллар гына булып калырга тиеш икәнлеген хәтергә алу йитсә кирәк.

Мәмләкәтемезнең бөтен киләчәк тормышын халык теләгән юлга салу, халыкның әксәриятен тәшкил иткән сыйныфка мөмкин кадәр җиңел хәят юлы хәзерләүгә нигез кору – болар һәммәсе Учредительный собрания теләвенә тапшырыла. Болар һәммәсе, фәкать, шул собраниянең генә ихтыярында буладыр, шуңар күрә дә хәзерге Русиядәге бөтен милләтләрнең күзләре шул ноктага терәлгән, бөтен дәрд вә гайрәтләр шуңар хәзерләнергә хәзер ителгән.

Безнең дә иң төбәп торкан ноктамыз шул булырга тиеш. Бу собраниядә үземезнең Русиядәге санымызга мөтәнасыйб микъдарда вәкил булындыру вә башка милләтләрдән вә, хосусән, руслардан бу собраниягә әгъза булачак кешеләрнең гайре рус милләтләргә мәдәни автономия бирү тарафындагы затлар булучылыгына үз кулымыздан килгән кадәр тырышу безнең күз алдымызда тора торган иң зур максадымыз булырга тиешдер.

Бу ике максадка ирешү өчен, безнең игътикадымызча, иң тугры, иң дөрест юл – милләтне бүлендермичә, бер милләт хәлендә сайлауга алып бару юлыдыр. Промышленносте, зур йир хуҗалары, зур капиталы булмаган бер милләткә мөгаен бервакытка кадәр бөтен килешчә бару, безнең игътикадымызча, бик асат булмавы белән бергә, мөмкин булмаган эш түгелдер.

---

[1] Сәлби – инкяр итә торган.
[2] Мөәссәсәләрнең – оешмаларның.
[3] Иҗра итеп – үтәп.

Күпчелегемез йир эшләүче һәм кечкенә буржуаздан гыйбарәт булганлыктан, миллият флагы астында җыелган хәлдә Учредительный собраниягә барсак, без монда рус милләтчеләрендән гыйбарәт булган кадетлар белән рус демократиясенең көрәшендә зур роль уйный алачакмыз, Учредительный собраниянең рус милләтчеләре кулына төшүендән саклый торган, рус демократиясенә зур ярдәм күрсәтә торган бер гамәл була алачакмыз.

Билгаке, әгәр бәгъзе бер нәзарияткә бирелгән һәм шул нәзариятнең матур сүзләрен сөйләп йөрүне бу көнге көнемезнең модасы хисаплый торган кешеләремез уйлаганча, без милләт арасында, сыйныф көрәшен бу көндән үк чыгарсак, без, әүвалән, үземезнең санымызга мөтәнасыйб[1] татар вәкилләрен Учредительный собраниягә үткәрүдән мәхрүм булачакмыз, саниян[2], кадетлар белән демократлар көрәшендә һичбер роль уйный алмаячакмыз. Бу вакытта һәм миллиятләр мәнафәгы, һәм демократия монафәгы җуялтылган буладыр.

Андан-мондан чүпләнгән нәзариятнең матур сүзләре хөрмәтенә, шуны ике-өч ай алдан сөйләп калу хөрмәтенә һәм милли, һәм гавами монәфагане корбан итү ихтималын чыгару сәяси сукырлык, сәяси вә сыйнфый тәрбиясезлек вә, гомумән, аңсызлыктан башка бернәрсә булачак түгелдер.

Шуңар күрә, безнең самими игътикадымызча, безгә Учредительный собраниягә сыйныфлар флагы астында түгел, бәлки миллият флагы астында барырга тиешдер ки, моның өчен дә беренче вә иң куәтле шарт – милләт арасындагы сыйнфый көрәшне үткенләндererлек һәрбер хәрәкәт вә һәрбер сүздән сакланудыр.

Сыйныф көрәшләренең иң фагыйль[3] тарафдары, Русия пролетариатының иң үткен күзле лидерларындан берсе булган Плеханов үзенең соңгы мәкаләләрендән берсендә хәрфиян түбәндәге сүзләрне яза:

Истибдаддан котылыр өчен, безнең халкымызның һәрбер табәкасенә[4] берләшергә кирәк булды... Шөһбәсез, бу бүлек мәңге дәвам итәргә тиеш дигән сүз түгел. Вакыт килер, хәзергә бергә бара торган бу ике бервакыт аерылып, төрле тарафка вә, бәлки, капма-каршы тарафларга китәрләр. Ләкин ул дәкыйка әле йитмәгән ди.

---

[1] Мөтәнасыйб – пропорция(дә).
[2] Саниян – икенчедән.
[3] Фагыйль – эшлекле.
[4] Табәкасенә – катлавына.

Ышанычлы социалистның бу сүзен аңлап хәтердә тоту безнең бу көндән сыйныф көрәшү башлануны теләүчеләремез өчен дә зарар итмәс иде.

Учредительный собраниягә сайлаулар вакытында безгә рус партияләрендән кайсы белән бергә барырга кирәк булу хакында киләсе мәкаләләрнең берсендә мөхакәмә ителер.

VII

Без үткән мәкаләмездә Учредительный собраниягә булачак сайлауларның әһәмияте турысында язган идек.

Бу мәкаләдә безгә, шул мәсьәләнең безгә генә, ягъни мөселманларга гына үткен кагыла торган бер җәһәтенә тукталырга туры киләдер.

Әле Учредительный собрания сайлауларының бөтен тәфсилаты рәсми игълан кыйлынган юк, ләкин аның төп матдәләре инде мәгълүм: гомуми, тигез, яшерен һәм тугры сайлаулар булачак, ягъни хәдде белугга[1] ирешкән һәрбер граждан сайлауларга мөшарәкәт итәчәктер[2].

Бүгенге көндәге иң куәтле партияләрнең бу сайлауларда хатын-кызны да катышдыру тарафында икәнлекләре дә инде ачык мәгълүмдер. Шулай булгач, уйларга тугры килә ки, сайлау хакы хатын-кызларга да бирелер.

Хәл болай булгач, безгә бу мәсьәлә тугрысында хосусый сурәттә уйланырга тиеш буладыр.

– Әле сөтрә эчендән чыгып бетмәгән хатын-кыз ярымымыз белән без нишләргә тиешләрмез? Әгәр бу ярты милләт үз хәлендә калдырылса, ул сайлауларга мөшарәкәт итмәячәк, икенче гыйбарә белән әйткәндә, сайлауларда гаять зур роль уйнавы мөмкин булган 10 миллионга якын мөселман тавышы җуелачак, мөселманлар үзләренең гадәдләренә нисбәтән тотарга тиеш булган урынларның фәкать яртысын гына тотып калачаклардыр ки, бу эш безнең өчен сәяси бөлгенлек булачактыр.

Әгәр инде бу афәтне булдырмый калдыру тиеш дисәк, безгә һәрбер дәкыйканы[3] ганимәт белеп, шул тугрыда хезмәт итәргә тиеш буладыр.

---

[1] Хәдде белуг – балигъ булган.

[2] Мөшарәкәт итәчәктер – катнашачак.

[3] Дәкыйкане – минутны.

– Менә шул хезмәт кайдан башланырга вә нинди юл белән алып килергә тиешдер?

Безнең игътикадымызча, моның бердәнбер өмидле вә уңгайлы юлы – хатын-кызларымызны үзара җәмгыятьләргә оештырып, шул җәмгыятьләр аркылы аларны киләсе хәрәкәтләргә хәзерләүдер. Шул юлдан башка юл белән барылганда, хатын-кызларымызны киләсе хәрәкәтләргә кушу мөмкин булмаячак, гаять зур әксәриятне тәшкил итә торган, сөтрә астындан чыкмаган хатын-кызларымыз хәрәкәттән читтә калдырылачактыр.

Менә шуңар күрә дә без Казан вә гайре зуррак шәһәрләрдәге могътәбәр ханымнарның хатын-кызларымыз өчен җәмгыятьләр оешдырырга керешүләрен бик куанып каршы алырга һәм шул эшнең башында йөрүчеләргә кулдан килгән һәрбер ярдәмне итә торырга тиешләрмез. Өсттән караганда, зәминсезрәк[1] күренгән шикелле булган бу хәрәкәтнең безнең милли хәятымыз өчен бик әһәмиятле вә бик тиешле хәрәкәт икәнлегенә без ачык күз белән карарга бурычлылармыз.

Хатын-кызларымызның гомуми хәяткә катышмый, мәфлуҗ[2] хальдә ятуларындан, без бу көнгә кадәр икътисади вә мәдәни зарар итеп килсәк, инде мондан соң бу зарарлар өстенә сәяси зарар итүемез дә кушылачактыр ки, монысы инде тугрыдан-тугры истикъбалемез[3] өчен гаять куркыныч эш булачактыр.

Менә шуңар күрә дә без олуг шәһәрләрдә башланган бу хатын-кызларымыз хәрәкәтенең кечкенә шәһәрләр вә авылларга да җәелүе, гаять зур әһәмияткә малик дип саныймыз; ирләр хәрәкәте булган һәрбер йирдә хатын-кызларымыз да хәрәкәткә китерелергә вә оешдырылырга тиешдер, моны аңлы имамнар мәсҗедләрдә сөйләсенләр, моны аңлы аталар үзләренең гаиләләренә аңлатсыннлар. Бу хәрәкәтнең хатын-кызга гына түгел, бөтен милләткә кирәк икәнлеген һәрбер йирдә игълан вә игълам итсенләр.

Чынлап та, сайлауларга катышырга хаклы мең җанга малик рус авылы мең тавышка малик булып та, шундый ук бер татар авылы 500 дән дә ким тавыш белән генә калса, бөтен милләт өчен эур хәсран[4] булачактыр.

---

[1] Зәминсезрәк – нигезсезрәк.
[2] Мәфлүҗ – авыру.
[3] Истикъбалемез – киләчәгебез.
[4] Хөсран – хәсрәт, зарар.

– Менә бу мәсьәләгә һәркайсымыз ачык күз белән карарга тиешләрмез.

VIII

Мәмләкәтнең тарзе идарәсе тизлектә җыелачак Учредительный собраниянең сайланган вәкилләрнең карарлары вә теләүләре белән тәгъйин ителәчәк булгач, без мөселманнарга инде бу тугрыда аерым-ачык бер игътикад, бер мәсләк ясап куярга вә сайлаулар вакытында шул мәсләк теләгән рәвештә хәрәкәт итәргә тиеш буладыр.

Мәгълум ки, мәмләкәт идарәсендә ике төрле рәвеш булырга мөмкиндер: падишаһлык (монархия) һәм җөмһүрият (республика) рәвешләр. Бу ике төрле тарзе идарәнең төп аермалары мәмләкәттә ике баш хуҗалыкның нәселдән нәселгә күчеп килә торган падишаһка тапшырылуы белән мөгаен бер вакытда, халык тарафындан сайлана торган бер кешегә (рәисе җөмһүрияткә) табшырылуындадыр. Без бу мәсьәләгә тәфсиллерәк рәвешдә тукталыйк:

– Без мөселманнар үземезнең ватанымыз һәм үземез өчен нинди тарзе идарә артыграк күрәмез, нинди тарзе идарәне тиеш саныймыз? Мәмләкәттәге баш хуҗалык нәселдән-нәселгә күчү шарты белән бер кешегә табшырылсынмы, яхуд бөтен Русия халкы тарафындан мөгаен мөддәткә сайлана торган кешегә табшырылып, бу баш хуҗалык чынында халыкның үз кулында калсынмы?

Иң әүвәл падишаһлык (монархия) мәсьәләсен карыйк: безгә падишаһ нәселендән нәселгә күчеп, мәмләкәтдә хуҗалык итеп килә торган бер кеше кирәкме, юкмы?

Падишаһ кирәк дип әйтүче кешеләр үзләренең шул фикерләрен куәтләр өчен түбәндәге дәлилләрне китерәләр:

1. Падишаһ – мәмләкәтнең, ватанның бер тәмсиле, мөҗәссәме[1] булып торып, халыкны бер-берсенә нык баглый вә, шулайтеп, мәмләкәтдә нык берлек вөҗүдкә китерә.

2. Падишаһ – фирка низагъларындан, сыйныф низагъларындан өстдә тора вә шунлыкдан мәмләкәтдә бер генә фирканең, бер генә сыйныфның бөтенләй баш булып китүенә манигъ[2] була.

3. Мәмләкәт эчендәге төрле милләтләрнең көрәшләре вакытында миллият мәсьәләсендән өстдә тора торган падишаһ әкалли-

---

[1] Тәмсиле, мөҗәссәме – мисал итеп китерелеше, гәүдәләнеше.

[2] Манигъ – киртә.

ят[1] тәшкил итә торган милләтләрнең әксәрият[2] тәшкил итә торган милләтләр тарафыннан бөтенләй изелүенә каршы тора ала.

4. Әдьян, сәмавияләр вә, шул җөмләдән, христианлык да вә исламият дә ватанның башында бер падишаһ булуны таләп итәдер.

Бу дәлилләр тугрысында төпләп уйлап караганда, аларның һичберсе без мөселманнар өчен ышанычлы булырлык түгелдер.

1. Падишаһ халыкны бер-берсенә нык баглап, мәмләкәт эчендә нык берлек вөҗүдкә китерә дигән дәлил ышандырырлык түгел, чөнки без хәзерге көндә, бик күп җөмһүриятләрдәге рәисе җөмһүриятнең теләсәң нинди падишаһыннан артык берлек вөҗүдкә китергәнен күреп торганымыз хальдә, бу көнге көндәге падишаһларның бик күбесенең, билгакес[3], шул берлекне вөҗүдкә китерә алмаганыкларын күрәмез: Русия падишаһлары менә инде гасырлардан бирле Русия халкының төрле милләтләрен вә төрле-төрле халыкларын бер-берсенә дошман итеп кенә киләләр иде; Юнанстан короле, фәкать, бер генә төрле милләтдән гыйбарәт Юнанстанда да берлек вөҗүдкә китерә алмады гына түгел, бәлки ихтиляф[4] кына төшерегә ярады; әгәр Константин урынына Витизилос король булган булса иде, ул да нәкъ шулук ихтиляф төшерүче булудан артыкга ярый алмаган булыр иде. Әле мондый падишаһлыклар гына түгел, хәтта падишаһлыкның иң мөкәммәл булган Англиядә әле бу сугыш вакытында корольнең шәхси ирландиялеләрне инглизләр белән берләштерә алмады, Ирландиядә хәтта ихтилал күтәрелү мөмкин булды. Вәлхаль, җөмһүрият булган Франциядәге эчке берлек бу көнге көндә искитмәле нык тазадыр.

Шулай булгач, халыкны берләштерә торган нәрсәнең падишаһ булмыйча, бәлки ватан мәхәббәте вә аның халкына бирә алган рәхәт вә сәгадәте булганлыгын уйларга тиеш буладыр.

2. Падишаһ – фирка низагъларыннан өстен торып, бер фирка вә бер сыйныфның гына бөтен мәмләкәткә баш булып китүенә манигъ булып тора дигән дәлил дә игътикад ителерлек[5] нәрсә түгелдер.

Чөнки чын парламент ысуле илән идарә ителә торган падишаһлыклар да падишаһ кулындагы көч иң көчле фирка вә сыйныф

---

[1] Әкаллият – азчылык.
[2] Әксәрият – күпчелек.
[3] Билгакес – киресенчә.
[4] Ихтиляф – фикер каршылыгы; дау, ызгыш.
[5] Игътикад ителерлек – ышандырырлык.

белән көрәшергә йитәрлек булмый; парламент ысулы кертелмәгән мәмләкәтләрдә исә, падишаһларның моңар кадәр килгән, вә бу көнге хәлләре шәһадәт бирәләр, алар азлык тәшкил итә торган бер фирка вә бер сыйныф күпчелек өстенә атландарып, күпчелекне таландырырга маил[1] буладыр.

3. Падишаһлыкларның миллият низагъларында бер гадел хаким булучылыклары – мәсьүл шәйдер[2]. Бу мәсьәлә дә вакыйгаларның шәһадәте буенча, коры бер сүздән гыйбарәтдер. Нинди бер падишаһлык милләте хакимгә каршы кечкенә милләте мәхкүмәгә[3] ярдәмләшкәнен күргәнегез бар? Австрия императорлары кайбер вакытта миллият низагъларына катышкалап әкаллият тәшкил итә торган бер милләте хакимәне әксәрият тәшкил итә торган икенче милләт хакимәгә каршы кайбер вакытта яклашсалар да, мондый вакыйгалар гомум мәмләкәттә әкаллиятдән уза алмый торган милләте хакимә булган немесләр файдасы өчен генә эшләнә иде. Мондый яклашудан милләте мөхәкамәләр файда алмыйлар гына түгел, бәлки зарар гына итә алалар. Шуңар күрә падишаһлык файдасына китерелә торган дәлилләрнең безгә иң күп тәгаллекъ итәрлек бу матдәсе дә безнең өчен һичбер кызыкдырырлык нәрсә түгелдер.

Әдьян[4] – сәмавиянең вә, шул җөмләдән, исламиятнең дә падишаһлык фикерләрен куәтләүләре мәсьәләседер. Христианлыкның бу мәсьәләгә карашын христианларга калдырып, без, фәкать исламиятнең бу тугрыдагы карашына гына тукталсак, исламиятнең бик күпләр уйлаганча монархизм тарафдары бер дин түгел икәнен ачык күрәмез.

Ислам ганганәләренең[5] иң яңа вакытында хилафәт[6] мәсьәләсе, нәселдән нәселгә күчә торган булмыйча, сайлау юлынча була иде:

Әбу Бәкер, Гомәр, Госман вә Гали (р.гъ.) хәзрәтләре һәммәсе мөселманларның теләве буенча хилафәт урнына утырдылар вә үзләренең баш хуҗалыкларын ирс тарикы[7] белән түгел, бәлки җәмәгате мөслимин кулындан алдылар. Икенчерәк тәгъбир белән

---

[1] Маил – һәвәс.
[2] Мәсьүл шәйдер – җаваплы нәрсә.
[3] Милләте мәхкүмгә – хөкем астында торган (изелгән) милләткә.
[4] Әдьян – диннәр.
[5] Ганганәләренең – традицияләренең.
[6] Хилафәт – хәлифәлек.
[7] Ирс тарикы – мирас юлы.

әйткәндә, болар һәммәсе, падишаһлардан бигрәк, гомерлеккә сайланган рәисе җөмһүриятләрдән гыйбарәт иделәр.

Шуңар күрә, без катгыян әйтә аламыз ки, исламият җөмһүрият әсасына хилаф булмау гына түгел, бәлки ул хилафәт мәсьәләсендә шул әсасны күрсәтеп киткәндер.

Шулайтеп, падишаһлык тарзе идарәсе файдасына китерелә торган һичбер дәлил безне икънагъ итерлек[1] түгелләрдер. Ул хәл падишаһлык тарзе идарәсе вакытында халыкның вә, шул җөмләдән, без мөселманларның да сәяси рольләремез, табигый, дәрәҗәсендән кими вә кечерәядер. Шуңар күрә дә, без мөселманларга падишаһлык тарзе идарәсен якларга һичбер риҗа[2] юк кына түгел, бәлки аңар каршы торырга, җөмһүрият тарзе идарәсен якларга бик күп вөҗүһләр[3] бардыр.

Болары хакында инде киләсе мәкаләдә.

IX

Без үткән мәкаләдә ватанымыз вә үземез өчен бер падишаһның кирәге бармы-юкмылыгы мәсьәләсендән бәхәс иткән вә мәмләкәтдәге баш хуҗалыкның атадан балага мирас тарикы[4] белән күчәр өчен бер кешегә тапшырылуының һәм мәмләкәт монафәгы һәм үз монафәгымыз ноктаи нәзарендән[5] һичбер кирәге юклыгын бәян иткән идек.

Падишаһсыз мәмләкәтләр җөмһүрият юлы белән идарә ителәләр.

Хәзер инде йир йөзендә бу юл белән идарә ителә торган мәмләкәтләр күбәйделәр һәм көндән-көн күбәеп торалар. Затән[6], бу шулай булмаска мөмкин дә түгел, чөнки моны адәм тәрәккый иткәй саен ул иркенчелеккә һәм үзен үзе идарә итәргә омтыла. Әнә шул иркенчелек вә шул халыкның үз-үзен идарә итүенең иң мөкәммәле җөмһүрият тарыз идарәсендә табыладыр. Бәни адәмнең вә милләтләрнең тәрәкъкыйсе – шул җөмһүрияткә таба бара; ысулы идарәнең дә иң гакылга вә хикмәткә муафигы – шушы җөмһүрият ысулыдыр.

[1] Икънагъ итәрлек – канәгатьләндерерлек

[2] Риҗа – теләк.

[3] Вөҗүхләр – юллар, ысуллар.

[4] Тарикы – юлы.

[5] Ноктаи нәзарендән – карашыннан.

[6] Затән – нигездә.

Төрле идарәләр белән яши торган мәмләкәтләр арасында, үзенең халкына иң күп иркенчелек, иң күп рәхәт вә сәгадәт бирә торган мәмләкәтләрнең бу көнге көндә җөмһүрият тарыз идарәсе белән идарә ителә торган йирләр икәнчелеге әхвале галәм белән таныш булган һәркемгә мәгълүм хакыйкатьтер.

Җөмһүриятле мәмләкәттә халык өстендән баш хуҗалык итү халыкның кәмалән үз кулында буладыр. Мондый мәмләкәтләрдә халыкка золым итә торган гына түгел, бәлки халык теләгән һәммә нәрсәләрне булдырып өлгерә алмый торган бер хөкүмәт тә, бер баш вәзир дә һичбер көн үз урынында тора алмый, төшерелә, халыкның риза вә мәхәббәтен җәлеп итәрлек икенче хөкүмәт вә баш вәзир белән алмаштырыладыр.

Җөмһүриятле мәмләкәтнең башы, рәисе җөмһүрияте дә үзенең бөтен хәрәкәтләрендә мәмләкәт халкындан күбрәк кыйсемнең теләкләренә иярергә вә шуңар карап эш итәргә бурычлы була ки, ул, фәкать, халык теләгенең бер үтәүчесе, халык кулындагы бер корал гына булып торадыр. Бу урынга менә торган кеше халык тарафыннан сайланып менгерелгәнгә күрә, үзенең әүвәлге хәрәкәтләре белән дә ышанычлы булып танылган гакыллы вә халык сөючән буладыр.

Шулайтеп, җөмһүрият тарыз идарәсендә мәмләкәтнең баш хуҗалыгы бер кешенең мөстәбид[1] теләвенә тапшырылмыйча, халыкның кулында буладыр.

Мондый мәмләкәтләрдә идарә эшенең һәр бабында сайлау ысулы хөкем сөргәнлектән, гадәди күп[2] вә үзара иттифак белән эш күрә торган милләтләр бөтен мәмләкәтнең эчке сәясәтенә генә түгел, бәлки тышкы сәясәтенә дә тәэсир йөртергә мөкътәдир[3] буладыр.

Рус милләтендән кала, иң күп гадәд тәшкил итә торган без, Русия мөселманлары, мондый тарыз идарә вакытында руслардан кала иң зур тәэсиргә малик буда алырлык хальдәмез. Әгәр без, моңар кадәр сайлаулардагы хәрәкәтләремез шикелле, моннан соң да сайлауларда берлек вә иттифак белән хәрәкәт итә алсак, җөмһүрият тарыз идарәсе вакытында бик зур сәяси роль уйный алачакмыз ки, бу инде – үземезнең дини, милли-мәдәни

---

[1] Мөстәбид – монда: үзенчә.

[2] Гадәди күп – күп санлы.

[3] Мокътәдир – сәләтле.

вә хәтта икътисади хәятымызны тәэмин итә алырлык хәлдә булу димәктер.

Менә шуңар күрә, без, мөселманлар. хәзерге көндә мәмләкәтемез вә үземез өчен җөмһүрият тарыз идарәсен иң фаидәле тарзе идарә дип танырга тиешләр вә таныймыз да. Шул тарыз идарә куелып китү юлында кулымыздан килгән һәрбер нәрсә белән тырышырга тиешләрмез.

X

Җөмһүриятләр, сайлауга бөтен халыклар катышдырылып катышдырылмау игътибары белән ике төрле буладыр. Әгәр сайлауларга катышыр өчен бер микъдар малга малик булу, яхуд бер микъдар налог түләү шарт ителсә, бу вакытта мәмләкәт идарәсе бөтен халык теләвенчә була алмый, бәлки, шул сайлауга катышучы кешеләр теләгәнчә буладыр. Әгәр инде сайлауга катышу өчен һичбер төрле мал вә мөлек шарт ителмәсә, мөгаен бер микъдар налог түләү-түләмәү дә игътибарга алынмаса, ул вакытта, мәмләкәт идарәсе чын-чынлап бөтен халык теләгәнчә була, халык җөмһүрияте (демократическая республика) була.

Без мөселманлар өчен бу ике төрле җөмһүриятнең кайсысы матлубрак? Боларның кайсысын без һәм ватанымыз, һәм үземез өчен фаидәлерәк күрәмез? Бу сөальләргә җавап бирмәстән борын, без үземезнең икътисади халемезне хәтеремезгә алырга тиешләрмез. Русиядәге бәдәви хальдә яши торган бик вак милләтләрне игътибарга алмасак, без – Русиядә тора торган милләтләрнең иң фәкыйре вә икътисади иң зәгыйфемездер. Безнең сәүдәгәрләремез – вак сәүдәгәрләр; Безнең һөнәрмәндләремез – вак һөнәрмәндләр; милләтемезнең йөздән туксанын тәшкил итә торган крестьянларымыз да малсыз, мөлексез, фәкыйрьләрдән гыйбарәттер. Шуңар күрә, әгәр сайлауларга катышу өчен мал вә мөлек, яхуд мәгълүм бер микъдардан ким булмаган налог түләү шарт ителдисә, бу шарт һәрбер милләтгкә караганда безнең милләткә зарарлы тәэсир итәчәк, безнең милләтнең тавышын киметәчәкдер. Фәкать, бер Төркестан дәһкан (крәстиян) ләрен генә алыгыз, болар бит һәрбер төрле мал вә мөлекдән мәхрүм, фәкыйрьлек ниһаясенә ирешдерелгән вә чынлап караганда һичбер төрле налогны күтәрмәскә тиешле халыкдыр. Әгәр дә сайлауларга катышыр өчен бертөрле вә хәтта иң кечкенә генә мал вә мөлек. яхуд налог түләү синзы шарт ителсә, бу эш Төркестанның

90 фанз[1] әһалисен сайлаулардан мәхрүм итәргә вә, шулай итеп, мөселманларны 7–8 миллион тавыштан мәхрүм итәргә тиешдер. Сайлау өчен шарт ителә торган синза күпме күбрәк булса, безнең тавышларымыз шул дәрәҗәдә, билнисбәдә, күбрәк җуяла барачакдыр, ки хәтта, билахирә, безнең, Русиядә бөтен гадәдләре 5 миллионга тулмый торган яһүдләр дәрәҗәсендә тавыш бирә алудан мәхрүм калуымыз бик ихтималдыр. Әлхасыйль, сайлауларда синзаның шарт ителүе, бай милләтләр өчен бик фаидәле булуы белән бергә, безнең шикелле фәкыйрь милләтләр өчен гаять вә гаять зарарлыдыр. Шул синзалы сайлаулар аркасында без моңар кадәр земстволарда роль уйнаудан мәхрүм булып килдек һәм, кыйсьмән[2], шул синзалы сайлаулар аркасында Дәүләт Думасында кирәгенчә вәкилле булындырудан мәхрүм ителеп тордык вә шул ук синзалы сайлаулар аркасында без Г. Советта бер генә вәкил дә булындыра алмадык.

Менә шуңар күрә дә, без инде бөтен көчемез белән мәмләкәт идарәсендә ысулның халык җөмһүрияте ысулы (демократическая республика) булуына тырышырга тиешләрмез.

Бу әле – мәсьәләгә фәкать сәяси тарафындан караганда болайдыр. Әмма икътисади җәһәтдән караганда, безнең өчен халык җөмһүрияте кирәклеге вә хәтта аның гына безне канәгатьләндерә алучылыгы тагы да ачыграк күренсә кирәк.

Югарыда әйтелгәнчә без, бөтен бөр милләт итеп алыңдыкта, гаять фәкыйрь вә гаять кысынкы икътисади әхваль эчендәмез; безнең кристиянларымыз күбрәк урынларда йирсезлекдән аптыраштa; йирләремез киңрәк урынларда аларга мөһаҗир тутырылып, без тәдриҗа йирсез калдырыла бара идек. Шулай булгач, кристиянлар вә фәкыйрь халыкның икътисадый хәятын күтәрү юлында күтәрелгән һәрбер чара, безнең өчен гаять әһәмиятле вә зарурдыр. Крестьяннар вә фәкыйрь халыкның әхвале ислахсыз калу, безнең милләтемезнең 90 фаиздан артыгын изәчәк. Вә, билгакес, фәкыйрь халыкның икътисади күтәрелүенә сәбәп булачакдыр. Менә шуңа күрә дә, безгә бөтен бер милләт уларак Русиядәге икътисади сәясәтнең ислах ителүен теләмәскә мөмкин түгелдер. Без моны телимез, без үземезнең милли бөтенлегемез өчен дә моны беренче шарт саныймыз. Безнең сәүдәгәр сафымыз да, үз

[1] Фаиз – процент.

[2] Кыйсьмән – өлешчә.

мөнафәгын яхшы аңлаганда, крестьян сыйныфының икътисади күтәрелүен теләргә тиешдер, чөнки мәмләкәтнең төп халкы булган крестьян күпме икътисади таза булса, шулкадәр аның сатып алучылык куәсе арта, ягъни мәмләкәттә сәүдәнең тәрәккъыйсенә чын-чынлап ярдәм итүче гамәл буладыр.

Мәмләкәттә икътисади гадәләт вә тәрәккъыйне иң мөкәммәл сурәттә вөҗүдкә чыгара ала торган бер тарзе идарә – халык җөмһүриятедер ки, без, мөселманнар ватанымызның вә үземезнең икътисади мөнафәгамыз ягыннан караганда да, шушы тарзе идарәгә тарафдар булмый кала алмыймыз.

Милли-мәдәни ноктаи нәзарләрдән караганда исә, бу тарзе идарәнең халык җөмһүриятенең безнең өчен матлуб булучылыгы тагы да куәтлерәкдер.

Монысы хакында инде киләсе мәкаләләрнең берсендә язылыр.

## XII[1]

Без үткән мәкаләмездә сәяси вә икътисади ноктаи нәзарендән[2] караганда Русия мөселманлары өчен иң матлуб[3] идарә халык җөмһүрияте тарыз[4] идарәсе икәнлегенә даир мөляхазәләремезне[5] язган идек. Инде мәсьәләгә халис[6] милли ноктаи нәзардән, үземезнең милли бөтенлекгемезне саклавымыз ноктаи нәзарендән карыйк. Без Русия мөселманларына үземезнең бөтенлегемезне саклар өчен әүвәлге вә иң мөһим чара бөтен милли мәсьәләләремезнең үз кулымыз, үз ихтыярымызда булучылыгымыздыр; моның өчен безгә дини, милли һәм мәдәни автономияләр зарурдыр. Безнең миллиятемез генә түгел, динемез дә Русиянең башка әһалисенә генә караганда бөтен асылындан бам-башка булганга, безнең хәзергә кадәр килгән бөтен ганганәтемез[7], бөтен гадәтемез, бөтен төреклегемезнең рәвеше ватанымызда әксәрият[8] тәшкил итә торган олугъ рус милләтнекендән бөтенләй аерым булганга күрә, безнең бу автономиямезгә гаскәри бүлекләремезнең аерым, махсус

---

[1] *XI кисәк (өлеш) газетаның чираттагы санында басылмаган.*
[2] Ноктаи нәзарендән – караштан.
[3] Матлуб – таләп ителгән.
[4] Тарыз – ысул.
[5] Мөләхәзәләремезне – уйлануларымызны.
[6] Халис – саф (бары тик).
[7] Ганганәтемез – традицияләремез.
[8] Әксәрият – күпчелек.

булучылыгы да керергә тиешдер. Ягъни безнең өчен ватанымызның миллиятләр федерациясе буларак идарә ителүе лябед[1] менәдер. Мәмләкәтдә мондый федерация була ала, фәкать, төп, баш идарә халык җөмһүрияте тарзында булганда гына – бу бер.

Без мөселманлар өчен Русиянең баш парламентында үз гадәдемезгә мөнасиб[2] санда вәкилләр булындыру өчен, безнең уйлавымызча, иң мөһим вә иң кирәкле чара сайлауларның пропорциональный (ягъни милләтләрнең гадәдләренә мөтәнасиб) булучылыгыдыр. Шушылай булмаганда, без ике якдан отдырабыз. Беренче, Урта Русия мөселманлары гаять вак-вак фиркаләргә бүленеп, башка милләтләр арасында әкаллиять[3] тәшкил итеп утырганлар. Сайлаулар катыш булганда, мондый фиркаләргә бүленеп утырган мөселманлардан вәкил кертә алу һәрвакыт башка милләтләрнең теләү-теләмәүләре белән баглы булып торачакдыр. Икенче, мондый әкаллиять тәшкил итә торган йирләрдә мөселманлардан вәкил сайлау мөмкин булган урынларда да, ул вәкилләрнең мөселманлар теләгән кешеләр булуларындан бигрәк, башка милләтләр өчен дә мәкъбуль булырлык кешеләр булучылыгы шарт буладыр. Бу хәл безнең милли мәнфәгатемез өчен зарарлы тәэсир итәргә мөмкин булган шикелле, безнең вәкиллеккә хәзерләнә торган кешеләремезне тәрбия җәһәтендә дә начар тәэсир итәчәк, үсә торган зыялы буынның хәзерләнүен икеләндерәчәк. Вә аның фикере барышына бер нифакъ[4] кертә алачакдыр. Менә шушы мөләхазәләр безгә сайлауларның катышы булмаучылыктан бәлки милләтләрнең гадәдләренә мөтәнасыйб рәвештә[5] булучылыкларын теләтдерәдер.

Безнең бу теләгемездә, фәкать, төп идарә халык җөмһүрияте тарзында[6] булганда гына мөмкиндер. Шулай итеп, безгә халис[7] милли бөтенлегемез ноктасындан гына караганда да, безнең өчен ватанымызның халык җөмһүрияте рәвешендә идарә ителүе матлубдыр[8].

---

[1] Лябед – котылгысыз.
[2] Гадәдемезгә мөнасиб – саныбызга туры килгән (нисбәтле).
[3] Әкаллиять – азчылык.
[4] Нифакъ – икейөзлелек, эчтән әшәкелек.
[5] Гадәдләренә мөтәнасыйб рәвештә – саннарына туры килгән.
[6] Тарзында – рәвешендә.
[7] Халис – чын, саф.
[8] Матлубдыр – таләп ителә, сорала.

Шуңа күрә хәзер бөтен Русия мөселманлары бер милләт булarak үзләренең тавышларын халык җөмһүрияте теләүчеләр тарафына кушылырга тиешләр.

## XIII

Кадетлар съездында Садри әфәнде Максудовның җиңел кулыннан мөселманларның бугаз һәм Истанбул мәсьәләләренә карашлары да хәтергә төшерелеп үтде.

Садри әфәнде ап-ачык сурәтдә Русия мөселманларының Истанбул вә бугазлар мәсьәләсендә кадетларга караганда бөтенләй башка төрле караганлыкларын игълан итде.

Бу игъланга әсасән[1] кушылмаска мөмкин түгел.

Ләкин Садри әфәнде, бу ап-ачык мәсьәләне гаять муаффәкыятьсез[2] бер дәлилгә терәп, гаять икънагъсыз[3] бер формулага куйды вә шуның белән, мәгаттәэссеф[4], мәсьәләне бик уңгайсыз хәлдә калдырды.

Садри әфәнде мәсьәләне дини әсаска куйды:

– Истанбул бугазларыны алырга, әлбәттә, омтылу – Русия мөселманларының дини хисләренә тия, – диде. Кадет хатибләрендән берсе моңар каршы бик җиңеллек белән җавап бирә алды гына түгел, бәлки Садри әфәнденең игъламын[5] бөтенләй зәминсез[6] калдырырга муаффәкъ булды; ул әйтә:

– Бугазлар вә Истанбул мәсьәләсендә без чыкмыймыз, бәлки Русия мөнәсәбәтенең икътизасындан[7] чыгамыз, шуңар күрә бу тугрыда безгә хәтер саклау мәсьәләсе уңгайсыз була. Андан соң Истанбул мәсьәләсенең мөселманларның дини хисләренә тәгаллекъ итмәгәнен[8] күрсәтер өчен гарәбләрнең Төркиягә каршы сугыш вакытында гыйсъян чыгарганлыкларын хәтергә төшерү йитәдер, – ди.

Һәм, чынлап да, мәсьәләне Садри әфәнде куйган зәмингә куйганда, кадет хатибының сүзләре бик урынлы чыгадыр.

---

[1] Әсасән – нигездә.
[2] Муаффәкыятьсез – уңышсыз.
[3] Икънагъсыз – ышанычсыз.
[4] Мәгаттәэссеф – кызганычка каршы.
[5] Игъламын – белдерүен.
[6] Зәминсез – нигезсез.
[7] Икътизасындан – таләп итүеннән.
[8] Тәгаллекъ итмәгәнен – бәйләнмәгәнен.

Безнеңчә, мәсьәлә бөтенләй икенче зәмингә куелырга тиешледер. Затән, безнең аңымыз вә идракемездә[1] бу мәсьәлә – бөтенләй икенче төрле урнашкан вә үзләштерелгән мәсьәләдер.

Сугышны «бөтен вак милләтләрнең истикълаллары[2]» исеменә дәвам итдерергә теләгән сымак булып күренергә тырыша торган империалист кадетлар бөтен ислам галәменә каршы гаять ачык икейөзлелек ясыйлар. Бөтен милләтләргә хөрлек, әмма төрек милләтенә, әмма иранлыларга – аларга коллык: Иран Англия белән Русия арасында бүленергә тиеш, моңар кадәр мөстәкыйль дәүләт булып килгән төрекләрдән бөтен истикълалларының иң ышанычлы бердәнбер терәге булган Истанбул вә бугазлык көчләп алынып, Русиягә кушылырга тиеш. Менә сугышка бу караш ап-ачык империалистлык карашы, бөтен кечкенә милләтләргә тәгъмим[3] итәргә тиешле хөрриятне бөтен ислам галәмендән суырып алу суи касд[4] бит. Менә шул карашка, мин кадетларның шушы сәясәтләренә каршы без, Русия мөселманлары, протест итми кала алмыймыз. Алар яхуд ачыкдан-ачыкга әйткәнләр ки, аларның кечкенә милләтләргә хөррият вә истикълал дигән сүзләре – үзләренең империалистик максадлары өчен кирәкле булган урынларда шундый хөррият дигән сүз, яхуд бу нифакълы[5] сүзләрен ташлап, тугрыдан-тугры үзләренең йөзләрен ачсыннар.

Садри әфәнденең кадетлар съездындагы бу сүзләренә каршы, мөселман фракциясе тирәсендә оешкан зыялылар вә җәмәгать хадимләре фиркасе гадәм риза әзһар итеп игълан таратды[1+]. Без дә бу гадәме ризага кушыламыз вә Садри әфәнденең бу съезддагы игъланын Русия мөселманлары тавышы түгел, бәлки хосусый үз тавышы уларак кына икърар итәмез.

## XIV

Русия мөселманлары, шималь төрекләре хакында сүз сөйләгәндә Төркестан мөселманларының хәлләре мәсьәләнең нәкъ урта бер йиренә куелмаска мөмкин түгелдер.

---

[1] Идракемездә – аңлавыбызда.
[2] Истикълаллары – азатлыклары.
[3] Тәгъмим – гомум.
[4] Суи касд – явыз ният.
[5] Нифакълы – икейөзле.

Төркестан – Русия дәүләтенә дәхел[1] төркиләрнең иң төп ватанлары, иң төпле урнашкан вә бөтен мәгънәсе белән оешып утырган йирләредер ки, монда утырган кардәшләремезнең хәлләре безнең өчен кызыксыз була алмый. Истигъдадлы[2], ерак тарихында шактый парлак бер мәдәни ганганәләре[3] булган Төркестан төркиләре безнең бөтен милли бөтенлегемезнең иң ышанычлы терәге, яхуд иң куркынычлы, зәгыйфь тарафы булып сәхнәгә чыга аладырлар.

Бөтен әтрафындан башка төрке милләтенә мәнсуб кабиләләр белән чолганып алган Төркестан, билахирдә[4], безнең милли терәклегемезнең иң чын мәркәзе булырлык шәраит[5] эчендәдер.

Русиягә табигъ[6] вә хәзергә кадәр әле рәсми рәвештә кәгадь өстендә, автономиягә малик булган Бохара вә Хива ханлыклары мондан соң чын-чынлап вә билфигыль[7] автономияле, йиргә баглы автономия белән автономияле булган кечкенә-кечкенә мәркәзләргә әйләнеп китә алырлык шәраит җәгърафия вә хокукыягә малик мәмләкәтләр булганлыкдан, болар белән чолганган Русия Төркестаны безнең өчен хосусый әһәмият кәсеб итәдер.

Иске хөкүмәтнең бөтен сәясәте әүвәлге мәдәни ганганәсен онытып, мәфлүҗ[8] хәлгә килгән Төркестанны мөмкин кадәр караңгылыкта вә наданлыкда калдырып, аны начар хөкүмәтләрнең мөстәмләкәләрен[9] идарә иткән рәвеш белән идарә итүгә вә, шулай итеп, Төркестанның бөтен йирле әһалисен чертеп мөнкарыйз итәргә[10] юнәлдерелгән иде.

Шул сәясәт мокътәзасы[11] буларак, иске хөкүмәт болар арасында ысуле җәдидә мәктәпләре ачылуга каршы бөтен көчен сарыф итде, шул сәясәтнең икътизасы буларак Төркестанда вөҗүдкә килергә теләгән милли матбугатның һәрвакыт тамырына балта чабып торды, шул ук сәясәтнең теләвенә бинаэн[12], Төркестанга Урта

[1] Дәхел – кергән.
[2] Истигъдадлы – сәләтле, булдыклы.
[3] Ганганәләре – традицияләре.
[4] Билахирдә – ахыр чиктә.
[5] Шәраит – шартлар.
[6] Табигъ – буйсынган, кергән.
[7] Билфигыль – чынлыкта.
[8] Мәфлүҗ – авыру, параличланган.
[9] Мөстәмләкәләрен – колонияләрен.
[10] Мөнкарыйз итәргә – юкка чыгарырга.
[11] Мокътәзасы – таләбе.
[12] Бинаэн – нигезләнеп.

Русия мөселманлары барып урнаша алмасын өчен кирәкле һәр чараларны күрә торды, шул сәясәтнең теләвенә күрә, Төркестан соңгы вакытка кадәр хәрби законлар белән идарә ителеп килеп, халкы бөтенләй бер Русия хөкүмәтенең әсирләре хөкемендә йөртелде. Иске хөкүмәт түрәләренең Төркестанда эшләмәгән золым вә җәберләре калмады, алар үз ватанларында үзләре килмешәк хөкемендә тотылдылар, аларны коруне вөстада[1] гына мөмкин булган җәзалар белән тәһдид итеп[2], инсаният хокукларындан тәмамән мәхрүм бер хәлдә тотдылар вә шулай итеп аларның бөтен мәдәни ганганәләрен үтерделәр, аларның бөтен кабилиятләрен мәфлүҗ хәлгә китерделәр, алардан бөтен тәшәббес вә тәрәккый куәтләрен суырып, сыгып алдылар. Шул эшләр белән алар тәмам телсез вә идарәсез бер хәлгә китереп йиткергәч, анда мөһаҗирләр тутырып, аларның гасырлардан бирле һәрбер карышын эшләб килгән йирләрен газаблап, талап алып килмешәкләргә өләшә башлап, йирле әһалине рус мөһаҗирләре кулында батраклар итеп калдыру юлында чараларга керешделәр.

Әлхасил, французларның үзләренең мөселман халыклы мөстәмләкәләре өстендә ижра иткән[3] вәхшәтләре иске хөкүмәт тарафындан Төркестан халкы өстендә дә эшләнә торды.

Бәйнелмиләл буенча автономияле булырга тиеш Бохара вә Хива мәмләкәтләре иске хөкүмәт тарафындан талантсыз, имансыз, гакылсыз, фәхешдән башка эш белми торган ханлары аркылы тәмам бер хәрабә хәленә китерелделәр. Иске хөкүмәт аларны шул ханлар аркылы талады, шул кодсиятсез фахешләр аркылы изде вә сытды.

Хода белә, әгәр бу инкыйлаб булмыйча, яңадан 25 ел бу хәл дәвам иткән булса, бу бичара мәмләкәтләр вә бичара Русия Төркестаны нинди мөдһиш[4] бер хәрабәгә әйләнер вә нинди бер терелмәслек рәвештә мөнкарыйз булып өлгерер иде.

Ходайның рәхмәте, тәкъдирнең бер шәфкате белән бүген ул коточыргыч албасты бөтен Русия өстендән ыргытылган да Төркестан өстендән төшәргә мәҗбүр булды.

Ләкин ул үзендән соң Төркестанны бер хәрабә хәлендә калдырды. Төркестанның бөтен әһалисе андан соң һушлары киткән хәлдә урынларында ятып калдылар.

[1] Коруне вөстада – урта гасырларда.
[2] Тәһдид итеп – куркытып.
[3] Ижра иткән – эшләгән.
[4] Мөдһиш – куркыныч.

Менә шул хәрабәне тәгъмир итү[1], менә шул һушсыз калган күп миллионлы халыкны һушка китерү өчен гаять күп хезмәт вә гаять зур гайрәт кирәкдер. Тарихның барышы, гомуми әхвальнең оешуы шул иҗади хезмәткә безне чакыра, шул иҗади хезмәтнең зур бер кыйсемен, шуның авыр башлангычын бездән, Урта Русия төркиләрендән, таләб итә; чөнки бу көндә без – Русиядәге төрки кабиләләрнең иң мәдәнисе, иң аңлысы вә зыялы көчләргә баерагымыз.

Хәзерге әхвальне аларга кирәкле рәвештә аңлатырга мөстәкыйд[2] бер халык булса, ул да – бездер. Аларны оешдырырга, аларга һушларына килергә әүвәлге ярдәмне бирә торган бер табиб булса, ул да бездән гыйбарәтдер. Без моны бер төркестанлылар монафәга[3] өчен генә түгел, бәлки үземезнең монафәгамыз өчен дә, бөтен милли монафәгамыз өчен эшләргә тиешләрмез.

– Мәсьәлә гаять олуг, гаять җитди вә шул нисбәттә һәм авыр мәсьәләдер.

Галимҗан Баруди хәзрәт, Гаяз әфәнде Исхаков һәм Казан мөселман комитеты тарафындан башланган вә оешдырыла торган, Төркестанга зур бер димләү, аңлату һәм эшкә башлау һәйьәте йибәрү мәсьәләсе, безнең игътикадымызча, түбәндәге мәсьәләләрнең иң әһәмиятле вә иң җитдиләрендәндер. Бу мәсьәләнең әһәмиятен без йөрәкләремез белән генә түгел, салкын гаклы мөхкамәмез белән дә яхшы аңларга тиешләрмез. Бу – безнең хәяти мәнфәгатемездер.

Шуңар күрә, без өмид итәмез, бөтен Урта Русия мөселманлары Казанның бу тәшәббәсенә кулларындан килгән микъдарда ярдәм итәрләр вә кушылырлар вә тиздән җыелачак мөселман съезды да мәсьәләгә даир үзенең игътибарлы сүзен әйтер.

## Вакытлы мөфти

Уфа әһалисендән бер кыйсем[4] халык 9–10 нчы мартларда мәҗлесләр ясап, Баязитов һәм Гыйниятулла казыйларның хәбес ителүләре[5] белән эшләүчеләре закон таләп иткән гадәддән аз булу сәбәбле, әһәмиятле эшләрдән тукталырга мәҗбүр хәлдә калган

[1] Тәгъмир итү – төзү.
[2] Мөстәкыйд – сәләтле.
[3] Монафәга – файда.
[4] Кыйсем – өлеш.
[5] Хәбес ителүләре – кулга алынулары.

мәхкәмәи шәргыяне эшне дәвам иттерергә мөстәгыйд[1] хәлгә китерү тугрысында киңәшкәнләр.

Аз гына гадәдле мөшарикләрдән[2] гыйбарәт бу мәҗлесләрдә фикер ике төрле булган: бер тараф хәзерге вакыттан ук, шушы мәҗлесләрдән үк мөфти урынына вакытлы уларак кеше сайлау һәм аның янына вакытлы уларак яңа казыйлар тәгаен кыйлыпб тору фикерен тәкъвия иткән[3].

Башларында Әбүссогуд әфәнде Әхтәмов булган икенче тараф исә, мәхкәмәи шәргыянең эчке Русия мөселманлары өчен уртак бер мәхкәмә икәнен хәтергә алып, аны Уфа әһалисе тарафыннан гына зур үзгәрешкә һәдәф итәргә[4] мөмкин түгеллекне бәян итә вә хәзергә әле иске низамларга[5] муафикъ рәвешдә, казыйлыкда сәбакате булган[6] Мамлиевне вакытлы уларак мөфтилек ләвазимен[7] үтәп торучы итеп калдырып, аның янына берме-икеме вакытлы казыйлар чакыру юлы белән генә эш күреп торырга, зуррак бер үзгәреш өчен башка тараф мөселманларының фикере белән хисаплашырга гарыз итә[8].

Кызу моназарәләрдән[9] соң, әүвәлге фикер тарафдарлары әксәрияте[10] тәшкил итәләр дә вакытлы мөфти сайларга керешәләр һәм, Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдов дигән бер кешене вакытлы мөфти итеп сайлыйлар...

Мондан әүвәл, Баязитов мөфти булып тәгаен ителмәс борында, Уфа халкы үз башына гына, башка әтраф халкы белән хисаблашмасдан, мөфтилеккә кандидатлар күрсәткән вә шундан соң мәсьәлә ихтиляфлы[11] булып чыккач, анда да, монда да вәкилләр чабдырып, үзләре күрсәткән кандидатларның башка әтраф мөселманлары тарафыннан да кабул ителүен таләп иткәнләр дә шуның белән мәсьәләгә әллә никадәр чуалчыклык төшергәнләр иде.

---

[1] Мөстәгыйд – сәләтле.
[2] Мөшарикләрдән – катнашучылардан.
[3] Тәкъвия иткән – куәтләгән.
[4] Һәдәф итәргә – монда: дучар итәргә.
[5] Низамнарга –тәртипләргә.
[6] Сәбакате булган – беренче урынны биләгән.
[7] Ләвазимен – (хезмәт) урынын.
[8] Гарыз итә – тәкъдим итә.
[9] Моназарә – дискуссия.
[10] Әксәрият – күпчелек.
[11] Ихтиляфлы – каршылыклы.

Тәәссефкә[1] каршы, бу юлда да, әүвәлге фикер тарафдарларының җиңүе белән шундый бер ашыгычлык эшләнгән; Әбүссогуд әфәнде тарафыннан гарыз ителгән бик әсаслы фикер, саклык белән хәрәкәт фикере, бик тәәссеф итәргә тиешдер ки, үзенә тарафдарлар җәлеб итә алмаган.

Әүвәлге фикернең хаталыгын иң ачык сурәтдә исбат итәргә кирәк булса, аның өчен Хөҗҗәтелхәким әфәнденең мөфтилек урынына сайлануын хәтергә алу кямилән йитәдер.

Мөфтилек урыны, вакытлы гына булганда да, милләтнең иң ихтирамлы вә иң әһәмиятле урынларыннан берседер. Ул урынга вакытлы куела торган кешенең дә, анда утырырга үзе риза булуы гына йитми, бәлки бик күп хасләтләрне малик кеше[2] булуы шартдыр.

– Уфадагы бер уч халык тарафыннан бу урынга сайланган Хөҗҗәтелхәким әфәнде кем ул? Нинди хасләтләре өчен аңар шушындый әһәмиятле вә тәрәддедле вакытда шундый әһәмиятле вә мәсьүлиятле урын бирелә?

Боларга җавап юк!

Бу әфәнде халкымызның гаммәсенә һичбер иҗаби[3] хезмәт белән танылмаган, гыйльми вә фикри куәте белән һичбер беленмәгән бер кеше булуы өстенә, мөфтилеккә риза булучылыгы белән, фәкать, үзенең артык вә әсассыз җөрьәтен һәм үз хакындагы мизанының бер якга салынкы икәнен генә күрсәткән әфәндедер.

Хәзерге көндә, мөфти урынындагы адәмнең милләтенең һәр табәкасы[4] арасында танылган вә игътибар җәлеп иткән, зур нөфүзле[5] адәм булуы иң мөһим шартлардан берседер. Хөҗҗәтелхәким әфәнде исә бу шартларның берсенә генә дә тугры килми. Аның моннан берничә еллар «Бәянелхак» гәзитәсендә чыга барган мәкаләләре вә соңыннан зур тавыш белән башлаган «Әлислах мәҗмугасы» – безгә аны иң гади вә күпдән чәйнәлеп беткән «тәрәккыйпәрвәр» сүзләрне бик яңа үзләштергән бер кеше итеп таныта ки, бу тип адәмнәр инде безнең яшьрәк авыл имамнарымыз арасында кирәгендән артык дәрәҗәдә күпләрдер.

---

[1] Тәәссефкә – кызганычка.
[2] Хасләтләрне малик кеше – сыйфатларга ия кеше.
[3] Иҗаби – уңышлы.
[4] Табәкасы– катлау.
[5] Нөфүзле – авторитетлы.

Шуңар күрә, Уфа әһалисендән моны мөфтилеккә сайлаган кешеләренең нинди бер әсасдан чыгып хәрәкәт итүләре безгә аңлашылмый, дөрестрәк тәгъбир белән әйткәндә, кирәкмәгән бер ашыгычлык вә кирәкмәгән бер җөрьәт булып күренә.

Болай итеп, халыкны булып беткән бер факт алдында торгызып калдыру юлы белән хәрәкәт итү – иң җиңел тәгъбир белән әйткәндә, әтраф халкы белән хисаблашырга теләмәүдән гыйбарәт дип әйтерлек эштер.

Милләтнең зур хезмәтләре сәбакать иткән голямасын, зур зыялыларын бер читдә калдырып, мәхкәмәи шәргыя эшләрендә катгый адымлар эшләүгә Уфаның бер кыйсем халкына һичберкем хак бирмидер.

Иң азында инде вакытлы мөфтилек урынына кеше дәшелгәндә, милләткә беркадәр хезмәте белән танылган кешеләр арасыннан, яхуд мәхкәмәи шәргыянең үзендә хөсне хезмәт белән танылган, эш белән таныш берәр кеше ихтияр итәргә кирәк иде.

Имеш дә Хөҗҗәтелхәким әфәнде үзе мөфти булырга риза булган! Без шөһбә итмимез ки, бездә, безнең үз дәрәҗәмезне зәгыйфь үлчи торган даирәмездә мондый риза булучылар меңләп кенә түгел, ун меңләп табылачакдыр ки, бу хасият мөфтилеккә сайланыр өчен бик аздыр.

Шуңар күрә, без, Уфа инде мөфтилек мәсьәләсендәге ашыгычлыгы белән икенче вә бик зур хата эшләде, вә шул хатасын ул үзе төзәтергә тиеш, булмаса, аны төзәтергә тәшәббес итүне[1] башкалар үз кулларына алырлар, димез.

## Корылтайда хатын-кыз мәсьәләсе

Июль ахырында Казанда башланып киткән өч съезд вә алар ахырына август башында ялганып киткән дүртенче съезд – болар һәммәсе һәятымызның төрле тарафларына тәгалликълы[2], гаять әһәмиятле, гайре мөтәнаһи мәсьәләләрне кузгаттылар вә алар хакында карарлар чыгардылар ки, аларның гаять төрлелекләре вә күплекләре вакытлы матбугатны алар артыннан өлгереп бара алу шәрәфендән мәхрүм итеп калдырдылар. Гәзитәләрнең көндәлек булмаулары вә микъдарларының кечкенәлеге бу тугърыда иң тә-

---

[1] Тәшәббес итү – тотыну, керешү.
[2] Тәгалликълы – бәйләнешле.

эссефле гамәлләр иде, шул сәбәп белән безгә ул мөһим милли мәсьәләләр тугърысында соңга калып, нәүбәт көтеп кенә үз мөләхазә вә үз карашларымызны язарга тугъры киләдер.

Шул мәсьәләләрнең берсе вә хәзерге көндә зури низагълысы икенче гомуми корылтаемызның хатын-кыз мәсьәләсе тугрысындагы карары иде.

Бу мәсьәлә тугрысында без хосусый тукталырга кирәк табамыз, чөнки күренә ки, икенче корылтайда бу мәсьәләнең ничек үтешен бик күп кешеләр, хосусән, уңлар вә суллар дөрест аңламаганлар һәм шул хата аңлау нәтиҗәсендә корылтайның мәркәзен тәшкил иткән фиркагә вә, шул җөмләдән, Милли Шура әгъзаларына һәртөрле шелтәләр йибәрүдән тартынмыйлар.

Вәлхаль, мәркәзнең бу мәсьәләдә үз-үзен тотышы гаять уйланган бер юл белән вә гаять гакыллы бер хаттыл-хәрәкә белән булды ки, әгәр мәркәз шуны эшли алмый калган булса, бу мәсьәлә гаять үткенләнеп китеп, милләт арасында зур тәфрикәгә[1] сәбәп була алачак иде.

Мәсьәлә болай булды:

Гомуми икенче корылтайның бу мәсьәлә мөзәкарә ителгән[2] мәҗлесенә гарыз итделәр:

1) Идарәи рухания гарыз итде.

Ул карар ляихәсенең мәфһүме әүвәлге корылтайның хатын-кыз мәсьәләсендәге карарын, ягъни бөтен сәяси вә гражданский хокукта вә, шул җөмләдән, мирас вә шәһадәт мәсьәләләрендә дә хатын-кызның тигезлеге карарын фәсех итеп, аның урынына хатын-кызга сәяси хокук бирү һәм әүвәлге съездның тәгаддеде зәүҗатене ган асыл[3] бетерергә дигән карарын бетереп, аны шәригать тәҗвиз кыйлган микъдар белән бик каты чикләүне идарәи рухания карамагына тапшырырга гарыз итүдән гыйбарәт иде.

2) Корылтайның мөхалифене фиркасе, ягъни үзләрен һәр мәсьәләдә без суллар дип игълам итүчеләр фиркасе итте.

Аларның карар ляихәсе буенча, беренче Мәскәү корылтаеның карары, ягъни хатын-кызның җәмигъ сәяси һәм гражданский хокукта вә, шул җөмләдән, шәһадәт вә мирас хакларында да мөсәватләре тугрысында карар вә тәгаддеде зәүҗатенең бөтенләй

---

[1] Тәфрикәгә – аерымлануга.

[2] Мөзәкарә ителгән – каралган, тикшерелгән.

[3] «Күп хатынлылыкны нигездә...»

бетерелүе карары куәтләрендә калдырылалар вә боларга һичбер төрле үзгәреш кертелми.

3) Корылтайдагы хатын-кыз фракциясе гарыз итте.

Бу карар ляихасе буенча, мөслимәләр җәмигъ сәясе хокукта вә шәһадәт һәм мирас мәсьәләсендән башка һәммә гражданский хокуклар да ирләр белән тигезләр. Тәгаддеде зәүҗәт мәсьәләсе иң күбендә бер рөхсәттән фаидәлану мәсьәләсе генә булганлыгыннан, милләт гомуми идеаллар наменә ул рөхсәттән фаидәләнүдән ваз кичәргә тиеш, ки бу Коръәнгә хилаф булырга мөмкин түгел.

Менә шушы өч карар ляихасенең һәр өчесе икенче гомуми корылтай мәҗлесендә тавышка куелып, иң соңгы өченчесе, ягъни хатын-кыз фракциясе әксәрияте тарафындан гарыз ителгәне корылтайның карары буларак, зур әксәрият белән кабул ителде.

Бу ни дигән сүз иде? Ни өчен корылтайның мәркәз фиркасе беренче, икенче ляихаләргә тавыш бирмичә, өченче ляихагә тавыш бирде.

Бу сөальгә җавап бирүдән әүвәл шуны әйтеп китәргә кирәк ки, корылтайга хатын-кыз мәсьәләсенең куелышы, аны әсасендән хәл итәр өчен түгел, ул сөальгә бер фәнни җавап бирер өчен дә түгел, бәлки хыялымызның иң үткен мәсьәләләрендән берсе булган ул мәсьәләне хәл итү юлында, сүи мәдәния вә фикриямез һәм шәраэте хәятиямез белән хисаплашканмыз, бер реальный адым атламак вә чын-чынлап шул үткен мәсьәләне милли әсасләремездән дә ерак китмәгән вә халкымызның икътидарындан тыш сикеренмәгән хәлдә хәл итә башлау өчен иде.

Шуңар күрә, корылтайның фикере барышын идарә итә торган мәркәзгә мәнсүб зыялылар кыйсеме бу мәсьәләгә тавыш биргәндә, үз-үзләренә:

– Мәсьәләгә әсасә ничек карарга кирәк? – дигән сөальне бирмәделәр, бәлки:

– Мәсьәләне нинди сәтыхка куелса, ул милләт өчен фаидәле рәвештә хәл ителә ала вә нинди тарафдан аңар килгәндә милләтнең гомуми барышына ярдәм ителә? – дигән сөальне бирде вә шуның буенча тавыш бирде. Затән, мәсьәләгә бердәнбер тугры караш шуннан башка нәрсә булырга мөмкин дә түгел иде. Чөнки бу корылтай нә дә бер дини вә фәләфи корылтай иде вә нә дә әсаси мәсьәләләр хәл ителә торган фәнни бер конгресс иде. Ул – бу көн алдымызга килеп баскан милли вә сәяси мәсьәләләрне бу көнге әхвальгә карап хәл итеп тору өчен төзелгән тәмам сәяси бер корылтай иде.

Мәсьәләгә шул карашны үзләштереп алгач та, мәркәз фиркасенә мәнсүб зыялыларның нинди юл белән барырга тиешлекләре үз-үзендән хәл ителде:

Мәскәүдәге беренче корылтайның хатын-кыз хакындагы карары үз хәлендә калдырыла алмый иде. Чөнки ул халкымызның сүи фикере белән мөтәнасыйб булмаганлыкдан милләт эчендә зур гаугага сәбәп булган иде ки, бу гауганы гаксел хәрәкәчеләремезнең үз кулларында иң куркынычлы сәяси корал итеп тота башларга омтылганлыгы инде ап-ачык күренә башлаган иде.

– Шуңар күрә, мәркәз «суллар» карар ляихасенә каршы тавыш бирде.

Идарәи рухания гарыз иткән карар ляихасе исә үзенең тәгоддод зәүҗәткә карашындагы катгыятсезлеге белән кирәк хатын-кызларымыз өчен вә кирәк зыялыларымыз өчен зәгыйфь күренә иде.

Затән, Урта Русия мөселманлары арасында бу мәсьәләне хәят инде хәл итеп бетергән дип әйтергә мөмкин. Шуны инде бер калыпка сугып, бер фикъһә үлчәүгә тыгарга вакыт йиткән иде. Бигрәк тә, бу мәсьәләдә милләтнең бөтен хатын-кызының бер тавышта икәнлеге шөбһәсез мәгълүмдер. Милләтнең шул ярымының тавышына ирләрдән тәгоддоде зәүҗәткә мөхалиф булган зур бер кыйсемнең тавышларын да кушкач, мәсьәлә чын-чынлап әксәрият белән вә мөнәфигъ инсания таләп иткәнчә хәл ителгән була. Мондый бер оҗмах, шөбһә юк, иң күбендә дин тарафындан рөхсәт ителгән бер нәрсәдән ваз кичәр өчен тәмама кафидер.

Менә шуңар күрә, мәркәз зыялылар идарәи рухания гарыз иткән карар ляихасенә дә каршы тавыш бирде.

Идарәи руханиянең ляихасе итмәгәч анык әгъзаларына вә шул җөмләдән мөфти хәзрәткә дә урынларындан истигъфа итәргә тиеш булу ихтималы корылтайның мәркәзе өчен зур истихалә иде. Әүвәлге корылтай тарафындан сайланган идарәи руханиямезнең урынында калуы мәркәз өчен матлуб иде. Шунлыктан мәркәз идарәи руханиянең карар ляихасенең үткәрелмәвен аңар әмниятсезлек изһар итү[1] түгел, бәлки хосусый бер мәсьәләдә ихтиляф әфкяр генә дип икърар итәргә үзенә тиеш күрде вә мәсьәләне аңламыйча корылтайны чуалырга йөрүче берничә шәхес тәэ-

---

[1] Әмниятсезлек изһар итү – ышанычсызлык белдерү, күрсәтү.

сиренә бирелгән бер кыйсем солдатларның мәҗлесне ташлауларына рәгъмән[1] корылтай зур бер әксәрият белән идарәи руханиягә имният изһар итте. Вә шулай итеп һәм идарәи рухания урынында калды вә һәм хатын-кыз мәсьәләсендә урта вә гакыллы бер карар чыгарылды.

## Оят булды!

Икенче гомуми мөселман съездының пәнҗешәнбе көнге мәҗлесендә өстән караганда кечкенә генә, ләкин әсасән караганда, бик зур вә йөз кызартырлык оятлы бер вакыйга булып узды. «Шураи милли» исеменнән аның эшләре хакында доклад укучы Мамлиев әфәнде һәм аның артыннан тагы бер озын бәянәт[2] бирүче Тукумбитов әфәнде, һәр икесе бер дә заруриятсез нотыкларын русча сөйләп, «купшыландылар». «Купшыландылар» дим шунлыктан, чөнки без ике егетнең һәр икесе кирәксенгән вакытларында бик аңларлык итеп, татарча сөйли алалар. Бу ике егетнең һәр икесе съездга хәзер булган вәкилләрнең, бер-ике истисна[3] белән, һәммәсенең төрек-татар балалары вә төрек-татар теле аларга ана теле икәнлеген бик яхшы беләләр; бу ике егетнең һәр икесе милли мохтариятнең иң зур терәге ана теленең истигъмальдә[4] булуы вә аның әфраде милләт[5] арасында гына түгел, хәтта бөтен мәмләкәттә мәгъруф вә мөстәгъмәл[6] булуы тиеш икәнен дә бик әгъла[7] беләләр... Һәммәсен, һәммәсен беләләр, ләкин шулай да алар Милли мохтарият игълан иткән милләт съездының иң эшлекле мәҗлесләреннән берсендә үзләренең бәянәтләре өчен рус телен ихтыяр итәләр, чөнки йекетләр – купшы!

Интеллигентному человеку как-то неудобно объясняться на каком-то там татарском языке.

Халыкның бер кыйсеме, табигый, бу купшылыктан һәяҗанга килә[8]; өч-дүрт көн генә әүвәл Милли мохтарият игълан иткән мил-

---

[1] Рәгъмән – карамастан.
[2] Бәянәт – аңлатма.
[3] Истисна – чыгарма.
[4] Истигъмальдә – кулланылышта.
[5] Әфраде милләт – милләттәшләр.
[6] Мәгъруф вә мөстәгъмәл булуы – танылуы һәм кулланылуы.
[7] Әгъла – яхшы.
[8] Һәяҗанга килә – аптырап кала.

ләтнең гомуми съездында шул милләтнең үз балаларының бу кыйланмышлары мантыйксыз, мәгънәсез вә хәтта ахмаклык урынында тәләкъкый ителә[1]. Тукумбитов әфәнде бу тугрыда моназарага[2] керә. По-русски мне легче говорить, ди.

«Гозере – гаебеннән кабәхәт!» – диясе килә, моны ишеткәч.

Менә шул вакытта съездда йөз кызартырлык вакыйга була: Тукумбитов әфәнде үзенең нотыкының нинди телдә дәвам иттерелүе матлуб икәнлек хакында тавышка куйдыра, рәис шуны тавышка куя, артта ниндидер шәхесләр «по-русски, по-русски» итенгәләп, купшы тавышлананалар. Имеш тә алар да русча аңлыйлар, имеш тә аларның «мәдәни вә зыялы» икәнлекләре бер дә шөбһәсез имеш тә, алар тәмам өлгереп йиткән «абразауный» кешеләр булганнар инде имеш тә, алар белән син инде не шути.

Менә шул әфәнделәрнең тавышлары белән съезд Тукумбитовка нотыкын русча дәвам иттерергә карар чыгара.

– Йә Алла! Бу мәҗлестә булмаган кешеләр нинди бәхетлеләр: бу позорны карап утыру һәм оят һәм ачы иде! Бу бер Тукумбитов ояты булудан чыгып, съезд әксәриятенең[3] оятына вә аның хурлыгына әйләнгән вә барымыз өчен йөз кызыллыгы булып әверелгән иде.

Монда күңел җуата торган бер нәрсә булса, ул да зыялы җәмәгать хадимнәремездән Гомәр әфәнде Терегуловның бу хактагы кызу вә самими нотыкы булды. Ул, мең мәртәбә хаклы буларак, гаять иске вә шуның белән бергә съезд әксәрияте өчен өр-яңа бер хакыйкатьне әйтте:

– Үз ана телләрендә сөйли дә белмәгән кешеләр съездларга вәкил булып килмәскә бурычлылар иде! – диде ул. Гомәр әфәнденең кызу протесты[4] булмаса, бу оят безнең зыялыларымызның ояты вә аның хурлыгы булачак иде.

Русия мөселманнарыннан булып та, төрек-татар милләтенә мәнсүб булмаган ислам кардәшләремезгә, яхуд шивәләре съезд әксәриятенә бик үк аңлашылып йитмәслек вәкилләргә рус телендә сөйләүләре өчен без һичбер сүз әйтмимез, әйтергә хакымыз юк!

---

[1] Тәләкъкый ителә – кабул ителә.
[2] Моназарага – бәхәскә.
[3] Съезд әксәриятенең – съездда катнашучыларның күпчелегенең.
[4] Протесты – газетада: пранситы.

Ләкин рус телен дә бу көндә мөселман съездларында купшылык урынында истигъмаль итүчеләргә без:

– Оят, господа хорошие! – дими кала алмыйбыз. Сөйләшер кадәр ана телләренә өйрәнергә дә теләмәгән кешеләрнең милли вә мәдәни мохтарият тугрысында сөйләүләрен мантыйксызлыкка саныймыз!

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәрләре З. Рәмиев, А. Мөбарәкшина, А. Әхмәтова, Н. Насыйбуллина әзерләде*

**Аңлатмалар һәм искәрмәләр**

11 бит.

**Сәясәт галәмендә.** «Әлислах» газетасының 1907 елның 17 декабрь (11 нче) санында «Ф.» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

«Әлислах» – Казанда татар телендә 1907 елның 3 октябреннән 1909 елның 22 июленә кадәр нәшер ителгән газета (барлыгы 68 сан); нашире һәм редакторы – Вафа Бәхтияров, асылда ул Ф. Әмирхан җитәкчелегендә чыгып килгән, төп автор да – ул.

12 бит.

**Беренче Дума әгъзаларына хөкем.** «Әлислах» газетасының 1907 елгы 24 декабрь (12 нче ) санында «Ф. Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1+] әүвәлге парламент – Беренче Дәүләт Думасы 1906 елның 27 апреленнән 9 июленә кадәр эшли.

15 бит.

**Гаспринский юбилее.** «Әлислах» гахзетасының 1908 елгы 25 март (24 нче) санында «Дамелла» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

«Тәрҗеман» газетасы Кырымда (Бакчасарай шәһәрендә) Исмәгыйль Гаспринский (Гаспралы; 1851–1914) наширлегендә һәм редакторлыгында чыккан.

17 бит.

**Мәдрәсәләрне берләштерү (Без 27 номеру ...).** «Әлислах» газетасының 1908 елгы 27 апрель (28 нче) санында имзасыз гына чыккан. Текст шуннан алынды.

[1+] «Мәдрәсәләрне берләштерү (25 нче номеру «Әлислах»да ...)» дип исемләнгән ул имзасыз мәкалә «Әлислах»ның 1908 елгы 19 апрель (27 нче) санында басылган.

18 бит.

**Мәдрәсәләрне берләштерү (Без үткән номерда...).** «Әлислах» газетасының 1908 елгы 4 май (29 нчы) санында «28 номердагы мәкаләгә гыйлавә» дип искәртелеп, имзасыз гына чыккан. Текст шуннан алынды.

[1+] Мәсәлән, Газетаның 27 май (31 нче) санында Казандагы Татарская учительская школа (Татар укытучылар мәктәбенең) программасы бирелгән.

20 бит.

**«Әлислах»тан ни көтәргә ярый?** «Әлъислах» газетасының 1908 елгы 20 июль (38 нче) санында басылган. Текст шуннан алынды.

22 бит.

**Гыйбадәт.** «Әлислах» газетасының 1908 елгы 13 ноябрь (51 нче) санында «Ф.Ә». имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

22 бит.

**Минем тәрҗемәи хәлем.** «Фәтхулла хәзрәт» повестеның Беренче җөзьәсендә (Казан: наширләре «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе», 1911; мөхәррире «Ташмөхәммәд») әсәр тексты алдыннан басылган. Ике томлы «Сайланма әсәрләре»нең 1 нче томына (Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1957) кертелгән.

[1+] таңында тудым. – Ф. Әмирхан 1886 елның 13 гыйнварында туган.

[2+] «Дин вә мәгыйшәт» айгыры – «Дин вә мәгыйшәт» журналында редакторларыннан берсе үзенең мәкаләсендә: «Бозыклыкның башы – хатын-кыз, ирләрнең азгынлыгы шулардан килә. Хатын-кыз ирләргә күренмәскә тиеш. Без, аларны күргәч, үз-үзебезне тыя алмыйбыз», – дип язып чыкты. Шуннан соң татар матбугатында бу дини журнал фикерендә торучы кешеләрне, мыскыллап, «Дин вә мәгыйшәт» айгырлары дип атап йөртә башлыйлар.

32 бит.

**Балаларга бәйрәм.** «Аң» журналының 1913 елгы 4 нче (1 февраль) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

34 бит.

**Муса әфәндегә җавап.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 29 март (84 нче) санында «Ташмөхәммәд» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

36 бит.

**Мәхмүд Әсгадь әфәнде хәзрәтләре белән «Кояш» сайфиясендә мөсахәбә.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 5 август (188 нче) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Газетаның 4 август (187 нче) санындагы «Казан хәбәрләре»ндә («Мөхтәрәм кунак» исемле язмада) «Истанбулда Дәфтәр хаканы Әминә вә дарелфөнун мөдәррисләрендән Мәхмуд Әсгадь әфәнде җәнабләре кичә иртә белән сәгать алтыда шәһәремезгә тәшриф итеп (килеп) кичке сәгать унда Нижнийга сәфәр итте. Мәхмүд Әсгадь әфәнде илә мөсахәбәмез тәфсилен киләчәктә язармыз» диелгән була.

Мәхмүд Әсгадь – галим, хокук белгече, университет укытучысы, язучы, дәүләт эшлеклесе (1857–1917 елларда яшәгән).

40 бит.

**Хыял галәмендән.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 20 август (198 нче) санында «Ташмөхәммәд» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

41 бит.

**Кызганыч бер тәнасеб.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 9 октябрь (238 нче) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

43 бит.

**Дини мәктәп һәм мәдрәсәләр хакындагы истифсарга даир.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 15 октябрь (243 нче ) санында «Ф.Ә.» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[1+] 237 нче номерында дәреҗ ителгән иде. – Газетаның бу санындагы «Дахили хәбәрләр» бүлегендә «Мөселман рухани мәктәпләре» исемле хәбәр басылган. Анда «Идарәмезгә алынган хәбәргә күрә, Рухани эшләр департаменты директоры, мөфти хәзрәтләренә мәктүб язып, ... дин кагыйдәләрен өйрәтү вә дини тәрбия бирүләре өчен нинди эшләр илә мәҗбүр ителүләре хакында тиз заманда мәгълүмат бирүеңне үтенәмен» диелгән.

45 бит.

**Коръән бозу.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 14 ноябрь (264 нче) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән чыккан. Текст шуннан алынды.

47 бит.

**Харитонов җавабы мөнәсәбәте белән.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 2 декабрь (276 нчы) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән «Коръән бозу мөнәсәбәте белән» рубрикасында басылган. Текст шуннан алынды.

Бу рубрикада ахунд Сәлимов, Шакир СӘлимов, Ибраһим Галиев, Х.Еникиев, Закир Галиев, Шакир Әхмәдов, Бастановларның «Чиләбе. – Кәляме Шәрифне тәхриф итү мөнәсәбәте белән Харитоновка протест итәмез һәм аның мөхакәмәгә (хөкемгә) бирелүен таләп итәмез» дигән «Идарәгә телеграм»нары да басылган.

50 бит.

**Мөфти хәзрәткә бердәнбер юл.** «Кояш» газетасының I913 елгы 6 декабрь (280 нче) санындагы «Киңәш мәҗлесен җыймый калдыру» рубрикасында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

54 бит.

**Бездә вә кардәшләремездә сөтрә мәсьәләсе.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 11 декабрь (284 нче) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән чыккан. Текст шуннан алынды.

56 бит.

**Мәгънәсез тәкълид.** «Кояш» газетасының 1914 елгы (335 нче) санында «Фатих Әмирхан» имзсы белән басылган. Текст шуннан алынды.

58 бит.

**Наилбәк һәм иптәше белән мөсахәбә.** «Кояш» газетасының 1914 елгы 28 апрель (399 нчы) санында «Ф.» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Газетаның 22 апрель (394 нче) санындагы»Казан хәбәрләре»ндә «Төркиянең Укаф нәзарәтенә табигъ мәктәп, мәдрәсә вә көтебханәләр мөдире Наил Рәшид бәк илә аркадашы Гомәр әфәнде бин хаҗи Рамазан җәнабләре берничә көндән бирле шәһәремездә мөсафирлардыр. Аларның шәһәремезне тәшриф итүләре (күрүләре, булулары) мәстәшрикъ Катанов көтебханәсен сатып алмак максады иләдер. Килгән көннәрендән бирле мәзкүр көтебханәдәге китапларны тәфтиш итмәк илә шөгыльләнмәктәдерләр» диелә.

61 бит.

**Беренче шәүвәл, шинбә көн.** «Кояш» газетасының 1914 елгы 8 август (480 нче) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

64 бит.

**«Йолдыз»га җавап.** «Кояш» газетасының 1914 елгы 10 сентябрь (506 нчы) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

66 бит.

**Олуг милләтче тугрысында кечкенә бер хатирә.** «Аң» журналының 1914 елгы 18 нче (сентябрь) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

Исмәгыйль Гаспринский (Гаспралы) 1914 елның 11 сентябрендә вафат була. Истәлек шул уңай белән язылган. Ф. Әмирхан аның белән Петербургта вакытында очраша. Бөтенрусия мөселманнарының II съездына (1906 ел. 12–23 гыйнвар) Ф. Әмирханны Казандагы «Ислах» комитеты Казан шәкертләре исеменнән җибәргән була.

68 бит.

**Хурлык сәнәде.** «Кояш» газетасының 1915 елгы 30 июль (762 нче) санында «Ф.Ә.» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

69 бит.

**Хәррәфуль кәлям ган мәвазыйгиһи.** «Кояш» газетасының 1915 елгы 11 август (770 нче) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

«Вакыт» газетасының 1915 елгы 6 август (1838 нче) санында «Ф.К.» (Фатих Кәрими) имзасы белән басылган «Гәзитәләр арасында» исемле мәкаләдә, аерым алганда: «Инде “Кояш” рәфикымезгә килгәндә, аның бәйрәм номерында Фатих Әмирханов “Мәдәни ганганәсезлек хурлыгы” гонванлы озын бер мәкалә язып, вакыты әллә качан үткән мөфти әфәнденең “Мәдрәсәи галия”ләрендән вә аның критикадан түбән булган календарьларындан-фәләндән бәхәс иткәндән соң “Вакыт”да Камил әл-Мотыйгый фельетоны язылуга кагылып үтә вә: “Аны басу ничөндер “Угодно было”, ди.

Югарыдан бирле язып килүләремездән аңлашылса кирәк ки, бездә һич нәрсә берәүнең күңеле, хатере ичүн басылмый. Һич мөнәсәбәтсез уларак бер гәзитә мөхәрриренең фикерендә шундый нәрсә эзләү матбугат әдәбенә хилаф булу өстенә, ул кешенең үзенең шул “угодно было”лар ичүн язу гадәте барлыгын күрсәтмәктәдер.

Рәфикъларымыз хакында безнең күңелгә андый нәрсә килгәне юк вә рәфикъләремезгә: ничөн аны басасыз, ничөн моны басмыйсыз, дип әйтергә вә бу хакта аларга дәрес биреп гакыл үгрәтергә дә керешкәнемез юк», – диелә.

74 бит.

**Инкыйлаб вә без.** «Кояш» газетасының 1917 елгы 7,9, 12, 14, 17, 19, 21, 23, 30 март һәм 4,9, 11 апрель (1089, 1090, 1091, 1092, 1093, 1094, 1095, 1096, 1097, 1099, 1101, 1103, 1104 нче ) саннарында имзасыз, 12 март (1091 нче ) санында «Фатих» (Әмирхан) имзасы белән басылган (XI кисәге газетада чыкмаган). Текст шулардан алынды.

103 бит.

**Вакытлы мөфти.** «Кояш» газетасының 1917 елгы 23 март (1096 нчы) санында «Фатих» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

106 бит.

**Корылтайда хатын-кыз мәсьәләсе.** «Кояш» газетасының 1917 елгы 6 август (1148 нче) санында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

110 бит.

**Оят булды!** «Кояш» газетасының 1917 елгы 1 август (1146 нчы) санында «Ф. Әмирхан» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Аңлатмалар һәм искәрмәләрне ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре З. Рәмиев әзерләде*

## ФАТИХ ӘМИРХАНГА ЯЗЫЛГАН ХАТЛАР

Ф. Әмирханның зур югалтулар аша безнең көннәргәчә килеп җиткән кульязма мирасы аңа язылган хатларны да үз эченә ала. Аларның бер өлеше Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Ф. Әмирхан фондында (16 ф., 3 тасв.) саклана. Биредә 1902 елдан 1926 елга кадәр вакыт арасында язылган 90 га якын хат теркәлгән.

Ф. Әмирханга язылган хатлар илнең төрле төбәкләреннән, шәһәр-авыллардан әдипнең дуслары, хезмәттәшләре, фикердәшләре тарафыннан юлланган. Алар Ф. Әмирханның шәхесенә, аның иҗатына мөнәсәбәтне тулырак күзалларга ярдәм итә.

Күп кенә хатларны Ф. Әмирханның «Әлислах» газетасының рухи-мәгънәви җитәкчесе булуы берләштерә. Алардан күренгәнчә, мәдрәсәләләрдә укытуны яңарту максаты белән Себер шәһәрләренә чыгып киткән мөгаллим, журналистлар Ф. Әмирхан белән һәрдаим хатлар алышып, яңалыклар белән уртаклашып яшәгәннәр. Шундыйлардан Ерак Себердә (Ачинск, Чита, Иркутск, Благовещенск, Хабаровск һ.б. шәһәрләрдә) эшләгән мөгаллим, журналист Ризван Алуши һәм аның хатыны Фәрханә Алушилар, шулай ук Себер шәһәре Томскида балалар укыткан җәмәгать эшлеклесе, педагог, журналист Ибраһим Бикколовларның хатлары игътибарга лаек. Ф. Әмирхан аларга Казанда чыккан «Әлислах» газетасын Себер халкы арасында тарату өчен күпләп җибәреп торган. Әдип, педагог, журналист Борһан Шәрәф үзе эшләгән «Хөсәения» мәдрәсәсендәге яңалыклар белән әдипне таныштырып барган.

Дуслары, фикердәшләре Ф. Әмирханга киңәш-ярдәм сорап та мөрәҗәгать иткәлиләр, язучының басылып чыккан әсәрләре хакында фикерләрен дә белдереп баралар. Гомумән, һәр хат язма мирасыбызның кадерле бер кисәге булып тора.

Кульязмалардан күренгәнчә, хатларның күбесе гарәп графикасында, татар телендә язылганнар. Шулай ук кирилл хәрефләре белән рус телендә язылганнары да бар. Күбесенең кем тарафыннан

язылган булулары билгеле булса да, араларында авторлары ачыкланмаганнары да шактый.

Хатларның беркадәре, өлешчә укылып, И. Нуруллинның «Ф. Әмирхан. Атаклы кешеләр тормышы» дип исемләнгән әдәби-документаль хезмәтендә чагылыш тапкан.

Әлеге җыентыкта гарәп графикасында язылган хатларның зур өлеше гамәлдәге язуга күчерелеп, текстологик яктан эшкәртелеп тәкъдим ителә.

## Борһан Шәрәф хаты

Казан
1 апрель, 1907 ел

Газизем Фатих!

Синең белән тәбаделе хиссиятдан[1] күбдән бирле мәхрүм торам. Ялкаулыкдан катгы назар[2] язу минем өчен тәфһимдә касыйр[3]. Чөнки чын күңелдән сөйләнә торган сүзләрне уен-көлке арасына гына катыщдырып әйтеп йибәрергә кирәк (1 нче апрельгә ышанып сөйләп булмый. Ул елда бер генә килә). Чынлап сөйләсәң, гак буласын[4], тәрбиясез буласын, бәрәкәтсез, өмидсез, ышанычсыз буласын, кяфер буласын, тагын әлләниләр буласын. Мин бөтен игътикадларым[5] (илхадларым)ны[6] игътибар итдекем кеби күренгән күб шәйләр, күб кешеләргә чынлыкда бик өстән, бик мәсхәрә илән каравымны мәңгегә яшереп тора алмам. Хәер, мин яхшы мәләкәле[7]. Тора алырмын. Ләкин мин инде аны теләмәскә тиеш.

Хәзердәге кеби әллә нindәй мөтәнакыйз игътикаддагы[8] кешеләргә һәммәсенә үземне яхшы күрсәтергә маташу бинаән галәйһи[9] җидди бер мәсләке махсус[10] илә эшкә тотынмауга инде хатимә[11] чигәргә кирәк. Мин искечә барсам, сезгә бик мәгълүм

---

[1] Тәбадәле хиссиятдан – хисләр белән уртаклашу.
[2] Ялкаулыкдан катгы назар – ялкаулыкка карамастан.
[3] Тәфһимдә касыйр – җитәрлек булмаган аңлату.
[4] Гак буласын – фетнәче буласың.
[5] Игътикадларым – ышануларым.
[6] Илхадларымны – тулы юлдан тайпылуларымны.
[7] Мәләкәле – осталыклы.
[8] Мөтанакыйз игътикаддагы – каршылыклы ышанудагы.
[9] Бинаән галәйһи – шуның өчен.
[10] Мәсләке махсус – махсус ысул.
[11] Хатимә – азак, эпилог.

Хәйрулла Сабитов, Исмәгыйль Рәхмәтуллинлар тибы булып калуым ихтимал: ягъни һәр нәрсәдән хәбәрдар (?), һәр мәҗлескә сыя, юаш кешегә зарарсыз... тагын бераз тәрәкъкый итсәм, Хәлил казый кеби булырга мөмкин: ягъни һәркемгә һәмфикер[1], сер сүз сөйләшә, кем ни әйтсә, шуны бик мәгъкуль күрә[2], һәркемгә ярый... Хакыйкать, бер эш дә эшләмәсә дә, һәр эшкә катышкан була ... ләкин үз файдасыны кешегә зарар булса да онытмый. Һәммә сүзне уйлаганча батырлык илән сөйләп бетерсәм дә, эш эшләмәенчә файда чыкмас бит! Ул вакытда мине Ибраһим Шәүкәт, Лотфи Исхаков, хәтта Камилил әт-Төхфәтуллиләргә[3] ошатып, шулар рәтендән саный башларлар. Моны да сөймим. «Казан мөхбире» киткәч, чынлаб (бик чынлаб) укырга тотыныйм микән дип тә уйлаган идем. Бер дәрәҗә тәмам итәрлек сөбат[4] вә иҗтиһадым[5] барлыгына ышанмадым. Бик күбләр кеби мин дә «готовиться» итеп кенә йөрермен дип уйладым. Сәяхәт итәргә дә ният итдем дә, алай да «Карчыга»дагы Бәдигъ мәзин күркәсе булудан котылуыма ышанмадым. Бу фикерләремнең һәр каюсының арасында берәр (бәлки берәр [...] илә) өйләнергә дә уйлап карадым. Бәлки андан соң күңел бик күб чубарлана алмас иде. Ягъни эскәнҗәгә[6] кысылыр иде. Андан соң «Әйдә эшлә! Фаразлардан тамак туймай» диярләр...

Мәга залик[7] кызларга ихтирамымлә бәрабәр аларга бик ихтият илә[8] мөгамәлә иткәнем сиңа мәгълүм. Шунлыкдан, бер кызга чынлап күңел утыртып предложение ясарга биреп беткәнем юк. Берсенә карар бирмәү башкалар кала дип түгел, бәлки берсе бәйләнә дип. Әле бит хатын гына булса бер хәл иде. Андан соң кайнана, кайната, кодача, кодагый.. гайре мөтәнаһи[9] әллә ниләр була. Андан соң «инде ул килешми...»ләр бик күбәя... менә бәла. Хәер... төрмә дә катор да, вакыйгда[10], читдән күренгән шикелле үк куркыныч

---

[1] Һәмфикер – фикердәш.
[2] Мәгъкуль күрә – лаеклы күрә.
[3] Камил Төхфәтуллиннарга.
[4] Сөбат – ныклык.
[5] Иҗтиһадым – тырышлыгым.
[6] Эскәнҗәгә – кыскычка.
[7] Мәга залик – шуның белән бергә.
[8] Ихтият илә – саклык белән.
[9] Гайре мөтәнаһи – чиксез.
[10] Вакыйгда – чынлыкта.

түгел имешләр икән, шайтан тугрысында да русда шундый мәкаль бар[1]. Бәлки өйләнү дә шулайдыр ... Әллә бу сүзләр «жених» кешегә бер дә килешмиме? Ул бик матур хыяллар илән генә йөрергә кирәкме? Шулай булса, язармын. Иң элек, кемгә предложение ясарга теләгәнемне бу хатымда язмыйм. Элек, принципиально, ничек киңәш биргәнеңне ишетергә кирәк. Син, ничә айдан бирле, әүвәлгә башка бер хәятдә гомер кичергәч, бәлки искедәгечә, икемезне бер кандала ашаганны тиз хәтерләмәссен! Сиңа Фатих әфәнде! Яисә товарищ Фатих! дип хитаб кылырга[2] кирәк булыр. Простой гына (Фатих!) бәлки аз күренер. Алай булса инде (әлбәттә, булмас дип ышанам) потальле[3] дәгъватнамә генә йибәрергә кирәк була. Анда исеме язылмыячагы мәгълүм йа...

«Казан мөхбире» ничек беткәнен, ягъни Сәйдәшкә күчкәнен миндән хәбәр аласың килә торгандыр. Сәедгәрәй, Бәһрамгәрәй һәм Сарегаскәргәрәй илә бертуган икәне сиңа мәгълүм булганга, бу хосусда да әсаси[4] мәгълүматыңыз бар. Шуңа күрә эшнең сурәтене генә бәян кирәк. Ләкин аны да тел белән сөйләшү яхшы булыр иде, дидем ки «язу касыйр[5]». «Мөхбир»нең Мөхәммәджан Сәйдәшевкә күчүендә яман авызлы кешеләр «Алкин[6] карта уйнаб оттырган» дип сөйлиләр. Без инде, әлбәттә, аңа ышанмыйбыз. Ләкин мөгамәләнең Черек күл ресторанында кабинетында иртә 4 сәгатьдә бутылкалар хозурында беткәне сабит[7]. Моңа гаҗәбсенергә ярамый. Һәрбер зур әһәмиятле мөгамәләи тиҗарияләр[8] шундай урында эшләнәләр. Һәм Алкин (шаярып гына булмаса) чынлап «Казан мөхбире»не картага салырга да мөмкин түгел. Чөнки ул аны «Иттифак» ширкәтенә тәмам тәслим итеп[9], мөселманча язышып, кул да куйган иде. Бары «Иттифак» ширкәте рәсми игъ-

---

[1] *«Не так страшен чёрт, как его малюют» мәкале күздә тотылса кирәк (Г. Ханнанова искәрмәсе).*

[2] Хитаб кылырга – мөрәҗәгать итәргә.

[3] Потальле – бай бизәлгән.

[4] Әсаси – төпле.

[5] Касыйр – кыска.

[6] *Биредә сүз хокук белгече, нашир, публицист, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Алкин Сәетгәрәй Шаһиәхмәт улы (1867–1919) турында бара.*

[7] Сабит – шиксез.

[8] Мөгамаләи тиҗарияләр – сәүдә эшләре.

[9] Тәслим итеп – тапшырып.

лан иделмәгәнгә, нотариусда да язышу бер-ике көн кичекдерелгән иде. Мөселманларга бик хәерхаһ Михайло шул форсатдан истифадә итеп[1], гәзитәнең ширкәткә бирелүенә күрә, бетерелүе файдалырак булганны дустанә, мөхәрәманә[2], хәерхаһанә[3], хосусый уларак гайре рәсми[4] Сәедгәрәйгә аңлаткан. Ул да бу арада аның һәр фикерене (яңыдан кайтып) мәгъкуль күрә[5] башладыгындан, гәзитәне ширкәткә бирмәскә, бәлки бетерергә мәгъкуль күреп ярар, ярар дигән. Бөтенләй җавып бетерелсә, «Казан мөхбире»ндә хезмәт итүчеләр аны чыгара башлыячак. Михайло аны теләми. Бетерер өчен, бөтенләй игътибардан төшереп бетерер өчен, иң муафикъ[6] хәрәкәт – Сәйдәшкә бирүдер. Чөнки ул бик күб-күб ширкәтләр, тиҗарәтханә[7], сәнагатьханәләрне[8] эзен калдырмаслык бетереп, үзенең тәҗрибәсен күрсәткән кеше. Бу мәсьәләдә йитәр.

«Ислах»да кешеләр калмау Казан шәкердләрене чубалтды. Әллә нинди яңа союзлар ясагалап маташалар. Эш чыкмый (май булса ботка пешерер идек дә, җарма юк). Исмәгыйль хәзер дә Ялтада. Адресы: Метрополь номерлары.

«Тәрбияи әтфаль» күбдән килгән юк. Матбага забастовкаларындандыр дип уйлыймыз. Гыймад кайтды. Габидовларда тора.

Заһид әфәндейә ихтирам гарыз идәм[9].

Кулыңны кысам. Хуш саг ул, хуш.

Бакый өмид. Сәнең Борһан.

Хат 1907 елның 1 апрелендә Ф. Әмирханга журналист, педагог, җәмәгать һәм мәдәният эшлеклесе Борһан Шәрәф (1883–1942) тарафыннан язылган. Хат «Г. Шәрәф» типографиясенең логотиплы бланк кәгазенә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 3 биттән гыйбарәт.

---

[1] Истифадә итеп – файдаланып.
[2] Мөхәрәманә – яшертен.
[3] Хәерхаһанә – яхшы теләк күрсәтеп.
[4] Гайре рәсми – рәсми булмаган.
[5] Мәгъкуль күрә – урынлы, лаек дип таба.
[6] Муафикъ – яраклы, урынлы.
[7] Тиҗарәтханә – сәүдә йорты.
[8] Сәнагатьханәләрне – мастерскойларны.
[9] Гарыз идәм – җиткерәм.

## Кәбир Бәкер хаты

Казан
30 июнь, 1908 ел
К. Бәкер

Мөхтәрәм борадәре газизем Фатих әфәнде!

Тарафы мөхиббанәләреңездән[1] 25 июньдә күндерелгән мәктүбе мөнифләреңез[2] бүген йолкып, фәүкылгадә[3] мәмнүн улдым[4]. Илтифатыңыза[5] тәшәккер идәрем[6]. Бу тараф сәламәтлек, әшратыс-сәгатьтдән[7] һич шәй сизелгән юк. Үзем этләр урамында торамын. Бер комнатда ялгызым, урыным яхшы. «Әлислах» өчен зан иттекеңезчә кальбемнең иң тирән йирендән чыкган ихласым илә кулдан килгән кадәр хезмәт итәмен. Фәкать якын мослихләрдән[8] эш калмас. Хәзергә чынлап дәрескә тотынганым юк. Алайда да, тик үткәргән минутым да юк дияргә хакым бар... Повторение илән иштигаль итәмен[9]. Һәм чтение берлән дә маташамын. Икътисад тарафым бик күңелле түгел. Кыш эшләр ничек улыр. Көнләр болытлы, ал карангы, кыскасы, томан баскан... Көзгә курска керерменме дигән исәп бар иде. Бу ел яшьләр бигрәк дә сүнгән күренәләр. Бер русча укучы да юк, ичмаса. Үткән ел 30дан артык кеше: мөгаллим, шәкердләр, русча укымышлар иде. Димәк, тәрәккъкый кирегә табан.

Киләсе номера «Әлислах»да бәлки язылыр. Сарт Садыйк мулланың «Егерменче гасыр шәкерде»нә вөжданыма хилаф[10] уларак бер тәнкыйд яздым[11]. Тәнкыйд язгач, серьёзно язарга кирәк булса, әгәр серьёзный язсаң, бәлки укырлар. Үзенә күрә яхшы гына язылган булганлыкдан, яшьләргә, бигрәк дә татар шәкердләренә, әсәр итәр[12] дип язмам дигән идем. ... Вафалар шул, яз дип, яздырды-

---

[1] Мөхиббанәләреңездән – дусларча сезләрдән.
[2] Мәктүбе мөнифләреңез – югары мәктүпләрегез.
[3] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[4] Мәмнүн улдым – шатландым.
[5] Илтифатыңыза – игътибарыгызга.
[6] Тәшәккер идәрем – рәхмәт белдерәм.
[7] Әшратес-сәгатьдән – дөнья бетү галәмәтеннән.
[8] Мослихләрдән – төзүтәчеләрдән.
[9] Иштигаль итәмен – шөгыльләнәмен.
[10] Хилаф – каршы.
[11] *Кәбир Бәкернең әлеге тәнкыйд мәкаләсе «Әлислах» газетасының 1908 елгы 36 нче санында «Казакъ» имзасы белән басылып чыга.*
[12] Әсәр итәр – тәэсир итәр.

лар. Алай да «мөхәррир» җанәбләренә бер-ике төн йокламаслык булды шикелле, берсен дә калдырмаганмын: тел асты[1] да керде, бәтчә базлыгы[2] да керә язды... Кыскасы, барын да азрак аңлаткан булдым. Китабыннан бигрәк мөхәрриренә тәнкыйд керә торган булды. Шаяд, ачуланмассыз.

«Чүкеч»дә сезнең бер тәнкыйдеңезгә ачуланып, ислахчыларны урам теле белән ачуланып, ачуланып сүккән Тимерша Сандугачев[3] булырга кирәк. Аңарга бәгъзеләр киләсе номерга берәр нәрсә языйк, дигәнләр иде. Ләкин аны тәнкыйд итеп ваксыну «Әлислах»га якышмый дигәч, куйдылар. Вакыйган, көлке журналы берлән бер әдәби гәзитәгә талашырга монасыйб түгел бит? «Арурак мәсләкле бер гәзитә» булса, сүз арасында ачыддырыб йибәрсәң, анда ярар иде. Юкса, урамча сүгешүдә һич мәгънә юк.

Фатих Кәримев ике борадаре илән килеп китдe. Әстерхан ягыннан киләләр икән. «Әлислах»ка бу арада яхшы гына акча килде шикелле. Бүген «Шәрык» матбагасын ябдылар. Губернатор кушкан. Мәгълүмегез ул кушды, бетде. Сөйләүләренә караганда, за неблагонадёжность дип ябканлар. Усиленный охрана беткәнче шикелле, чынлап белмим, яңа гына ябдылар әле. «Фөрьяд[4]» исемле бер шигырь язмышлар иде, шуны цензурага күрсәтми басканлар. Баскан соңында күрсәткәч, конфисковать итмешләр. Минемчә, шуның илән бетәргә кирәк иде дә бит, юк, алай түгел, «теләделәр» дә ябдылар. Әлеге дин шул ук «Фөрьяд» рисаләсе Салих дигән бер затның «дин»гә кямале ихласындан итдеке миссионерлар хакында, фөрьяды имеш. Миссионерларны яхшы гына тешләгән булырга кирәк. «Динем өчен җаным фида!» Ходай саклый күрсен инде, безнең ислахка касд кылмасынлар[5], юкса эш начар... Тагын ни языйм? Да, кичә Вафа[6] белән «Швейцария»гә барып, икебезгә егерме тиенлек кымыз эчдек, су кердек, то есть сезнеңчә

[1] Тел асты – биредә тел астына куела торган тәмәке (наркотик), нисвай күздә тотыла булса кирәк .

[2] Бәтчә базлык – кайбер мөселман илләрендә яшәп килгән, ир балалар белән җенси мөнәсәбәт кылу гадәте .

[3] *Биредә сүз журналист, нашир, язучы, педагог Тимерша Салаватулла улы Соловьев (1875–1947) турында бара .*

[4] Фөрьяд – зарлану.

[5] Касд кылмасынлар – явыз ният кылмасыннар.

[6] *Вафа (Әхмәтвафа) Гали улы Бәхтияров (1881–1960), журналист, җәмәгать эшлеклесе һәм педагог.*

коендык. Әхвәләтеңезе мөшәгъгарь мәктүбе мөнифеңезе мөнтәзыйрәм[1]. Бакый борадәранә сәламе кәмтәранәме[2] тәкъдим идәрәк кулыңызны кысамын.

Адьё![3]

Бу хат 28 дә язылса да, бу көнгә әллә нишләп кенә кичектерелде.

Хат 1908 елның 28–30 июнендә Ф. Әмирханга язучы, журналист, театр тәнкыйтьчесе Кәбир Бәкер (1885–1944) тарафыннан язылган. Хат киң буйлы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 4 биттән гыйбарәт.

## Кәбир Бәкер хаты

Казан
6 июль, 1908 ел

Мөхтәрәм Фатих әфәнде!

Икенче июльдә язылган мәктүбеңезне бүген йолкып, фәүкылгадә[4] мәмнүн улдым[5]. Казан әхвәлен гәзитәләрдә күреп торасыз. Язмыйм. Алай да ышпиклар[6] бер туктамый төрле хәбәрләр чыгарып торалар шикелле, күбдән түгел берсе: «Сабах», «Мәгариф», «Кәримевләр» көтепханәләрен бәлки шул арада карарлар дип сөйләп йөргәнләр. Җондыз[7] Һади абзыйдан[8] да кереп, 60 тиен алып чыкган шикелле (ышпик әфәнде Һадига көн дә керсә дә, алмый калмасдыр, андый куян җөрәкле кешеләрне шул юл илән имәргә бик яхшы инде).

Юрист, фәкыйһ[9], мөхтәрәм Садретдин әфәнде Максуди җәнабе галиләре, Һади абзый хәбәр бирүенә караганда, бөтен парламент исемендән Франциягәме, әллә кайда гына, хәтеремдән

---

[1] Әхвәләтеңезе мөшәгъгарь мәктүбе мөнифеңезе мөнтәзыйрәм – хәлләрегезне хикәяләүче бөек хатыгызны көтәм.

[2] Сәламе кәмтәранәме – түбәнчелекле сәламемне.

[3] Адьё – хуш.

[4] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

[5] Мәмнүн улдым – шатландым.

[6] Ышпиклар – шпионнар.

[7] Җондыз – берәр шпионның кушаматы булуы ихтимал.

[8] *Һади абзый – Һади (Әхмәтһади) Низаметдин улы Максуди (1868–1941), нашир, журналист, педагог, сәясәт эшлеклесе.*

[9] Фәкыйһ – шәригать кануннарын яхшы белүче.

чыкган, бара, ди. Думада андан башка французчага оста кеше булмаган икән (?).

«Әлислах» кртитический положениедәрәк, финанс тарафы тәмам кипмеш күренә. Алай да, бу номерны соң пәнҗешәмбе көн чыгарырбыз дип торабыз. Аръягы тагын бер-бер юне чыгып, бәлки августка кадәр алай-булай итеп булса дә, барылмас микән? Айһай! Сөаль галәмәте куярга тугры килә.

«Әлислах» хакында язучылар, белмәм, кайдан алып, нинди хәбәрләр яздылар икән. Мөхтәрәм ислахистлар бер дә кыйшаймый гына йөргән күренәләр. Исключая Г.Тук. и Ә.А. Хәер, мин идарәдә күп булганым юк. Көненә бер мәртәбә барып киләмен. Андан идарәне күчерү кирәк дип, мин килгәч дә әйткән идем, әллә нишләп, күчермәделәр. Шул акча ягындан бераз хәвефләнгән булырга кирәк. Вафа, борәдәре[1] илән Горшечныйда тора. Ибраһим, Таһир идарәдә торалар. Моңа кадәр мин: мәкалә язарга кирәкме дип, сорап кына яздым. Кирәк дигәндә, кирәгенчә язып бирдем. Башка мәкалә бар дигәч, һәм ул минем кулымдан да килмәсдәй булгач, язганым да юк. Башка мәкаләләрне миңа күрсәткәлиләр. Кулымдан килгән кадәр төзәтеп маташамын. Я төзәтергә мәслихәт итәмен. 35 нче номер начар чыкды дип, үзләренә дә үпкәләдем. Вакыйган[2], ул номера[3] рухсыз кеби иде. Тәгълим-тәрбия бабында[4] да бик кызык бит эшләр. Ничек язсаң да, абдырау. Ни эшләсәң дә, әлеге һаман бер акча. Милләтдә исә, ул юк. Башка бар да бар. Гайбәт дә бар, зина да бар, рия[5] да бар, риба[6] да бар, адәм хакы ашау да бар, иллә шул тугрыга акча юк. Мөгаллим юк, мәктәб юк, мәдрәсә юк, […] юк, кыскасы, ул бабда бар да юк. Шуның белән Рәшид кеби автономистлар гына оялмаенча фәлән итәргә, төгән итәргә, идарәне үз кулымызга алырга кирәк, дип кычкыралар. Инсафлы кеше, һичнәрсә әйтерлек түгел. Чөнки бер дә юл юк. Шул сәбәбле мәкалә бик кыскара: табигать җәрәянына[7], тарих изахына[8]

---

[1] Борадаре – ир туганы белән.
[2] Вакыйган – дөрестән дә.
[3] Номера – номер.
[4] Бабында – темасында.
[5] Рия – икейөзлелек.
[6] Риба – процент алу.
[7] Табигать җәрәянына – табигать процессларына.
[8] Изахына – аңлатуына.

карап торабыз гына диюдән башка юк. Шул бабдан алай да бер рухлы һәм серьёзныйрак бер баш мәкалә хәзерләп йибәрсәңез, яхшы булыр иде. «Әлислах»дан зарланучылар: «“Әлислах” ислах итмәде» диләр, бондан да глупость булырмы? Имеш, «Әлислах» кәгазьләре бөтен татар мәдрәсәләрен төзәтмәгән, түбәләрен калай илән ябып, эченә мөгаллимләр дә йитештермәгән, менә кызык... Андан соң «Әлислах» научный мәкаләләр язмаган, имеш. Әллә ислахчыларны күкдән иңгән дип беләләрме икән? Аларның да шул үзләре кебек татар балалары икәнендән хәбәрләре юк микәнни? «Әлислах»ның мадди җәһәтендән хәтереңезә килгән мәслихәтләрне язып йибәреңез. Югыйсә, мондагылар тугры әйткәндә сыйфырдан[1] артык дәгелләр.... Андан соң, арыслан булып да кыла торган эшләре артык түгел. Мин исәм бер чит кеше. Вафаны русча укырга димли-димли яңы гына борадәре илән азрак заниматься итдерергә муаффәкъ булдым[2]. Бу нинди халык болар? Тик ятарга бер дә иренмиләр, эчләре пошмый!

Башка тагын ни языйм? Каләм кызды, сүз азаеб килә. Ә, табдым. «“Әлислах” дан ни көтәләр?» дип, мәкалә язмакчы буламын, ярыймы? Төрек яшьләренең ихтиляльлары[3] хакында «Әлислах» мәсләкенә муафыйграк итдереп[4] берәр мәкалә язып йибәрсәңез дә килешер иде дим. Мәкәрҗә вакытына табан Мәкәрҗә байларына, ярмаркачыларга фәлән дип, рухлырак мәкаләләр дә хәтер килгән вакытда язгалап куярга кирәк бит.... Да, кирәк. Бик күб тәгълим-тәрбия бабында да кирәк дидем. Киләсе кыш шәкердләре хакында да кирәк, диеп күкрәк леп-леп итеп тора.

Бу йиргә килеп җиткәч кенә [...] көендән бәдбәхет әлеге бик тырыш еврейка үтеп китде. Менә минем күңелемне, минем дикъкатемне шундый тырыш халык җәлеп итә.

Менә мондан артык җөмләи могтәзирә[5] булмас инде.

Әхвәлеңезе мөшәгъгар[6] мәктүбезе мөнтәзыйрәм[7] .

---

[1] Сыйфырдан – нольдән.
[2] Муаффәкъ булдым – ирешә алдым.
[3] Ихтиляльлары – баш күтәрүләре.
[4] Муафыйграк итдереп – яраклырак иттереп.
[5] Җөмләи могтәзирә – көтеп алынган җөмлә.
[6] Мөшәгъгар – бәян итүче.
[7] Мөнтәзыйрәм – көтеп калам.

Бакый борадәренә сәламдән башымны алам (мәҗаз[1] икәне билдәле[2]). Адъё![3]

Минем соңгы закирияти[4] хат бардымы, юкмы?

Хат 1908 елның 6 июлендә Ф. Әмирханга язучы, журналист, театр тәнкыйтьчесе Кәбир Бәкер (1885–1944) тарафыннан язылган. Хат киң буйлы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 4 биттән гыйбарәт.

## Вафа Бәхтияров хаты

[29] июнь, 1908

Фатих әфәнде!

Үзеңнең хәлеңдән бер дә язганың юк. Ничек, эш алга табамы? Монда биң[5] мәртәбә сорыйлар. Шуны яз, яме? Казанда хәзер сәбзәват[6], әфәндем, пәк[7] күбәйде. Һәр төрлесе вар, әфәндем. Бары җәнабеңез юк. Виктория[8], әфәндем, Г. Кәрам хатыны, яхуд җизнәң Шәкүр әфәнденең борнысы кадәр олуглыкда. Бакчалардан «Аркадия» бетәчәк тиздән. Ара-тирә ягмурлар булгалый. Суфия, Шәмсекамәрләр 3 сендә бер авылга китәләр дип, Каюм сөйләде. Каюмны полиция эзли дип үзе сөйли. Бәлкем бер куык кынадыр. Ибраһим мәгълүм, һәрвакыт пәдәреңезлә[9] ат илә гиздекләрене берничә дәфга сукакта[10] күрдем. Яшь «Бакчаларга», хосусый «Державин»га ауга чыгыюрлар. Каюм илә Бикколовны мактыйлар.

Ибдәш! Хәзер дә безнең эш орлыкда, атна ярым булды, почтадан бер тиен килгәне юк. Андан-мондан алгалап кына маркага һәм Кәримевләргә бирдем. Менә 36 нчы «Нур» өчен Кәримевләргә кайдан да алып булмады. Атна уртасында бирәчәкмен дип, конторына әйтеп килдем. Нишләргә инде? «Сабах – Мәгариф»дән әллә ничә мәртәбә сорадым. Алар да безнең кеби фәлән көнне, фәлән

---

[1] Мәҗаз – метафора.
[2] Билдәле – билгеле.
[3] Адъё – хуш.
[4] Закирияти – телгә алынган.
[5] Биң – мең.
[6] Сәбзәват – яшелчәләр.
[7] Пәк – бик.
[8] Виктория – монда: җиләк төре.
[9] Пәдәреңезлә – әтиегез белән.
[10] Сукакта – урамда.

вакытда бирербез дип йөртәләр. С. Аитов да китеп калды. (Аның хакында сезгә хат язган идем. Троицкида дип адрес һәм язган идем). Хәкимов да килгәне юк. Тагын бер хат язган идем. Каршы алганым юк. Аитовка хат язмадыңмы? Бу соңгы номер гәзитәләр ничек? «Егерменче гасыр әфьюнчесе»[1]не бирмикме басарга, әллә калсынмы? Бик каты булмасмы?

Ибдәш! Исмәгыйльгә дигән хатыңны, хатны алгач та, кибетләренә илтмеш идем. Приказчикларның кайсы Уфага, кайсы Оренбурга китде дип сөйләделәр. Мин дә Оренбурга, кибетләре исеменә йибәрдем. Анда булса, сезгә хат язар дип уйлыйм. Байбәтчәләргә ышанып та булмый. Мондан да арбаны сораклап карадым, һичберсендә юк. Кыш көнендә генә сатканлар, бик шәбе бар иде бит. Аны да, бер бай алып китде дип, кибетче сөйләй. 37 нче номерга баш мәкалә кирәк булыр, вакытың булса.

Хат 1908 елның июнендә Ф. Әмирханга язылган. Хат имзасыз һәм язылу вакыты да куелмаган. Язу почеркына таянып, журналист, җәмәгать эшлеклесе һәм педагог Вафа Бәхтияров (1881–1960) булуы тәгаенләнә. Хат кара төстәге кара белән гарәп графикасында, татар телендә язылган. Ачык хатның уң ягында: «Ст. Серноводскъ. П.-Т. отдел. (Самарской губер.) Фатиху Амирханову» адресы язылган.

Шулай ук биредә ике почта мөһере бар. Беренчесендә: «Казань. 29.6.08», икенчесендә: «Серноводск. 2.7.08» дип язылган

## Вафа Бәхтияров хаты

Казан
9 июль, [1908]

Өммегөлсем сәлам диде.

Фатих әфәнде!

Хәзергә кемдән дә акча алганым юк. 36 нчы номер өчен Кәримевләргә бирдем. Киләчәк көнләрендә юнәйтсәм кирәк. Ягкубдан 7 сум алачак бар иде. Шуны бер көн сораган идем. Шундый кызулап җаваб бирде. Исең дә китәр. Менә, кардәш, «Әл мөкяфәт[2]»,

---

[1] *Ф. Әмирханның бу – «Егерменче гасыр әфьюнчесе» исемле фельетоны Әлислах» газетасының 1908 елгы 37 нче санында «Ташмөхәммәд» имзасы белән басылып чыга.*

[2] Әл мөкяфәт – бүләк; яхшылыкка каршы эшләнгән яхшылык.

син ут йотып йөр дә, йөр. Килгәч, сиңа да хатын күстәрермен. 37 нче номер өчен кәгазьгә дә алдым. Башкача язардай хәл хәзергә юк. 37 нче номерда яхшы булачак та, синең баш мәкалә һәм тәнкыйд, кечкенә фельетон кирәчәк. Тукаевның ике шигыре, Кәбирнең «Аңлы ханым» нам[1] мәкаләләр керер. Ничек булса да, 35 нче номер кебек булмаячак. 38 нче номер өчен материаллар бар. Бүген генә Үтәмишев (Сембер тиҗарәт[2] мәктәбендә укучы) «Ислах мәсьәләсе» нам мәкалә килде; яхшы гына озын. Шунлыкдан мөтәфәррикъ итеп[3] басылыр. Бер-ике номерга таратылыр. Кәбир дә яратды. «Авырулар галәмендән» 38 нчегә дип әзерләдем. Кичекде дип, пошынмас дип уйлыйм. Ибдәш! Безнең хакда ничек язалар, шуларны аңлатып язсаң икән? Ислахчылар тибәләр дип язалар икән. Шуларны беләсем килә. Мин профессорский переулокда торам. Фатир яхшы. Кич «Панайский» һәм «Эрмитаж» бакчаларындан музыка ишетелеп тора. Бик тыныч, балалары юк. Әгәр син килеп тә, фатирга чыгарга тугры килсә, шунда чыгарга яхшы булыр. Унберендә Мәхмүднең туе була. Мине дә туйга чакырып дәшкән. Ахрысы, барырга тугры килер. Һавалар бик коры. Ягмырлар юк. «Аркадия» бакчасы шартлады. Хәзерге «Эрмитаж» алда дип сөйлиләр. Ибдәш! Мондан элек бер ябык хат язган идем. Аны укыгач да ертып йибәрсәң икән. Өйдәгеләрең сәламәтләр? Арбаны алдымы? Эшләр алга табамы? Саг ул. В.Б.

Хат 1908 нче елның 9 июлендә Ф. Әмирханга журналист, җәмәгать эшлеклесе һәм педагог Вафа Бәхтияров (1881–1960) тарафыннан язылган. Хатта «В.Б.» имзасы куелган. Ачык хат көрән төстәге кара белән, гарәп графикасында, татар телендә язылган. Күләме 1 бит.

Ачык хатның уң ягында: «ст. Серноводскъ, (Самар. губ.). Квар. Трифонова. Амирханову Фатиху» дигән адрес язылган. Шулай ук биредә: «Казань, 11.7.08» һәм «Серноводск. 14.7.08» дигән почта мөһерләре дә бар.

---

[1] Нам – исем.
[2] Тиҗарәт – сәүдә.
[3] Мөтәфәррикъ итеп – буленеп.

## Борһан Шәрәф хаты

14 июль, 1908 ел

Фатих!

Хатыңны алдым. Әллә ник бик кызык булмады. Җүри язган шикелле күренде. Сеңелләр тугрысында язганыңны берсенә язып йибәрдем. Кайгыртучылар бар икән, дип куанып торсын дидем. Сеңелләрнең икесен, үткән ел Казанда торганларын, бер марҗа йөреп укытды. Димәк, синең киңәшең элекдән хәтерләнгән. Матбага ябылгандан «Әхбар» да туктап тора. Эшсезлек – кызыксыз. Эч поштыру ихтимал. Матбаганың тиздән ачылу өмиде әле юк. Гыйльметдин илә икемез дә, Казандан китәргә уйлап та торабыз. Белмим, тагын ни булыр. Яңадан яңа эш башлау шактый читен. Исмәгыйльдән күбдән хат алганым юк. Йосыф атна саен бик озын-озын хатлар яза башлады. Бүген, беренче тапкыр уларак, дамеллага хат яздым. Андан һәм искедә таныганым башка күб кешеләрдән ихлясым сүрелгәнне бәян итдем. Затән[1], бәндә ихляска истигъдад[2] бетә бугай, ахрысы. Булса, бик кызганыч түгел. Толстойның «Балалык, мөраһикълык[3]» әсәрен укып чыкдым. Бүген «Йегетлек»[4] дигәнен укыйм. Ихляс илә язганга охшый, яратдым. Төркия, Персия, Ыславлар вакыйгаларын тәгъкыйб итәсең[5] булыр. Һәммәсе кызык. Дөнья хәрәкәтендә бер рольсез калу гына кызыксыз.

Хуш. Ибдәшең Борһан.

Хат 1908 елның 14 июлендә Ф. Әмирханга журналист, педагог, җәмәгать һәм мәдәният эшлеклесе Борһан Шәрәф (1883–1942) тарафыннан язылган. Хат «Шәрәф» типографиясенең логотиплы бланк кәгазенә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 бит.

---

[1] Затән – нигездә.

[2] Истигъдад – сәләтлелек.

[3] Мөраһикълык – яшьүсмерлек.

[4] *Бередә сүз Л.Н.Толстойның «Детство.Отрочество. Юность» автобиографик трилогиясе турында бара.*

[5] Тәгъкыйб итәсең – күзәтәсең.

## Борһан Шәрәф хаты

Оренбург
11 сентябрь, 1908

Фатих!

Үзем язганчы синдән хат алыр кебек идем. Инде көтмичә язам. Аерылганда бик күб сүзләр сөйләшәсе калды. Анда әллә нинди суык кешеләр тугры килеп, күрешүнең бөтен ләззәтен җуйдылар. Фу!... Шундый вак кешеләрдән дә зарланырга тугры кылә.

Мин Оренбургда тәмам үземнең кәефемдә торам. Һичбер нәрсәдән кечкенә генә дә тарлык, уңайсызлык сизмим. Эш Казандагыдан күбрәк түгел. Тынычрак. Укырга да вакыт күб кала. Чөнки сөйләшерлек кешеләр күб юк. «Анна Каренина»[1]ны бетердем. Толстойның иске нәрсәләрен һәммәсен укып чыгарга илтизам итдем[2]. Нөсхәсен табкач да «Война и миръ»[3]ны укыячакмын. Көтепханә нөсхәсе әле буш түгел икән. Кропоткинның икенче китабын «Записки революционера»[4]сын укый башладым. Татар яшьләре хәрәкәтендән шундый берәр нәрсә язылса, бик яхшы булыр иде. Син вә минем шикелле кешеләрнең рухындагы үзгәрүләр татар үзгәрүенең гайне[5] бит. Иң карт татар илә иң яшь татар арасындагы һәммә аермаларны без үз рухымыздан кичергән. Һәммәсе безнең гомернең бер кисәге бит. Классический образование (хәтерендәме Чистай истыйляхы[6]) алган кешеләр алар өреп ясалган кешеләр. Алар татарның алмашыуын күрсәтә алмыйлар. «Ислахчы хатирәләре» кеби гонванда[7] берәр җилд китаб язылса, татар хәятындагы иң мөһим инкыйлаб тарихының иң мөһим сәхифәсен тәшкил итәр иде. Зыя хәлфәдән ничек Борһан чыккан, Ибнидән Фатих, Сорахдан Ибраһим, Мөбарәкҗандан Габделгазиз, Рәхимдән Галимҗан Шәрәф вә һакәза[8] күренер иде .

Татар әдәбияты тарихы һәм ысулын язуны да сөйләшеп уздырган идек бугай. Аны да татарча белми торган, яисә бер әдәбият тарихындан да хәбәрсез кешеләрдән көтәргә ярамый. Әлегәчә

---

[1] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Илтизам итдем – үз өстемә йөкләдем.
[3] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Гайне – нәкъ үзе.
[6] Истыйляхы – атамасы.
[7] Гонванда – исемдә.
[8] Һакәза – шулай.

шуңа керешүче юкмы икән? Мин бу көннәрдә әдәбиятымызның мәдрәсәләрдә укылуын кирәксенеп, бер мәкалә дә язмакчы булып торам. Мәдрәсәи Хөсәениядә укулар бик шәп түгел кебек. Аның тугрысында махсус язармын әле.

«Идел» 85 нче номерда Гобәйдуллиннарда булган мәҗлесне хурлап язганлар. Алдаганлар. Укыгансыңдыр. Закир эше булыр. Әгәр рәддия[1] язмакчы булсаң, мәҗлесдә һич нотыклар сөйләнмәгәнне зикер итү кифая[2] булса кирәк. Шулай онытылуы янә яхшы. Аны кем укыгандыр дисең? Һич. Исмәгыйльдән һичбер хат хәбәр алганым юк. Син миңа аның тугрысында яз әле. Үзем уйлап кына чыгарырга калмасын. Син дә андый нәрсәнең яхшы булмаганын син беләсәң бит. Һәркемгә хөсне зан[3] кыла белсәм дә, ялгышмас өчен сүи зан[4] кылырга кирәк дим. Бүген редакциягә килгән «Пробуждение» журналының 15 нче номерасында гыйлавә буларак бик шәп, буяулы картина килде (4 x 6 вершок). Бу баш, чәчләре, күзләре, кыйсмән[5] чырае илә дә сеңлең Өммегөлсемгә охшаганга күрә, мин аны үз бүлмәмә алып кайтып куйдым. Үзе дә бик яратыр иде. Кайтсам, күрсәтермен. Сизәсең, Казанны сагына башлау шулай була торгандыр инде; аз гына бәһанә[6], искә төшерергә сәбәп була. Чынлап та, Казанның шәп яклары бар икән. Монда душевный удовольстволар табарга бик читен. Шуңа күрә фәхешкә бирелү бик табигый шикелле. Мин дә куркып торам. Курыкмыйм, ягъни ихтималланып торам димәкче идем. Монда катышырлык ирләрнең һәммәсе кабакта. Рәхәт таба торганлар булуы өстенә, әлегәчә танышканым хатын-кызлар да һәммәсе, гыйффәте шөбһәлеләргенәдер. Һичбер мөслимә илә таншыканым, күрешкәнем юк әле. Күренгәннәренең бик кабәхәт киенүләре, килешсез йөрүләре, ямьсез кыланышларына караганда, танышмаганга да үкенерлек түгелдер дип уйлыйм.

Бер казарма артында, амбарлар шикелле тәбәнәк вә тәрәзәсез бер бина күренә. Шуны шәһәр театрусы дип атыйлар. Анда сентябрь ахырында кәмит (Драм-комедия) башлана, ди. Оренбургның үзенә күрә высшее обществосы шунда күренер инде. Бик

---

[1] Рәддия – кире кагу.
[2] Кифая – җитәрлек.
[3] Хөсне зан – яхшы уй.
[4] Сүи зан – начар уй.
[5] Кыйсмән – берникадәр.
[6] Бәһанә – сылтау.

тилмереп көтеп торам. Уездный барышняларның любопытносте, кершән ягынган, исле май сөртенгән бабаларның[1] мещанский гордосте тугрысында күп язарга ихтыяҗ юкдыр инде. Алар Казанда торып та мәгълүм. Фатих, рәсемеңне йибәр әле. Почта, йә рәкыйб[2] илә мөмкин. Фуад та монда килә имеш дип, ишетдем. Иң соң алдырганың, яисә үзең иң яратканы булсын.

«Әлислах»ка мәкаләләр язарга вакыт табармын. «Казандан китеш»не йибәрермен дигән идем. Бик төче чыкты. Аны үзгәртмәсәм, башка нәрсә язармын. Зариф хәзрәткә ихтирам. Ислахчыларга сәлам. Кулыңны кысып, Борһан.

Хат 1908 елның 11 сентябрендә Ф. Әмирханга журналист, педагог, җәмәгать һәм мәдәният эшлеклесе Борһан Шәрәф (1883–1942) тарафыннан язылган. Хат шакмаклы кәгазьгә, кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 3 биттән гыйбарәт.

## Исмәгыйль Аитов хаты

Оренбург
27 сентябрь, 1908 ел

Газизем Фатих!

Оренбургка килеп җитдем. Сәламәт килеп яхшылап урнашмас борын, әллә ни яза да алмыйм. Шулай да хатларның коллекциясе арасында минем тагын бер конвертым артык булсын дип, йибәрергә уйлыйм. Килгән көн Борһанны барып табдым. Кәримов-Хөсәенов матбагасы каршысында бер дантистда бүлмә алып тора икән, өендә тугры китерә алмагач, матбагага кереп, сорашмак булып барганда, Фатих Кәриминең җомгага барган вакытына тугры килеп, күрешеп сорадыкымда, ул Госман Акчукраклы номерасында булса кирәк дип, мине йибәрде. Бардым. Дөрестән дә, анда икән. Күргәч, бик трогательный[3] күрешү булып, кофейняга барып, Казан гайбәтләрен сөйләдем. Гайбәт сөйләү кызык эш, тотылмаслыгыңа ышанып, ялганлап сөйләсәң, тагын да тәмлерәк. Кирәкмәгән сүзләр... Нәрсә языйм. Тукта, Борһан хакында. Борһан үзгәргән, энергия[4]ле кеше төсле кылана, фатирына алып барып,

---

[1] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Рәкыйб – күзәтүче.
[3] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*

язган мәкаләләрен күрсәтеп, ибдәш, һәммәсен күңелдән яздым. Чындан интересоваться[1] (ибдәшләргә сәлам, сиңа Борһан сәлам ди)[2] итәм ди бичара, табкан шадлык, бетде монысын җүри генә әйтәм. Үзенә яза күрмә.

Фатих! Сиңа бер-ике сүз, ник йоклыйсың? Ник күзеңне ачмыйсың, аз гына ачып кара! Күрәмсең, күршеләрең яныңа җыелган, ибдәшләрең, дустларың һәммәсе үзе өчен, үзләренең киләчәкләрен тәэмин өчен (тоткан тактикалары яхшымы – яманмы башка мәсьәлә) тырышалар, әллә ниндәй восторженный[3] вакытларында да онытмыйлар, әмма син! Син! Сиңа да алардан үрнәк алырга вакыт. Без «05» ел ахырларында «Работник»[4]лык модыдан чыкгангамы, яисә чындан аңлапмы, болай инсаниятгә хезмәт итеп булмый ул. Самоусовершенствование[5] кирәк дип сөйли идең. Бик дөрест. Син дә шул принцип[6]ны дөньяга чыгарырга тырышасың, ләкин сиңа бик кыен. Ике нәрсәне тәрәкъкый итдерергә кирәк умствен[7]но һәм физически. Икесе бердән булуы, минемчә, бер-берсенә бик уңайсызлый. Әүвәлгесенең тәрәкъкыен белмим. Әмма икенчесе бик акрын бара, минемчә, сәбәбе шул икенче булырга кирәк. Ибдәш, әле никадәр юргалансам да, мөхәррир булып булмас. Сиңа дөп-дөресен генә әйтим. Минемчә, син бүгендән башлап чындан үз исәнлегеңә күз салырга тиеш, аның өчен башка хезмәтләрне куеп торырга тиеш (курыкма, милләт сине ташлап китә алмас, бер гасыр йоклап торсаң да, «Әлислах»-ны беренче номердан башлап чыгарырга туры килер). Берәр җиргә – суга, диңгезгә барырга кирәк. «Акча мәсьәләсе» – юк мәсьәлә. Иренмичә, ислахга җыйган куәтең ярымын гына сарыф кылсаң да, үзеңне тәмам терелгәнчегә җитәрлек таба аласың. Булмаса, болай ислахга дарым «Алла ризалыгы» өчен, яисә милләт өчен хезмәт итеп, үзеңне бетереп, тагын катырак авыру булып, ахыры үлеп китү, әллә ни вакыт үткәч татар исенә төшерәме? Төшерсә, һәм ни файда... шулай, ибдәш, ташла һәммәсен, үзеңне карарга башла. Һәммә үзе өчен тырыша. Сиңа ике вакыт тырышырга кирәк.

[1] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Чыганакта җәяләр эчендәге сүзләр, поляга гади карандаш белән язылган.*
[3] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*

Әүвәл сәламәтлек, андан наука[1]. Кара, Габдулла Гыйсмәтине һәм башкаларны язалар, укыйлар, милләт кайгырта, дин, ди. Һәммәсе истирахәт өчен генә, башка вакыты һәммәсе үзләре өчен, алдагы гомре өчен. Син шуларны чистая монета[2]га аласың. Мин әйтмим алар синең зарарыңа союз ясаганлар дип, әлбәттә юк. Алар аңлаганлар!! Без моңарчы «чудо көтеп җөргәнбез. Тагын бер мисал, Борһанның эшләгәнен үзенең исе китүе. Хатлар настроение[3]дән зависит[4]. Минем ниндәй настроение дә икәнемне белдерә, шулай да, минемчә, язганлар хакдан ерак булмасалар кирәк, уйлаб кара. Тиздән хат көтәм. Һәрбер яхшылыкны теләп калган Исмәгыйлең.

Хат 1908 елның 27 сентябрендә Ф. Әмирханга зыялы, эшмәкәр Исмәгыйль Сөләйман улы Аитов (1888–1930) тарафыннан язылган. Хат, Казанның 1 гильдия сәүдәгәре Сөләйман Аитовның логотиплы бланк кәгазенә, кара төстәге кара һәм графит карандаш белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 4 биттән гыйбарәт.

## Әхмәд Исхак хаты

Орски,
6 октябрь, 1908 сәнә

Һөвә![5]

Мөхтәрәм Фатих әфәнде!

Мәктүбеңезне 14 нче сентябрь алдым. Бу көнгә кадәр җаваб яза алмадым. Гафу идеңез. Илтифатыңыздан[6] бик мәмнүн улдым[7]. «Шәрык китапханәсе» нә тәвәҗеһеңезә[8] тәшәккерләр идәрем.

«Дымъ»[9] кеби җидди әсәрләрне нәшер итмәк бәнемчә бик матлуб[10] исә дә, мадди җәһәте эшне уңгайсызлата. Майдан бирле

---

[1] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Һөвә! – Ул! (Аллаһы Тәгаләне телгә алу билгесе).
[6] Илтифатыңыздан – игътибарыгыздан, яхшы кабул итүегездән.
[7] Мәмнүн улдым – шатландым.
[8] Тәвәҗеһеңезә – илтифатыгызга.
[9] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*
[10] Матлуб – таләп ителгән, соралган нәрсә.

алынган йиде-сигез рисалә бар. Берсе дә басылганы юк. Акча юк. Йитешеб булмый. Истанбул – Мисыр матбугатына күб акча сарыф идәргә мәҗбүрмен. «Шәрык»ның ябылуы да эшкә күб зарар бирде.

Әгәр акча булса иде у кеби бөек әсәрләрен мәмнүниятлә[1] нәшер идәр идем. Илтизам итдекем тәкъдирдә[2], хаккы тәэлиф[3] көче таләб улынса да, вирер идем. Фәкать нә кадәр арзу идәрсәм дә[4], басдыра алмавымны кәмале тәэссеф[5] илә гарыз идәм[6].

Галимҗан Ибраһимов Орскига килде. Аның ике-өч рисаләсен алдым. 50 сум бирдем. 50 сумны кыш йибәрергә вәгъдә итдем.

«Әлислах»ка игълан йибәрермен. Мисыр китабларының килеп йитүен көтәм. Бер һәфтәгә[7] кадәр килер. Андан соң, баш-күз алгач, берничә мәртәбә басырга йибәрермен.

Тизлекдән тәмам сәламәдләнеп йитүеңезне чын күңелдән телим. Аллаһыдан сорыйм.

Мәхәббәт илә кулыгызны кысып,
Әхмәд Исхакый.

Бүген «Әлислах» идарәсенә «Асар» 14 нче – «Ислам», «Җиһанша хәзрәт»ләрне йибәрдем. «Ислам» күбдән басылган булса да, «Әлислах»да күренгәне юк. Мөнасиб[8] күрсәңез, өчесене дә «Әлислах»ка языңыз, интикад идеңез[9], риҗа идәрем[10].

Әхмәд.

Хат 1908 елның 6 окятбрендә Ф. Әмирханга шагыйрь, тәрҗемәче, тәнкыйтьче Әхмәд Габдулла улы Исхаков (1905–1991) тарафыннан язылган. Хат «Шәрык» көтепханәсенең логотиплы бланк кәгазенә кара төстәге кара белән язылган. Күләме 1 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

---

[1] Мәмнүниятлә – шатлык белән.
[2] Илтизам итдекем тәкъдирдә – үз өстемә алган очракта.
[3] Хаккы тәэлиф – гонорар.
[4] Арзу идәрсәм дә – теләсәм дә.
[5] Кәмале тәэссеф – тулы үкенү.
[6] Гарыз идәм – җиткерәм.
[7] Һәфтәгә – атнага.
[8] Мөнасиб – яраклы.
[9] Интикад идеңез – тәнкыйтьләгез.
[10] Риҗа идәрем – өмет итәмен.

## Исмәгыйль Аитов хаты

21 октябрь, 1908

Фатих!

Менә тагын хат. Өченче! Синдән бер ачыкдан башка бер нәрсә, бәхетсезлекгә каршы «Әлислах» да, килми (бәйрәм номеры әле килгәне юк!).

Элекке хатларымны алгансыңдыр инде. Яңа хәбәрләр юк, фәкать эш юкдан гына язам.

Бүген Борһанга барган идем. Синең хатыңны күрдем. Ике көндән хат көтәм. Өченче көнге хатымда гәзитәдән татар уенчылары хакындагы мәкаләне йибәргән идем. Бүген шуңа җавабымны йибәрәм, (либеральный гәзитә) сез дә протестсыз калдырмассыз дип уйлыйм. Чөнки бу Казан кызларының честенә тия бит. Син дә, ибдәш, минем землячкәләрнең честьләрен саклаганны җавыб калдырмасдан, урыны килгәндә, тиеш булган кешеләрдән бәһаләндерерсең, дип уйлый. Уйнама, ибдәш, шакдый рыцарьлек бит ул, әгәр мин каршы язмасам, һәммә укыган кеше, чындан да, «Казан любительницалары һәммәсе фахишә икән» димәсләр идеме; шул, ибдәш, бәһане тәкъдир кылдырырга[1] тырыш.

Монда литературно-драматический кружок ачмак булып йөрибез. Иртән беренче җыелыш. Башда үзара гына булачак. Зурайса, тагын күрелер. Интеллигентная труппа һәм булды. Дүрт артистка табылды, мин режиссёр (просить итәләр, әле җаваб биргәнем юк!). Рольләр бирүне минем кулыма табшырсалар, бәлки булырым да.

Ибдәш. Йибәргән гәзитә кисәкләрен В.К.Р.[2], яки В.Л.[3] кеби рус гәзитәләренә йибәреп сүз ачдырсаң, шумы күбрәк булыр иде, рәхим итеп, шулай эшлә әле.

Ибдәш, килгәндән бирле авырыйм, күбесенчә өйдән чыкмыйм. Доктор һаман килеп йөри, мышьяк вспрыскивать итмәк булам. Хат яз. Иренмә. Күрәсең, нидәй иренчәк кеше – мин өченче хат язам.

$19\frac{21}{X}08$. Исмәгыйлең.

---

[1] Тәкъдир кылдырырга – бәяләргә.

[2] *В.К.Р. – «Волжско-Камская речь» газетасы булырга тиеш. Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] *В.Л. – «Волжский листок» газетасы булырга тиеш. Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*

Хат 1908 елның 21 октябрендә Ф. Әмирханга зыялы, эшмәкәр Исмәгыйль Сөләйман улы Аитов (1888–1930) тарафыннан язылган. Хат шакмаклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазьдән, 1 биттән гыйбарәт.

*Хат текстларын, искәрмә һәм аңлатмаларны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*
*Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Хәлил Әбелханов хаты

Фатих әфәнде!

Яңа урынга тамыр йибәргәчдән үк сезгә хат яза торган кеше, тәмам искереп беткәч, мондан күчәр вакыт йиткәч, саф биш ай вакыт узгач, кулга каләм алып, сезнең берлә сөйләшә; әллә ни эшләр хәл юк бит, Алланың тәкъдире шулай булгандыр, никадәр язам-язам дип йөресәк дә, Ходаның вәгъдәсе йитмәгәч, язып булмый икән, әфәндем. Ул бик шәп корал шул: төрле урында ярый, тугрысын әйткәндә, минем хат язмый торуыма бик зур-зур таудай сәбәпләрем бар, аларны бер-бер артлы саный башласам, үзегез тәмам ышанып, катып калачаксыз һәм язмаганыма рәхмәт укыячаксыз.

Беренче сәбәп – сезгә язар өчен мин сенсационный яңа, кер дә тимәгән хәбәр көтдем, ләкин ул хәбәрне ачык хәлдә бу көндә дә ала алганым юк! Әллә ни эшләп көннән-көн мәсьәләне чуалта бирә һәм көннән-көн койрыгын ераграк яшерә бирә. Көтеп-көтеп дә, ул «хәбәр»не ала алмагач, булган кадәресен хәзергә язарга карар биреп, менә кулыма каләм тотып, агач тотып түгел, язам. Әллә ул тыштан караганда гына сенсационный нәрсәләр булыр кеби. Әмма тормышның эченә кереп аралашкач, андый нәрсәләр һәммәсе гади бер хәлгә әйләнсәләр кирәк. Чөнки хәзер генә шул тугрыларда уйлый башлагач, әллә никадәр бик кызык, кызык гына сезгә язарлык нәрсәләр килеп чыга. Минем үзем бик билгеле булгач да, мин баядан бирле сөйләп килсәм дә, кем хакында, кем тугрысында сөйләдекемне сезгә язмадым әле. Сүз мәгълүм Мария-Мәрьям тугрысында. Көз көне, иске урынга барганда, Мәрьямгә хәбәрсез барып кердем. Мәкъсуд аның гади тормышын күрү иде. Аның тормышы мине төрле подозрениеләргә төшерде. Һәм аның тарафыннан бер төрле салкынлык да сизелде. Ул аны тиз генә яшермәкче дә булды,

ләкин барлыгы да бик сәнгый[1] чыкды. Мин, китәр алдыннан Мәрьямгә язу калдырып, бу үзгәрешнең сәбәбен бәян итүне үтендем. Монда кайткач, алган мәктүпләрендә ул, фәкать настроение юклыгына гына хәмел кыйлып[2], йиңелчә генә бетерәсе килде. Соңра мин үзем бер озын хат язып, берничә сәбәпләр күрсәтеп, баш сәбәпдә «ике арадагы милләт башкалыгындан гыйбарәт таш коймаһы» куйдым. Ләкин ул, йомшак кына, минем ул баш сәбәбемне инкарь идеп язды. Ләкин чын сәбәпне язармын-язармын дия-дия, әле һаман язганы юк. Соңгы хатларында күбрәк: «Мине онытасың, бик сирәк язасың» дип, мине генә шелтәләп яза. Көтелгән хәбәр «теге» сәбәбе бәяны иде. Ләкин алынганы юк әле. Һәр көнне көтәм. Гади хатлары җыш-җыш килә. Бу урында ул мәсьәләгә нокта куеп, башка нәрсә тугрысында язарга башлыйм. Чөнки гыйшык утындан хәбәрдар булмаган кеше, гашыйкларның кадерене белми диләрме? Хасыйл шундай... Минем авылдан 6 чакрым еракда – Яльчик дигән авылда – мәшһүр ат печүче Газиз Сәйфелмөлеков ветеринарный фельдшер булып тора. Яңа елга килде. Ул Тәтешдән үзенә бер кыз да алып килгән. Шулай итеп, кыпшырдатып, икәү карт белән карчык булып торалар. Тормышы чын «өйләнгән» кешенең тормышы: тамагы тук, өсте-башы бөтен, Аллага шөкер, хәзер шулай ни булганына разый булып торалар. Ярый, бу да шулай булып торсын. Алар да торсыннар.

Язу, черепашьи шаг берлә булса да, акрын гына, аз-аз гына алга таба бара. Бу көндә әүвәлге планга кертелмәгән «Маскарад»-мәсхәрәт» дигән главаны язып маташам. Хасыйл, ул тема зурая бара һәм тармаклары да көннән-көн арта. Шуның берлә, бу кышда бетерергә уйланган нәрсә бетми калачак күренә. «Хәят»-не басмадан чыккач да бер-ике мәртәбә укып чыкдым. Һәр главаны аерым-аерым алганда бик тирән тойгылар калса да, бәгъзе бер главалары гаять тә кыйммәт, кадерле булса да, гомумән караганда, әллә ничек тузган впечатление хасил була. «Хәят» кем? Ниндәй тормыш берлә тора? Ни белән азыклана? Сөальләренә тугры гына булмыйча җавап бирүе читенрәк. Ихтимал, моның сәбәбе үз тормышымызның шулай ким, эшләнеп бетмәгән ярты-йорты булуыннан булса да булыр – ул вакытда «Хәят» кеби типны бик реальный

[1] Сәнгый – ясалма.

[2] Хәмел кыйлып – сылтап.

дип кенә санап, гаепне тәмамән тормышка аударып калдырырга туры киләдер. Милли матбугатда бу хакда «Хәят» тугрысында тәнкыйть булдымы-юкмы, анысын белмим, башка кешеләргә «Хәят» ниндәй тойгы калдыргандыр, аннан хәбәрем юк. Шуның өчен дә мин әйткән нәрсә, ихтимал, минем хосусый фикерем генәдер. Һәр нә исә, татар кызларыны рус малайлары уйнатып йөрткәнең өчен сезгә кем дә рәхмәт димәс, кыяматдә алла җәзаңны бирер әле. Бер дә инде мөселман кызына килешә торган эш түгел. «Михаил малай»ның уң кулы берлә Хәятның сул кулыннан йомшак кына тотган»да, Михаилның кулына сугасы килә. Әфәндем, хәмияте диния[1]! Бик шәп бит! Ярый, Аллага тапшырдык. Хәзергә хуш әле. Хат язсагыз язарсыз, язмасагыз – теләсәгез нишләгез, улысы важный түгел! Кулыгызны кысып: Хәлил Әбелханов.

1март, 1912 сәнә.

Хат 1912 елның 1 мартында язучы, журналист, педагог Хәлил Әбелханов (Әбелханов Хәлиулла Габделвәли улы (1887–1919), Казан) тарафыннан язылган.

Хат гарәп графикасында, татар телендә кара каләм белән язылган. Күләме 2 кәгазьдән, 4 биттән гыйбарәт.

## Йосыф Казаков хаты

Кынады
17 апрельдә 1912 ел

Мөхтәрәм Фатих Әмирханов җәнабләренә!

Мәгълүм улсын ки, боңача арамызда һичбер мөнәсәбәт илә танышлык булмаган булса да, бу аралыкда басылып чыкган: «Хәят» нам кыйммәтдар әсәреңезе моталәгамыздан[2] кичереп, бондан нә кеби сурәтдә махсус улдыйгымы: рәфикым улан каләм васитәсы илә[3] ихтыярсыз уларак, биззат[4] кәндиңезә гарыз итәргә[5] мәҗбүр улдым.

---

[1] Хәмияте диния – динне яклау.
[2] Моталәгамыздан – өйрәнүебездән.
[3] Васитәсе илә – арадашчы белән.
[4] Биззат – турыдан-туры.
[5] Гарыз итәргә – үтенергә.

Хәят туташның тышкы матурлыгы, берничә вәҗеһ[1] илә Лизаныкыннан артык булса да, ләкин (татар галәменең моктәзасынча[2]) аның әүвәлдә алган тәгълим вә тәрбиясе Мәлихә абыстайдан гына булып, теге Лизаныкы чук була алмавы бәрабәр эчне пошыра төшәдер. Алай да, ул, үзенең булгырлыгы илә, аз аралыкта байтак мәгълүмат артдырырга өлгереп, эчдән дә ярыйсы гына матурланып йиткән. Үзенең табигый чибәрлеге өстенә, модадан да бер дә калышмавы аңа бик яраган.

Бу заманда чын кеше булып яшәргә керешелсә, безнең татарлар эчендән дә, әүвәлдәге кебек, буш вә караңгы бүлмәләрдә ята торган хатын вә кызлар урынына, бәлки кешелек мәйданы булган театрларда кеше күзенә кешечә булып күренерлек җазибәле[3] Хәят, Әминә, Рөкыяларны да йитешдереп булачак икән! Фойеда арлы-бирле кайнап йөри торган студент, офицер, яшь чиновниклар сафында (йөри торган) Гали Мөхәммәд углы Арсланов кебек егетләремезнең булынуы, килешле булу гына түгел, бәлки ул үзенең артында булган бөтен татар галәмен үзе кебек үк булгылыклы итеп күргәзер өчен дә аның кергәнлеге хәтергә киләдер.

Моның өстенә, бу кызларда бөтен интеллигенция галәмен ялгыз үзләренә генә мәҗзүб итәрлек[4] кадәресе ләтафәт[5] вә нәзакәт табылуы да мөмкин икән!

Кызлар театрдан кайтканда, чаттагы ямщикның җырлап биргән җыры бик урынлы булып, бездә шундай урынлы һәм кызыклы җырлар да бар икән!

Хәят туташ шундай матурлыгы илә читенлек беләнрәк булса да, гыйффәтне югалтмаенча, Салих Фатиховга хатынлыкга баралган кебек үк башка татар кызлары да булдыра алырлар икән!

Татарлыкда да чынлап яшәп була икән! Болай булгач, ник юкга, татарлар бетә дип пессиминально[6] булырга! Хәзер инде өмидсез булып борчылмыйбыз. Яшәргә тотынамыз! Инде яшәргә тотынгач, Хәят, Әминә, Рөкыя кебек кызларны, Гали, Салих кебек егетләрне, элекке кебек берәмләп кенә түгел, бәлки дистәләп-дистәләп йитешдерәсе генә бар икән! Бу көнгәчә татар киоскларында

---

[1] Вәҗеһ – сәбәп.
[2] Моктәзасынча – таләбе белән.
[3] Җазибәле – сөйкемле.
[4] Мәҗзүб итәрлек – тартып торырлык.
[5] Ләтафәт – матурлык, гүзәллек.
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

ята торган «Фәзаилеш-шөһүр», «Бакырган»лар арасына кереп өлгергән Гаяз Исхаковның «Бай углы», «Инкыйраз», «Өч хатын...», «Җәмгыятьләре» татар әдәбиятына вакытында күңелләрне җәлеп иткән булса да, болар өстенә янә 90 гыйльме халь, 70 тәҗвид, 60 җәгърафия, 40 тарихе-әнбия, алар өстенә, тагын йиңел әлифба, салмаклы әлифба, сап-сары әлифба, хөснел-хатлы әлифба, капкачлы әлифба, башлангыч, атлангыч, үрнәкләр, күбәләкләр, терелек, үлемлек кебек чепуха китапларны аваландырып торудан туктый алмаганлыгы өчен хәзергәчә шул әдәбиятка үпкәм зур иде.

Инде бу замангача үзенең ярлылыгы илә мөттәһәм[1] тотылган татар телен һәм шулай ук эшдән чыгарга якынлашкан татар хәрефләрен үзләренең булгылыклары илә укып туймаслык татлы «Хәят»не вөҗүдкә чыгара[2] алганлыклары өчен һәм татар әдәбияты «Хәят»не танып, мәйдане интишар[3]га куйганлыгы өчен боларның һәркайсын җитди хис илә тәбрик итәмен! Яшәсен татар теле! Бозылмасын татар хәрефләре!

Рәваҗ тапсын[4] (эчендә «Хәят»е булган) татар әдәбияты! Моңа даир сезгә язачак сүзләрем шул кадәрлесе илә бу урында тәмам булса да, башка хосусларда тагын әллә никадәр язачак сүзләрем калып, мөнәсәбәте чыкгач, әлбәттә, язармын.

Мондан артык сүз язарга иң әүвәл сезнең илә танышлыгымыз юклыгы, андан соң бу хат бик озынга китәрлек булгач, шунда туктап калдым. Алай да бу кадәресе язуым урынсыз булмас дип уйлап калдым.

Бакый ихтирам там.

Йосыф Казаков. Кузнецк, Саратовской губернии Юсуфу Казакову.

Кулъязма хат гарәп графикасында, татар телендә, кара каләм белән язылган. Күләме 2 кәгазьдән, 4 биттән гыйбарәт. Хатта Йосыф Казаковның шәхси мөһерен дә күрергә мөмкин.

---

[1] Мөттәһәм – гаепле.

[2] Вөҗүдкә чыгара – барлыкка китерә.

[3] Мәйдане интишар – таралу мәйданына.

[4] Рәваҗ тапсын – таралсын.

## Ибраһим Бикколов хаты

11 август, 1913 ел.
Ибраһим.

Мөхтәрәм Фатих әфәнде!

Сезнең идарәдән зур мәсьүлият[1] илә Мәкәрҗәгә килсәм дә, канәгатьләнерлек үти алмыймын ахры. Бонарга, әлбәттә, тәҗрибәсезлек дә зур манигъ[2] буладыр. Шулай ук табигый булган юашлык вә йомшаклык да диергә ярый. Ләкин гаепне үз өстемә генә дә алып бетерә дә алмыймын. Хасыйл, монда гәзитәнең базары «Бәянелхак»-фәләннәр тарафыннан шулкадәр төшкән ки, әбунә сорап бирәүгә мөрәҗәгать итү гүя сәдака сорап мөрәҗәгать итү кебек. Шуның өчен бәгъзе бер киңәшләр тәэсире илә дә мин номердан-номерга йөрмәс булдым. «Сибирия» өчен Вагыйз[3]ның бәрадәре килде. Ул йөридер. Ләкин рәт бер дә чыкмас төсле. «Кояш» шәүкәтенә хәлал китермәс өчен, шулай булмәмдә генә әбунә көтеп торырга булдым инде. Игълан өчен бик күп фирмаларга мөрәҗәгать итдем, ләкин һәммәсе Питербургга, Мәскәүгә баш конторага мөрәҗәгать итәргә кушалар. Монда реклама кыйсеме илә шөгыльләнмимез, баш конторага мөрәҗәгать итсәгез, бирермез, диләр. Үзем сентябрь башына кадәр ярминкәдә каламын әле. Сентябрь башларсыз Казанга кайтып җитә алмамын.

Менә нәрсә тагын, Фатих әфәнде, сез мине «Кояш»да даими язучы итеп калдыра алмыйсызмы? Сезгә бит, кажется, кеше кирәк. Мин гәзитәнең хәбәрләр кыйсеменнән төрле бүлекләрне идарә итәргә булдыра аламын. Аннан башкасы, әлбәттә, үзегезгә мәгълүм инде. Әгәр сезгә кеше кирәк булып, мәгъкуль тапсагыз, шул тугрыда Зәкәрия абзый[4] илә сөйләшеп миңа шушы арада хәбәр итсәгез иде. Минем Казанда калырга дәрдем бар. Бу ел Себергә китәргә әллә нигә охота юграк. Бәхетне икенче төшдән эзләп карыйсы киләдер. Монда миңа берничә йиргә мөгаллимлеккә дә (шәһәрләрдә) урын гарыз итәләр[5]. Ләкин шулай да бу тугрыда мин

---

[1] Мәсьүлият – җаваплылык

[2] Манигъ – тоткарлык

[3] *«Сибирия» сәяси, әдәби, икътисадый газетасы 1912 елның 18 мартыннан 1913 елның августына кадәр Томск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире – Мөхәммәдвагыйз Нәүрузов.*

[4] *Зәкәрия Садретдинев – «Кояш» газетасы мөхәррире.*

[5] Гарыз итәләр – тәкъдим итәләр

сезгә мөрәҗәгать итеп карарга уйладым. Җәй көне бу тугрыда Зәкәрия абзый берлә дә сүзләр булган иде. Сез шул тугрыда миңа шушы арада бер җавап яки бер киңәш язып йибәрсәгез, мәмнүн калыр идем. Хәзергә хуш улып торыңыз.

Ибраһим. Адрес мәгълүм.
Ярминкә, «Двухсветная»га.

Хат 1913 елның 11 августында җәмәгать эшлеклесе, педагог, публицист, Ф. Әмирханның якын дусты Биккóлов Ибраһим Җамалетдин улы (1884–1938) тарафыннан язылган.

Хат гарәп графикасында, татар телендә, кара каләм белән язылган. Күләме 1кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Камил Мотыйгый хаты

28 июль, 1915 ел.

Мөхтәрәм әхбаб Мөхәммәдфатих Әмирхан әфәнде!

Чистайга китешли сезгә бер-ике сүз әйтеп китәсем килде дә, шуны язып бирүемне артыграк күрдем, чөнки сезне аулакда тугры китереп булмый, идарәгә керсәм, һәрвакыт яныңызда кешеләр була, хәлбуки, мин бераз гына әһәмиятле булган эшне кеше алдында сөйләргә яратмыйм.

Мәсьәлә бондан гыйбарәт:

Мәгълүмегез! «Тормыш» мине бик изеп язды. Әлбәттә, һәр нәрсәнең вә һәр кешенең ике тарафы да бар. Теләсә кемне мактап була вә теләсә кемне яманлап була. Монда, асла, шөбһә юк. «Тормыш»ның мәкаләсе башында ук (№ 285) пессимистларча язылганы күренеп тора. Иң (башдук) башта ук мине 3–4 кенә тәфсир кисәкләре язып чыгарган (әле ул аны бетермәгән. Вә фиһи бәхәс) ди, хәлбуки, аның җиденчесе чыкты. Сигезенчесе матбагага басылырга бирелде. Әгәр ул мәкалә хәерхаһлык нияте илә оптимистларча язылса: «Камил Мотыйгый артист вә җырчы вакытында тәфсирләр язарга, мәктәпләр идарә итәргә, гыйльми мәкаләләр язарга («Шура»ның 10 нчы номерендагыча), мәсҗедләрдә Коръән укырга вә гайре төрле эшләр эшләргә өлгергән кеше мөфти булгач, әллә нинди файдалы эшләр, төрле китаплар чыгарыр, мәктәп вә мәдрәсә эшләренә, шөбһәсез, әһәмият бирер һәм кирәкле фәтва-рисаләләр язып таратыр» иде диярәк башланыр иде.

Хәзер «Тормыш» идарәсендә Гаяз әфәнде дә бар, ул да мине сүгеп язуны куәтли булырга кирәк дип уйлыйм. Чөнки тәбган[1], җенсән[2] миңа тараф булмаган бер кешенең минем хакда хәерхаһ булуы мөмкин дә түгелдер. Әлегәчә аның миңа бер яхшы сүз әйтмәсе дә моңа дәлилдер. Бинаән галәйһи[3], сездән ошбу шәйләрне мөляхәзә идәрәк[4] ошбу хакда җитди бер мәкалә язмакыңызны үтенәм. Күптәнге танышыңыз вә хәерхаһыңыз Камил әл-Мотыйгый Төхвәтуллин.

Хат 1915 елның 28 июлендә татар журналисты, нәшир Камил Мотыйгый (Төхфәтуллин Камил Мотыйгулла улы, 1883–1941) тарафыннан юлланган.

Хат гарәп графикасында, татар телендә «Мөхәммәд Камил әл-Мотыйгый-Төхфәтуллин» дигән бланклы кәгазьгә кара каләм белән язылган. Күләме 1кәгазьдән, 1 биттән гыйбарәт.

## Фәхрелислам Агиев хаты

Хөрмәтле Фатих!

Мәскәүдә аз гына арада Ибраһимны күреп алган идем. Сезнең Кырымга баруыгыз хакында да бер-ике сүз әйтеп үтте. Үткәндә Мәскәү аркылы үтәрсез, әлбәттә, шуңар күрә бәлки берәр көнгә тукталырсыз да. Суфия һәм Үзбәкләрне дә Кырымның бер читенә озатдым. Өем буш, үзем ялгыз гына – шуңар күрә дә Мәскәдә туктыйсыгыз булса, миңа туктарсыз дип уйлап калам. Бу – бер.

Икенчедән, сезнең бастырырга уйлаган әсәрләрегез хакында. Бу турыда Гасыйм ипдәшкә язган хатларыгызны күреп алган идем. Ләкин ул мәсьәләне тәмам тишеп бетерә алмасдан, тизлек белән ял итәргә китеп калды. Ибраһим белән бераз сүз алышкач, мин мондагы әрбабны күрдем, фикер алышдым. 10 табаклар күләмендә бер җыентыгыңны бастыру фикеренә киленде. Әлбәттә, гел әледә басылып чыкканнардан гына түгел, моңарчы басылмаганнарының да булулары мәтлуб[5] дип миңа боерык бирелде.

---

[1] Тәбган – ияреп.
[2] Җенсән – җенес-нәсел ягыннан.
[3] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.
[4] Мөляхәзә идәрәк – фикер йөртеп.
[5] Мәтлуб – соралган, таләп ителгән.

Бинаән галәйһи[1], шундый мәҗмугачыңыз бар булса һәм аны үзегез белән алып килә алсагыз – яхшы булыр иде.... Мәскәүдә чагында могаһәдә[2] язышканда ук сезгә тиешле булган акчаны бирә алмасак да, сез Кырымга барып җитүегезгә акчаңыз да, иншалла, барып җитәләр дип, безнең шартлар тәкърибе шулай:

1) бер табак дип 40 000 мең матбага галәмәте санала. Бу инде без аңлаган гади басма табакдан артыграк чыга.

2) могаһәдә язышканда, 25% бирелә. Кульъязмалар тапшырылгач, янә 55% бирелә. Басылып чыккач һәм тәмам хисапланып беткәч, калган 25% бирелә.

3) әдәби әсәрләрнең табагына моңарчы 70–75 сумнар түләнә килде.

Шуларны белгереп сезгә ошбу хатны 4 ендә үк язарга дип вәгъдә кылсам да, шөгыльләр килеп чыгулары аркылы вәгъдәмдә тора алмадым. Шуның өчен дә бу хатны инде сезгә ашыгыч почта илә җибәрәм.

Хөрмәт илә кулыгызны кысып, Фәхрелислам Аги.

Мәскәү, Зур татар урамында, 25 нче йорт һәм беренче фатирда.

8.08.1925.

Хат 1925 елның 8 августында журналист, педагог, язучы, Ф. Әмирханның якын танышы Аги́ев Фәхрелислам Нигъмәтулла улы (1887–1938) тарафыннан юлланган.

Хат гарәп графикасында, татар телендә, кызгылт-көрән каләм белән язылган, конверты да сакланган. Күләме 1 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Ләбибә Хөсәения хаты

Мөхтәрәм мөхәррир Фатих әфәнде Әмирхани!

Дарел-мөгаллимат[3] хакында сөалегезә җавап.

1 нче: бу сәнә бер сыйныф булды, көзгә икенче сыйныф илә бер тәхзария[4] сыйныф булачак.

2 нче: ханымнар иганәсе вә шәкертләрдин дөхулия[5] акчасы илә тәэмин иделде.

---

[1] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.

[2] Могаһәдә – килешү, договор

[3] Дарел-мөгаллимат – хатын-кыз укытучылар әзерләү мәктәбе

[4] Тәхзария – хөрмәтләнгән, зурланган. Монда: зурраклар.

[5] Дөхулия – уку өчен алынган хак.

3 нче: укыган дәресләрдин һәм гарәбият, хисап, һәндәсә[1], тарих, табигать, ана теле, җәгърафия, русча, рәсем һөнәре.

Программа буенча гимнастика керер тиеш булса да, урын булмадыгындин калдырылды. Һәм русчалары йитешсез булдыгындин хыйфзес-сыйххәт сәгатенә дә русча укытылды.

4 нче: рөкъгә[2] мөгаллиме – Габдрахман хәзрәт Галиев, дин, гарәбият мөгаллимәсе – Ләбибә Хөсәения, тәхсиле[3] эткәсе Чуаш иле мулла Һади Бакировда һәм бөрадәре Чиләбе имамы мулла Мөнир Һадиев һәм Галимҗан хәзрәтдән.

Фатыйма Дәүләткилдиева – тарих мөгаллимәсе, гали мәктәп тәмам иткән.

Сара Шакулия – һәндәсә мөгаллимәсе, Мәскәү дарелфөнүнен тәмам иткән һәм Парижда математический факультетта тәхсил иткән.

Суфия Таһирия – хисап, җәгърафия һөнәре мөгаллимәсе, тәхсиле эткәсе Шакир Таһировдан дин һәм фән үтеп, ибтидаи мәгълүмат алгандан соң, хосусый рәвешдә хәзерләнеп, 4 сыйныф гимназия дәрәҗәсендин имтихан тотып, ибтидаи мәктәпдә рус теле мөгаллимәсе булган, дин һәм гарәбиятне Ләбибә Хөсәениядән укыган. Ләбибә Хөсәения мәктәп вә мәдрәсәсендә 12 ел мөгаллимлек итмәкдә.

Әминә Галиева – ана теле мөгаллимәсе, Ләбибә Хөсәения мәдрәсәсендә укып, соңра Төркиядә тәхсил иткән.

Мәдинә Сәгыйдова – табигать мөгаллимәсе, гимназия тәмам иткән.

Александра Павлова – рәсем мөгаллимәсе, художественный мәктәп тәхсил иткән.

5нче: шәкертләр һәрбер дәресне бик тырышып, бик яратып укыйлар һәм һәр укытучылар үз дәресләрендин бик мәмнүн булдылар.

Ләбибә Хөсәения[4].

---

[1] Һәндәсә – геометрия.

[2] Рөкъгә – язу төре.

[3] Тәхсиле – гыйлеме.

[1] *Ләбибә Хөсәения, Ләбибә Һади (Кади) кызы Хөсәения (Һадиева) (1880–1921) – 1904–1918 елларда Казан шәһәрендә татар кызлары өчен мәктәп ачучы һәм аның мөдәррисе.*

Хат 1904–1918 елларда Казан шәһәрендә татар кызлары өчен мәктәп ачучы һәм аның мөдәррисе Ләбибә Хөсәения тарафыннан юлланган. Язылу датасы күрсәтелмәгән. Хат гарәп графикасында, татар телендә, көрән кара белән язылган. Күләме 1 кәгазьдән, 1 биттән гыйбарәт.

*Хат текстларын, искәрмә һәм аңлатмаларны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*
*Ләйлә Гарипова әзерләде.*

## Ризван Алуши хаты

1908 сәнә, ноябрь

Фатих! Мин үзем кешедән килгән хатларны, әһәмиятсез булса да, укырга яратдыкымдан үзгәләрне дә шулайдыр, диеп белеп, озын-озын хатлар язгалыйм. Без синең хатыңны алгач, әллә чыннан да тагы язармы, дию, бераз көтеп тормыш идек. Ләкин мин синең андай язармынларыңны белгәнгә күрә, алай ышанмадым да. Фәкать һәрнәрсәгә ышанучы хатынлар таифәсендән[1] улган рәфикам[2], тәмам ышанып, синдән хат көтеп тора...

Синең хатыңдан рәсемләр хосусында, «юмира»[3] уларак, тәнкыйдләр көткән идек. Әллә син анларны бер дә дикъкатькә алмагансың? Дөрестне генә язганда да, анда бик күп кызыклары бар. Җөмләдән берсе: «Мин курыкган идем, артда күренмәм, дию», вәхаләнки[4] берәр аршин кадәр аякларым сездән узып төшкән. Икенче, Фәрханәгә: «Мунчадан чыкган халәтдәге кеби төшдең, димеш, идем». Вакыйган, изүнең ачыклыгыны мөляхәзә итдекдә[5], нәкъ шул рәвешдә булган. Синең астагы кулыңның фига (кукиш) көстәреп[6] торуы, белмәм, фотографист менә сиңа дигәннеме, әллә нине белдермәкдәдер?

Мәктүбеңдә Ибраһим Бейрутка китде, дигәнсең. Аны ишеткәч, әллә ниндәй бер солдат хикәясе хәтеремә килде. Әллә хәзер сыерны кеше итәргә Бейруткамы йибәрә башладылар? Борһан

[1] Таифәсендән – төркеменнән.
[2] Рәфикам – хатыным.
[3] Юмира – юмор.
[4] Вәхаләнки – чынлыкта.
[5] Мөляхәзә итдекдә – игътибар итүдә.
[6] Көстәреп – күрсәтеп.

«Вакыт»ка киткән икән. Бездә бер кеше бар, шул әйтә: «Каюбер гәзитәне туктатуны теләсәгез, мине мөштәри[1] яздырыгыз, – ди. – Әфсүн укыган кеби, акча барып җитмәс борын ук туктый, – ди. Мин әйтәм: «Каюбер гәзитәне туктатасыгыз килсә, Борһан Шәрәфне секретарь итегез», – дию...

Фатих! Мин сиңа беркөн бер рисалә сымак нәрсә язып йибәргән идем. Анда иске мәдрәсә сәмәрәсе[2] генә, диеп китәчәк йирдә «Гаспринский илә Шәркы рус»ны, бу да татар мәдрәсәсенең сәмәрәсе, диелгән. Әгәр эшкә ярарлык булса да, шул көе нәшер иделсә, анларны татар мәдрәсәсенең шәкерде итеп көстәрү бик көлке булып чыгачак. Шуның өчен әйтәм, зинһар шул җөмләне бозып, иске мәдрәсә, диеп кенә калдыр.

Чита хәбәрләре.

Читада хедмәтләремезнең сәмәрәсе көн-көндән күзгә күренә бармакдадыр: хәзер бу йирдә дә Ачинскидагы кеби ирләр вә кызларны бергә җыйнап, «Мөсавәт» мәктәбе ачдык. Каршы торучы булмады. Хәтта үткән ел безгә һөҗүм иткән кешеләр зур-зур кызларны китереп тапшырдылар. Пәрдә тәмам бетеп бара дияргә ярый. Безгә теләгәнчә йөрергә, сүз тиермәскә, дию сүз бирделәр. Икенчедә, хатынлар мәктәбе ачылды. Анларны Фәрханә укыта. Татар хатынлары гына дәгел, татарлар илә торучы рус-еврей кызлары да Фәрханәдән укыйлар. Үткән ел, күз ачырмый, кайда күрсәләр, эт кеби өргән хатынлар хәзер, кулларына грифель такта тотып, сабак укыйлар. Гаеддә картлар өчен мәктәп ачарга кызыкдырып сөйләмеш идем, ихтимал, ул да ачылыр.

Хәзер русский класс ачарга рөхсәт сорап һәм иганәт[3] сорап, управага гариза бирдек. Гаеднең өченче көнендә мәктәп файдасына «цирк» уйнатылды. Татарларны хатынлары илә барырга мәҗбүр итдек. Мәктәп файдасына буфетдан эчәргә мелла фәтва[4] бирде. Расхутдан[5] тыш халис[6] ике йөз кырык сум акча алдык.

---

[1] Мөштәри – сатып алучы.
[2] Сәмәрәсе – җимеше, нәтиҗәсе.
[3] Иганәт – акчалата ярдәм.
[4] Фәтва – рөхсәт.
[5] Расхутдан – дөресе: расходтан – чыгымнан.
[6] Халис – саф.

Читага указлы имам килде. Болай хәзергә минем өчен зарарлы күренми. Зыялы сафында үзене тотарга тырыша. Яшьләргә каршы килми, хатынын качырмый, хотбәләрне[1] татарчалап укый. Бу ел городскойда һәм коммерческийда берәр ир бала, приходскийда ике кыз бала укый булыр ахры инде.

Фатих, Казанда кемләр бар? «Әлислах»да кемләр калды? Син кайда торасың? Исмәгыйль шулай чындан да кеше булып җитдемени? Вечер-театрларда була аламсың? Вакытың илә яз. «Әлислах» миңа шул әүвәл бирмеш биш данәдән башка килмәде. Хәзергә хуш. Ризван. Терелә аламсың?

Хат 1908 елның ноябрендә Ф. Әмирханга мөгаллим, журналист Ризван Алуши (Ибраһимов Ризван, 1883–1938) тарафыннан язылган. Алар Ф. Әмирхан белән сабакташ дуслар булалар. Фәрханә – Фәрханә Рәхимгәрәй кызы Бәхетгузина (1886–1958) – Ризван Алушиның хатыны.

Хат озынча шакмаклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Борһан Шәрәф хаты

Оренбург, 5 декабрь 1908 сәнә

Фатих!

Бу арада бер дә хат язмаганымны искә төшереп, кичә җавап язасы хатларны аерып куйдым, 14 гадәд[2] чыкды. Үземә дә шактый оят булды. Инде рәтдән тезеп, җавап язарга керешдем. Синеке өчен тагын бер кат гөнаһлы булдым. Чөнки андан элек алынган башка хатлар һаман да көтә калдылар әле.

29 октябрь хатыңны беренче укыгандук бик яхшы аңлаганыма ышансам да, тагын-тагын укыдым. Кызык бит. «Хәят» әсәре бар. Ләкин минем сиңа каршы булган ихтисасатымны[3] Сәгыйтькә каршы булганларына ошатуың яисә ошый, диеп шикләнүең мине борчый язды. Без икемез дә әлегәчә морадларымызны[4] бик тугры аңлаша идек бит. Ялгыш аңлату ихтималлары була башласа, күңелдәге яшерә башланыладыр (нинди кыен сүз чыкды).

---

[1] Хотбәләрне – нотыкларны.

[2] Гадәд – сан.

[3] Ихтисасатымны – тоемлавымны.

[4] Морадларымызны – аңлатырга теләгәннәрне.

Минем көндәлек илә мәрак итүеңә[1] куанмаска мөмкин түгел. Чөнки бик якын кешеләрнең генә хосусый мәгыйшәтләре[2] интересный тоеладыр. Бәйрәмне ничек уздырганымны тагын сорыйсың! Яздым бит: мин бәйрәмне уздырмадым, бәйрәм миндән кырыйда узып китде, мин бүлмәмдә утырып калдым. Хуш. Син императрица Мария Феодоровнаның туган көнен яисә Смоленский божья материның табылган көнен ничек уздырдың? Ә! Мин бәйрәмдә һичкемдән һичнинди хиссият алмадым. Инде бик җөдәткәнгә күрә хәзер исемә төшкән бәйрәм вакыйгасын языйм: икенче көндә, яшьләр илә җыелып, Ибраһим Каргин фатирында 5 сәгать карта уйнаганның соңында 7 тиен зарарлы чыкдым. Шул сылтау илә, кайтканда ямщик акчасын мин түләмәдем. «Бер үгездән 7 тире суймыйлар», – дидем.

Фатих вә Риза әфәнделәр тугрысында берни дә язарга хәтеремә килми. Өйләренә мин еш йөрим. Алма бәлешләрен яхшы пешерәләр. Сөтләре куе, чикләвекләре һәрвакыт мул була. Безнең өчен шунысы йитде түгелме? Бик җидди мөзакәрәләргә[3] керешә башласалар, минем һәрнәрсәдән көлә алуым ярдәмгә йитешә. Диннең генә түгел, мәдәниятнең дә мөкаддәс нәрсәләрен аяусыз мәсхәрә итә алуым сүзне икенче сурәткә кертми калмый. Менә шул.

Вак хикәяләр яза башлыйм дигәнсең. Бик хуп. «Шура»га дигәнләреңне йибәр. «Ярар» диделәр. Хәкарәт[4] саналган мәхәббәт тугрысында «чепуха» диюеңә игьтираз итә алмыйм[5]. Ләкин ул башкаларның да шулай чыгачагына дәлил түгел.

Коләхмәтовның сүрелүенә тәэссеф итәм[6]. Мин аның илә бу җәй генә танышып, мәҗлесендән «Хушнуд»[7] калган идем. Кстати, Гафур очраганда миндән бер сәлам бир әле.

Әдәбият кружогын бетергәнсез, дип ишетдем. Яхшы түгел.

Рәкыйб монда килгән иде. Казанны сорашдым, сорашдым. Эчке вә комар[8] мәҗлесләрен генә сөйләде. Шул арада миндән дә ике бутылка эчде. Вәссәлам.

---

[1] Мәрак итүеңә – кызыксынуыңа.
[2] Мәгыйшәтләре – тормышлары.
[3] Мөзакәрәләргә – фикер алышуларга.
[4] Хәкарәт – хурлык.
[5] Игътираз итә алмыйм – кире кага алмыйм.
[6] Тәэссеф итәм – кайгырам.
[7] Хушнуд – канәгать.
[8] Комар – отышлы уен.

Монда мәдрәсәи «Хөсәения»гә мөгаллим булырга ике нури килделәр. Берсе шактый белекле вә эшлекле. Идеягә хедмәт өчен йөри. Күп катышсам, миңа тәэсир иҗраэ[1] итмәсен, дип, бер минут улса да шикләнеп алдым. Икенчесе сиртүкдән[2], фәсдән[3] [...]. Мин Закир Рәмиев вә Ризалар алдында булса да көлүемне яшерә алмадыгымдан беренче очрашкандук рәнҗемәсен дия, чыгып китдем.

Кичә Истанбулдан Сибгать Дәүләткилдиевдән хат алдым. Хат язышыйк, дигән. Белмим әле, язышасымыдыр, юкмыдыр.

Мин корбан бәйрәменә кайтмыймдыр, ахры. Бер дә бәйрәм итәсем килми. Казанны әле бер дә сагынмадым да. Читдә торуның үзенә күрә бер кызыгы бар бит, ягъни сагыну ләззәте (тәнакыз[4] куркынычлы түгел).

«Әлислах»ның гомумяшьләр органы булуын язган идең. Шул мәсьәләне белдереп, калганы монда мәгълүм булмай тора. Үзеңнең саулыгың, өмид итәм, алга бара торгандыр.

Кәбир, Вафага сәлам.

Мөкаддәс хиссиятләргә ихтирам белән ипдәшең Борһан.

Хат 1908 елның 5 декабрендә Ф. Әмирханга әдип, педагог, журналист Борһан Шәрәф тарафыннан язылган.

Хат озынча шакмаклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Ризван Алуши хаты

1908 сәнә, 30 декабрь

Фатих! Син, «Чүкеш» илә сүгешә-сүгешә, безне тәмам оныттың, ахры. Аның илә сүгешер өчен безнең Аидовлар бакчаларында урындыкымыз сүгешләр генә кифаять идәчәк[5] дәгелдер. Дөрестен генә әйткәндә, ул эшегезгә «Ислах» укучыларының күбесенең кәефе кырыла, разый дәгелләр.

«Әлислах» безгә никдер килми, туктагандыр, ахры, дию, сорашып карадык, чыга әле дә, диделәр. Кеше күзенә күренерлегем калмады, «Таң»га екерме сум җыйнап йибәрдем, ул туктады.

---

[1] Тәэсир иҗраэ – тәэсир.

[2] Сиртүкдән – сюртуктан.

[3] Фәсдән – конуссыман формалы, чуклы милли баш киеменнән.

[4] Тәнакыз – каршылык.

[5] Кифаять идәчәк – җитәрлек.

«Тәрбияи этфаль»га унсигез сум йибәрдем, ул килмәде. «Әлислах»ка катышмам, дигән идем, бу ел эшегездә җиддиятне күреп, вә дәвам итдерергә тырышдыкыгызны белеп, янә мөштәриләр табып йибәртдем, тагы тозакга эләкдем. Һәрбере «Ислах» нишләр, ник килми, диләр... Хасыйл[1]. Бик күп пинәләшерлек[2] эшләрегез бар.

Бән берничә дәфгалар[3] мәктүб яздым. «Әлислах»га мәкаләләр дә йибәрдем. Ләкин һичберсенә җавап ала алмадым. Язмыйм инде, дию торсам да, янә хәбәрләр күбәйгәч, язарга мәҗбүр булдым.

13 нче декабрьләрдә Рәшид бабай бездә булды. Бичара шәйхе фанилек[4] дәрәҗәсенә килгән. Сүз вә кылынышларының җае беткән. Садакачы карт меллалар дәрәҗәсенә төшкән. Гакылы вә зиһене таралып, эшдән чыкган. Һәр кылган эшләренә үкенә, тәүбә итә. Ике сүзнең берендә «Алла» кычкыра. Үзенең дингә булган хедмәтләрен искә алып сөйли, егълый, көлә. Бер зур мәҗлесдә, иске китапларга ничек алай юк-барны язганлар икән, дию сүз чыккач, диде: «Менә, язучыларың берсе мин. Ләкин мин үзем язган нәрсәләрнең әксәрен[5] күрдекемдә үзем оялам. Мин екерме биш сәнә, хотбәләрне татарча кирәк, дию кычкырдым. Үзем һаман тугры килгәндә татарча укыйм. Әмма мин Казандан киткәндә, бер зарурәт сәбәпле, "Миръат"да, ул фикеремдән кайтдым, дию яздым. Безнең Тарада пәрдә булганы юк, безнең гаилә аны белмидер дә. Мин ул тугрыда күп яздым, сөйләдем, әмма бу соң заманларда мин, безгә хәзергә пәрдә зарури дигән булып язгаладым. Моның әмсале[6] бик күп эшләр бар. Аны барын да әйтмәк лязим дәгел. Монда байларның да гаебе бар. Анлар кибетләренә хуҗа булган кеби, безгә дә хуҗа булалар. Безнең кеби гаҗиз мохтаҗ голяманы[7] кулга алып, үзләренә муафыйк фәтва[8] бирдерәләр. Безнең өчен хәят кыйммәтле. Безнең башкача сәүдәмез юк. Жизнь безне күп дәфга вөҗданымызга хилаф эшләрне кылырга заставить итә», – диде. (Мин Рәшиднең бу кадәр инсафка килүенә, вөҗданга кайтуына, үзенең

---

[1] Хасыйл – нәтиҗә.
[2] Пинәләшерлек – гаепләрлек.
[3] Дәфгалар – тапкырлар.
[4] Шәйхе фанилек – картлык.
[5] Әксәрен – күбесен.
[6] Әмсале – мисаллары.
[7] Голяманы – галимнәрне.
[8] Муафыйк фәтва – туры килгән күрсәтмә.

сатлык бер кеше идекен шулкадәр әһали алдында икърар кылуына шаккатдым.)

Себердә ишанизм юк, милләт акчасы алай әрәм китде юк, дию фәхерләнә[1] идек. Бу исә ишанлардан да яман. Бер эшсез, көчсез Себернең бер башындан икенче башына кадәр себереп, җыйнап йөри.

Без яз өчен планлар төзи башладык. Син дә вакыты илә үз фикереңне белдерерсең, өмидләнәмез.

Ниятләремезнең берсе: шул «яшьләр китап сәүдәсе» бер ширкәт уларак тәэсис итмәк[2], икенче ниятем: Америкага китмәк.

Хат яз. Аякларың ничек? Ниләр бар? Ризван.

Хат 1908 елның 30 декабрендә Ф. Әмирханның Ерак Себердә эшләгән сабакташ дусты мөгаллим, журналист Ризван Алуши (Ибраһимов Ризван, 1883–1938) тарафыннан язылган.

Хат ак кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 3 кәгазьдән, 2 ярым биттән гыйбарәт.

## Борһан Шәрәф хаты

«Вакыт» гәзитәсе
Оренбург. (Россия)
1909 сәнә. 31 март

Фатих!

20 март хатыңны алдым. Казандан хатларың күп килде. Ялыкдырмаса да, сирәк килүе тансыкландыра икән. Син күпдәндән бирле язмый идең. Газиз дә никдер язмый башлады.

«Эсперанто» нөсхәсен алдым. Рәхмәт. «Вакыт»да язылуы аны алуымдан мөкаддәм[3] иде. Шуңа күрә үзенә йибәргәч дә кыска язган, дип, игътираз килмидер[4]. «Йиде асылган кешеләр»не күпдән түгел укып чыкдым. Ләкин синең шикелле егъламадым. Син укудан да бик тәэсир булгач, бәлки бик һәйбәт тәрҗемә кылгансыңдыр. Успех телим. Исеменә «Асылган йиде кеше хикәясе» дип куелса, «Йиде асылган кешеләр хакында хикәя» диюгә күрә

[1] Фәхерләнә – горурлана.
[2] Тәэсис итмәк – төзү.
[3] Мөкаддәм – алда.
[4] Игътираз килмидер – кире какмыйдыр.

йиңелрәк булыр. Сатылу вә мәкъбүлият[1] өчен аның да тәэсире юк түгел. Син шуның өчен дә мине «Борһан хәлфәлеге» әле дә бетмәгән, дип сүкмәссең бит. «Фәтхулла хәзрәтнең үлгәндән соң терелүе» «Әлислах» дагыга башка буламыни? «Җуялган хатын» тугрысындагы премияң миңа эләкде. Тронут.

Айтуган вакыйгасы сине пошырмаган түгел. Инде андый хадисәләргә[2] күнә башларга, бәлки шуны урегулировать итәргә заман килмәдеме икән?

Монда мәдрәсәи «Хөсәения»не һичничек дә низамга[3] сала алмыйлар. Инде апдырагач, «Хәбәр»дә, кешеләрне җыеп, мәҗлес ясарга карар биргәнләр. 2 нче апрельдә мәҗлес була. Мөдирләр (попечительләр) мөгаллимләр һәм бөтен Оренбургдан 25 кадәр кеше чакырылган. Мин дә бүген дәгъвәтнамә[4] алдым. «Мәдрәсәне ислях кылу[5] тугрында мөшавәрәт[6] мәҗлесенә» дип язылган. Мәдрәсә мәсьәләсендә ничә ел чуалып йөрелеп дә иҗаби[7] һичбер нәрсә тәклиф итәргә[8] карар бирә алмый тору кыен икән. Бу мәҗлесдән дә бернәрсә дә чыкмасдыр.

Гыйрфанзадәнең фельетоны чибәр. Кем ул? К. Бәкер әдәбият юлына нык баса. Ул шактый юл алыр. Богданов да шулай. Икесе арасында әллә нәрсә общий бар шикелле тоела.

Тасхих[9] Коръән мәсьәләсенә без («Вакыт») сарыфны гына карадык. Беренче мәҗлесендәге отчетын язганда мәсахиф[10] «Госмания»гә әтбаг[11] важиб[12] булмаудан котылып, Коръән тугрысында күңелләрдә генә булса да бер какшау, бер тәзәлзел[13] ясауны ният иткән идек. Инде мәҗлес әтбагны важиб, дип карар биргәч, ул максат фәүт булды[14]. Шәйхелисламга илтеп торуымыз шушы

---

[1] Мәкъбүлият – кабул күрелү.
[2] Хадисәләргә – вакыйгаларга.
[3] Низамга – тәртипкә.
[4] Дәгъвәтнамә – чакыру кәгазе.
[5] Ислях кылу – үзгәртү.
[6] Мөшавәрәт – киңәшләшү.
[7] Иҗаби – уңайлы.
[8] Тәклиф итәргә – көчләп кушарга.
[9] Тасхих – төзәтү.
[10] Мәсахиф – китаплар.
[11] Әтбаг – китап бастырулар.
[12] Важиб – тиешле.
[13] Тәзәлзел – тетрәү.
[14] Фәүт булды – үлде.

сылтау илә аңа мөнәсәбәт пәйда итүдер. Истамбулда шул мәсьәләне кузгату үзе дә әһәмиятсез түгел. Бөтен мөселманлар арасында общий мәсьәләләр кузгату, я кузгалганларны общийлату кызык булыр иде. Истамбулда да Муса шикеллеләр бетмәгәндер. Тик кычкырышсыннар. Без шул арада үземезгә кирәген подчеркнуть итә торырмыз. (Бу юлларның сиңа кызыксыз сурәтдә тәкрар ителүенә ихтимал ясамассың.)

Үзеңнең савыгуыңны язмагансың, алга табадыр бит?

Җәй көне выставка күрергә кайтачакмын. Бу арада болай да Казанны сагына башладым әле.

Гомуми мәсьәләләрдә үзара бик радикальный хатлар язышып, шуны таратсаң, кызык булыр иде. Анда гаммәгә[1] сөйләмәслек нәрсәләр язарга да була. Соңыннан нәшер итүе тагын була. Язучы да, нәшер итүче дә гаепле булмый. Болай китап чыгарган шикелле түгел. Пәдәреңхәзрәткә сәлам. Мәгассәляме галәйки вә галәйһи ләйкә. Бакый Ш. Борһан.

Хат 1909 елның 31 мартында Ф. Әмирханга әдип, педагог, журналист Борһан Шәрәф (1883–1942) тарафыннан язылган.

Хат Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасы бланкына кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Ризван Алуши хаты

1909 сәнә, 13 апрель

Мөхтәрәм Фатих әфәнде!

Сине борчыган вә сыхратканым өчен гафу үтенәм. Ләкин «гаепне үз өстемә алмаенча, кара таплы тарихымызга ташлыйм». Бәнем кемлегемне яхшы белә торып, кәефең киткәнгә, сине бераз мөахәзә итмәк[2] булам. «Үткән вәкаигымыз[3] кешегә көстәрергә дәгел, хәтта үземезгә әйләнеп карарга да яраклы булмадыкы өчен, бөтен яшьлек-шәкердлек чакларымызга ләгънәт укыйм». Кеше аңларлык яза белмәвемә вә кеше язганны аңлый алмавыма үземне шелтә итә-итә сезнең алга тез чүгеп, баш иям. Вә мондан соң кеше

[1] Гаммәгә – массага.

[2] Мөахәзә итмәк – тәнкыйтьләмәкче.

[3] Вәкаигымыз – вакыйгаларыбыз.

язганны укудан, күз вә телемне тыеп, язу язудан, кул вә каләмемне тотмак булам». Дуст вә аркадашларымдан «газизем, фәләнем» кеби титулларны теләмәенчә, фәкать Ризван исемем илә «яд» иделергә лаек булсам, шуны бөек шәрафәт[1] белеп, аңларга меңмең мәртәбә риза идекемне белдерәм...

Фатих дуст, син, мәктүб язмавыңа гозер көстәргән булып, ни язаем, авыруымнымы? Ул исә сезне туйдырган вә ишетәсегез килмәүне беләм, диясез. Бу сүз вә бу җөмләне тәшрих итеп[2] карагандa ни булып калачак, без белдерергә теләмимез, имеш. Нинди бер дуст, җандан газиз күргән бер аркадашының рәнҗеп ятканын белеп, аның хәлен белергә теләмәсен. Бездә улкадәр каты җан юк. Менә мин икәвемезнең дә кальбен сиңа көстәрим, безнең һичбер чәй яны – я һичбер карават... яны сине искә төшерми, сине сагынмый үтми. Хатчыдан көткән мәктүбләрнең иң әһәмиятлесе – син. Дүрт күз илә көтелгән синең мәктүбдер, мәктүбеңдән көтелгән хәбәр дә шул синең авыруыңның ни дәрәҗәдә, алдамы әллә искечәме идекен белүдер. Син «замана хикәяләр» яза башлаган икәнсең, әлбәттә, әллә ниндәй хыяллар язуга караганда вәкаигъны хикәя тарызында тасвир итеп язу, үзең өчен дә вә кариэләр[3] өчен дә бик зур файда вә тарихга да олуг ярдәмдер. Без синең язган мәкаләләреңне, башдан бирле бер дә калдырмый, сөеп, ничек укыган булсак, «замана хикәяләре» яза башладыкдан соң бигрәк дә ихлас илә укырга керешдек. Казый, мирза, моталәга иткән[4] шәкердләр кеби язуларыңдан мәгънә аңларга тырышып, төрлечә тәэвилләрдә булынып[5], ни тугрыда язылдыкларына кадәр барып җитә башладык. Затән[6] тарихи булдыкларындан наши[7], ни тугрыда язылдыкларын белмәк кариэләрнең вазифалары булырга тиеш. Менә без дә «Милләт тәрәккый итдерү» хикәягезне укып вә үз тарих сәхифәләремезне ачып, аның илә бергә-бер мотабикъ[8] табып, шул хакда фикеремезне йөртеп карадык. Безем тарихның кешегә дәгел үземезгә карар өчен дә йөз кызарткыч булуындан наши

---

[1] Шәрафәт – дәрәҗә.
[2] Тәшрих итеп – ачыклап.
[3] Кариэләр – укучылар.
[4] Моталәга иткән – укыган.
[5] Тәэвилләрдә булынып – аңлатып.
[6] Затән – нигездә.
[7] Наши – барлыкка килгән.
[8] Мотабикъ – охшашлык.

үземезнең хәятымызда мәйданга куелуын әүвәл дә синең кул илә көлке сурәтдә нәшер иделүен бер дә көтми вә теләми идем. Истикъбаль[1], әлбәттә, аны казып чыгарыр иде, ләкин ул заман берничә кешене генә дәгел, бәлки шул комедиядә автор булган сезне дә катыштырыр иде, дию уйланды. Безем кәефкә тукынган[2] йире шулкадәр булды. (Мин үз аңлавыма улкадәр таянмасам да, ихтимал шул нәтиҗәләрне чыгардыкым өчен артык гафу ителмәслек дәрәҗә яңлышлык иткәнмен, дию дә белмим.)

Сезең ул мәкаләңегезне «кәндемә алдыкымны» кеше аркылы белдерүем, сездән һичбер төрле җавап ала белмәдекемдәндер. Борадәр газизем! Мин русча аз аңласам да, тырышып укый торган гадәтем бар, сезең русча язган мәктүбегезне алып, әллә ниндәй «рассказлар», әллә ниндәй кара гәзитәләргә мәкаләләр язуым өчен үпкәләр аңладым. Минем кулыма каләм тотдырып, язу язарга үгрәткән сез идегез һәм гәзитәләргә мәкаләләр яза тору кувәи тәхририянең[3] артуына олуг ярдәм була, дию төшендергән дә син идең. Шуңар бинаән[4] бән бәгъзән[5] гәзитәләргә мәкаләләр язгалыйм, ел әйләнәсендә һәрбер гәзитәгә аз-аз язып чыгам. Фәкать мең тәәссеф[6] язган мәкаләләремне «Әлислах»ка, каю ки үз гәзитәмез саналган «Әлислах»га ярата алмаем. Ничә дәфга мөрәҗәгать итеп, бер мәкалә дәрҗ итдерә[7] алганым юк. Имди ни кыласың, бөтенләй язу ташламас өчен шул караларга булса да язгаланыла. Анда да синең хөсне ризаң[8] илә язам. Имди хәзер сез разый дәгел идекегезне белдем, каләмемне куйдым, бетде. (Хасыйл, дустлар арасында әлмисакдан бирле[9] үпкә дәвам итә!)

Фатих! Язган мәкаләләрең, белмәм, хәятдән алындыкынданмы, белмәм, кувәи тәхририянең артуынданмы көн-көндән укучылар өчен ләззәтле вә хәссани[10] була бара. Шуның өчен дошманнарыңның тагыныңдан[11], аңсыз дустларыңның үпкәсендән

---

[1] Истикъбаль – киләчәк.
[2] Тукынган – кагылган.
[3] Кувәи тәхририянең – әсәр язу көченең.
[4] Бинаән – таянып.
[5] Бәгъзән – кайвакыт.
[6] Тәәссеф – ачынып.
[7] Дәрҗ итдерә – бастыра.
[8] Хөсне ризаң – ризалыгың.
[9] Әлмисакдан бирле – яратылганнан бирле.
[10] Хәссани – бик гүзәл.
[11] Тагыныңдан – хурлавыннан.

тартынмый яза бир. Язылган мәкаләнең хәятка тәгалекъле[1] булуы мөхәррире өчен үзе бер фазыйләт[2]. Укучылар өчен дә аерым бер ләззәтдер.

«Сабах»дан алдырдыкым китаплар арасында синең каләмең илә вөҗүдкә чыкган «Эсперанто теленең кагыйдәләре» намында бер китап күземезгә күренеп, гаять шадландырды. Ул китап күптән безнең арзу кылып[3], эзләп йөрдекемез нәрсә булуы өстенә, сезнең каләм илә язылган булуы рәгъбәтемезне[4] дәһа бер мәртәбә артдырып, сезгә кат-кат рәхмәтләр укырга мәҗбүр итде.

Үземез сәламәтлек илә кышны уздырып киләмез. Апрель екерме бишләрдә имтиханларымыз башланып, май башында хедмәтемез тәмам улачак. Шундан соң Читаның үзендә берәр кәсебкә шөругъ итмәк улып[5] торамыз. Амур, Благовещенск тарафларына сәяхәт касдымызда[6] бар иде. Ләкин хәзергә ул фикерне куеп торамыз.

Менә борадәр! Чәчәк кеби яшьлек гомеремез фәкыйрьлек илә тәхсилле[7] узды. Андан үпкәмезне черетеп чыкдык. (Воспаление легкий илә авырдыкым хәтереңдәдер.) Андан чыгып, сыйххәткә мәзар[8] улган сасы – тузанлы суык мәктәпләрдә балалар укыткан булып (гыйлемемезнең файдасын күрәмез дигән булып, үземезне алдап), калган сәламәтлегемезне дә, юклы-барлы кешелегемезне дә бетердек. Бу ел шактый гына агырулар да күреп үткәрдем. Менә инде, шул ахры кабердән башка нәрсә күренмәгән хедмәтне терәк итеп, икенче берсенә керешмәк буламыз... Икенче берсенә димәккә, белмәгән, хәзерләнмәгән, соңы мөбһәм[9] булган эшкә. Ләкин бу да куркынычлы, өмидсез , но ни кыласың, мәңге мөгаллим булып үткәрер дә хәл юк. Әлбәттә, беркөн бу хедмәтне ташларга тугры киләчәк, бер көн әүвәл ташлаганда, ихтимал, файдалырак булыр. Менә, борадәр, без хәзер мәгыйшәт дулкынлары арасында чынлап сугышамыз, каршымыздагы кара болытларны чынлап то-

---

[1] Тәгалекъле – бәйләнешле.
[2] Фазыйләт – яхшы эш.
[3] Арзу кылып – эзләп.
[4] Рәгъбәтемезне – кызыксынуыбызны.
[5] Шөругъ итмәк улып – керешергә.
[6] Касдымызда – теләгебездә.
[7] Тәхсилле – гыйлем алып.
[8] Мәзар – зыян, зарар.
[9] Мөбһәм – билгесез.

тынып таратмак буламыз. Хәзер минең[1] нервам тәмам бозылган. Мин дөньяга, бәхеткә өмид дигән нәрсәләргә ачулы. Мин бу уй, бу яман фикерләр илән үз мәгыйшәтемез, «гаилә» тормышымызның да ямен бетерә торганмын, шул хәстәлекнең зарарыдыр бәлки. Сездән дә шелтәләр аламын. Ләкин мине шул шелтәләр генә, шул тәнбиһләр[2] генә юата. Шул «балалык дустым» дигән кальби сүзләр генә мине иске эзгә сала. Шуның өчен мин үпкәләп-үпкәләп сездән хат, фикерләр көтәм. Башка хәбәрләрне фараз[3] язарга булып калдым. Хәзергә икәвемездән дә, сагынып, сәлам.

Сезгә, каләмегезне тәбрик итеп, кечкенә булса да бернәрсә йибәрмеш идек. Фәкать таможнядан алып чыгуы агыррак булдыкдан, урлап чыгып, Иркутскидан салып йибәрергә бер кешедән йибәрдек. Ирешсә, хәбәр итерсең. Бакый[4] тагын бер сәлам.

Ризван.

Хат 1909 елның 13 апрелендә Ф. Әмирханның Ерак Себердә эшләгән сабакташ дусты мөгаллим, журналист Ризван Алуши (Ибраһимов Ризван, 1883–1938) тарафыннан язылган.

Хат озынча шакмаклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 3 кәгазьдән, 3 биттән гыйбарәт.

## Билгесез мөселман хаты

1908 сәнә, 22 нче ноябрь

Әдиб мөхтәрәм Фатих әфәнде! Җәнабеңезә түбәнчелек илә сәламеме сөйләп, татар гадәтенчә, фатихагызны үтенәм. Борадәрем Вафа илә Ибраһимга вә бөтен «Әлислах» идарәсендә хедмәт итүчеләргә сәлам. Сатылган «Ислах»ларның акчасына 1909 нчы сәнә өчен яңа мөштәриләр[5] кайд иткәч[6], берьюлы җибәрәм. Хәзер дә «Ислах»лар яхшы сатыла. Көндән-көн рәваҗда[7], яңа елга сәнәлек аздан да ун мөштәри табармын.

---

[1] Минең – минем булырга тиеш.
[2] Тәнбиһләр – кисәтүләр.
[3] Фараз – чамалап.
[4] Бакый – мәңге.
[5] Мөштәриләр – сатып алучылар.
[6] Кайд иткәч – кайгырткач.
[7] Рәваҗда – уңышлы сатыла.

«Әлислах» тугрысында бик күп сүзләр сөйләшүгә тугры килә. Бәгъзән[1] безне дә, «Ислах» тарафдары булдыкымыз өчен, динсез диеп дә сүгеп куялар. Ләкин «Ислах» һаман алга бара. Көндән-көн сторонниклары күбәя. Өстән генә тарафдарлык кылып, хәкыйкатән[2] дошман, кулындан килсә, бер көн мәслихәт бирми, юк итәргә йөрүче, корсагы өчен генә яңалык тарафдары булган паразит хәсрәтләрнең куәтене ала, иректе-ирексез чуен тәрилкә тотдыра. Менә күпдән түгел бер мәҗлесдә «Ислах»чылар тугрысында бер хаҗи сүз башлап, әле мин Тройскиның фәлән кода илә сөйләшеп утырдым, Казандан кайта икән, «Ислахчылар» бөтенләй бозылганлар, ди. Ураза да тотмыйлар, Алланы да «юк» диеп әйтәләр икән, үз колагым илә ишетдем, ди. Без, белмичә, динсез кешеләрнең язганларыны бик тугры язалар, диеп укыймыз тагы, диде. Мин, хаҗи бабаның бу сүзенә бер кеше дә җавап бирмәгәч, хәсрәтләрдән узып булса да, сез хаҗи әфәнде үзегез яхшы гына бер карт булып, үзегез күрмәенчә Тройскиның бер мөтәгассыйб[3] мужикы сүзе илә ничек кешегә динсезлек илә хөкем итүгә кадәр хөрьәт итәсез. Көфернең печате сездә түгел бит, көфер, иман илә хөкем Аллага. Хаҗи, сезнең бу сүзегездән үзегезгә генә зар. Тагы Тройски кешесенә беренче мәртәбә инабәт[4] юк, 2 нче, Алла тугрысында мөнафәрә тарикы[5] илә сөйләшү бар. Иске мәдрәсәләрдә бар укыган нәрсәләре Алладан бәхәс, ля нөсәллим[6], 3 булсын, фәлән булсын иде. Вәхаләнки[7] сез әгәр ни берсен дә дәһри[8] дими идегез, дидем. Шул сүзгә Кортаз Галиев: «Безгә Казанда бер-икәве килгән иде. Беренче дәрәҗәдә инсафлылар, динсез дияргә һич юл юк», – диде. Хаҗи туктады, шул арада Мөнир абзый әллә нинди вәкарлар[9] илә сүзгә керешеп: «Менә бу чагында аз-маз укыган татар малайлары урысча укып, фәлсәфәи динияне белмәгәнгә, русларга йөреп, динсезләнәләр, мин бер-икесене яхшы беләм, дәһриләр», –

---

[1] Бәгъзән – кайчак.
[2] Хәкыйкатән – чынлыкта.
[3] Мөтәгассыйб – фанатик.
[4] Инабәт – ышаныч.
[5] Мөнафәрә тарикы – нәфрәт ысулы.
[6] Ля нөсәллим – алай түгел.
[7] Вәхаләнки – чынлыкта.
[8] Дәһри – динсез.
[9] Вәкарләр – горурлыклар.

диде. Мин: «Чыдам тәкъсыйр[1] ислахчыларны аз-маз укыган татар малайларына тиңләвегез хата, чөнки мин үзем беләм, «Әлислах»-ның башында Фатих әфәнде бән хедмәткә китмәсдән каблә[2] гомерендә беренче иде. Бәндән соң 3–4 сәнә тәхсил итде», – дидем.

Юк, фәлсәфәи диния мәдрәсәләрдә укылмый иде. Менә Мисырда яңа чыкган, мәсәлән, Габдүһ әсәрләре кеби әсәрләр генә бәхәс итә. Аларга Фатихның көче җитми. Бән: «Тәкъсыйр, фәлсәфә Габдүһ әсәрләренә генә мөнхәсыйр түгелдер[3] ич. Гакыллы адәм өчен аяк асты тулы фәлсәфә», – димеш идем. «Син яклашасың. Сиңа сатлык «Ислах» килә. Базары төшә бугай», – диде. Миңа яңалык исемене күтәргән хәзрәтнең биля гакыл[4] тышында сөйләшүе, мужикларга ислахчыларны дәһри итеп күргәзүгә тырышуы гаять дә обидно күренде. Шул сәбәбдән тәкъсыйрдән сүз сорап, ислахчылар тугрысында сөйләнгән сүзләрнең асылсыз ифтира[5] итекене, хәсәдләрендән[6] дошманлары тарафындан чыгарылган сүзләр идекене дәлилләр илә исбат итеп, хаҗига хитаб кылып[7], сез хаҗи әфәнде шикелле үк, алар да татарларны җәллиләр, шул аларның кадерене белми торган татарлар мәсгуд[8] улсын, юлга салынсын өчен җиләк кеби яшь гомерләрен сарыф итеп, мәҗанән[9] диярлек хедмәт итәләр, дидем. Без аларның шундый мөкаддәс хедмәтләре мокабиленә дәһри динсезлек мөкяфәте[10] бирәмез. Өстенә аларның язган нәрсәләрен уку тиеш түгел, ышану тиеш түгел, диямез. Мондан да бер зур хәкъканиятьсезлек[11], кабахәтлек булырмы, дидем. Бәнем бу сүзләремә бер мөгаллим дә иштиракъ итде[12]. Бу сүзләремдә, валлаһел газыйм, бер сүз булсын ялган юк. Менә үзегез уйлап карагыз. Мөнир абзагыз, ничек, бу сәнә мәдрәсәләргә яхшы программалар төзеп, моктәдир[13] мөгаллимләр китерик

---

[1] Тәкъсыйр – руханиларны олылап эндәшү.
[2] Каблә – әүвәл.
[3] Мөнхәсыйр түгелдер – карамыйдыр.
[4] Биля гакыл – акылсыз.
[5] Асылсыз ифтира – нигезсез яла ягу.
[6] Хәсәдләрендән – көнчелекләреннән.
[7] Хитаб кылыб – мөрәҗәгать итеп.
[8] Мәсгуд – бәхетле.
[9] Мәҗанән – бушлай.
[10] Мөкяфәте – бүләге.
[11] Хәкъканиятьсезлек – дөрес булмаган.
[12] Иштиракъ итде – катнашты.
[13] Моктәдир – сәләтле.

дигәч, указымны ташлыйм, китәм, диеп йөрде. Ахыры китерт-дермәде. Шул сәбәпдән мин мәдрәсәләр тугрысында берәр нәрсә язмыйм, диеп, сезгә яхшы атлы булса, ләкин валлаһе куркуындан, күрәсез, Галиевләр илә кычкырыша торып (мөгаллимләр тугрысында рөшди өчен Бубидан яхшы мөгаллим китермәкчеләр иде. Рөшдигә бән үзем дия, китертдермәде. Мөнирнең кәсер әгъшари[1] укытуына кем ышана), иганә[2] җыеп йибәрмәкче булган. Бәңа сездән Мөниргә хат бар икән, байлардан иганә сораганлар. Ихласчыларның эше начармыни, диеп, Галиевләрнең берсе әйтде. Мин, аларның эше начар ук түгел, Мөнир предлагать иткәндер, дидем. Монда да мәкъсуды[3] тиздән туктаячак. «Ислах»ка кешеләр күп язылмасын, дигән. Аның шундый дурной политикасы була торган, чөнки хәзер дә «Йолдыз»дан тәмам дәрәҗәдә туйдылар. Хальбуки[4] ул әгъният[5] сезгә Мөнирне тәгърифдә[6] хаҗәт түгел. Мәдрәсәи «Мөхәммәдия»дә аның кем идекене белмәгән кеше почти юкдыр. Мин бу көнләрдә генә китап илә сәүдә кылуга губернатордан рөхсәт алдым. Шуңа хәсәд кылып[7], әвендә 5 төрле китабы булмаган тәкъдирдә, оялмый, һәртөрле китап сатыла дия игълан итде. Милләтче шул, әгәр «Ислах»да урын бирсәгез, Мөнир мәдрәсәсе һәм дә якшәнбе дәресләре тугрысында әльхәкыйкатьне икътидарым кадәр[8] язармын.

Тагы шуны әйтәм, валлаһе, Мөнир хакыйкый «Әлислах»ның дошманы, куркуындан күпләп, ул барын да берьюлы йотмакчы була. [...] Безгә шулай кылана. Чөнки бу вакыт акча корсагына керми.

Шул сәбәпдән, бу хат эченә 7 тиенлек марка салам, «Ислах»да урын булачагына җавап язарсыз. Агентыгыз мөслим.

Хат 1908 елның 22 ноябрендә Ф. Әмирханга билгесез мөселман тарафыннан язылган.

Хат киң буйлы кәгазьгә кара кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 4 кәгазьдән, 4 биттән гыйбарәт.

---

[1] Кәсер әгъшари – унарлы вакланма.
[2] Иганә – берәр эш өчен халыктан җыелган акча.
[3] Мәкъсуды – теләге.
[4] Хальбуки – шулай булуга карамастан.
[5] Әгъният – байлык.
[6] Тәгърифдә – танытуда.
[7] Хәсәд кылып – көнләшеп.
[8] Икътидарым кадәр – кулдан килгән кадәр.

## Әфтәхетдин Габдуллин хаты

Казан, 17/III

Мөхтәрәм Фатих әфәнде!

Ушбу атнада яңа төзелмеш Идел-Урал мөселман халык комиссариаты тарафыннан «Идел-Урал өлкәсе» исемендә татарча гәзитә чыгарылырга хәзерләнеләдер. Инде шул гәзитәне нәшер итүдә сезнең дә каләм көчеңез берлән иштиракъ итүеңез[1] матлуб[2]. Гәзитә бер мәсләк тотып, түбәндәге шигарьләр тугрысында мөзакәрә[3] итәчәкдер:

1) Октябрь инкыйлабында сугышып алынган эшче һәм крәстиан халкының хокукларын саклау;

2) нинди генә юллар берлән булмасын «Идел-Урал өлкәсе»н вөҗүдкә китерү;

3) хакимиятне милли вә тәнасеб[4] әсасларына корылган эшче һәм крәстиан шураларына тапшыру;

4) «Идел-Урал өлкәсе»ндә яшәгән бөтен төрек-татар демократиясен берләшдерү, организовать итү;

Әгәр иштиракь итүегезне мөмкин тапсагыз, рәхим итеп, бәңа бүген үк хәбәр итәсез. Язган өчен вазыйфә[5] юл хисабындан (вакытлы). Гәзитәнең чыгу көне тәгаенләнгәне юк әле. Хәзерге көндә һәйәт тәүрия[6] төзелә. Ләкин ничек кенә булса да бу атна ахырларында чыгар, диеп уйлаймыз.

Үз тарафыгыздан гәзитәдә язу өчен мөәррихләр[7], экономистлар, финансистлар күрсәтсәгез, яхшы булыр иде.

Идел-Урал мөселман халык комиссариаты әгъзасы: Әфтәхетдин Габдуллин.

Казан, 17/III.

Старо-Горшечная, дом № 9.

P.S. Гәзитә идарәсе «Апанаевски подворье»да беренче бүлмәдә. Ә.Г.

Хатның язылу датасы 17 март, елы куелмаган. Мөселман халык комиссариаты органы булган «Идел-Урал өлкәсе» иҗтимагый-сәяси газета-

---

[1] Иштиракъ итүеңез – катнашуыгыз.
[2] Матлуб – сорала.
[3] Мөзакәрә – фикер алышу.
[4] Тәнасеб – бер-берсенә охшаш.
[5] Вазыйфә – хезмәт хакы.
[6] Һәйәт тәүрия – яшерен комиссия.
[7] Мөәррихләр – тарихчылар.

сы 1918 елның 24 мартыннан 27 сенә кадәр нәшер ителә. Барлыгы ике сан чыга. Димәк, хат 1918 елның 17 мартында «Идел-Урал өлкәсе» газетасының мөхәррире Әфтәхетдин Габдуллин тарафыннан язылган.

Хат киң буйлы кәгазьгә шәмәхә кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазь, 2 биттән гыйбарәт.

*Хат текстларын, искәрмә һәм аңлатмаларны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*Фәния Фәйзуллина әзерләде*

## Ибраһим Бикколов хаты

Мөхтәрәм Фатих әфәнде Әмирхан җәнабләре!

Сезгә күбдән түгел бер мәктүб язган идем. Үзегездән бер дә җаваб алмасам да янә шушы мәктүбне язамын. Бу мәктүб илә җанәбләрегезне якын арада чыктыгы, ике әсәрегез белән тәбрик итәмен. «Танышдык» ны ике мәртәбә укыдым һәм байбәтчәләргә дә укытдырдым. «Бик оста тешләгән диләр». «Йолдыз» да язучы Габдинең сезнең тугрыдагы заметка[1]сы бик тугры. Сез үзегез реализмдан ераграк йөрисез. Татар купец кызлары арасында пожалуй, Разияне табуы бик читен булыр, яки мөмкин булмас. Шулай ук студент Мортазин да татар арасында бәлки булмас. Ләкин Гайсә нәкъ татар байбәтчәсе инде. Гайса тибы Гали Апанаев, Вәли Апанаевларны бик искә төшерә. «Асылган»ны укыганым юк. Һәм укый да алмыймын. Мин аның русчасын да бик көчкә тәмам итә алган идем. Татарчасы (миңа нисбәтән) янә укырга бик авыр. Укый башлаган идем дә бик начар тәэсир итеп кәефне китәрә башлагач туктадым. «Татар кызын» кызлар укыйлар. Ләкин бик аңлый алмыйлар. Ул кара көч, нәрсә соң? дия сорыйлар. Мин бик кыска гына әйтеп, «дин» дия җавап бирәмен. «Идел»дәге мәкаләгезне укыдым. Ләкин Һади абзый «үзенчә» бик әсаслы рәвештә ибталь кылды[2] бит. Атласовка тагын бераз тия төшәргә иде. «Юл» нәшриятындагы яңа әлифбаны допускать итүегезгә бераз гаҗәбсендем. Мәгълүм әүвәлләргә рәкабәт идәчәк[3] әлифбаның шулкадәр изелгеч рәвештә, бигрәк дә мөгаллимнәр флагы астындагы

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Ибталь кылды – юкка чыгарды.
[3] Рәкабәт идәчәк – көндәшлек итәчәк.

«Юл» китабханәсенең нәшрияты арасында, шундый хламның булуы кимчелек. Вафа бит мөгаллим, шуны ничек күрмәгән. Шиһаб тәнкыйде рәкабәт касды[1] берлә булса да бик тугры, урынлы. Фәтхулла хәзрәтнең гаед көнен һаман көтәм әле. Шулай ук карточкагызны да көтәм. Һаман көтәм. Вагыйзь бик үпкәли. Шул вакытны бер-ике юл җаваб язмадылар ди. «Татар түрә булса, чабатасын түргә эләр» мәкаленчәрәк, Вафа тугрысында истихфаф[2] берләрәк сөйләшә. Аның кебек үк татар шәкерте, аның кебек үк мөгаллим (җәмгыяте хәйрия мөгаллиме), редактор исменә мәгърур булып бер җаваб та язмаган. Вагыйзь әйтә: «Мин солыхка ул вакытда ук чакырдым, 4–5 ай көтдем, шулай да илтифат итмәгәч, судка бирдем» – дип. Прошениесенә дә шулай язган. Ике мәртәбә солыхка чакырсам да солыхны кабул итмәделәр диеп. Шул эштә галякалары[3] булган байларны солыхка күндердем инде. Вагыйзь берлә генә сөйләшәсе калды. Солых кылышырмыз төсле. Солых кылышмаганда да оправдаться итәчәкмез кебек.

Хәзер Себер халкын яңа коерыклы йолдыз бик ишгаль итәдер[4]. Хосусән, япон-рус сугышы хәбәрләре өстенә бу яңа кометаның күренүе халыкны бик куркыта. Монда ул комета бик ачык мәгърибдә[5] Венера (Зөһрә) йолдызының уң ягында күренәдер. Япон-рус сугышы монда бик сөйләнә. Рәхмәте гомумия мәсьәләсе дә байтак татарларны кайнатды. Бик күб сугышдык. Шунысы кызык, «Исабәт» бер дә телгә алынмый. Аны укымыйлар һәм аңламыйлар ахры. Безнең татарга хәзер иң тәэсир иткән журнал вә гәзитәләр икәнен бу бик ачык күрсәтә.

Хәзер татарларга русларның 40–50 нче елгы әдәбият дәверләре кергән төсле күренә. Хотя[6] бездә әле Герцен, Чернышевскийлар чыкганы юк югында! Ләкин шул дәвернең типлары күренә башлады инде. Менә Мансур (җыентыкда) шул дәвердәге помещикларның укыр өчен, халык өчен качып киткән угылларын искә төшерәләр. Ну, йитәр инде. Фәлсәфә сатып, синең эчне пошырып бетерәм, бугай. Буның өчен гаеп итмәгез тагын. Монда бер дә фәлсәфә сатушы өчен кеше булмаганга ирексез бу хатка языла-

---

[1] Касды – уе.
[2] Истихфаф – мыскыллау.
[3] Галякалары– бәйләнешләре.
[4] Ишгаль итәдер – мәшгуль итәдер.
[5] Мәгърибдә – көнбатышта.
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

дыр. Хәзерге хуш, саг улыңыз. Бәлки бер открытка язарга форсат табып, мине шадландырырсыз. Томск. Ибраһим Бикколов. 1910, 22 январь.

Хат 1910 елның 22 гыйнварендә Фатих Әмирханга җәмәгать эшлеклесе, педагог Биккулов Ибраһим Җамалетдин улы (1884–1938) тарафыннан юлланган.

Хат киң сызыклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 4 биттән гыйбарәт.

«Танышдык» – Ф. Әмирханның «Танымаганлыктан таныштык» (1909) хикәясе.

Габди – Галимҗан Ибраһимовның псевдонимы.

«Асылган» – Ф. Әмирханның «Асылган йиде кеше» хикәясе (1909).

«Татар кызы» – Ф. Әмирханның «Татар кызы» хикәясе (1909).

«Исабәт» – Г.Чыгътайның «Исабәт» (Хаклыкка ирешү) (1909) исемле китабы.

## Ибраһим Бикколов хаты

9.03.1910

Мөхтәрәм Фатих әфәнде Әмирхан җанәбләре!

Мәктүбегезне алып бик шадландым. Илтифат итүегез өчен бик рәхмәт. Үзем шулай искечә генә торамын. Артык эшләр бер дә күренми. «Яшьләр»не укыганым юк әле. Шаяд[1] тиздән килер. Исхаковның «Кыямәт» ен укыдым. «Кыямәт» миңа бик ошады. Минем фикеремчә, «Кыямәт» дә татар муллалары вә аларның мәгълүматлары психологияләре бер дә арттырмый, киметми тәмам язылган да салынган. Исхаковның бу комедиясе муаффәкыятьле[2] чыкган кебек. Әмма сценага куелу җәһәтендән, ягъни сценада күрсәтелү өчен бик матур түгел түгелен. Нәфасәт[3] изящность[4] юк. Ләкин бунда Исхаков гаебле булмыйча, тормыш гаебле шул. Башка төрле, пожалуй, чыгарырга мөмкин булмас иде, яки тормышдан ерагайтып, боламык ясарга тугры килер иде.

Сезнең «Танышдык» тугрысында бер дустымдан алган хатымда (дустым татарча мәгънәсе илә образованный) бик начар

---

[1] Шаяд– бәлки.

[2] Муаффәкыятьле – уңышлы.

[3] Нәфасәт – гүзәллек, нечкәлек.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

критиковать ителә. Укыдым, укыдым, идеальный бернәрсә дә таба алмадым ди. Фатих әфәнденең талантына тәмам мөсәлләм[1] улдыкым хәлдә бу әсәрендән һич доволен[2] түгел ди. Коры сүзтезмәсе генә димә кели. Мин аңарга үземчә возрожать итдем.

Мин үзем рассказ вә повестьләрдән әллә нинди идеаллар көтмим. Дөрест, Горький вә Андреевлар рассказларыны үзләренең идеалларыны бәян итәргә беренче яхшы юл саныйлар.

Ләкин «Танышдык»ны бөтенләй алай бушка чыгарып булмый. Байбәтчәнең дәрәҗәи мәгълүматы вә тормышка, вә үзенең тирә-ягындагы нәрсәләргә карашы заһирән[3] никадәр зыялы булса да, фикере берлә һаман да иске мелла тарафдарлары булуы бик матур тасвир ителгән кебек. Бу тасвирларда тәрбия вә әхлак җәһәтендән бик күп нәрсәләр аңлатылган.

Безнең һәрвакыт яшьләргә сабак бирүче «Вакыт» абзый да бик нык гына сезне чеметеп куйган бит. Ләкин аны мин хаксыз табдым. Монда һаман тормыш, татар халкы гаебле бит. Татарларга высший[4] идеаллар аңлатыр өчен бераз подготовка[5] да кирәк түгелме? Сүз арасында шуны да әйтим әле. Безнең татар халкы бик хыялый нәрсәләрне укырга яраталар. Сезнең Фәтхулла хәзрәт, Әбугалисина шикелле тарала. Бик яратып укыйлар.

Ну минем Галиәсгар меллага ачуым килде. Указ китүдән куркып шулкадәр рәзаләт[6] берлә кеше тәүбә итәме соң инде?

«Идел» гәзитәсе әйткәндәй, «Татар артист түгел, юрист булса да татар шул». Әле указ китүдән куркып шулай тәүбә итә. Әгәр төрмә яки казна булса нишләр иде? Исабәтне[7] меллалардан үлчәтергә вә алардан дөрестлеген тәфтиш иттерергә[8] булгач, чыгарасы да юк иде. Меллаларның ничек үлчәүләре билгеле. Икенче көн үк Хәмзә мелла безгә карап «Безне корсак хуры дисез. Үзегезнең Чыгътаеңыз нишләде?»дия йөзгә бәрде. Ни дә диер хәл юк шул. Юк ул мелла сыйныфы никадәр дәһри, никадәр зыялы булсалар да ышаныч юк икән. Иң передовойлары Атласов берлә Чыгътай.

---

[1] Мөсәлләм – канәгать.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Заһирән – тыштан караганда.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] Рәзаләт– хурлык, түбәнлек.
[7] Исабәтне – дөрестлекне.
[8] Тәфтиш иттерергә – эзләтергә.

Шул булгач инде башкаларына ни калды. Тамигъ[1] вә шәхсәният канларына сеңгән күрәсен. Әхмәджан Биктимеров берлә Вагыйзь монда татарча гәзит чыгарырга йөриләр әле. Әхмәджанны алтаистлар вә башка зур кешеләр берлә танышдырдым. Ләкин мескен татарларның мөхәррирләре диеп представить итсә дә (ә оныттым әле, этнограф диеп дә кайчан представить ителәдер; ә үзе еврейләрнең телләре немецчәгә бик якын ди). Бер дә русча белми икән. Мәгълүмат развитие бер дә юк. Кызарып утырырга гына туры киләдер. Шулай да үзе бик түбәнчелекле, бер дә армыйча эшли торган кеше, тик мәгълүматы гына юк. Шуның берлә барәбәр бик фәкыйрь. Төркестанда Остроумов үзен тәмам эшдән чыгарган. Китабларын барын да конфисковать итеп, күп расходланырга мәҗбүр итәрәк белдергәнләр. Хәзер толчокда сәүдә итеп маташа. Укырга иренмәсәгез, шуны да языйм әле. Без монда Борһан Шәрәфнең сәяхәтләрендән бер дә разый түгел. Иранга барып, Иранның үзендән бары ике-өч мәктүб илә кифаяләнде. Иранилары хатынлары тормышындан, мәктәб-мәдрәсәләрендән, матбугат вә әдәбиятларындан, рабочий вә буржуазия сыйныфларындан бер дә мәгълүмат бирмәде. Милләт мәҗлесе ачылуын «Русское слово»дан да тәрҗемә итеп язарга була иде бит. Шулай ук Бохарадан да бик аз мәгълүмат бирде. Сонгыйрак булса һәрбер тормышта видный[2]рак булган әхвалдән мәгълүмат бирү кирәк иде.

Хәзер Томскида алтай татарларындан художник Г. Горкинның картина-выставкасы ачылды. Горкин бик яхшы рәссам булып чын алтай татарыдыр. Картиналары бик шәбләр. 225 дән зиядә[3] картина вә этюд[4]лары бар. Аның тугрысында «Шура»га бернәрсә язмакчы булып торам да әле вакыт юк.

Алтай мәнзаралары вә алтай татарларының тормыш вә типлары вә легендаларына гаид[5] картиналар.

Язга Алтайга барырга кызыгып торам әле. Планлар күп. Кайсысын кылырмын инде. Ләкин быел Казанга кайтмыйм. Әле без мөгаллимләр «Идел» дә «Әлислах»ны тергезү тугрысында фи-

---

[1] Тамигъ – саран, ач күзле.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Зиядә – артык.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Гаид – караган.

кер йөртешәмез. Ну хуш, саг улыңыз. И. Биккулов. Томск. Иренмәсәңез илтифат итеп хат язугызны үтенәм.

Хат 1910 елның 3 мартында Томск шәһәреннән Фатих Әмирханга Ибраһим Бикколов тарафыннан юлланган.

Хат киң сызыклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазь, 4 биттән гыйбарәт.

«Яшьләр» – Ф. Әмирханның «Яшьләр» (1910)драмасы.

«Кыямәт» – Г. Исхакыйның «Кыямәт»(1910) комедиясе.

## Ризван Алуши хаты

1910 сәнә, март 29.

Фатих әфәнде!

Без һаман сыхранудан, күңел болгаткыч хәбәрләр язудан тыела алмыйбыз. Бу эш безгә табигать булып урнашыр ахры инде. Затән сыхрамаслык да түгел, ике ел кадәр табигатьнең һөҗүменә грифтар булып[1] син авырып ятдың. Ярый әле үзеңне алып кала белдең. Шуның илә безне шадландырдың. Юк исә бирелеп куйган булсаң бөтен өмид вә максудларымыз вөҗүдкә чыкмай[2] бергә бетә иде. Ул вакыт син әле танылмаган улдыкыңдан тәмам онытылып дусларның калбендә[3] генә калган булыр идең. Ә хәзер! Ә хәзер син мәңгегә бар. Бу җөмләләремә күңелсезләнмә. Бер үземнең хиссиятемне генә бәян, түбендә язылачак кызганыч кан агарлык күңелсез хәбәремә мөкаддәмә[4] генәдер. (Ягъни үләргә тели икән димә!) Без үземезнең теләк вә максудларымызны сөеклемез Рәхимә туташка тапшырган идек. Безнең бар өмидемез шул иде. Ул үзенең иҗтиһады[5] вә татар кызларында мисле[6] күренмәгән истигъдады[7] вә хөсне әхлакы илә безне үзенә мөсәххәр иткән[8] иде. Без андан башка тора алмаслык дәрәҗәгә килгән идек. Анардан бер җәмигъ хат килмәсә, тәмам кайгыга салына идек. Менә инде хәзер анардан мәңгегә аерылдык, мәңгегә хәбәрен ишетмәскә иделдек. Чөнки ул

---

[1] Грифтар булыб – дучар булып.
[2] Вөҗүдкә чыкмай – тормышка ашмый.
[3] Калбендә – йөрәгендә, күңелендә.
[4] Мөкаддәмә – кереш.
[5] Иҗтиһады – тырышлыгы.
[6] Мисле – кебек, төсле.
[7] Истиъдады – сәләтлелеге.
[8] Мөсәххәр иткән – әсир иткән, сихерләгән.

хәзер вафат, ул безнең һәм үзенең бар өмид вә максудларыны, үзе илә бергә алып китде. Безне вә ата-анасын мәңгегә егълатып калдырды һәм вакыйган мәрхүмә егъламаслык да түгел. Ул бит бөтен Себергә бер өмидле татар кызы иде. Ләкин татар милләте андай кояшлардан мәхрүм, татар галәме анларны шулай күрә алмас ахры инде. Аның вафаты безнең өй эченең нуры, хозуры китүгә дә сәбәб булды. Хәзер Фәрхәнәне юатудан гаҗиз улып[1] торамыз.

Мөхтәрәм Фатих әфәнде «Яшьләр» наме рисаләңне алдык. Сөенә-сөенә тәкрар укыдык һәм һаман килгән-киткән бер кешегә укыймыз. Менә ул тормышка ашна[2] күбесен күреп белдегемдән, бигрәк сезнең үз җизнәгезнең тәмәссәле мөҗәссәме булуы[3] хиссиятендән бигрәк яратдык. Укыганда һәрберсен көнләре илә искә төшерәм. Вә шундай бер ядкәр язуың өчен аеруча рәхмәтләр укыйм. Үз арамыздан шунларны тасдыйк идәрлек[4] кеше заһир итүенә[5] шадланам.

«Ялт-йолт» игъланында сезнең дә исем күренә һәм башка язучылар да безнең каршыда оста саналдыкындан яхшы булып чыгуына өмидемез куюдыр. Фәкать «Карчыга», «Чүкеч», «Яшен», «Әлислах» кеби бер мөштәриләренә[6] тиешенчә бирелмәй калдыкларындан алучыларның рәгъбәт[7] вә ышанычлары аз улу ихтималы да бар. Шулай да халык андай бер журналга мохтаҗ улдыкындан шаяд муаффәкыятьле[8] улыр.

Бездә артык мөһим әхвальләр юк, сәүдәне шулай бер көе итеп торамыз. Шундай кайгылы вә тынычсыз вакытыгызда берәр мәктүбдән шаяд[9] мәхрүм итмәссез.

Бакый сагынып сәлам. Ризван.

Да шуны да язасы бар икән. «Ялт-йолт» ны «Яшен» кеби Казан тирәсендә генә ялт-йолт итдермәй, гомумирәк ясарга тырышыгыз.

Хат 1910 елның 29 мартында Фатих Әмирханга мөгаллим, педагог, журналист Ризван Алуши (Ибраһимов Ризван, 1883–1938) тарафыннан юлланган.

---

[1] Гаҗиз улып – көчсез, зәгыйфь булып.
[2] Ашна – таныш.
[3] Тәмәссәле мөҗәссәме булуы – прототибы булуы.
[4] Тасдыйк идәрлек – расларлык.
[5] Заһир итүенә – билгеле булуына.
[6] Мөштәриләренә – яздырып алучыларына.
[7] Рәгъбәт – теләк.
[8] Муаффәкыятьле – уңышлы.
[9] Шаяд – бәлки.

Хат ак кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Фәхрислам Агиев хаты

Дамелла Фатих хәзрәтләре!

Хәзер генә Кәбирдән «Яшьләр»не алып цензурный комитетка тапшырып кайттым. Прошение Кәбир исемендән яздым. Тагын 75 тиенлек марка алырга туры килде. Цензурный комитетта Шамилне күреп сөйләшүдән көткән өмидләрем нольдән артмадылар... Ихтыярсыз: «Таз баш чиновникдан гомумән бер фаидә[1] көтмичә, ачка үләргә хәзер теләнчедән садака көтү, мең өлеш өмидлерәк!» дияргә мәҗбүрмен! Минем: «Фатих әфәнде Әмирхан әфәнде җәнабләренең пьесасын комитетка тапшырдым. Каралуын тизләтүегезне Фатих әфәнде сездән үтенгән иде!» дигән сүзләремә: «Тырышырмыз бездән эш тормас!» дигән әллә нинди күгәргән мүк исләре килә торган сүзләрдән мөрәккәб[2] бер җавап кайтарды. Хәерле булсын. Шулай да ун-унбиш көндән бер-бер җаваб булыр дип көтәргә ярый. Чөнки гариза (прошение)не кабул иткән заттан мөмкин хәтле тизрәк каралуы максад дигән сүзләргә каршы йомшак кына җаваб алдым. Тагын бер-ике көндән барып белешермен. Һәм баш цензорны күреп, эшнең ни хәлдә икәнен белеп кайтуны үземә вазифа иттереп йөкләдем. Күрәсең, иптәш «Яшьләр» бүгенгә хәтле комитетның бусагасын да күргәне юк! Ә син матбугатның баш идарәсенә жалоба бирергә дип торасың! Әлхасыйль, кайткач, бу тугрыда сөйләрлек сүзләр күп һәм Кәбиргә «Яшьләр» тугрысында хәзергә берни дә язма. Мин синдән үтенәм.

Китапчылар белән Габди эше ничек бара? Син ни дә булса яздыңмы? Әгәр мәкаләң басылмаган булса һәм теләсәң, үзеңнеке астына минем дә имзаны куярга иреклесең. Галимҗандан «Гауга» номерларын алып килмәвемә хәзер бик үкенәм. Чөнки эшнең асылы мәгълүм булса да, күп фактлар хәтердән чыкганлар. Шуңа күрә язган мәкаләмне дә җибәрергә уңайсызланам. Шулай да, иртәгә бу тугрыда яхшы гына уйлап карармын. Ихтимал, җибәрермен дә. Ләкин мәкаләне сиңа бик дикъкатьләп карап чыгарга туры

[1] Фаидә – файда.
[2] Мөрәккәб – кушылган.

килер. Һәм Байбуриндан (әгәр басдырырлык тапсаң) акка күчереп «Йолдыз»га җибәрерсең. Хәзер Муса әфәндегә ашка китәм. Хуш.

Кулыңны кысып Фәхерислам Агиев.

Хат 1911 елның 21 декабрендә Петербургтан Фатих Әмирханга Фәхерислам Агиев тарафыннан юлланган.

Хат киң сызыклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазь, 2 биттән гыйбарәт.

### Габдрахман Гомәров хаты

11 февраль

Мөхтәрәм Фатих әфәндем!

Бу ел Мәрҗани хәзрәтенең вафатына егерме биш улмак мөнәсәбәте илә мәрхүмнең ядкяре өчен һиммәт сахибләрендән[1] җыелынмыш һәйәт[2] тарафындан бер мәктүб юлыкмыш идем. Вә шул мәктүби гаммәгә[3] «Идел» гәзитәсендә һәм гарыз итмеш идем[4] дә бу көнгә кадәре һәйәткә җавап язарга тугрысы илтифатларына тәшәккер идәргә[5] форсат табмадыкыма тәәсефеме дә[6] язмыйча узар хәл юкдыр. Нә исә һәр нәрсәне вакытында җитешеб торырлык көчем булса да бу хәлгә дә калган булмас иде. Имде шул һәйәткә күңелемнең бер урта йирендән чыкган мәхәббәтем илә ихласымы гарыз итәмен. Вә буны белдерүдә сезне илче итдем. Әфәндем! Сездән үтенәмен Мәрҗани хакындагы рисаләңез тәмам улдымы, басарга бирдеңезме, яки басылып та булдымы вә кайчан тарата башлыйсыз? Сезнең хезмәтеңезә Казан егетләре кушыламы вә ни берлән кушылалар вә каю көн бәйрәм кеби нәрсә ясыйсыз? Гайре рәсми генә узачакмы? Һәрхәлдә безгә шу сорагганларыма җавап язуыңызны тәкрар үтенәмен. Оренбург тирәсендә ахун Сәруратдин Сабитов нам кемсә Мәрҗани хакында тәрҗемәи халенә тиеш мәкалә язганлыгыны белдереп каю шәһәргә вә кемгә җибәрәчәгене миндән сорыйдыр. Мин дә сезнең адресыңызы язып күндердем.

---

[1] Һиммәт сахибләрендән – тырыш дусларыннан.
[2] Һәйәт – коллегия.
[3] Гаммәгә – гади халыкка
[4] Гарыз итмеш идем – аңлаткан идем.
[5] Тәшәккер идәргә –рәхмәт белдерергә,
[6] Тәәсефеме дә – үкенүемне дә, кайгыруымны да.

Фатих әфәндем! Бәнем сөальләрем бере артындан бере туктаусыз язылганлыкына үзем дә кәефсезләнә төшдем. Ни хәл итәсең. Безләр шулай язып үгрәнгәнмез. Кимчелекне муенга алмый да хәл юк. Дәһи дә шуны язамын. Мәрҗани хәзрәтенең вафаты 28 нең шәгъбанда иде. Сезнең мәктүбеңез дә 30 ы шагбан язылмышдыр. Һәйәтеңезнең барчасына бик тә зур ихтирамым илә яшәңез, дигәнемдән соң Габдрахман Гомәрев.

Хат Фатих Әмирханга Әстерханнан «Идел» газетасының нашире һәм җаваплы мөхәррире Габдрахман углы Гомәрев тарафыннан язылган. Язылу елы анык түгел, числосы 11 февраль дип куелган.

Хат Габдрахман Гомәревның бланкасына, озынча шакмаклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазь, 1 биттән гыйбарәт.

## Кояш Җәббәрова хаты

Фатих абый! Сезнең «Тигезсезләр» минем күңелемдә әллә нинди яңа бер хисләр тудырды. Ул мине шадландырды, кайгыртды.

Мин инде сезгә ничек дип аның турында белмим, фәкать шуны әйтәм, ничек бер яшь баланың кулына уенчык бирсәң,- шуны төшмәсен өчен бик нык кысып тота шуның кебек «Тигезсезләр»пьесасы да минем күңелемне үзенең әллә нинди тойгылары арасында калып [...]ахры.

Менә ул пьесадагы Рөкыя кебек милли туташларның һәм Сәлимә кебек мөхәррирләрнең безнең татар милләтендән булучылыклары мине шадландыра һәм менә шуның берлә мактана алам. Ә үзләренең татар булып туганларына хурланып, татар милләтенә түбән күз берлә караучы Габдулкаларның минем мактыйсы милләтемнән булучылыклары мине кайгырта, тавышландыра. Минем аның кебек (Иванушкаларга) Габдулкаларга элекдән үк ачуым киләдер иде. Сезнең пьесагыздагы Габдулканы күрүем тагы бер кабат ачуымны китерде.

Шулар менә, башка да пьесагыз нык күңелемне үзенә җәлеп кылган иде. Шактый булганлыкдан, авыры да, сезнең татар галәменә чыгуына бик шадланып, андый мөкаддәс мөхәррирләр тагын да күбрәк чыгуларына өмид иткәнемне сезгә язып белдерәсем килде.

Яшәсен! Рөкыя кебек милли туташлар, Сәлимә кебек мөкаддәс мөхәррирләр. Бигрәк тә яшәсен кыйммәтле, эшлекле Фатих абыем!

Фатих абый!

Пьесагыз бик шатландыргач, сезгә бик рәхмәт әйтәсем килде. Берничә мәртәбә үзегезгә әйткән рәхмәтем берлә генә канәгатьләнмичә тагы бер мәртәбә тәкрарлап янәдән йибәрдем, гаеп итмәгез ярыймы.

Рәхмәт Фатих абый!

Тагын да шундый күп, күп пьесаларыгызны шатланып, шатланып чыгаруыгызны, бәхетле вә рәхәт булып озак, озак яшәвегезне теләп ихтирам илә: кызыгыз Кояш Җәббәрова. 1910 сәнә, 10 нчы февраль.

Хат 1915 елның 10 февралендә Фатих Әмирханга Кояш Җәббәрова тарафыннан юлланган.

Хат киң сызыклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазь, 2 биттән гыйбарәт.

## Таһир Ильяси хаты

Әдиб мөхтәрәм Фатих әфәнде! Әссаләме галейкем вә рәхмәтуллаһы вә бәрәкатеһү.

Бу тарафда без лилләһи әлхәмде сәламәт торамыз. Габделбари әфәндедән сезнең әхвалне сорашып, яңа дөньяда искечә торганыңны белеп шадландым. Төрекләрчә алсак, улмагыз (тарлык, кимлек күрмәгез) әфәндем, димәктәмен.

Безнең тормыш һәм искечә диярлек бер хәлдә, әмма халык һәм мөгаллимлек эшләре чибәр генә дәвам итеп тора, язу эшләрем дә бар. Хосусән бу ел институтда гарәп теле мөгаллиме булып лөгать китаплары тирәсендә чуалдым. Бик күп җәһәтдән кирәк табып шактай зур «татарча-гарәпчә» лөгать китабы тасвир итдем, бер кыйсеме табигъ да иделде[1]. Буның татарча лөгатьләрен аерып алып, тиешле шәрех вә бәян кушылса, ана телемезнең мөкәммәл[2] лөгатен тәшкил идәрлек рәвешчә монтазам[3] чыкды. Иншалла ансы

---

[1] Табигъ да ителде – басылды да.

[2] Мөкәммәл – камилләшкән.

[3] Монтазам– тәртипкә салынып.

да вакыты илә вөҗүдкә чыгар яки чыгаручыларга анык материал булыр дип өмид итәм. Бундай эшләрне сезгә киңәшкәндә дәрд вә нәшат[1] бирерлек сүзләрегезне ишетә идем вә сезгә чын куңелдән рәхмәт укыйор идем. Бәлки бу эшләремдә дә «кирәкмәс» димәгән булыр идегез. Фазыйләтле[2] йөреңез. Хәзрәтләрендән хәер догаларын үтенеп сәлам укыйм. Мөбарәк вәрәкаларыны[3] алыб мәмнүн булдым. Фәкать Габделбари әфәнде миңа ихтыяҗсыз эшләрен башкарганлыкларын дидекләренчә могавәнәт итә[4] алмадым, ихтыяҗлары булса, кулдан килгәнчә могавәнәткә хәзер идем. Йә, Фатих әфәнде кайчан инде сезгә «Биррафәһ вә әлбәни»[5] дип тәбрик итәмез. Бик вакыт иде!

Ихтирам илә: Таһир Ильяси.

1921 ел, 13 гыйнвар.

Хат 1921 елның 16 гыйнварында Фатих Әмирханга гарәп теле һәм әдәбияты буенча зур белгеч, лексикограф-галим Таһир Әхмәтҗан улы Ильяси (1881–1933) тарафыннан юлланган.

Хат киң сызыклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазь, 2 биттән гыйбарәт.

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Эльмера Галимҗанова әзерләде.*

## Шәһид Гайфи хаты

Мөхтәрәм Фатих әфәнде!

Башдан ук әйтим әле. Сез мине «Синдән җиңгәлек теләмиләр» зинһар орышмаңыз! Минем сезгә язачак нәрсәм дә бер төрле җиңгәлек аңла шундан. Менә кулларым калтырыйлар. Ләкин аңа карап үземчә изге саналган бер эшемне эшләми кала алмыйм. Менә нәрсә: мин Казанда вакытымда сезне таный белә

[1] Нәшат – шатлык, сөенеч.

[2] Фазыйләтле – өстенлекле.

[3] Вәрәкаларыны – хат, запискалар.

[4] Могавәнәт итә – булыша, ярдәмләшә.

[5] Биррафәһ вә әлбәни – уңышлар һәм балалы (нәсел) булу шатлыгы мәгънәсендә.

идем... Сез сау идеңез. Үткән ел гына Казандан килгән мөгалимләрдән сезнең авырулыкыгызны белдем. Шул вакытдан бирле сезне кызганам. Һәм күңелемдә ничек булса да шул тугрыда сезгә кечкенә генә булсын бер ярдәмдә булынырга уй саклыйм. Ләкин «коры кашык авыз ерта» дигән кебек кулда куәт булгач, коры уй бөтен елны үткәрде. Ә менә хәзер күңелемчә изге булган шул уемны эшкә ашдырырга бер юл тапдым. Юл: минем тора торганым авылдан 20 минутлык йирдә «Грязь-Тинак» исемендә шифаханә бар. Бу сезнең авыруыңыз кебекләргә файдалы, носилкада китерелгән кешеләрнең аякга йөргәнләрне үзем күреп беләм. Бу шифаханә берлә танышыңыз дип аның юл күрсәтүчесене йибәрдем. Бу шифаханәдә дәвалануга түбән хисап, айга 70–80 сум кирәк. Гафу итеңез! Түбәндәге сүземне эш җаена карап язам. Сез Казанда Локман Хәким исемендә Арсланов баласыны беләсездер. Мин шуның аркылы сезнең мин күрсәткән шифаханәгә килергә теләвеңезне, акча юклыкдан килә алмавыңызны белгән идем. Эш шулай булса, мин сезгә шифаханәдән бер тиенсез файдаланырга юл күрсәтергә телим. Менә болай: сез шифаханәдән файдаланырсыз. Буңа каршы буш вакытыңызда 4–5 баланы русча укытырсыз. Балалар татар балалары, хәреф таныйлар. Шифаханәдә тормазсыз, әле әйтелгән авылда тыныч кына, пакъ кына өйдә торырсыз. Өй хуҗасы баш катыра торган түгел. Сезгә особый өй була. Һәр көн шифаханәгә хәзер ат берлә барырсыз, килерсез. Болай йөрү шифаханәдән файда алуга тыгызлык бирми. Күп кешеләр шулай итәләр. Ашсу, кыскасы, барлык кирәк нәрсәләр хәзер булыр. Ишдүемә күрә сезне күтәреп йөртергә кирәк бугай. Буны мин үзем эшләрмен, үзем булмаганда ипле бер кеше куелыр. Мин кемнең өендә торып, кемнең балаларыны укытачак, анлар мине кайдан беләләр? дисезме? Мин мәктәбемезне караучылардан берсе Шәехгали Түләков берлә әдәбиятымызда язучыларымызны сөйләп ултырганда, аңар сезне танытдым. Дәвалануга ихтыяҗыңыз барлыкны аңлатдым. Уйлашдык-сөйләшдек дә әле сөйләнгән юлны тапдык. Аның өендә торып, аның һәм бу эшкә мадди ярдәме катышачак тагын бер кешенең балаларыны укытырсыз дип сүзне бетердек. Йә, инде бокырдадым, бокырдадым, тик теләгемне дөрест аңлата алган булсам ярар иде. Сез бер җавап язарсыз инде. Ни булса да мине орышмаңыз!!

1910 12 декабрь. Шәһид Гайфи.

Адресым: Астрахань Калмыцк. Базар Шагиду Гайфутдинову.

Теге сүз бетде. Бу инде икенче.

Әнә шул открыткалардан берендә татар көнендән «Рәхмәте алиһия[1]»не, икенчесендә Тукайның бер шәех агызындан сөйләдеке «И Ходай, сиңа мәгълүм тик яхшылыкда касдымыз[2] зикремездер[3]: казы[4], кузый[5], яшь кенә кыз, каз, кымыз»[1+] шигырьне эшләгән булган идем...

«Рәхмәте алиһия» открыткасына шундагы татар агызындан «Ходай рәхмәте киң имеш дә, бар да оҗмахга керәчәк имеш. Алай булганда безнең буларыбызга «себерке, комган, башмак урынында калмаз» дип, ә Тукайныкына әлеге шигыре басылачак.

Ф. Әмирхан!

Үзеңнең иң сөйгән нәрсәң татар әдәбияты хөрмәтенә шул открыткаларны күздән үткәреп, нәшер ителергә ярау-ярамаулары тугрысында фикереңне язып миңа йибәрсәнә?! Тукайның үзендән рөхсәт берлә эшләп, нәшергә ярау-ярамауда фикерне белергә, яраганда рөхсәтне алырга открыткаларны үзенә дә йибәргән идем. Җавап алганым юк әле. Йөрәгем пыт-пыт итә...

Яраса нәшер итәргә, әдәбиятны былчыратачак булса, әллә кая аска басдырып куярга ашыгам...

Шәһид Гайфи.

Тукай шигырене икәведә дә эшләдем. Бәлки икедән бере охшар дидем. Әгәр открытка тупас булып Тукай шигырене бозарлык булса, беренә «ни генә инде йитми?» икенчесенә барлык теләкләр булгач, бер шөкер диеп язса, нәшергә ярармы?

Хат 1910 елның 12 декабрендә Ф. Әмирханга мөгаллим Шәһид Гайфи (Гайфетдинов, 1881–1941) тарафыннан язылган. Хат киң буйлы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

[1+] сүз Г. Тукайның 1908 елда «Бер шәехнең мөнаҗәте» исеме белән басылган шигыре хакында бара.

---

[1] Рәхмәте алиһия – Алланың рәхмәте.
[2] Касдымыз – теләгебез, максатыбыз.
[3] Зикремездер – һаман кабатлый торган теләгебез.
[4] Казы – казылык.
[5] Кузый – куй бәрәне.

**Фәрханә Алуши хаты**

Мөхтәрәм Фатих әфәнде!

Мин сиңа «Татар кызы» рисаләңне алгандан бирле хат язарга җыенам, ләкин һаман бушый алмыйм. Мин ул рисаләңне укыгач, татар кызларыны дүрт стена эчендән якты галәмгә чыгарырга тырышучы бердән-бер муаффәкыятьле[1] герой «татар екете» дию сине атый башладым. Шуны алгач да Ачинскига китдем. Ул рисаләне татар кызларының ул тормышын күрмәгән сөекле сеңлем өмид кояшым Рәхимәгә бирдем. Укыды «җанлы курчак», «кара көч» кеби гыйбарәләре күңеленә ятлап алды. Аны язган өчен калебенең иң нечкә йирендән сиңа рәхмәтләр укып сәламен ирешдерергә кушды. Мин һаман бу көнгә кадәр кичектердем яза алмадым, гафу боерасыз. Имди язам, ләкин ул фәрештә, ул бәгърем туфрак астында, ул хәзер башка галәмдә, ул безне ташлады, мәңгегә калебемезне җәрәхәтләде. Хәятда интересым калмады, мин аның өчен генә яши идем.Үземез ирешә алмаган дәрәҗәләргә аны ирешдерү касдында идем. Бөтен көчемне шуңар сарыф итә идем. Ул без көткәндән артык булып бара иде. Менә дүртенче класска ирешде. Бер ел калмады һәр заман бишен алып ибдәшләре арасында беренче булып килде. Ул аның илә генә калмый. Татар галәме илә дә таныш иде. Бар теләк вә максуды татар кызларын яктылыкга чыгару иде. Аның өмид вә максудларын мин сиңа язып бетерә алмыйм. Мин фәкать үземнең андан соң яши алмаячагымны, бөтен интересым бетдекене генә язам. Фатих менә икенче җомга улды, мин һаман айный алмыйм егълыйм, кан егълыйм, йөрәгем парә-парә булып бетде. Бөтен жизнемнең яме югалды. Мин аның рәсеменә карый алмыйм, хатларын укый алмыйм. Аның соңгы хатын сиңа язсам, күпме каты күңелле булсаң да, ереп китәр идең, инде мин нишлим. Миңа ни илә юанырга кушасың, минем хәзер ихтыярым үземдә түгел. Мине фәкать бер такым[2] дини куркытулар илә генә саклыйлар.

Менә кара мин сиңа иң соң алдырган рәсемен йибәрәм.

Мин аңар табынам. Фатих нидән бу кадәр несчастье, неужели шундый вакытсыз үлем бар, минем бер тутам ике елдан бирле өмидсез авыру берлән аурады. Менә хәзер сәламәтләнгән дию

[1] Муаффәкыятьле – булдыра алучы.
[2] Такым – бер төркем.

ишетәм. Ә бу 13 нче гыйнварда юри гына башым авыра дию яткан йирендән 17 нче мартда үлде. Һәр көн иртә берлән хәлем яхшырак дию гимназиягә барырга хәзерләнә икән. Бу нидән Аллаланмы бу золым фәләкдәнме[1]? Мин апдыраган. Минем күзләрем яшь, йөрәгемә кан урнашкан, кулым калтырый, артык яза алмыйм. Фәкать синдән берәр нәрсә илә күңелемне юатуыңны теләп сүземне тәмам итәм.

Фәрханә.

Хат Ф. Әмирханга укытучы Фәрханә Алуши (886–1958) тарафыннан язылган. Хатның язылу вакыты куелмаган. Хат кара төстәге кара белән белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Фәрханә Алуши хаты

Фатих абзый! Фатих (әфәнде) абзый!

Хатыңны алып укыдым, язганыңа рәхмәт.

Казанда Камаловага гашыйк булдым дию хәбәрен чыгаргансың икән, ул була торган эш – пәйгамбәрләрдән калган. Шулай юри генә сөйләнгән сүзләрнең соңында хакыйкать булып киткәнләре дә юк дәгел. Чын булса да екет кешегә гаеп түгел, яшь чакда бар да була.

Сафия, Әминәләр киткәнләр икән. Рабигаләр илә йөрешмисез бугай. Сиңа ухаживать итәргә кеше дә калмаган. Ә мин үз тарафымдан Шәмсекамәрне предлогать итәм. Күңел юатыр өчен забавга[2] баласы да бар бугай.

Ни хәл, тансовайт итә башладыңмы инде?

Без яхшы торамыз. Синең тәтиле тәбрикеңне алдык.

Гаедем бик аның аркасында мөбарәк узды, хәтта постелемдан тора алмый агырап ятдым.

Көнләремез яхшы үтә, ләкин Казанны да сагынамыз. Бик-бик кызык гына хат яз.

Аллам, Алла дигәндә ...

Без кыз екетләр, екетләр дигәндә ...

Вәссәлам

---

[1] Фәләкдәнме – язмыш, тәкъдирдәнме.

[2] Забавга – забава дигән рус сүзеннән (күңел ачарга).

Фатыймага, Фәйрүзәгә миндән сәлам әйт. Синдән хат алгач, озынны язармын.

Сеңелеңез Фәрханә ханым.

Хат Ф. Әмирханга Фәрханә Алуши тарафыннан язылган. Хатның язылу вакыты куелмаган. Хат кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Зәкәрия Сәдретдинев хаты

Газизем Фатих әфәнде!

Көз көне рамазанда ук мин сезгә барганда яшьләр илә Мәрҗанинең вафатына егерме биш ел тулуына мөнәсәбәте илә аның тәрҗемәи хәлен нәшер итмәк мөзакәрәсендә[1] идеңез! Шул вакыт Мәрҗанинең мин сабавәтендәге[2] әхвалене пәдәремдән[3] язып алып сезгә тәслим итмәки[4] мин үзлекемдән сезгә вәгъдә иткән идем. Көз көне миңа карьягә[5] бару ясир[6] булмады. Корбан бәйрәме вакытында карьяме дәгъвәт итдем[7]. Бу вакыт картның кадерләре кунаклары кияүләре бар иде. Даим[8] алар илә сөйләшүдә иде. Мин бу вакыт карьядә фәкать өч көн генә тордым. Шундан зыядәге форсатым юк иде. Картдан имля итмәкне сорагач, «Әй минем сөйләшеп утырасым килә; үзеңнең форсатың да бик аз; ул арада гына хәтергә бар әхвали килеп бетәме соң», диде. Мәга ма фиһи[9] сөйләгән кадәрләрене забыт итеп[10] алдым. Бу мәктүбем илә барәбәр тарафыңызә күндерәюрем. Максадыңызә шул язганларымның бер кәлимәсе[11] бәлки бер хәрефе хезмәт итә белсә, фәүкылгадә мәмнүнмен[12]. Итмәсә мөахәзә[13] итмәвеңезне бөтен күңелем илә риҗа идәмен[14]. Ни

---

[1] Мөзакәрәсендә – сөйләшүендә.
[2] Сабавәтендәге – сабыйлык.
[3] Пәдәремдән – атамнан.
[4] Тәслим итмәки – бирүне, тапшыруны.
[5] Карьягә – авылга.
[6] Ясир – җиңел.
[7] Карьяме дәгъвәт итдем – авылда булдым.
[8] Даим – өзлексез.
[9] Мәга ма фиһи – шуның белән бергә.
[10] Забыт итеп – теркәп, язып.
[11] Кәлимәсе – сүзе.
[12] Фәүкылгадә мәмнүнмен – гадәттән тыш шатмын.
[13] Мөахәзә – тәнкыйть.
[14] Риҗа идәмен – үтенәмен.

эшлим үзлекемдән вәгъдә итеп дә, кулымдан килмәгән булса, мин гөнаһлы вә оятлымын. Косурымдан игъмаз гайн итсәңез[1] екетлекеңездән улыр. Тәкрар[2] әйтәм бу хосусда мин сезгә бик оятлы булдым. Гафу итеңез!

Мәктүбемнең ирешүендән бер-ике сәтырлык[3] открытка илә хәбәр итсәңез, фәүкылгадә шадланачакмын...

Адрес мәгълүм Уфада братья Кәримевлар.

Хуш! Борадәрән кулыңызны кысамын...

Зәкәрия.

Хат Ф. Әмирханга педагог, журналист Зәкәрия Садретдин улы Садретдинев (1880–1930) тарафыннан язылган. Хатның язылу вакыты куелмаган. Хат кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазьдән, 2 биттән гыйбарәт.

## Зариф Бәшири хаты

Хөрмәтле Фатих абзый!

Тимерша абзыйга язган хатыңызны күрдем. Хатыңыздагы «Зинһар гарәп сүзен белер-белмәс тыкмаңыз. Тыксагыз бераз гарәпчә белгән кешегә күрсәтеңез» дигән җөмлә бәнем игътибарымы җәлеп кылды. Гүя Зариф вә мин тәмам агач бит ... дигән сүзләре ишарә кылып торадыр иде. Ләкин хакыйкать сүзгә ни диясең. Бармагымны тешләдем дә калдым. Даха да[4]: «Чүкеч» берлән «Әлислах»ның сугышуы Тимерша берлән Фатихның бозылуы дип тора идем дигән җөмләне укыгач, мин артык уйларга чумдым. Хакыйкать хәлдә шундый уйны – «Әлислах» берлән «Чүкеч» сүгешүе Зарифның «Әлислах»ка улган иске мәхәббәте узачакмы һәм итмеш хезмәтләрен үзе җуячакмы сүзләрен» уйлый идем. Ләкин сез ул мәсьәләне Зариф ачды, ул Тимершага куштанлык итде диярсез. Хәер уйланса уеңыз хата! Башлап сезгә бәйләнүче мин түгел. Ул вакытларда мин «Чүкеч»кә катышырга да теләми идем. Чөнки мин «Вакыт»да корректор идем. Дөрес бара-бара мин «Чүкеч»че булдым. Чөнки мин хөррәк мәсләкне[5] һәрвакыт яратам.

---

[1] Косурымдан игъмаз гайн итсәңез – кимчелегемне күрмәмешкә салышсагыз.

[2] Тәкрар – кабат.

[3] Сәтырлык – юллык.

[4] Даха да – тагы да.

[5] Мәсләкне – карашны.

Ләкин «кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырла» мәкаленчә мин Тимерша берлән җырлый-җырлый үземне белми калдым. Хакыйкатен әйтәм: мин яшьлегем илән болай булып алдануыма бөтенләй гаҗәпсенәм. Ни улса улсын кичде. Ләкин сез дә минем бөтен җирләремне сүкдеңез. Әмма мин аңа куанам. Аның өчен үземдән бөекләрнең мине каләмгә алып сүгүләре, хатамы күрсәтүдер. Чынлап караганда сүгү дәгел, остазлык итүләредер. Бәлки хәтереңездәдер, сез бервакыт «Ислах» идарәсендә миңа: «үзеңнең хатаңны күрсәткәндә түзсәң вә шул хатаңны бетерергә теләсәң генә кеше булырсың» дигән идеңез! Бу җөмлә бәнем йөрәгемдә бик зур бер урын алган вә үзе генә дә бөек остазлык ролен тоткан.

Бездә бер конторщик бар. «Яшен» яхуд «Әлислах»да мине төеп язган нәрсә күрсә, «син аңа куан, чөнки мине бер дә шулай язучы юк. Аның өчен минем барымны да белмиләр» ди. Мин «Яшен» берлән «Әлислах»да күргән хата вә йитешмәгәнлекләремнең күбесен төзәтдем. Фатих абзый! Мин хәзерендә 19 яшьлек бер малай булып, авыл мәдрәсәсендә тәрбияләнгән кеше түгелме вә шулай булса ничек начарлыклар булмасын. Ләкин сезнең кеби затлар хаталарымны күрсәтеп торганда, бәлки дә төзәлермен өмидендәмен.

«Чүкеч» хәзерендә бөтенләй минем кулда. Башдан аяк үзем язып да чыгам. Ләкин шулай була башлавы бары өч-дүрт номердан гына әле. Әмма мәсләген байлар култыкы астындагыча йөртергә мәҗбүр. Чөнки мәсьүл[1] мөхәррир Соловьев. Җөмләдән берсе дә, «Мәдрәсәи Хөсәения» хакында язган мәкаләмдән шуны җыелганын алдырды. Үзеңез мөхакәмә[2] кылырсыз. Инде аны сезгә йибәрдем. Әгәр мәгъкуль[3] булса, «Әлислах»ка басарсыз. Әгәр бассаңыз, монда хәлләрене язып торырмын. Мине иң туйдырган кеше Фатих Кәримидер. Әгәр байларның бераз хәтере калырдай урын булса, тәмам черносотенный була да куя.

Әле мин анлар хакында да язармын бәлки. Ну рәхмәт валла тагын да бер рәхмәт Мәхмүд бай хакында язган нәрсәңез өчен.

Фельетоныгызны үзем өч-дүрт мәртәбә укып, бөтен дусларыма күтәреп укып йөрдем. Тагын да бер әйтәм, рәхмәт. Чук яшәңез. Әле тагын да монда Рәмиевләрнең туе булды. Улсын беркадәр бәян итеп Гыйльметдин әфәндегә[1+] язмыш идем, бәлки ул сезгә сөйләр.

---

[1] Мәсьүл – җаваплы.
[2] Мөхакәмә – хөкем.
[3] Мәгъкуль – урынлы.

Хәзерендә минем ике данә шигырь мәҗмугам, ялгыш әйтәм берсе басылып чыкды. Әхмәд әфәнде гәзите идарәләренә йибәргәнме юкмы, мин улсын белмәдем. Хәзерендә сезгә үз тарафымдан йибәрәм. Зинһар һичбер нигә карамый хакыйкатен яза күреңез. Сүгәрлек булса, чытырдатып сүгеңез.

Гомуми ислахчы әфәнделәрә, хосусан Вафа абзыйга[2+], сәлам! Хуш сау булыңыз. Зариф. 2 нче май.

Хат 2 майда Ф. Әмирханга язучы, публицист, журналист Зариф Бәшири (1888–1962) тарафыннан язылган. Язылу елы билгесез. Хат «Зариф әл-Бәшири» дигән бланклы кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 2 кәгазьдән, 4 биттән гыйбарәт.

[1+] Гыйльметдин әфәнде – сүз җәмәгать эшлеклесе, нашир Гыйльметдин Шәрәфетдин улы Шәрәф (1885–1942) хакында.

[2+] Вафа абзый – сүз журналист, җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм «Әлислах» газетасы мөхәррире Вафа Бәхтияров (1881–1960) хакында.

## Муса Бигиев хаты

Әдибе мөхтәрәм дамелла әфәнде хәзрәтләре!

Бән сезең могтәбәр[1] «Әлислах» идарәсенә «Таһарәтел гарәб»ы вирмеш идем; ләкин гафу идеңез, җәридәңез сөтүнләрендә тәүсыя[2] улынмак шәрәфенә наил улсын[3], яхуд сезең тәнкыйдеңез мизан[4] илә вәзен[5] улынсын өмид илә дәгел иде. Ялңыз карендәшлек һидаясе[6] кабилендән бер шәй[7] иде. Игъланчылык вазыйфасына лязимсез тәнзил[8] итмешсез.

У[9] китабы тәэлиф[10] идән адәм тиҗарәт касды[11] илә яхуд ике-өч тиен истифадә касды[12] илә тәэлиф итмәмеш. Ялңыз «әл-һөмумә»

[1] Могтәбәр – хөрмәтле.

[2] Җәридәңез сөтүнләрендә тәүсыя – газетагыз битләрендә киңәш бирү.

[3] Шәрәфенә наил улсын – кадер, хөрмәтенә ирешү булсын.

[4] Мизан – авырлык.

[5] Вәзен – үлчәү.

[6] Һидаясе –туры юлга керү.

[7] Шәй – нәрсә.

[8] Тәнзил – ташлама.

[9] У – ул.

[10] Тәэлиф– төзү.

[11] Тиҗарәт касды – сату максаты.

[12] Истифадә касды – файдалану максаты.

нәшер улынмыш, илля[1] бу да нәшер улынсын» фикре илә тәэлиф улынмышдыр.

Галәм мәдәниятдә мөстәшриклар галәм диянәтдә[2] миссионерлар «әл-һөмумә» кеби китаплары насл[3] бер гарыз[4] илә тәэлиф идәрләр исә, «Таһарәтел гарәб»ы да мөәллифе[5] гайн гарыз илә тәэлиф итмешдер.

Белерсез: матбугат галәме гаять киңдер. У кадәр киң галәми ялңыз «Әлислах» масштаб илә кыяс итмәк[6], гөман идәрем[7], даимән сәхих улмас[8].

Игъланыңыз өчен тәшәккер[9] итмәк бәнем, әлбәттә, бурычымдыр белейорумм. Рәхмәт. Зирә[10] бән табигъ[11] итдермеш идем.

Ноябрь 8 дә.

М. Бигиев.

Хат 8 ноябрьдә Ф. Әмирханга дин галиме, җәмәгать-сәясәт эшлеклесе, публицист Муса Бигиев (1875–1949) тарафыннан язылган. Язылу елы күрсәтелмәгән. Хат кара төстәге кара белән язылган. Гарәп графикасында, татар телендә. Күләме 1 кәгазьдән, 1 биттән гыйбарәт.

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты*
*Гөлназ Хөснетдинова әзерләде.*

---

[1] Илля – әмма.
[2] Диянәтдә – дин тотучылык.
[3] Насл – ничек.
[4] Гарыз – тәкъдим итү.
[5] Мөәллифе – язучысы.
[6] Кыяс итмәк – чагыштыруым.
[7] Гөман идәрем – уйлануым.
[8] Даимән сәхих улмас– чын булмас.
[9] Тәшәккер – рәхмәт.
[10] Зирә – чөнки.
[11] Табигъ – бастыручы.

## ФАТИХ ӘМИРХАН – ЗАМАНДАШЛАРЫ ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ

Габдулла Тукай «Уянгач беренче эшем» исемле бер мәкаләсендә («Кояш», 1913. 18 март) «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле» дип, әдип иҗатының халык күңелендә урын алуда әнә шундый җентекле шәрехләүнең әһәмиятенә басым ясаган иде. Мондый шәрехләүдә төп таяну ноктасы – билгеле ки, әдипнең язма мирасы. Әдәбиятчы галимнәр нәкъ менә аны беренче планга куеп эзләнүләр алып баралар, әсәрләрен барлыйлар, аларның мөмкин кадәр тулырак басмаларын төзиләр, әдәби-нәзари проблемалар яктылыгында тикшерергә омтылалар. Бу эштә ярдәмгә килә торган чыганаклар арасында әдип турында язылган истәлекләр, мемуар язмалар да зур урын биләп тора. Аның белән очрашкан, аралашкан, дуслашкан, кайчак исә катлаулырак мөнәсәбәтләргә дә юлыккан замандашларының фикерләре дә игътибардан читтә калырга тиеш түгел. Шул чакта гына тикшеренүче сүзенең ышандыру көче арта.

Ф. Әмирханның татар әдәбияты үсешенә керткән өлеше үзе исән вакытта ук танылып өлгерсә дә, вафатыннан соң (1926. 9 март) инде аны яңа шартларда бәяләү мәсьәләсе алга килеп баса. Бу чорда яңа буын укучыларга танытуга ярдәм итәрдәй беренче истәлекләр дә языла. Беренчеләре исә март аенда ук басылып чыккан (Ф. Бурнаш, Д. Юлтый, Чыгътай, Г. Сәгъди һ.б.). Болар арасында күптәнге дуслары Р. Алуши, И. Бикколовларның әдипкә тирән хөрмәт белән сугарылган истәлекләре фактик материалга байлыгы ягыннан да аерылып торалар. 1897–1905 елларда Казанда укыганда, 1918–1931 елларда исә биредә фәнни һәм педагогик эшчәнлеген алып барганда, ихтимал, Ф. Әмирхан белән дә аралашкан Җамал Вәлидинең кечерәк күләмле язмасы барыннан да бигрәк әдип иҗатының төп үзенчәлекләрен ачарга омтылу белән кызыклы.

Әдип турында истәлекләр, 1950 елларга кадәр Ф. Әмирхан иҗатына мөнәсәбәтнең сыйнфыйлык принципларына нигезләнгән

булуы сәбәпле, матбугатта әлләни күренми. 1960–1980 елларда инде әдипнең үзеннән яшьрәк замандашларының истәлек язмалары да табыла. Бу урында тарихчы галим Равил Әмирханов (Ф. Әмирхановның атасы Зариф хәзрәтнең бертуганы Нәҗип хәзрәтнең оныгы) һәм әдәбиятчы Фатыйма Ибраһимоваларның текстологик эшчәнлекләре нәтиҗәле булды: 1986 елда, әдипнең йөз еллык юбилее уңаеннан, Татарстан китап нәшриятында алар төзегән «Фатих Әмирхан турында истәлекләр» китабы дөнья күрде. Анда моңа кадәр татар вакытлы матбугатында чыккан, шулай ук Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында сакланган Ф. Әмирхановның шәхси фондындагы истәлекләр урын алган иде. Ф. Ибраһимова һәм Р. Әмирхан моннан соң да эзләнүләрне дәвам иттерделәр һәм 2005 елда, Ф. Әмирханның 120 еллыгына багышлап, җыентыкның тулыландырылган икенче басмасын да төзеп чыгардылар. Чыннан да, китап шактый баеган, анда төзүчеләрнең үтенече буенча язып алынган тагын тугыз истәлеккә дә урын бирелгән. Боларның авторлары – күренекле шәхесләребез: А. Шамов, Б. Урманче, Р. Ишморат, И. Һилалов, М. Гайнуллин, З. Тинчурина, С. Садыйкова, Ф. Ильская, Ә. Шәрәф. Җыентыкның ахырына урнаштырылган, мәгълүматка бик бай «Искәрмәләр һәм аңлатмалар» да әдип тормышындагы һәм иҗатындагы, туганнары һәм замандашлары белән мөнәсәбәтләрендәге күп кенә «ак таплар»га ачыклык кертә.

Әмма әдип турындагы барлык истәлекләр дә бүгенге укучы игътибарына тәкъдим ителгән дип раслана алмый. Мәсәлән, 1940 елда язылган, «Казан утлары» журналының 1996 елгы 1 санында басылган шагыйрь Миргазиз Укмасый истәлеге бар. Ул әлеге ике китапның берсенә дә кертелмәгән. Күрәсең, шагыйрьнең Ф. Әмирхан белән аралашуларындагы «кытыршылыклар»ны, бер-берсен бәяләүләрендәге үзенчәлекле моментларны укучылар алдында да ачып салуны хуп күрмәгәннәр.

Тагын бер истәлек Казан шәһәренең Бишбалта бистәсендә озак еллар укытучы булып эшләгән Габдерахман Рәфыйковның оныгы Наилә Рәфыйковада сакланган. Күптән түгел ул аны Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчелегенә тәкъдим итте. Истәлек заманында елга транспортында эшләгән Хәбибрахман Рәфыйков исеменнән язылган. Аяклары параличланган булу сәбәпле теләсә кая бару, сәяхәт итү мөмкинлеге бик чикләнгән булса да, Ф. Әмирхан Казаннан чыгып йөрүләрне бик яраткан. Әлеге

истәлекләрендә Х. Рәфыйков үзе эшләгән пароходта Ф. Әмирханның Уфага, Түбән Новгородка, Әстерханга сәяхәтләрен бәян итеп, аның ачык чырайлы, шат күңелле булуын, ихласлыгын сурәтли. Бу истәлекләр дә киләчәктә әдипнең тулы фәнни биографиясен язуга, гомумән, Ф. Әмирхан феноменын тирәнрәк аңларга хезмәт итәр…

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре,*
*филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев*

## Миргазиз Укмасыйның
## Ф. Әмирхан турындагы истәлеге

*Шагыйрь Миргазиз Укмасыйның (1884-1948) Ф. Әмирхан турындагы истәлеге Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Ф. Әмирхан фондында саклана (Ф. 16. 2 тасв. 46 с. б.). Әлеге кульъязма истәлек тарихчы галим Равил Әмирхан тарафыннан өйрәнелеп, «Казан утлары» журналының 1996 елгы 1 санында басылып чыккан иде. Җыентыкка текст кульъязмадан алып эшләнде һәм бернинди үзгәртүләрсез тәкъдим ителә.*

### *Фатих Әмирхан турында истәлекләр*

Ачык әйтә алмыйм, «мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә 1897 нче елда укырга килдем, шул вакыт Фатих Әмирхан рөшди сыйныфында[1] бер ел миннән алда бара иде. Бу вакыттагы рөшди сыйныфы «Мөхәммәдия»нең хәзерге бинасында күренешендә булмыйча, капка асты юк, ул урын буш, йорт салынмаган, хәзерге капкадан кергәч тә уң якта Йосыф мулла мәдрәсәсендән читтәрәк кечкенә генә бер катлы йорт иде, шул чагында Ф. Әмирхан капкадан кергәч уң яктагы бер катлы таш йортта, мин килгәндә беренче яки 2 нче рөшдидә укый торган шәкерт булып, без мәдрәсәдә кунып торып укысак та, ул алай булмыйча, иртә белән Ф. һәм И. Әмирхановларны бик матур кара ат белән, өстенә калын толып кигән кучер мәктәпкә китереп куя торган иде.

Аларның кулларында сумкалар, өст-башлары шәһәрчә матур киенгән. Без, бала булу сыйфаты белән, Казан мулласының

[1] Рөшди сыйныфында – урта сыйныфта.

балалары дип, аларга сокланып карап тора идек. Алар төшке аш вакытында ләвәшләр, сумсалар ашыйлар, без авылдан килеп озак вакыт үтү сәбәпле, күгәрә төшкән икмәк ашыйбыз, җылы аш күп вакытта юк. Болар җимертеп кич белән, тагын кучер белән өйгә кайтып китәләр, җылы тәмле аш, иркә ана чырае күрәләр, йомшак урында йоклыйлар. Теләгән вакытларында мунча, ашарга теләсәләр кәләвә, төрле кәгазь, карандаш – барысы да болар кулында иректә дип, мин үзем шәхси боларга кызыга идем.

Икесенең дә төст-бит бик матур, килештереп тегелгән киемнәр, җитмәсә, алар төрле модага алмашынып торалар. Син бер камзулга яки бер чалбарга мохтаҗ, алар аны төрле фасонга алмаштырганга, безнең күк ярлы авыл шәкертенә бу бик зур алдынлык, бәхет күк тоела иде. Кыш көне сәгать 2 ләр генә теге кучер кара аты, без бер дә утырмаган һәм утырачак та күк тоелмас торган матур, утыра торган урын киң, асты тар, бик юка табанлы матур чана белән, кара атның өстендә «көмешләр» тезгән шлея, җиңел камыт, нечкә тубылгы дуга, тар каештан эшләнгән «көмешләр» тезелгән җөгән, аның тезгенен икегә аерып, дуганың ике ягына тарттырып куелган тасма дилбегә. Шул ат белән мәдрәсә алдына тукталган да Әмирхановларны көтә. Алар дәресләрен бетерүгә, ашыкмый гына икәүләп урамга чыгалар, без авыз суыбызны корытып, аларны да карап торабыз. Ямщик, алар утыра торган яктан чана алдына япкан тирене ачып, аларны утырта һәм алларына тагын теге тире юрганны ябып, тасма дилбегә белән атка чиертә дә, алар шул вакыт күздән юк булалар.

Менә мин, аякта агач башмак, авылдан яңа килгән малай, боларга карап сокланам, әле үзем Казанның рәтен белмим, «Мөхәммәдия»дә Кәрим хәлфә кул астында нәху кыйсме, тәҗвид, бәдәэл-мәгариф, матур язу, Коръән дигән нәрсәләрне укып йөри торган бер малай, бу көнгә кадәр мин язуны дөрест булмаса да, танып беләм. Әмирхановларның зурлыгына, Казан йортларының зурлыгына, мәчетләрнең зурлыгына, анда җәелгән яшел сукноларга исем китә. Мәдрәсәнең зурлыгына, анда укучы калын китаплы «зур» кешеләргә исем китә; ләкин мине, авылдан килгән малай дип, теләсә кем кыерсыта. Мин 3 юл чатында үскән каен күк: теләсә кем, кучер да, миңа суга. Безнең мәдрәсәдә ул вакыт электр юк иде. Бер вакыт Ф. Әмирханнар укый торган бүлмәгә барып кердем: электр чыбыгы үткән һәм лампасы куелган, ләкин ут кына җанмый, моны да эшләткән

кеше Фатих Әмирхан иде. Мин моңарда зур таңлану белән карап тордым.

Минем Яңа Бистәдә җизнәләрем бар икән, атам килгәч, аларга алып барды, аның исеме Вәли Сәйдәшев булып, Әхмәт байда кантурда эшли торган бер түбән язучы иде. Мин шуннан соң бу җизнигә һәр атнакич бара торган булдым, чөнки аларда аш ашап кайта торган идем. Шуның белән бергә, моның мунча алачыгы күк бер кибете яки өй алдысы булып, анда күмәч, күмер, утын, варенье, кәгазь һәм конфет булып, бөтен суммасы ул вакыт хисабы белән 30 сумнан артмаган товар булып, шунда авылда кузна уйнап үскән Хәсиб Төхфәтуллин дигән, миннән берәр яшь өстен күршебез малае минем элекке дустым жалованиясез приказчик булып торганга, ул миңа туйганчы ашарга күмәч бирә һәм «шау күмер» дигән пекарня тотучылардан аның белән күмәч алып кайта торган идек. Мин һәр атнакич көнне туйганчы күмәч ашый торган идем.

Менә шулай Яңа Бистәгә килеп йөргәндә, Ф. Әмирхановларның йортларын да, аталарын да белдем. Алар Вәли җизниләрнең нәкъ күршеләре Зариф мулла балалары икән. Аларның капкалары хәзерге вагон йөри торган урамда, беренче мәчеткә каршы кыйгач «наискосок» салынган булып, ләкин йортлары капкадан байтак эчтә, ишек алды түрендә, ишек алдына аркылы салынган иде. Мин аннары аталарын да күрдем. Ул урта буйлы, җуан, калын матур тавышлы, бер дә пошынмый торган, киеменә ут төртсәң дә ашыкмый торган бер кеше иде. Ләкин Яңа Бистә халкы аны башка сыйфаты белән түгел, тавышы матур дип җараталар иде. Мин аның җомгасында күп вакыт була торган идем. Чөнки син шәкерт, дип Вәли җизни алып бара торган иде. Аның вәгазь сөйләгәнен мин бер дә белмим. Мәчеттән чыккач, Вәли җизни: «Шәпме безнең мулла», – дип сорый торган иде, ә мин шәплек-фәләнен белмичә, җуан булганга, шәп, дип җавап бирә торган идем. «Шәп шул, тамагы бик матур бит аның», – ди торган иде.

Сүз җае килгәнгә, урынсыз булса да, язып узыйм. Бу урынга икенче җизнәм Садыйк Сивиргузин хуҗа булгач, ул Вәли җизнигә караганда яшькә сазаган һәм дөньяның бик нык әчеләрен татыган кеше булып, шул ук Зариф мулладан аз гына, «бер-ике» яшьләр түбән булганга, аның бик күп интимный эшләрен миңа сөйләгәне бар. Бервакыт, ди, Мәңгәргә кунакка кайттык, ди, Зариф мулла яшь иде әле, ди, аның сөеп орынтын тота торган бер кызы бар иде,

ди. Пар ат җигеп, мин ат башына утырып, Дегтярный урамнан шул кызны Мәңгәргә җыенга алып кайтып китдек, ди. Тарантасы артына чыпта белән төреп, ике кәрзинкә сыра бәйләдек, ди, ат башысы астына кызыл аракылар тутырдык ди, әлеге кызга чапан яптырып, авылда аны Зариф хәзрәтнең остабикәсе бу дип таныттык, ди.

Мәңгәрнең кемдер бер баенда бер атна гулять итеп, рәхәтләнеп кайтдык, ди. Моннан соң да мондый эшләребез күп булды, ләкин мин серле булганга, башка кешегә мондый эшләрне белгертмичә, миңа гына белгертә торган иде, дип сөйләгәне, мондан башка вакыйгаларны да сөйләгәне бар булса да, мин монда төп максат ул булмаганга, аларга кагылмый китәм.

Менә шулай мин Фатих Әмирханнарның йортларын да, аталарын да белдем. Ул шәһәр малае, уку эшенә миннән алдан тотынганга, ул миннән 1–2 сыйныф югары барадыр иде. Хәтеремдә ялгыш калмаса, Вафа Бәхтияровлар белән сыйныфташ, ул безнең белән Бишенче ел революциясендән бер яки 2 ел алдан катнаша башлады, чөнки бу чорларда шәкертләр эчендә яңалык теләү, уку системасыннан ризасызлык, укыла торган программаның хәят өчен кирәкле шартларга алып бармаганлыгы аңлашылды. Моның сәбәбе: мәдрәсә галәменә бердән, «Тәрҗеман» гәзитәсенең тәэсире булса, икенчедән, төрек гәзитәләре һәм мәдрәсәгә төрле яктан килеп-китеп, шәкертләрнең эч-үзәкләренә катнашып йөрүче төркия тәрбиясендә үскән милләтче агитаторлар иде. Шулай ук Бакуда чыга торган «Шәркый рус» гәзитәсенең дә тәэсирен юк дип әйтеп булмый. Шул чорларда мәдрәсәдә кружоклар оештырылып, ләкин ул кружоклар үзенчә булса да, сыйныф «класс» системасында иде. Монда хәлфәләр, мәдрәсәнең «зур саналган» сыйныфлары үзләренә бер кружок төзесәләр, безнең күк түбәнрәк шәкертләр үзебезгә аерым кружок төзегән идек.

Безнең кружок башында яки аның җитәкчесе булып Фатих Әмирхан тора иде. Мин хәзер бу кружокның төп программасын әйтә алмыйм, чөнки ул нигезле бер программага таянмаган, бәлки чикле рәвештә, мәктәп-мәдрәсәләрне ислах, «милләтне тәрәкъкый» иттерү нигезендә иде. Без һәр атнакич бу кружок членнары бергә җыелабыз. Җыелу урыныбыз урамга караган мәдрәсәнең уртанчы катында дәресханәдә булып, кружок членлары һәркайсысы бу җыелышка бер язма материал белән килергә мәҗбүр иде. Әнә шунда Фатих Әмирхан рәислек итә, бөтен әгъзалар шул

җыелышта үзләре хәзерләгән материалны укыйлар, соңра аны язма рәвештә Ф. Әмирханга тапшыралар иде. Безнең бу кружогыбыз өч елларга тартылды булырга кирәк. Шунда укылган һәм язылган материаллар һәркайсысы Ф. Әмирхан кулында кала килде, аларны Фатих кайда куйган, мин моңар җавап бирә алмыйм.

Безнең бу җыелышыбызда почетный кеше булып «Петербурдан» Ленинградтан килгән Рәшид казый Ибраһимовның да катнашкан чакларын беләм. Ул инде безнең өчен «зур акыл иясе» булып хисапланганга, без аның алдында бер сүз әйтергә дә кыймыйча, аның сүзләрен акыллар хәйран булып тыңлыйбыз, ул үзенең сөйләгән речьләрендә мәдрәсәләрнең яраксызлыгын, хәзерге мәдрәсәләр, анда укыла торган мантыйклар урынына, физика, математика, яграфия, төрек һәм татар телләре, шуның белән бергә фәлсәфәсе белән бергә, Корән тәфсире вә хәдисләр кирәргә тиеш икәнен сөйли. Без аңсыз яшь буыннарга милли яктан тәэсир итеп, Европа милләтләренең аң-белем ягыннан күтәрелеп, безнең йокы хәлендә икәнебезне «Казан ханлыкларын», «Чыңгыз бабаларын» татарларның бөтен Европаны тетрәтүләрен, гарәпләрнең ислам галәме саф вакытта, шәрыктан гаребкә кадәр үсүләрен, безгә дә шул үткән тарихны яшь буыннар тергезергә тиеш икәнне сөйләп, безне таң калдыра. Ул чорда сәяси белемебез юклык аркасында без аны растлап, бөтен йөрәгебез белән шул «адәмне» ихтирам итәбез. Без шунда, Чыңгызны да, Николай II не дә бар да бер кеше икәнен аңламыйбыз, ул гына да түгел, шул юлда безне агулаучы бер пычракны җан күңелебез белән ихтирам итәбез. Әй, бүгенге сәяси аң булсачы, безнең бу кружокта күп нәрсәләр, күп нәрсәләр укыла иде. Шул материаллар бар да Фатих Әмирханда калып, аларның бу көндә саклану урыннары бардырмы-юкмы, мин анысын белмим, ләкин ул материаллар бик күп булырга тиеш.

Бу көндәгедәй хәтеремдә, шушы кружок 1904 нче елда күңел ачу җыелышы үткәрде, гыйнвар числоларында булырга тиеш. Мәдрәсәнең капкадан керүгә үк як башында ул вакытта шәкертләр урнашмаган буш бина, «Сахалин» дип йөртелә торган бер почмагы бар иде. Аның «Сахалин» аталуына сәбәптә, мәдрәсәнең иң аргы башы, шуның белән бергә паровой отопление кертелмәгән һәм кеше тормый торган ялгыз бүлмә булганга шул исем бирелгән иде. Безнең әлеге кичәбез менә шунда булды.

Ул вакыт гармун, скрипка яки башкача уеннар мәдрәсә эченә керә алмыйлар. Без беренче тапкыр күргән симпонион[1]ны Ф. Әмирхан кайдандыр алып кайтып, шул җыелышка китерде. Ул төрле татар көйләрен уйный, без искиткеч рухланабыз, дөньяда мондан да зур «шәп мәҗлес» юктыр төсле представить итәбез, ул ниндидер бер марш уйный, без тезелеп, кулга-кул тотынып, тансыга ошаган бер хәрәкәт белән, ләкин һичбер тәртипкә салынмаган рәвештә шул симпонион тирәсендә әйләнәбез. Бик фәкыйр генә үзенчә бер буфет сымак нәрсәсе бар, ул бер дә сату итә алмый, чөнки бер шәкертнең дә акчасы юк.

Шундан соң кружок әгъзалары үзләре язган нәрсәләре белән выступать иттеләр. Болар беткәч, без симпонионга да гадәтләнгәч, мәҗлеснең төзелгән бер программасы юклык сәбәпле, мәҗлес үз-үзендән сүрәннәнеп, ахырында, күңелдә бер йогынты да ясый алмыйча таркалды. Ләкин Фатих Әмирханның монда төп теләге: шәкертләрне әдәбият кичәсе, аның төзелеше белән таныштыру иде. Ф. Әмирхан бу кичәдә активный катнашып, симпонионны да үзе борып торып һәм танса юлларын да үзе организовать итеп йөрде.

1905 нче ел революциясе шәкертләр арасына әллә ничегрәк килеп керде. Фатих Әмирхан кружокта безне «Марсельеза», «Похоронный марш» һәм башкача революционный җырлар белән таныштырып, без боларны барысын да язып алып һәм аларның русчасын шулай ук татарчага тәрҗемә ителгәннәрен һәркайсыбыз җырлап йөри башладык, шул ук кружокта без халык арасында төрле партияләр бар икәнен, кадетлар, социал-революционерлар, социал-демократлар, максималистлар бар икәнен аңладык.

Аңладык дигәч тә, программалары һәм тоткан юллары белән детальный танышып түгел, исемнәре белән таныштык һәм кайсы партияның кемнәргә, нинди сыйныфларга опираться итүләре белән таныштык. Кадетлар партиясе зур байларга, русның милләтче сыйныфына, помещикларга, социал-революциянерларның крестьяннарга, социал-демократларның завод-фабрикада эшләүче рабочийларга таянганын белдек. Шулай да бу соңгы ике партияның кайсы дөрест юл белән бара; без кайсын алда күрергә

[1] *Симпонион – Симфонион – Россиядә XIX гасыр ахыры – XX йөз башында күренә башлаган механик рәвештә көй чыгару җайланмасы. Әлеге җайланма Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә дә саклана.*

тиеш – моны аера алмый идек, икесенең дә бара торган юлы, теләге бертөсле күренә иде. Шуңар күрә без үзара обсуждать иткәндә, мин социал-демократия партиясен теге с.-революционер партиясен алга куя, ләкин бер-беребезне җиңәрлек, хаклыкны җарып салырлык икебездә дә көч юк.

Моны Фатих Әмирхан да ачык әйтеп бирә алмый. Бары Хөсәен Ямашев кына моны миңа бик нык доказательстволар белән төшендереп, ул с.-революционерларны чертеп салды. Алар ялганныйлар, крестьянга таянган төсле күренәләр, ләкин крестьян алар өчен бер вакытта да таяныч булачак түгел, крестьян үзе дә катлаулы, аның бер катлавы кадетлар юлына ияреп, икенче катлавы рабочийлар белән кулга-кул тотынып барачак, димәк, эсерларның программалары тыштан караганда изелгән халыкларны коткару төсле булып күренсә, бу күз буяу гына булып, алар шул ук кадетларга барып тоташачаклар, рабочий өчен дә, ярлы крестьян өчен дә алардан он да юк, йон да юк, диде.

Мин монда кыска язам, ул миңа бу турыда озак сөйләде һәм төшендерде. Мин шундан соң эсерларны кызыл күлмәк киеп йөрүдән башкага ярамаган, кайберсе алданган, кайберсе алдакчы, һәм революцияне булдырмаска юл эзләп йөрүче бер партия икәнен яхшы аңладым.

1905–1906 нчы елны булырга кирәк, кружокта Фатих Әмирхан безгә бер значок күрсәтте. Ул көмештән эшләнгән булып, аның төзелеше ук, җәя һәм укның өстендә нечкә ай белән йолдыз ясалган иде. Без бик кызыксынып алып карадык һәм безнең һәркайсыбызга шуны ясатып алып, тагып йөрергә кушты. Без: «Бу нәрсә соң?» – дип сорадык. Җавабында: «Монда «Болгар» нумерәсенә Будапешт профессоры, Мадяр «маҗар» Мәйсуруш исемне кеше килгән, без мадьярлар белән бер нәсел, аларның знаклары ук, җәя булып, безнең нечкә ай эчендә йолдыз булганга, алар белән без бер нәсел икәнебезгә билге булсын өчен бу галәмәтләр бергә тоташтырылырга тиеш», – диде. «Соң ул профессор монда нинди теләк белән килгән?» –дип сорадык. «Аның теләге – татар һәм чуаш телен өйрәнеп, җола-гадәтләренә төшенеп, шуларны үз тел вә җола-гадәтләре белән чагыштыру», – диде һәм шундук: «Менә аңар татарның такмак, такмаза, хикәя, табышмаклары белән таныштыручы бер кеше кирәк, атнага 2 көн чуаш теле, 4 көн кич белән татар телен өйрәнү өстендә булачак, һәр дәрескә 50 тиен акча түли, шул эшне кайсыгыз өстенә ала?» – диде.

Хуҗа Бәдигый алды, һәм ул Мәйсуруш белән кыш буенча шөгыльләнеп, җәй көне татарлар арасына җола-гадәтне өйрәнү өчен татар авылларына чыгып киттеләр. Хуҗа Бәдигый Мәйсурушга өйрәтү өчен кыш буенча шәкертләр арасыннан борынгы җырлар, мәкаль, такмак, такмаза татар телендә имнәү сүзләре, «кетер-кетер», «кытыр-кытыр», «чебер-чебер», «шабыр-шобыр» күк сүзләр арасындагы мәгънә аермаларын бергә обсуждать итеп, җыеп, һәр кич Мәйсурушка илтеп тапшыра һәм шундан җыелган бөтен материалларны да үз кулында да язып калдырып бара иде.

Бу вакытларда бездә рухта зур күтәренкелек, дәрт, энтузиазм кайнап-җанып тора, без мәктәп-мәдрәсәләрнең җитешмәгән якларын бик нык тикшерәбез, татар теле өчен кагыйдәләр, сарыф, нәхүе булырга тиеш икәнен, аңар юллар, кагыйдәләр хәзерлибез, шуларны тикшерәбез, шәрык логикасына караган «Исагуҗи», «Шәмсия» күк китапларны җыртып бетереп, тәрәзә аркылы бәрәбез, хәлфәләргә рәтләп буйсынмыйбыз, мантыйк «логика» дәресләренә беребез дә кермибез.

Көз көне безнең кружокның гына түгел, бәлки бөтен мәдрәсә күләмендә булган шәкертләрнең җыелышлары булды. Анда мәктәп-мәдрәсәләрнең программ һәм укыту юлларының төзелешен, нигезендән алып үзгәртү кирәк икәнен сөйләдек. Чыгып сөйләүче «оратор»лар бик күп булды, һәркайсы үзенең планын тәкъдим итте. Менә шунда Фатих Әмирхан да чыгып сөйләп, үз речендә ул бу реформаның акчага бәйле булганын, бу реформаны мәдрәсәләргә кертергә һичбер Казан баеның риза булмаячагын, буржуй байларның моңар начар караячаклар һәм мәдрәсәләргә биреп бара торган финансовый поддержкаларын өзәчәкләрен, бу реформага без ирешә алу өчен Петербурга вәкил җибәреп, хөкүмәт белән сөйләшергә һәм татар халкыннан җыела торган земский сборның мәгарифкә китә торган процентын татарларның үз мәктәп-мәдрәсәләренә бирергә тиеш икәнен доказать һәм таләп итергә тиешбез, диде.

Без бу «шәп акылга» исебез китте, вәкил җибәрәбез Петербур «Ленинград»ка кеше җибәрәбез, кемне сайлыйбыз, бу эшне кем башкарып кайта алыр, дигән обсуждениелар башланды. Ф. Әмирхан тагын торып, «вәкил җибәрербез, ләкин аны сайлаганчы, аның юл расходлары, ашау, йөрү расходлары бар, элек шуны карарга кирәк», – диде. Без һәр шәкерттән 50 тиен акча алып, бу чыгымны тәэмин итәргә дигән карарга килдек. Инде вәкил булып бару

өчен кандидатлар күрсәтелә башлады. Кайсы әйтә Әкрәмне сайлыйбыз, ди.

– «Бик йомшак, бер авыз рус теле белми, сөйләргә бик ярата, төпле бер сүзе юк, сүз белән сүз арасын 10 минут исәпләп тора, күзен йомып, йозрыгын йомып, һәр 5 сүзгә бер «милләт артта», «милләтне тәрәккъкый иттерергә кирәк», дип үзе сүзе белән тыңлаучыларны йоклата». Кайсы: «Вәли карыйны сайлыйк», һәм башкалар.

Бу кандидатлар эчендә Ф. Әмирханның да кандидатурасы алга сөрелеп, соңра бер авыздан Ф. Әмирхан Петербурда югарыда сөйләнгән мәсьәлә белән министр просвещениягә кереп сөйләргә вәкил булып сайланды. Юл расходына безнең һәркайсыбыздан 50 шәр тиен акча җыеп алдылар. Һәм Петербурда министрга керү өчен Фатих Әмирхан своеобразный җөббә тектерде, шундан соң ул Петербургка барып кайтты. Нишләгән, кергәнме, ни җавап алып кайткан, Дума әгъзалары белән бу турыда сөйләшкәнме. Без берсен дә белмәдек. Ул да сөйләшмәде һәм отчет та бирмәде, бу мәсьәлә шулай тып-тын сүнде һәм билгесез калды. Ләкин шунысы мәгълүм булды, ул Петербурда Шамил белән күрешкән, бусы Москвада «Тәрбияи әтфаль» журналы чыгарачак икән, Әмирхан шул журналны чыгарышырга һәм анда язышырга, Москвага барырга вәгъдә биреп кайткан.

Шундан соң Ф. Әмирхан Мәскәүгә китеп «Тәрбияи әтфаль» журналында эшли башлады. Исеменнән дә күренә, бу журнал балалар тәрбиясе өчен чыгарыла торган бер журнал иде. Ф. Әмирхан анда баргач, бу журналга «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» дигән хикәяне бастырып, аңар үз имзасын куйган иде. Мин Фатихтан бер очраганда: «Бу хикәя үзеңнекеме?» – дип сорадым. «Үземнеке», диде, ләкин мин бу хикәяне мондан 5–6 ел элек Лаеш өязе Күгәрчен авылында булган рус теле мәктәбендә укыган идем. Шундый мәктәпләр өчен Радлов та «Белек» исемендә бер уку китабы төзеп, бу хикәя аның китабында бар һәм заглавиесен «Шыксыз бәпкә» дип атаган иде[1]. Ләкин аны Ф. Әмирханның үзенә әйтмәдем. Радловның бу уку китабы нәгыз[2] татар теле белән язылган, бер генә дә гарәп яки рус сүзе юк, күләме 200 битләрдән азрак артык булып,

---

[1] *Бу хикәянең язучысын белсәм дә, хәтеремнән чыгу сәбәпле, монда күрсәтә алмадым. (М. Укмасый искәрмәсе).*

[2] Нәгыз – яхшы.

татар телендә мәктәп балары өчен язылган уку китабының иң беренчесе булырга тиеш. Шунлыктан бу китап «Белек» тарих һәм тел төзелеше ягыннан зур әһәмияткә ия була ала. «Белек» нәгыз татар телендә булу һәм сүз төзелешләренең матурлыгы ягыннан һәрвакыт үрнәк була алу белән бергә, моны төзү эшендә кемнәр булышкандыр, анысын мин әйтә алмыйм, ләкин моңар Каюм Насыйрилар һәм андан алдагы язучыларның катнашлары барлыгында бер дә шик юк. Бу китапны Мөхетдин Корбангалиев белә һәм хәтерли торгандыр дип уйлыйм.

Ф. Әмирханның мин жандармлардан да качып йөргәнен хәтерлим. Ул көндезләрдә Яңа Бистәгә аталары йортына кайтканда ал кабкадан кермичә, үзенә хас арт юлдан, хәзерге чуен юл киткән яктагы урамдан керәдер иде, ләкин кичләрдә өйгә кунарга кайтмыйча, читтәге танышларында йоклый иде. Һәм Ф Әмирхан бер вакытны «Музуров номерасында» торганын да хәтерлим, шунда мин аның номерасына кердем, янында матур гына бер гимназистка бар иде, ул чыгып киткәч: «Укмасый! Бу маржа кызлары бик матур булалар, ләкин картайгач, аларның карчыклары бик ямьсезләнә», – диде.

Ф. Әмирхан Мәскәүдән авырып, паралич сугу сәбәбле кайтты. Ул авырып ятканда, мин хәлен белү өчен йортларына бардым. Үзе карават өстендә, кулында ниндидер бер китап, шуны укып ята иде.

– Нихәл, Фатих, – дидем.

– Менә, син күргәнчә, авырыйм, – диде. – Дуслар сау вакытта гына тирә җүнендә кайныйлар, авыргач, бар да качып бетәләр, – диде.

Без нәрсәләр сөйләшкәнебез, аны хәтерләмим, ләкин авыруның сәбәбен сорагач, «Мәскәүдәен трамвай юлын аркылы чыканда гына шушылай булдым, ахры, электр тәэсир итте бугай», – дигән сүзен хәтерлим. Андан соң ул кул белән хәрәкәткә китерә торган, «үзен үзе йөртергә» резинка тәгәрмәчле бер арба алып, шуның белән урамга чыга һәм шул арбада килеш, урамда, капкалары янында һәрвакыт йә гәзит яки берәр кенәгә укыганын күрә идем. «Әлислах» гәзите рәсми чыга башлагач, ул һәр көн аның редакциясенә килә. Фатихны анда ат белән күчерлары китереп, кич белән килеп алып китә иде. Мин бервакыт «Әлислах»ка басарга бер шигырь бирдем. Шул шигыремдә «мөлаем керпекләре сыйпап сөйдерә», дигән бер җөмләне укыгач, бу сүз удачный чыккан, керпекнең күңелгә каты, сөйкемсез тәэсир итә торганнары

да күп була», – диде. Мин бу гәзиткә шигырь биргәндә аны бик җемтекләп тикшерә, җитешсез, җогышсыз урыннарын тәнкыйть итә, төзәтергә куша, кайбер сүзне берсен икенчесе белән генә алмаштырырга туры килгән вакытлар була иде. Аның кулында каләм, миндә юк. «Әйдә төзәтеп куй инде», – дигәч, – юк, мин төзәтмим, ул җинаятькә батырчылык итмим, үз кулың белән төзәт, әсәрең – синең балаң, син аны үзең тәрбия итергә, үзең киендерергә, чишендерергә тиеш», – ди торган иде.

Бервакыт без шулай укып торганда ишектән Г. Тукай килеп керде.

– Нишләп йөрисең, Тукай, – дидем.

– Ул бала әле, балалар белән кузна уйнап йөри, – диде Ф. Әмирхан. Һәм Тукай, кесәсендән, морҗа артына кузналар бушата башлады. «Нишләп син сакалың сәрйәйтеп кузна уйнап йөрисең?» – дигән сорауга каршы Тукай: «Бала вакытта уйнап булмады, шуның үчен алам», – диде. Шундан соң Ф. Әмирхан белән кузна уйнагандагы эффектларны, ничек аталуларын, бер малайның хәрәмнәвен, моның ата торган чөененең бик удачный икәнен сөйләргә кереште. Ф. Әмирхан иронический көлеп: «Бик зур эш бетердең инде», – диде.

Ул вакыт җоласы буенча ураза һәм корбан бәйрәмнәрендә белгән дуст-иш, гаедтән чыккач, 3 көнгә кадәр бер-берсенә кунак булып бару, йортка кереп чәй эчеп чыгу гадәте бар иде. Шуңар күрә һәркем кулындан килгән дәрәҗәдә өстәл һәм анда ашамнык нигъмәтләр хәзерләү гадәте бар. Вә килгән кунакларны каршы алу гадәте бар иде. Галимҗан Баруди, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең мөдәррисе, күп елларга кадәр, шул мәдрәсәдә укыганда, бәйрәм кунакларын каршы алу өчен Ф. Әмирханны чакыра, 3 көнгә кадәр ул анда, Барудига килгән кунакларны каршы ала һәм сыйлый иде. Чөнки Фатих анда югары катлау арасында булган, тәкәллеф, йола-гадәт һәм алар белән сөйләшү җаен белә иде, шуның белән бергә, безнең күк тартынып, кыюсызланып тормыйча, батыр сөйләшә, шул сыйфаты өчен аны Баруди мулла күп вакытлар, мәҗлес уздырганда үз янында йөртә иде.

Кай елларда икәнен хәтерләмим, «Әлислах» гәзитә рәсми чыга башламас борын подпольный чыгарыла иде. Менә шуның редакциясенә бервакыт жандармлар тарафыннан тентү кереп, анда аның пичәтен, берникадәр кәгазьләрен кулга төшереп, шулар белән бергә Нургали Мамин дигән бер егетне дә кулга алганнар

иде. Бу тентүдән берәүгә дә бер зыян булмады, шулай булса да Ф. Әмирхан бу чорларда качыбрак, өйләренә кайтмыйчарак йөрде.

Ф. Әмирхан бер вакытны «О повешенных семи людях»[1] дигән хикәяне тәрҗемә итеп, аның исемен дә «Асылган йиде кешеләр хикәясе» дип тәрҗемә кылган һәм аны шулай бастырып та чыгарган иде. Шул хикәя чыгуның 3 нче көнендә мин аның белән Яңа Бистәдә, урамда очраштык, сүз шул хикәя турында барды. Мин хикәянең телен яратканлыгымны сөйләдем, шулай да моны бик ашыгып тәрҗемә кылганын отмечать итеп узгач, исеменең дә ялгыш тәрҗемә ителгәнен әйтдем. «Ничек кирәк соң?» – диде. «Татар телендә саф исемендән соң килә торган исемнәр һәрвакыт күплек булып язылмыйча, берлек булып кына языла һәм сөйләнә», – дидем. Монда «йиде» саны үзе күплекне күрсәтә, андан соң килә торган «кеше» дигән исем, күплек булып язылмыйча, берлек булып кына язылырга тиеш һәм дөрест тәрҗемәсе «Асылган йиде кеше хикәясе» дип кенә тәрҗемә ителергә тиеш иде», – дигәч, бераз уйлап торды да: «Ах, черт возьми, промахнул», – диде.

Аның «Хәят» дигән әсәре мәйданга чыккач, тагын шул ук Яңа Бистәдә обсуждение ясадык. «Ничек яратдыңмы, Укмасый?» – дип сорады. Мин тартынмый әйтдем:

– Фатих, – дидем, – мин ул «Хәят» та булган типларны ратмыйм, алар төче типлар, морзалар, урталыкта калган халыклар типлары, аларның беркемгә дә кирәге юк. Каләмең, шиксез матур, ләкин әдәбиятка андый типларны кертмәү кирәк идең. Без аларны укымый, болай күреп тә тук, аларга хезмәт, кәгазь әрәм, дигәч: «Син дә, мин дә ул типларны кертмәсәк, алар «фи нәфсеһи», ягъни чынлап караганда хәятта бар бит, аларны ничек отрицать итәсең, – диде.

– Алар барын бар, ләкин аларның беркем өчен дә кирәге юк, шуңар күрә без аларны юк дип белергә тиеш, – дидем.

– Соң менә үзең дә барлыкларын икърар итәсең бит, – диде.

– Мин әйтсәм дә аларны, сан дип һәм кеше дип түгел, алар хакында хикәя язсам, аларның шул төчелекләре, мин-минлекләре, паразитлыклары турында язар идем, «Хәятта»гы күк кеше итеп саннап язмас идем, болай язсам, минем күңлем, тойгым кыерсытылган булыр иде, – дидем.

---

[1] *Бу Леонид Андреевныкы булырга тиеш (М. Укмасый искәрмәсе).*

– Син революционный фраза кулланырга телисең, сыйнфый күзлек аркылы карарга әйтәсең, – диде. – Соң, Гайфетдинне языйммы инде диде.

– Шуны яз, алыр чын типлар, кирәкле типлар, синең каләмең матур, шул каләм аркылы чыкканда алардан бик матур һәм ялган булмаган типлар мәйданга чыгачаклар, алар үзләрен синең каләмең аркылы укып, җанга азык табачаклар. Синең «Хәят»ыңны синең морзаларың укымыйлар, безгә дә ул төче, Гайфетдинга бөтеннәй җат, шулай булгач, әсәрең укучысыз кала, укысалар да, укучылар нәфрәт белән укыйлар, – дидем.

– Син бик тәнкыйтьче булып киткән әле, ну ярар, кирәк ул, аларны да уртага тартырга кирәк, – диде.

– Бу карашың, Фатих, бөтеннәй ялгыш. Уртага тартмаска кирәк, тартылсалар да, төртеп чыгарырга кирәк, – дидем. – Морза булып азапланма, аларга син дә үз түгел, кеше дә түгел һәм аларга, үзләрендән башка, кеше юк, аларны эткәндән-этәргә, кысарга, кысрыкларга кирәк, – дидем. Шулай итеп, мин бу хакта Фатих белән байтак сөйләштем.

– Алай булса борчылма, менә син әйткән типны язам, – диде.

–Ул кем? – дидем.

– «Фәтхулла хәзрәт», – диде.

– Ул турыда мин хәзергә бер фикер дә әйтә алмыйм, Фатих, – дидем. Ул һаман мин әйткән Гайфетдин түгел, «Фәтхулла хәзрәт», – дидем.

– Ярар, гомер вафа итсә, барын да язарбыз әле, «шагыйрь әфәнде», – диде. Чөнки Фатих сөйләшкәндә кайвакыт шундый чеметтермәле, өсте баллы, асты әче сүзләр куллана торган иде. «Шагыйрь әфәнде» дигән миңа хитабы, шул чеметтермәнең берсе иде. Аның бу чеметтерүенә сәбәптә мин аның «Хәят»ы белән ризалашып бетә алмавым иде.

Фатихка мин күп вакытларда андый «урталыкта» күк типларны язмыйча, халык тибы, дөрест типлар язарга кирәклеген әйтә идем. Ләкин Фатих элек сау вакытында җанып торган ялкынлы йөрәк булу белән бергә паралич суккач, яхшук боекты һәм эш көче дә кимеде. Театр күк гомуми урыннарга барырга уңайсызлана иде. Ләкин уңайсызлануын белдермәскә тырыша иде. Халык белән үз теләгәненчә аралаша алмый, бәлки үз янына килгәннәр белән генә сөйләшә, яки гәзит, журнал күк вакытлы әдәбият аркылы гына халык хәле, аларның рухлары белән таныша иде. Бу чорлар бик

катлаулы һәм үзгәрешле булганга, болай гына танышу Фатихны таныштырып бетерми иде.

Фатих сау вакытында көчле оптимист булса, Столыпин чорындагы көчле реакция аңар нык тәэсир итеп, шуның өстенә саусыз булу боеклыгы аны көчле пессимизмага алып бардылар. Фатих яшь, сау чорларында атеистик караштa булу белән бергә, соңгы чорларда, шул ук сырхау тәэсире булырга кирәк, дини тойгыларга бирелгән һәм ялгызлыкны ярата иде. Фатих белән күп вакытлар булдым, күп сөйләштем, шулай да андан бер вакытта да үзенең сырхавындан зарлану ишетмәдем.

Фатих Чехов һәм Андреев күк соңгы рус язучыларының әсәрләрен укырга ярата, Максим Горький әсәрләрен сөеп укый торган иде. Рус әдәбиятының байлыгына кызыга һәм төрек әдәбиятын да, аның соңгы шагыйрьләрен дә яратып укый иде. Фатихның псевдонимы «Ташмөхәммәт» булып, мин аның мондан башка псевдонимнарын хәтерләмим. Тукайның 3 төрле псевдонимы бар[1] иде. Мин үзем дә 3 төрле псевдоним белән яздым, ләкин Фатихта бер генә булырга кирәк.

Фатих миңа бер вакытны үзенең яшь, сау вакытта алдырган фотокарточкасын бүләк итеп, аның сыртына:

*«Җисмү зарым хакыда пинһан*
*уланча эстәрем.*
*Сурәтем бу рәсем илә калсын*
*җиһанда ядекәр.*
*Шагыйрь Укмасига хатирәм»,*

– дип язып куйган иде. Ләкин мин бу карточканы югалтдым.

Г. Тукайга мәгънән рух бирешүдә Фатихның көчле тәэсире һәм хезмәте байтак. Шунлыктан Тукай да Фатихны ярата, аңар бәһа бирә иде. Бигрәк тә Фатих Тукайга төрекчелектән чыгып, татар телендә язарга һәм шул телне баетырга куша, Тукайның саф татар телендә чыккан шигырьләрен төрекчелек тәэсире астында, корама тел белән язылган шигырьләрендән күп матур икәнен сөйли, һәм кайвакыт Г. Тукайны үпкәләтә дә иде. Г. Тукайның үпкәсе шундан гыйбарәт: ул байтак вакытка кадәр сөйләшми йөри яки исәнләшми чыгып китә, шулай да, бу үпкә бик озакка тартылмый иде. Г. Тукай да, Ф. Әмирхан да Галимҗан Ибраһимовны сөйми

[1] *«Шүрәле», «Гәнкабут» (үрмәкүч), «Касимский» (М. Укмасый искәрмәсе).*

гомер иттеләр, «эгоист», «мимлекле»[1], «скандалчы» дия торганнар иде.

Ф. Әмирханның мин аттестат зрелостига хәзерләнгәнен хәтерлим. «Заочное подготовление к поступление в университет». Аның моңар экономический көче җитмәгәнгә, һәм атасы Зариф мулла аның бу юлын сөймәгәнгә, ул бу хәзерләнүдә аптырау-читенлектә кала, теләге юридический факультетка керү. Атасы аның бу теләге белән күнми, ул шундан соң йортны ташлап чыгып, хәзерге Бауман урамының чатында булган, ул вакыт «Музуров номерасы» аталган номерада бүлмә алып, шул теләген дәвам иттерә.

Аны экономический хәл кыса. Ул анасына кайтып үзенең положениясен сөйли. Ана, хатын булу сыйфаты белән, атага, Зариф муллага тәэсир итә. Зариф мулла соңынтын аның аттестат зрелостига хәзерләнүенә разый булса да, ләкин Фатихка бер тиен ярдәм итмәячәген сөйли. Ана Фатихка ата сүзен сөйли, шундан соң Фатих өйгә кайта һәм ниндидер бер студент мулла йортына килеп, аны русча укытып шул юлга хәзерли башлый. Укыткан өчен студентка акча түләргә кирәк. Ф. Әмирхан моны юллау өчен Камчылы ишан улы Әхәт «күршеләре» һәм шуның белән бергә тагын 5 юлдашын русча укытып, алардан 5 шәр сум, һәр айга 30 сум акча хәзерли, шул акчаны әлеге студентка түли.

Мин сәбәбен белмим, никтер соңынтын Ф. Әмирхан бу теләге эшкә ашмый кала. Аның бу хәзерләнү чоры Хөсәен Ямашев белән бер вакытларда булып һәм һәр икесе дә аттестат зрелостигә юридический факультетка хәзерләнү чорлары булганга, монда, шиксез, Ямашевның тәэсире булган булырга тиеш.

Хәзергедәй хәтеремдә, Ямашев бөтен предмедтән «5» кә экзамен бирә, ләкин соңынтын андан славян, ягъни церковный языктан, «чиркәү телендән» сынау сорый башлыйлар, ул моңар татар булу сыйфаты белән хәзерләнмәгәнгә, провалиться итә. Моны профессорлардан үтенү өчен Алабуга мулласы Закир Хуҗаханов аркылы генерал Занфировка тәэссир иттереп, бу генерал профессорларга мөрәҗәгать итә. Профессор генералга әйтә: «Ул сәяси, «ялгыш юлда», син аның артыннан йөрмә, үзең өчен дә яхшы булмас, бу «губернаторның заданиясе», син үзеңә чокыр казыма», – дип җавап бирә. Занфиров һәм мулла мондан соң туктап калалар. Мин белмим, Фатих өчен дә бәлки шундый тоткарлык чыккан-

[1] *Мимлекле* – мин-минлекле.

дыр. Фатих та, реакция чорларында бу теләгендән туктый, сырхау, боек, өметсез хәлдә әдәбият дөньясында эшләп азаплана.

Ф. Әмирхан сүзгә оста, шуның белән бергә «вак язучы»ларга иронический карашы көчле булганга, аны пролетариат язучылары хөрмәтләмиләр. Ул да аларга түбән карый. «Акчарлаклар»ны яратмый, тозсыз, эчлеге аз, балык тозлаучы марҗаларны чагылдыра, аларның әдәбият белән һичбер бәйләнешләре һәм алар тормышыннан җанга азык юк, ди.

Димәк, Ф. Әмирхан өчен буржуа әдәбиятында гына җанга азык булып, хезмәтчел халык өчен булган әдәбият аның өчен азыксыз, тозсыз, төссез булып чыга. Ф. Әмирхан, һичшиксез, буржуа әдәбияты яклы, шуларны чагылдыручы вә шул әдәбияттан тәм табучы, үзе дә шул сыйныф белән килешә вә аларга үзен сөйдерә белүче «түбән сыйныф» язучыларына түбән карауччы «олуг табигатьле» язучы иде.

Максим Горькиның әсәрләрен яратып укый, ләкин аның сыйныф күрсәтү ягыннан булган характерын яратып түгел, бәлки телнең простой, төзелешенең матур, әсәренең чыгышлы булу ягыннан ярата иде.

М. Укмасый «Забиров»<br>10 март 1940 г. «Бишбалта».

Текстны Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать<br>институты Язма һәм музыкаль мирас үзәге хезмәткәре<br>Айгөл Әхмәтова әзерләде.

## Разия Бәхтиярова истәлеге

*«Әлислах» газетасы мөхәррире Вафа Бәхтияровның тормыш иптәше Разия Бәхтиярованың (Фатиха Аитова мәктәбен тәмамлаган укытучы) Ф. Әмирхан турында хатирәсе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (Ф. 16, 2 тасв., 62 с. б.). Язма 5 биттә, татар телендә, кирилл хәрефләрендә.*

### *Фатих Әмирхан турында кайбер истәлекләр*

Вафа Бәхтияров Саратов губернасы Хвалын өязе Земнича авылында туган. Уку яшенә җитүгә, авыл мәдрәсәсендә укып, башлангыч белем алган.

Аннан соң Казанга килеп, Урал урамы (хәзерге Зайцева) 6 нчы йортта хәзерге мамык фабрикасына каршы булган мәктәптә (Зариф хәзрәт Әмирхани мәктәбендә) 1892–1894 елларда Фатих Әмирхан, Хөсәен Әбүзәров, Вафа Бәхтияровлар бергә укып, аннан мәдрәсәи Мөхәммәдиягә күчеп укыганнар. Фатих мәдрәсәи Мөхәммәдиядә укыган чагында да анда укыла торган дәресләрен бик яхшы билгеләргә укып, мәкафәтләр алып килә торган булган. Ул рус телләрен дә өйрәнергә һәм белергә бик тырышкан.

1904 елның җәендә Самарага (хәзерге Куйбышев) шәһәренә китеп, берничә ай русча укып кайта. Аннан кайткач, Казанда большевик студент Сергей Николаевич Гассардан укырга керешкән һәм кайда гына укыса да, бик тырыш укучы булган.

1905 елгы революциянең йогынтысы астында мәдрәсәи Мөхәммәдиядән 82 шәкерт мәдрәсәне ташлап чыгалар. Болар да шунда катнашалар. Югарыда язылган Урал (Зайцева) урамындагы Фатих Әмирханның атасы Зариф хәзрәт мәдрәсәсенең ишек алдындагы бер катлы йортта Фатих Әмирхан, Вафа Бәхтияров, Габдрахман Мостафин, Фатих Сәйфи, Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә гектографта басылган беренче промакцияләрне Фатих Сәйфи, Габдрахман Мостафин һәм Хөсәен Ямашев тарафыннан тәрҗемә ителеп, Ямашев (хәзерге Меховщиков) урамы 37 нче йорт Дулат Алинең атасы Вахит мөәзин мунчасында бастырып таратканнар.

Хөсәен Ямашевны полиция эзләгәндә еш кына шунда качып кала торган булган.

1907 елның җәендә Фатих Әмирхан Москвадан кайткач, Вафа Бәхтияров белән «Әлислах» газетасы чыгару турында хәзерлек алып баралар. Һәм йөрүләре бушка китми: чыгарырга рөхсәт алып чыгара башлыйлар.

Шул елның август аенда Фатих кинәт каты итеп авырый башлый. Аякларына, кулларына һәм бер күзенә паралич булып больницада яткан. Кулларындагы һәм күзендәге авыру бөтен аяклар белән йөри алмаслык булып кала. Кечкенә арбада гына йөртәләр иде.

Шул хәлдә булса да, алар Вафа Бәхтияров белән һәрвакыт, һәр җирдә бергә булганнар.

1907 елда «Әлислах»та эшләгәндә Бәхтияров Тукайны Казанга чакырып хат язган. Хатны алгач ул Казанга килә. Килүгә ул тиз генә «Әлислах» идарәсенә килә. Шунда Тукай белән Бәхтияров танышалар да, «Әлислах»ның 2 нче номерын алып, берничә минут укыштыргалый да алып торырга рөхсәт сорап, «Мин Болгарның

40 нчы бүлмәсендә торам», – дип чыгып киткән. Бераз вакыт узгач Бәхтияровны чакырта. Бу менгәч, озак вакыт сөйләшеп, аңлашып утырганнан соң Бәхтияров Тукайны Ф. Әмирхан белән таныштырырга өйләренә алып бара. Алар бик озак сөйләшеп утырганнар. Шул күрешүдән соң алар өчәү күп вакыт бергә була торган булганнар.

Бервакытны Тукай белән Бәхтияров Фатихка баргач, Фатихның бүлмәсендәге өстәл өстендә бик матур рамкада гимназия формасында киенеп яланбаш, озын калын чәчен икегә үреп алга салып куйган бик матур, һәркем сокланырлык яшь бер кызның рәсеме куелган булган. Бу рәсем Фатихның атасы белән бертуган Мәрьям Апакованың рәсеме була. Гөлсем Апакова көндез гимназиядә, кич музыка мәктәбендә укучы кыз була. Тукай Фатихка барган саен шул матур кызның рәсеменә күз сала торган һәм рамканы кулына алып озак карап тора торган вакытлары да булгалаган. Ул кыз озак яшәмәде, үлеп китте, дип сөйли иде Бәхтияров.

1921 елда без Яңа Бистәнең Кызыл Татарстан урамындагы (хәзерге мех фабрикасы янында) асты таш, өсте агач йортта мәктәп иде. Бәхтияров шул мәктәптә директор иде. Безнең тормышыбыз шул мәктәпнең чардагында иде.

Менә шул елның җәй башларында көтмәгәндә Әмирхановны, авыру сәбәпле үзе йөри алмагач, үзен карый торган туганы Камил кечкенә арбага утыртып безгә (Бәхтияров янына) алып килде. Күтәреп алып менде. Ул елны авырулар да, үлемнәр дә бик күп була иде. Мин зур температура белән авырып ята идем. Шулай булуга да карамастан, ул ачык йөз белән күңелле итеп минем янга килеп сөйләштерергә һәм көлдерергә тырышып уен-көлке сүзләр сөйләп утырды. Аннан соң Бәхтияров белән күңелле генә итеп озак сөйләшеп утырдылар да шул ук китергән кешесе белән киттеләр.

Ул вакытта хәзерге Мәҗит Гафури урамы 35 нче йортта атасының йортында тора иде. Без шунда да берничә мәртәбә баргаладык. 1923 елларда Большая Красная урамы 46 нчы йортка күчкәч бик зурлап кунак уздыралар. Анда Солтан Габәши һәм Гөлсем Сөләймановалар булалар. Солтан Габәши пианинода уйнады. Гөлсем Сөләйманова бик матур көйләргә җырлады.

Килгән кунаклар да кушылып җырладылар. Анда Галимҗан Шәрәфләр, Гыйльметдин Шәрәфләр һәм башкалар да күп иде.

Мәҗлес бик күңелле үтте. Фатих кешене бик яратучан. Бик ачык чырай белән каршы алучан, киң күңелле кеше иде.

Исерткеч эчемлекләр эчүне яратмый иде. Ул эчү түгел, исереккә бөтенләй каршы кеше иде. Мәҗлесләрдә мәҗлес хөрмәтенә бер-ике генә йотса да, бик җирәнеп кенә эчә торган иде.

Бу истәлекне Галимҗан Ибраһимов институтындагы архивында саклау өчен бүләк иттем.

Разия Бәхтиярова
1982 елда язылды.

## Габделбари Баттал-Таймас истәлеге

*Габделбари Баттал (Габделбари Габдулла улы Сәетбаттал – 1880–1969) – тарихчы, җәмәгать эшлеклесе. Аның 1965 елны «Төрек культуры» журналының март санында Ф. Әмирхан турында истәлеге басыла. Биредә истәлек төрекчәдән татар теленә тәрҗемә ителеп бирелә.*

### *Параличланган хәлдә 10 ел иҗат иткән әдип Фатих Әмирхан (1885–1926)*

*80 еллык юбилее уңаеннан*

10 ел дәвамында параличланган хәлдә иҗат иткән атаклы татар әдибе һәм журналисты Фатих Әмирхан моннан 80 ел элек (1885 нче елда)[1] дөньяга килә. Ул – Казан шәһәренең, нигездә, мөселманнар яшәгән Яңа Бистә мәхәлләсе имамнарыннан Зариф Әмирхан әфәнденең олы улы. Урта белемне Казан шәһәрендәге җәдиди ысуллар нигезендә укытылган һәм алдынгы карашлы дин эшлеклесе Галимҗан Баруди җитәкләгән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ала. Гаиләнең фамилиясе Зариф имамның атасы, ягъни Фатих Әмирханның бабасы Хөсәеннең атасы Әмирхан исеменнән алынган. Казанның бер мәхәлләсендә имам вазыйфаларын башкарган Хөсәен Әмирхан дин гыйлеме өлкәсендә үз чорының алдынгы карашлы кешеләренең берсе саналган, шуның өстәвенә тарих өлкәсендә дә фәнни тикшеренүләр алып барган. 1883 нче елда Казанда аның «Тәварихе Болгария» исемле кечкенә генә бер хезмәте басылып чыккан.

---

[1] *Дөресе: 1886 елның 1 нче гыйнвары.*

Фатих Әмирхан 1905 нче елгы Беренче Рус революциясенә кадәр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган вакытта дин гыйлемен, гарәп әдәбиятын, берникадәр күләмдә дөньяви фәннәрне үзләштерә. Алга таба болар белән генә канәгатьләнмичә, рус теленнән дә шәхси дәресләр алып, аны җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнгәннән соң, рус матбугатын һәм әдәбиятын күзәтеп бара башлый. Бу тырышлыклары нәтиҗәсендә дөньядагы вакыйгалар, иҗтимагый тормыш һәм яңа фикер агымнары турында мәгълүмат туплаган акыллы егет, башка күп кенә яшьләр кебек, Россиядәге халыкларның тормышында яңа өмет чаткылары кабызган революцияне берникадәр дәрәҗәдә әзерлекле килеш каршылый. Шул сәбәпле, Фатих, кайбер иптәшләре белән бергә, мәдрәсә идарәсенә, дәрес программаларына яңа вәзгыятькә җавап бирә алырлык үзгәрешләр кертүне таләп итеп чыгалар, теләкләре кабул ителмәгәч, демонстратив рәвештә мәдрәсәне ташлап чыгалар һәм «Ислах» җәмгыятен коралар.

1906 нчы елның ахырында Кавказ халыкларының атаклы каһарманы Шәех Шамилнең оныгы Заһид Шамил (бәлки хатыны – Казаннан чыккан атаклы сәүдәгәрнең кызы – йогынтысы беләндер) «Тәрбияи-этфаль» исемле балалар газетасы чыгару фикеренә килә һәм тәрҗемәче итеп Фатих Әмирханны чакыра. Газетаның беренче номеры 1906 нчы елның декабрь аенда чыга.

Фатих Әмирханның Мәскәүдә күпме торганын белмибез, әмма аякларына паралич нәтиҗәсендә ул әлеге шәһәрдә булган вакытта хәрәкәтсез калуы мәгълүм[1]. Шуннан соң яшь әдип Казанга кайта һәм, нәрсә генә эшләп караса да, аяклары төзәлми.

Бу казадан соң әдип аякларында туры басып тора алмый башласа да, ни гаҗәп, паралич сугу аның йөрәк һәм ми эшчәнлегенә зыян китерми. Ул коляскага кадакланган хәлдә дә аң эшчәнлегенә сәләтен, киләчәккә ышанычын һәм күңел көрлеген җуймый. Әдип якыннары хәтерендә шушы хәлендә дә тормышының соңгы мизгелләренә кадәр шатлык нуры чәчеп торган кеше буларак сакланып калган. Хәтерем ялгышмаса, мин аның белән 1912 нче елның җәендә Казанга сәфәр кылган вакытта шәһәрнең Суконная дип аталган бистәсендәге йортында күрештем. Бу безнең беренче күрешүебез иде. Шул вакыт-

[1] *Истәлектәге әлеге мәгълүмат язучы авыруы хакындагы фаразларның берсе буларак карала.*

та мин хәрәкәтләнү мөмкинлеген югалткан бу кешедә ниндидер бер рух күтәренкелеге һәм шатлык хисләренең ташып торуына шаккаткан идем.

Фатих Әмирханның мөхәррирлек эшчәнлеге чын мәгънәсендә 1907 нче елда башлана. Мәскәүдән кайтып Казанда төпләнгәч, бераз соңлабрак, ягъни 1907 нче елның октябрендә үзенең кайбер фикердәшләре белән бергә «Әлислах» исемле атналык газета чыгара башлый. Бераз соңлабрак дидек, чөнки бу вакытка, 1907 нче елның 3 нче июнендә оештырылган хөкүмәт түнтәрелешеннән соң, дәүләт башында торган кешеләргә бик үк ошап бетмәгән Икенче чакырылыш Дәүләт Думасы куып таратыла һәм хөкүмәткә җайлы сайлау кануны кабул ителә. Хөкүмәт тарафыннан күрелгән көчле чаралар нәтиҗәсендә революцион хәрәкәт тә сүрелә, реакцион көчләр өстен чыга башлый.

Шул сәбәпле, радикал карашлы яшьләрнең матбугат органы саналган бу газета илдә алып барылган эчке сәясәтне теләгән кадәр каләм очына ала алмаса да, мөселманнарның иҗтимагый тормыштагы артталыгын, искелек һәм схоластика тарафдарларын, аларга терәк булган «могътәбәр» кешеләрне көчле тәнкыйть утына тота. Фатих Әмирхан – газетаның рухын һәм эчтәлеген билгеләүче дә, шул ук вакытта күпчелек мәкаләләрне язучы редактор да. Ул газета битләрендә әдәби һәм иҗтимагый тәнкыйтьче буларак та, сәяси эчтәлекле баш мәкаләләр редакторы һәм сатирик хикәяләр авторы буларак та чыгыш ясый (Моннан газетага мәкалә язган башка яшьләрнең ул кадәр белемле һәм талантлы кешеләр булмаганлыгы аңлашыла).

Фатих Әмирхан язган мәкаләләренең төренә карап, өч төрле псевдоним кулланган: 1) сәяси эчтәлекле мәкаләләрнең астына күп очракта үз исемен куйган (кайбер очракларда бу төр мәкаләләр имзасыз басылганнар); 2) җитди тәнкыйть мәкаләләрен «Дамелла» (Бохара шәкертләре телендә зур мулла) псевдонимы белән имзалаган; 3) сатирик эчтәлекле мәкаләләрендә «Ташмөхәммәд» псевдонимын кулланган.

Әдипнең беренче әсәре – «Гарәфә көн төшемдә» исемле фантастик хикәясе – әлеге псевдоним белән чыга. Язучы бу хикәясендә гарәфә көн күргән төшендәге вакыйгаларны, аерым алганда, милли бәйрәм дәрәҗәсенә күтәрелгән дини бәйрәм белән бәйле шатлыклы чараларны тасвирлый һәм, һичшиксез, ул әлеге уйдырма вакыйгаларның тормышта да чынга ашуын теләгән.

Фатих Әмирханның 1907 нче елда башланган җанлы әдәби эшчәнлеге 1917 нче елга кадәр, ягъни 10 ел дәвам итә. Язучы буларак кулыннан килгәннең барысын да ул нәкъ менә әлеге вакыт аралыгында башкара. Ун ел дәвам иткән «әдәби гомер». «Әлислах»ның тормышы ул кадәр озак булмый.

Газетасы ябылганнан соң Фатих Әмирхан биш ел журналистлык эше белән шөгыльләнми, бу вакыт аралыгында ул җитди һәм сатирик эчтәлекле хикәяләр, пьесалар язу белән мәшгуль була.

Әдипнең бу дәвердә «Хәят», «Кадерле минутлар», «Урталыкта», «Фәтхулла хәзрәт» исемле хикәяләре; «Яшьләр», «Тигезсезләр» һ.б. пьесалары басыла. Әлеге хикәя һәм пьесаларның төп геройлары – киемнәрендә, сүз һәм эшләрендә европалыларга охшарга тырышкан, кайберләре дәүләт мәктәпләрендә белем алган, күбесе исә әдипнең тар даирәсендәге яшь егетләр һәм кызлар. «Фәтхулла хәзрәт», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Салихҗан карый», «Сәмигулла абзый» исемле сатирик хикәяләрендә һәм фельетоннарында исә авторның көлү объекты – иске карашлы хаҗиләр, сәүдәгәрләр һәм кырык тартмачылар. Болар – язучының гаиләсе тирәсендәге танышлары һәм искелек тарафдарларының җыелу урыны булган Печән базары әһелләре. Димәк, Фатыйх Әмирханның әсәрләрендә ике төрле тип кешеләр тасвирлана: иске дәвер кешеләре һәм яңа чор яшьләре.

«Кояш» дәвере. Алдарак Фатих Әмирханның ун еллык әдәби эшчәнлегенең башында журналистлык һәм редакторлык эше белән шөгыльләнүе турында әйтеп киткән идек. Ул әлеге эш белән әдәби эшчәнлегенең соңгы биш елында да шөгыльләнә. 1912 нче елда Казанның атаклы сәүдәгәрләреннән Мөхәммәтҗан, Шәрифҗан һәм Хәсән Кәримовлар, нинди максатлардан икәнлеге билгесез, газета чыгарырга карар кылалар. Ул вакытларда Казанда татар телендә Һади Максуди нәшер иткән «Йолдыз» газетасыннан башка бернинди дә газета чыкмаган. Чөнки 1905 нче ел алып килгән яңалык җилләре тәэсире нәтиҗәсендә бер-бер арты чыга башлаган татар газеталары алга таба барысы да, кайсы сәяси, кайсы икътисади сәбәпләр аркасында ябылып бетәләр, бары тик бер «Йолдыз» газетасы гына торып кала. Яңа газетаның җаваплы мөхәррире итеп Кәримовларның каенагасы Зәкәрия Садретдин, баш мөхәррире итеп Фатих Әмирхан чакырыла. Газетага, бәлки «Йолдыз»ны тулысынча каралту максатыннандыр, «Кояш» исеме бирелә.

Биредә шуны искәртеп үтәргә кирәк: «Әлислах»та эшләгән вакытта Фатих Әмирхан үзен каты тәнкыйтьче һәм аяусыз революционер итеп танытса, «Кояш» газетасы битләрендә ул җитди бер либерал-реформатор буларак чыгыш ясый. Газетага мәкалә язган вакытта ул, бер яктан, хөкүмәт вәкиле саналган Казан губернаторының нәрсә әйтәчәген уйлап эш итәргә, икенче яктан «Кояш» хуҗаларының Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасының хуҗалары Рәмиевләр кебек алдынгы карашлы һәм билгеле бер сәяси юнәлеш тарафдарлары булмауларын да истә тотарга тиеш булгандыр. Шул сәбәпле Фатих Әмирхан сәяси мәкаләләрендә, «Әлислах»тагы кебек, каләменә тулы ирек бирмәгән булса, фельетоннарында да искелек тарафдарлары өстенә агулы укларын элеккеге кебек күп яудырмый. «Әлислах»ның Дамелласы белән Ташмөхәммәде «Кояш» редакциясенә бик еш кермәгәннәр. Кыскасы, сәяси мәкаләләрдә чиктән чыкса, газетаны губернатор яптырачак, ә милли мәсьәләләр күтәрелгән мәкаләләрдә сак булмаса, газета хуҗаларының хәтере калачак. Димәк, хәлләр югары төкерсәм, мыегыма, аска төкерсәм, сакалыма кебегрәк булган...

Минем фикеремчә, газетада Фатих Әмирханнан башка җүнле-башлы бер язучы да булмагандыр. Нәрсәдер өчен җаваплы язучының да каләмен үзе теләгәнчә тибрәтә алмавы шулай билгеле бер әйбер. Әлбәттә, «Кояш» битләрендә атаклы татар шагыйре Г. Тукайның да шигырьләре басылган, ләкин ул сирәк күренеш булган. Шул сәбәпле, яңа газета җәмәгатьчелектә зур уңыш казана һәм «Йолдыз»ны күләгәдә калдыра алмаган. Мин 1913 нче елның җәендә, «Йолдыз» газетасында үз өстемә сәркәтиплек вазыйфасын алган вакытта, «Кояш» газетасы ике ел чыгып килә иде инде. Әлеге ике газета, бер-берсен батырмыйча, 1917 нче елгы Рус революциясенә кадәр яшәп килделәр. 1917 нче елның язында мин «Йолдыз»дан киттем һәм җәй айларында, мәрхүм Фуад Туктар белән бергә, «Корылтай» газетасын чыгара башладык. Әлеге газетаны без большевиклар хакимияте яптырганга кадәр чыгардык. «Йолдыз» һәм «Кояш» газеталары исә большевиклар хакимияткә килү белән япканнарын көтмичә, үзләре чыгудан туктадылар. Шул рәвешле 1906 нчы елда чыга башлаган «Йолдыз» газетасы унбер елдан соң, ә «Кояш» газетасы чыга башлавыннан соң биш ел үткәч, тарих мәйданыннан төшеп калдылар.

Фатих Әмирхан «Кояш» газетасында эшләгән вакытта да «Яшен» һәм «Ялт-йолт» исемле газеталарга кайбер сатирик

мәкаләләр һәм фельетоннар, ә «Аң» журналына әдәби мәкаләләр язган.

Югарыда әйтеп үткәнчә, Фатих Әмирханның «әдәби гомере» 1917 нче елга кадәр ун ел дәвам иткән һәм ул бу вакыт аралыгы үтү белән тәмамланган. Большевиклар хакимияткә килгәннән соң Фаттих Әмирхан Казаннан башка бер җиргә дә китмәгән, качмаган, әмма ул һичбер вакыт советлар режимын кабул итмәгән.

Минем аңлавымча, ул 1922 нче елда Финляндиягә җибәргән хатында тасвирлап язган ачлык һәлакәте вакытында мохтаҗлар файдасына чыгарылган «Икенче Ярдәм Мәҗмуга»сында ачларга ярдәм максатыннан бастырган «Тәгъзия» исемле мәкаләсеннән тыш совет матбугаты битләрендә башка һичбер нәрсә бастырмаган. 20 ел параличланган хәлдә яшәгән атаклы әдип-журналист 1926 нчы елда вафат була.

1922 нче елны Идел буенда куркыныч ачлык котырган вакытта Финляндиядә яшәгән туганнанрыбыз тарафыннан Америка ярдәм оешмасы (АРА) арадашчылыгы белән Казанда яшәгән язучы һәм әдипләргә ашамлыклар тутырылган пакетлар җибәрелә. Алар арасында Фатих Әмирхан да була.

Пакетлар Финляндия имамы һәм мәхәллә җитәкчесе Хуҗа Вәли Әхмәт Хәким исеменнән җибәрелгәнлектән, аларны алган кайбер язучылар аңа рәхмәт хатлары җибәргәннәр. Бу хатларның иң әһәмиятлесе Фатих Әмирханныкы. Ул татар әдәби телендә язылган:

«Мөхтәрәм В.Ә. Хәким әфәнде, бүген 9 нчы мартта сезнең АРА арадашчылыгы белән минем исемемә җибәрелгән бүләкне алдым. Мин шәхсән сезнең белән танышмы, түгелме, белмим. Чөнки АРАның биредәге бүлекчәсендә сезнең тулы исемегезне һәм вазыйфагызны әйтмичә, В.Ә. Хәким дип әйтү белән генә чикләнделәр. Һич көтелмәгән, уйланмаган җирдән һәм һич өметләнмәгән бер вакытта килеп ирешкән бу бүләк мине бик тә сөендерде һәм рухымны күтәрде. Мин яшәгән җирдән еракларда, чит-ят җирләрдә, сине хәтерләгән, синең турында уйлаган дусларыңның булуын белү чыннан да рухны күтәрә. Бу бүген без яшәгән шушы караңгы көннәрдә яктылык бөркүче бер нур кебек күзләрне камаштыра; киләчәккә өмет хисләрен уята; арган, таушалган нервыларга бераз ял итү мөмкинлеге бирә һәм кешенең йөрәген куәтләндерә. Сезнең бүләгегез менә шулай миңа үзе белән бергә әлеге әйберләрне дә алып килде. Туганым, боларның барысы өчен дә сезгә иң самими рәхмәтләремне җиткерәм.

Аеруча ачлык соң дәрәҗәгә җитеп котырган иң авыр айларда килеп җитешкән бу бүләкнең минем өчен зур матди ярдәм булганлыгын һәм күңел тынычлыгы алып килгәнлеген әйтмичә булдыра алмыйм. Мәсьәләнең (ягъни ачлык мәсьәләсенең) чишелеше Татарстанда хәзерге вакытта гаять өметсез бер дәрәҗәдә. Ачлыктан урам уртасында үлеп ятучылар, хәтта кеше суеп итен ашаучылар, кеше мәетен ашаучылар чын мәгънәсендә гадәти хәлләргә әверелделәр.

Шул рәвешле, туганым, мине исегездә тотуыгыз, минем турында уйлавыгыз һәм матди яктан ярдәм иткәнегез өчен тагын бер тапкыр рәхмәт әйтәм.

Ихтирам һәм сәламнәр белән Фатих Әмирхан. 29/3/1922.

Искәрмә: Вакытыгыз мөмкинлек бирсә, миңа бер хат язып, үзегез белән таныштырсагыз, бик шат булыр идем. Ф.Ә.»

Россиядә ачлык бәласенә тарыган кардәшләремезгә «кырмыска кадәр генә» булса да ярдәм итү максаты белән Финляндиядә якташларыбыз тарафыннан 1921 нче елгы Корбан бәйрәме җыенында, мин Финляндиягә килер алдыннан, берникадәр иганә җыелган булса да, ул иганәнең ни рәвешле файдаланылачагы мин Финляндиягә килеп Хельсинкидә урнашкач кына хәл ителде. Аерым алганда, минем тәкъдимем һәм имам В. Әхмәт Хәким әфәндене҅ң хуплавы белән җыелган акчаның бер өлешенә Казанда ачлык бәласеннән газап чиккән фикер һәм каләм ияләренә АРА – Америка ярдәм оешмасы аркылы ашамлык тутырылган пакетлар җибәрү турында карар кабул ителде. Ашамлык пакетлары җибәрелгәннәр арасында Фатих Әмирханнан башка Казан татарларының түбәндәге зыялылары да бар иде: мөхәррир һәм мөгаллим Җамалетдин Вәлиди, мөгаллим Мөхетдин Корбангали, голамәдән мөхәррир һәм фикер иясе Муса Ярулла Бигиев, тарихчы һәм ул дәвердә мөфти Ризаэтдин Фәхретдин, тарихчы Хәсән Гата Габәши, Ислам мәҗлесе әгъзаларыннан Кәшшаф Казый Тәҗемани, тарихчы Һади Атласи, Әстерхан имамы һәм журналист Габдерахман Гомәр, шул ук шәһәрдән мөхәррир Нәҗип Гасрый, Оренбургтан мөхәррир һәм журналист Фатих Кәрими, Самара шәһәре имамы һәм журналист Фатих Мортаза, голамәдән мөдәррис Галимҗан Баруди, Диния мәҗлесе әгъзаларыннан Мөхлисә Буби (болардан Нәҗип Гасрый, Фатих Кәрими, имам Габдерахман Гомәрдән пакетларны алу турында озын яисә кыска җавап хатлары алынды). Бу мәгълүматны бер-ике ел элек Истанбулда басылган бер әсәремдә биргән булсам

да, иҗтимагый эшчәнлек алып баручы һәм тарих белән кызыксынган кеше буларак, биредә дә яңадан әйтеп китүне кирәк дип таптым.

Бу мәкаләне язган вакытта Фатих Әмирханның югарыда телгә алган хатын тагын бер тапкыр күздән кичергәннән соң, хәзер искә алган тәкъдимемнең ни кадәр урынлы булганлыгын һәм шуның белән бик тә саваплы эш башкарганымны уйлап, күңелләрем яктырып китте.

*Истәлек Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Р.Ф. Мирхаев тәрҗемәсендә бирелә.*

## Хәбибрахман Рәфыйков истәлеге

*Казанның Бишбалта бистәсе укытучысы Габдрахман Рәфыйковның улы Хәбибрахман (1897–1972) истәлеге. Истәлекне аның кызы Наилә ханым Рәфыйкова 2016 елның ноябрендә Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә бүләк итте.*

### *Зур әдибебез Фатих Әмирхан турында истәлек*[1]

Фатих абыйның Габдерахман Рәфыйков гаиләсе белән элемтәсе 1899 елда башлана. Фатих абыйның апасы Сәгадәт ханым Бишбалтаның яңа мәчетнең имамы Габдулла мулла Әмирхановта тормышта була.

Үзенең кадерле тутасы – Сәгадәт ханымның еш кына килеп, хәлләрен белеп китәдер иде.

Габдерахман Рәфыйковның иптәше Рабига ханым белән Сәгадәт ханым бик якын дустлар иде.

Габдулла мулла, мәчетнең имамы булуга карамастан, кара фикерле, фанатик мулла түгел иде. Үзенең балаларын урта рус школасында укытты. Аның өендә музыка кораллары – пианино да, мандолина да бар иде. Музыка укытучысы аның өенә килеп, кызы Разияга дәресләр бирә иде.

Ләкин Бишбалтаның мәчеткә йөри торган кешеләрнең күпчелеге надан, бик кара фикерле йөк йөртүчеләр, грузчиклар (крушник дип йөриләр иде), итек, кәвеш тегүчеләр, иске киемнәр сатып йөрүчеләр һәм башкалар иде. Кызының пианинода уйнавын,

---

[1] *Мәктәп дәфтәренең баштагы өлешенә язылган. Тышлыкта «№ 1» диелгән.*

балаларының рус мәктәпләрендә укуларын яратып бетермиләр иде. Мәчеткә йөрүчеләр үзара әйтерләр иде: бу имамга намаз укырга оесаң да, Аллаһ каршысында зур гөнаһлы гына буласың, имансыз булып үләрсең. Кайсылары иске мәчеткә күчтеләр.

Фатих абый Бишбалтага апасы Сәгадәт ханыма килгәндә, Габдерахман Рәфыйков аны кунакка чакырып аладыр иде. Безнең өйдә кояш чыгып – яктырып киткән кебек буладыр иде, әйтерсең, иң якын туганыбыз килгән. Матур көлеп, үзенең яңа язган әсәрләре белән таныштыра иде. Бәйрәмнәрдә Габдерахман Рәфыйков, үзенең Яңа Бистәдә яшәүче туганнарына барганда, иң элек Фатих абыйны һәм аның атасы Зариф хәзрәтне күреп, гаиләсе хәлләрен белеп һәм бәйрәм белән тәбрик итеп, озак утырып чыгадыр иде. Туры килгәндә, башка вакытта да керәдер иде. Габдерахман Рәфыйковның шулай ук иң якын туганы язучы Фатих Халидигә керәдер иде – ул аның җизнәсе булган. Ул Г. Рәфыйковның туганнан-туганы Хәдичә апасының иптәше иде. Шулай ук бергә Учительская школада укыган иптәше, соңыннан Казан университетының медицина факультетын бетергән табиб (врач) Исмәгыйль абзый Усмановка да керәдер иде.

Улы Хәбибрахман да, пароходтан кайткач, Фатих абыйга кереп чыгадыр иде. Сәгадәт ханым 29 яшендә үлеп китте. Фатих абый, апасы булмаса да, килеп, җизнәсе белән балаларының хәлләрен белеп киткәлидер иде. Таза дустлык элемтәсе 1926 елга кадәрле, ягъни зур, хөрмәтле, кадерле, бик якын, сөекле, нурлы йөзле, шат табигатьле Фатих абыебыз мәңгегә күзләрен йомганчыга кадәр дәвам итте.

* * *

[дәвамы][1]

Фатих абый Әмирханның Бишбалта бистәсендәге 2 нче башлангыч рус-татар училищесенең мөгаллиме (учителе) Габдрахман Рәфыйков белән элемтәсе 1900 елда башлана.

Фатих абыйның бертуган апасы Сәгадәт ханым (1911 елда үлә) Бишбалтаның яңа мәчете имамы Габдулла Әмирхановта (фамилияләр бер, әмма туганнар түгел) тормышта була.

Үзенең кадерле тутасы Сәгадәт ханым Бишбалтага тормышка чыкканнан бирле (1899 ел) һәм Фатих абый Бишбалтага килә

[1] *Мәктәп дәфтәренә язылган. Тышлыкка «№ 2» диелгән.*

башлаганнан бирле дустлык элемтәсе 1926 елга кадәр, ягъни ул матур, нурлы күзләрен мәңгегә йомганчы дәвам итә.

---

### *Пароход белән Казаннан Уфага барып әйләнеп кайту*

1917 елның июль аенда Фатих абый минем белән «Сорокин» исемле пассажир йөртә торган пароходта Уфага барып әйләнеп йөреп кайту теләген изһар итте. Мин ул вакытта пароходта капитан ярдәмчесе идем. Фатих абыйга Казан шәһәрендә шул елда рус гимназиясен бетергән Гомәр Ихсанов, Фатыйма, Мөхәммәд, Әхмәд Галиевләр, Гомәр Әмирханов, Әминә Рәфыйкова, Рабига, Габдулла Иштирәковлар кушылдылар.

Пароходта барганда көннәр бик матур иде. Фатих абыйны яшьләр югары палубага менгерәләр иде. Ул, анда штурвал рубкасы янында качалкада йомшак урындыгына утырып, саф һавада ял итеп барды, һәм шунда йоклап та аладыр иде. Ашап-эчеп, бераз каютада йоклап алгач, Фатих абый 2 нче этаж палубасына чыгып, үзенә билгеләнгән качалкага утырып, яшьләр белән гөрләшеп, матур көлешеп сөйләшеп бара, ә Фатих абыйның көлүе бигрәк тә матур иде. Яшьләргә тормышта була торган төрле мәзәк вакыйгаларны сөйли, бөтен кешене үзенең авызына каратадыр иде. Рус пассажирлары да Фатих абый белән сөйләшеп утыруны бик яраталар. Һәркайсы аны күңелле кеше, бик матур сөйли дип һәм бик якты чырайлы, шат табигатьле, мәгълүмате зур әдип дип әйтәләр иде.

Кич белән инде Фатих абыйны капитан штурвальный рубкага чакырадыр иде. Ул анда таң атканчыга кадәр утырадыр. Ләкин күбрәк пассажир палубасында утырадыр иде. Табигатькә соклана, табигатьнең матурлыгына гашыйк иде.

Фатих абый Агыйделгә, табигать матурлыгына бигрәк тә гашыйк булды. Пароход ике яктагы көпчәкләренең калаклары (лопастьлары) белән тып-тын суны ерып, шапылдатып баруын яратадыр иде. Таң атканда, урманлы яр буйларын узганда, сандугачлар сайрыйлар, башка җырлый торган кошлар да матур моңлык бирәләр, тырышып сайрыйлар иде. Аккошлар су өстендә парлап-парлап әнкәле-аталы сөйләшеп йөзәләр, акчарлаклар да пароход артыннан калмыйча, ризык ыргытмаслар микән дип очып баралар, су өстенә төшеп, балык та тотып алалар. Фатих абый әйтер иде: «Табигатьнең мондый матурлыгын күреп бару – минем

өчен иң зур бәхет, зур чистый рәхәт күрәм; моны әллә нинди акчаларга сатып алырлык түгел»[1]. Авылларны узганда сыерлар, бозаулар, сарыклар тавышлары ишетелеп китә иде. Кояш үзе әле күренми, ә күкне ерактан кызартып, урманнар артыннан, караңгылыкны җиңеп, нурларын чәчә башлады. Менә кояш үзе дә күренә, күтәрелә, бөтен табигать гөрелди, йокыдан бөтен җанварлар да уяналар, хәрәкәттә. Кояш бөтенләй чыгып беткәч, Фатих абыйны каютасына кертеп куялар иде. Ул пароход капитаны кебек, төнге вахтада булган кебек, үзе дә әйтер иде: «Хезмәтемне үтәдем, инде ял итәм, туганкайларым, рәхим итегез минем иртәнге чәемә (завтракка)», – дип әйтер иде. Сәгать 9 да, Хәбиб туганкаем, син мине уят инде». Әгәр йокысы туймаса, әйтер иде: «Хәбиб, мин тагын бер станцияга хәтле киттем», (ягъни тагын бер сәгать йоклап алам дигән сүз).

Пассажирлар бик туйдыра башласалар, Фатих абый капитан мостигына, ягъни 3 нче – югары палубага менгерергә үтенер иде. Ул анда үзе генә качалкада утырып, үзе генә журнал яки газета укып утыра һәм, аргач, шунда йоклап та аладыр иде.

Фатих абый Агыйделгә кергәч әйтер иде: «Мондагы табигатькә мин гашыйк, мин сокланып туя алмыйм. Күкрәкләрем җәелеп китте, сулышларым киңәйде, ничек мине, Хәбиб, син чакырдың йөреп кайтырга. Мин исән-сау булсам, ел саен синең белән пароходта күп дусларыбызны өндәп йөрермен, моңганчыга яшәп, су өстендәге сәяхәтнең күңеллелеген, рәхәтен аңлап йөрмәгәнмен».

Уфага килеп җиткәч, Гомәр Әмирханов һәм Әхмәт дустым Галиев, Фатих абыйның үтенүе буенча, үзенең язучы дусларына телефон белән хәбәр бирделәр. Бер сәгать тә үтмәде, 4–5 ат белән язучылар да, газета редакторлары да килеп, Фатих абыйны шәһәргә алып менеп киттеләр, аңар иптәшкә Гомәр Әмирханов (аның атасы Чистай шәһәренең имамы Нәҗип хәзрәт Фатих абыйның атасы Зариф хәзрәт белән бертуган). Русча әйткәнчә, Фатих абый Гомәр – двоюродные братья.

Икенче көнне пароход китәргә ике сәгать калганда, Фатих абыйны дуслары да, танышлары да китереп куйдылар. Утыз-кырыклап кеше төшкәндер. Рус, татар пассажирлары, пароход ко-

---

[1] *Бу җөмлә дәфтәр битенең кырына язылган, әмма төп текстның кайсы урынына кертелүе күрсәтелмәгән; бер үк төстәге кара белән аркылы-торкылы сызылган.*

мандасы гаҗәпкә калдылар, нинди халыкның атаклы язучысы икән дип. Шулай итеп, Уфадан пароход күзгалып китте, капитаныбыз Борис Григорьевич Иванов (Спас шәһәрендә[1] туган), Фатих абыйга зур ихтирам итеп, озатучыларның да күңеле булсын дип, аерылышу салютын өч мәртәбә бирде.

Пароход капитаны Фатих абыйга зур илтифат биреп, аны хәл кадәри пароходта булган рәхәтлек белән файдалануына бик ярдәм итте, аны, мине, Гомәр Әмирхановны да үзенең каютасында буфеттан матур өстәл хәзерләп сыйлады. Фатих абый шул хөрмәткә мәмнүн булып, пароход Нижний Новгородтан әйләнеп килгәч, энесе Гомәр Әмирханов капитан хатынына – Александра Александровнага Фатих абый тарафыннан бүләккә бирелгән, чиккән матур башмак тапшырды.

Фатих абыйны Чистайда туганнары каршы алдылар, пароход бары бер генә сәгать торды, Чаллы пристанендә күп иген төягән аркасында. Казанда Фатих абый минем үземә һәм мине каршы алган әтигә, әниемә бик зур рәхмәт укыды. Минем пароход кузгалмыйча, китмәде. Җегетләр дә, кызлар да, бик рәхмәт әйтеп, мине озатып калдылар.

Шулай итеп, Фатих абый минем пароходта Казаннан Уфага, кирегә Казанга беренче сәяхәттә йөреп кайтты. Мин пароходым белән Казанга килгәч, Фатих абый, хәл сорашып, мине һәм сәламне җибәреп торадыр иде. Әти һәм анакаем әйтерләр иде: «Фатихның шул хәтле күңеле булган, әтиең Яңа Бистәгә барса, аңар кереп чыкканда, һаман шуны гына сөйлидер иде.

Идел ябылды, Бөек Октябрь инкыйлабын мин Түбән Осланда (Нижний Услон) затонда каршы алдым, пароходым шунда кышларга калуы сәбәпле. Тынычлагач, Идел каткач, күп су юлында пароходларда эшләүчеләр Казанга мәйданга килде. Казан гөрләде. Иң зур шатлык – иптәшләр белән кочаклашып, үбешеп чыктык, чамадан тыш зур шатлыклы бәйрәм булды. Хөкүмәт эшчеләреннән, авыл хезмәтче әһелләреннән котлаулар, Ленинның һәм аның соратникларының чыгышлары бөтен Советлар Союзына яңгырады.

Күңелгә кояш тагын да куәтле яктырткан шикелле һәм тагы да җылылыгы арткан кебек булды. Табигать, көлеп, безне куандырган кебек тоелды.

---

[1] *Хәзер Болгар шәһәре.*

Һәр ел саен, Идел ачылыр алдыннан, билгеләнгән пароходым кайсы затонда кышлый, шунда китәдер идем. Ләкин киткәнче, Яңа Бистәгә Фатих абый янына барып, саубуллашып, аны якын туган агам кебек үбеп китәдер идем. Минем шул гадәтемә бик зур рәхмәтләр укып, үзе дә нык итеп кулымны кысып, яңакларымдан үбеп озатадыр иде.

Астраханьнән Казанга килгәч, әтием аркылы аңарга паюсная икра, тәмле осетрина балыгы җибәрәдер идем, ә фруктылар чыккач, аңа авыз иттерәдер идем.

Ул безнең гаиләгә үз туганы кебек карады. Үләр алдыннан, берничә ел элек Фатих абый Жуковский урамында яшәде. Татар театрына барсам, ул әйтер иде: «Төнлә Бишбалтага кайтып йөрмә, миңа кер кунарга» дип. Рәхәтләнеп, аның тәкъдимен кабул итеп аладыр идем. Мине ашатмыйча, ягъни яхшы итеп сыйламыйча, чәй эчертмичә яткырмыйдыр иде. Спектакльнең ничек үткәнен, нинди артистлар уйнаганын сорашадыр иде.

1923 нче елның навигациясендә мине «Год[1] Октябрьской революции» дигән теплоходка билгеләделәр. Ул Нижний Новгород – Астрахань арасында йөридер иде. Фатих абыйга мин әтием аркылы тәкъдим ясадым: кайчан минем белән теплоходымда йөреп кайтыр икән һәм кайсы айда икән. Ул июль аеның актыгында, Нижний Новгородка менгәндә, Казанда утырып, аннан[2] Астраханьгә, һәм кире кайтканда Казанда төшеп калырга, ягъни истирахәт чигәргә вәгъдә кылды.

Июльнең 25 ндә безнең теплоход, Астраханьнән Казанга килеп туктады. Хәйран калдым: пристаньда сөекле әтиемнән, әниемнән башка Фатих абый, профессор Әбүбәкер абзый Терегулов һәм Зыя әфәнде Ваһапов та бар.

Мин инде аларга өч урынлы каюта калдырдым. Теплоход туктагач, Фатих абыйны (күтәреп), шулай ук Әбүбәкер абзыйны да һәм Зыя әфәндене дә 1 нче класстагы зур урынлы каютага урнаштырдык. Әтием белән әнкәем минем каютада өйдән пешереп китергән тәмле ризыклар белән сыйлый башладылар. Ә мин аларны Волга түбәнендә яңа өлгергән яшелчәләр белән сыйладым да, өйгә дә биреп җибәрдем.

---

[1] Год – «17ый» дигәне сызылган.

[2] Аннан – кулъязмада: алдан.

Теплоход икенче свисток биргәч, әтием, әнием (бәгырьләрем) кунакларым белән саубуллашырга менеп киттеләр. Өч свисток биргәндә, Фатих абыйны аңар беркетелгән матрос, палубага күтәреп алып чыгып, качалкага утыртты; Әбүбәкер абзый да, Зыя әфәнде дә, аның янында басып, әтием, әнием белән сөйләшеп алдылар.

Теплоход кузгалып киткәч (мин инде вахтадан бушаган идем), кадерле, хөрмәтле пассажирларым янына кердем. Зыя әфәнде инде рестораннан ужин (кичке аш) хәзерли башлады. Фатих абый: «Йә, Аллаһ, бу саф, тузансыз һаваны иркенләп сулый торган сәгать тә туар икән» – диде. Һәммәсенең рухлары күтәренке, көлешә, гөрләшә башладылар. Зөя тамагына җиткәнче, Тау ягында матур урман, кошлар сайрый; теплоход суны ерып бара. «Нинди генә рәхмәтләр укырга сиңа, Хәбиб туганкаебыз, синең теплоходта, синең белән бару безгә нинди рәхәтлек бит!», – дип, өчесе дә кабатлап-кабатлап әйтерләр иде. Ашап-эчкәч, һәммәсе палубага чыгып утырдылар. Кич бик матур, Козловка пристанен дә уздык. Казан инде күздән югалды. Сәгать 11 дә, кич Чебоксарны да уздык. Мин инде йокларга төшеп киттем, кадерле, хөрмәтле пассажирларым да ял итәргә кереп киттеләр.

Икенче көнне Нижний Новгородка килеп җиткәч, сәгать 2 дә, көндез Фатих абый, Әбүбәкер абзый, извозчик яллап, шәһәр белән танышырга менеп киттеләр. Зыя әфәнде аларны иң зур урам – Свердлов урамында театр янында көтеп, бик яхшы столоваяга кереп ашап-эчеп чыгарга вәгъдә кылды.

Шулай итеп, алар шәһәрнең күп җирләрен, тарихи урыннарын карап, кич сәгать сигезләрдә арып-талып кайтып керделәр. Ләкин шәһәрнең яхшы төзелешен, чисталыгын бик мактадылар. Откостан Иделгә күренешнең матурлыгына гаҗәпкә калганнар. Үзләре гаиләләренә тәмле-тәмле конфетлар, пряниклар алганнар.

Икенче көнне теплоход сәгать 12 дә кузгалып китте, пассажирлар бик күп иде, бер буш урын да каюталарда юк иде. Пассажирлар арасында артистлар да, галимнәр дә, төрле һөнәр әһелләре дә бар иде. Юлда танышып, Фатих абыйның янына рөхсәт сорап утыралар иде, һәм Әбүбәкер абзый белән дә мөзакәрә кылалар иде. Фатих абыйны да, Әбүбәкер абзыйны да бик туйдырмасыннар дип, мин үзем вахтада вакытта рубкага чакыра идем, алар анда диванда (качалкада) утырып, табигатьнең матурлыгына сокланып баралар иде.

Казанга килеп җитеп теплоход туктагач, Фатих абый янына туганнан туган энесе (двоюродный брат) Гомәр Әмирханов, Әбүбәкер абзый ягындан Әминә ханым (аның җәмәгате), Зыя әфәндене кызы Сафия әнисе Нәфисә ханым белән каршы алдылар.

Әз генә вакытка минем әтием дә, әнием дә, хәлләрен белер өчен, беразга кадерле пассажирларым янына менеп төштеләр.

Ике ярым сәгать торгач, теплоход Казаннан 10 көнлек юлга (әйләнеп кайтуы белән) кузгалып китте. Фатих абый Яңа Бистә яныннан пароходта узганда, ничек дип әйтергә, бик моңайды, бераз сөйләшмичәрәк торды. Яңа Бистәнең зиратлары тәэсир иткәндер, ахыры. Фатих абый артыннан, аягы йөрмәгәнгә күрә, Зыя әфәнде Ваһапов йомышларын үтидер иде. Әбүбәкер абзый да ярдәм итәдер иде. Күбрәккә һәр сменадан берәр матросны беркеткән идек. Фатих абзый аларның хезмәтләре өчен тиешле вазифаларын бирде.

Астраханьгә килеп җиткәндә, көннәр бик матур иде. Фатих абый, Әбүбәкер абзый Терегулов һәм Зыя Ваһапов әфәнде – өчесе һәм бер рус пассажиры ике ат яллап, бөтен Астрахань шәһәре белән танышып йөрделәр. Ә кич белән дүртебез дә (минем белән), ике извозчик яллап, Астраханьнең данлыклы бакчасына – «Фонарик»ка киттек. Анда, матур бакчада, ресторанда (балконда) ашапэчеп, биш «кызыл йолдыз»лыны төшереп, тагын да рухны күтәреп, теплоходка сәгать 1 нчедә генә кайттык. Әбүбәкер абзый бакчада вакытта матур музыкага биеп тә алды. Миңа бик кәмит тоелды.

Казанга кадәрле бөтен пассажирлар (Фатих абыйга гына дип әйтергә ярый) зур илтифат кылдылар, аның янында булуны яраталар иде. Һәммә кешедә, пароход командасында да Фатих абый бик матур хатирә калдырды. Үзе төшкәч тә әйтәләр иде: «Нинди матур тәэсир калдырды сезнең сөйкемле, сөекле зур әдибегез – Фатих Әмирхан».

Мин теплоходым белән Казанда торган вакытта, әтием, әниемнән башка туганнар да, танышлар да, үзебездә укыткан вакытта яшәгән Хәсән Туфан да, Һади Такташ та, Каюм Мәһдиев тә (үзенең иптәше белән) һәм Казандагы башка туганнарым да, дустларым да минем белән сәяхәт кылып, ягъни йөреп кайталар иде.

*Текстны басмага ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев әзерләде*

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ ТУРЫНДА ЯҢА ТАБЫЛГАН ЧЫГАНАК: КӘРИМ СӘГЫЙД КӨНДӘЛЕГЕ

Бүген XX гасыр башы татар әдәбияты классиклары иҗатын яңа шартларда өйрәнү, заман ихтыяҗларына бәрабәр рәвештә анализларга омтылыш белән бергә, аларның тормыш юлына мөнәсәбәтле аерым бер фактларны ачыклау, калдырган мирасларын берәмтекләп туплау һәм саклау өлкәсендә дә хәрәкәт сизелерлек артты дияргә мөмкин. Бу әдәбиятыбызның күренекле әдибе, публицисты һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан мирасына бәйле рәвештә дә ачык сизелә. Үз чорында ук язучы һәм галим М. Мәһдиев «Фатих Әмирханның биографиясе – безнең әдәбият тарихында шактый гына “ак таплар” белән чуарланган. Бигрәк тә Ф. Әмирханның совет чоры аз өйрәнелгән. Ул бит әле Октябрь революциясеннән соң да тугыз ел чамасы яшәгән, эшләгән, иҗат иткән» дип билгеләп үткән иде. Соңгы вакытларда Татарстан Республикасы Милли музее фондларында «Хәят» повестенең икенче кисәге – дәвамы барлыгы ачыклану, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһим исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендәге Ф. Әмирхан шәхси фондына яңа материаллар кабул ителү – әнә шул «ак таплар»ны бетерү юнәлешендә башкарылган эшләрдән.

Яңа табылган материаллар арасында Ф. Әмирханның якын дусты, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Кәрим Сәгыйтев (Кәрим Сәгыйд, 1988–1939) язган көндәлек аеруча игътибарга лаек. Аны Санкт-Петербургтагы Европа университетының Россия ислам халыклары тарихы буенча ТАИФ профессурасы профессоры Әлфрид Бустанов табып ала. Бу кульъязма дәфтәр Кәрим Сәгыйднең шәхси архивында сакланып, оныгы, бүген Санкт-Петербургта яшәүче Эльмира Тисенко тарафыннан Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә тапшырылды.

Гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган һәм 65 биттән гыйбарәт әлеге истәлекнең беренче битенә үк Ф. Әмирханның

«авырый башлаган көннәреннән алып, кабергә илтеп күмгәнчәгә чаклы даими рәвештә диярлек янында булдым һәм күземнән үткәннәрнең күбесен ошбу дәфтәргә теркәдем. Истәлек булып сакланырга тиеш», дип язып куелган. Чыннан да, кулъязмада 1926 елның 26 февраленнән алып 12 мартка, ягъни Фатих Әмирхан күмелгән көнгә кадәр, аның авыруына, дәвалануына бәйле фактлар, гомеренең соңгы ике атнасында булып узган вакыйгалар, вафаты, күмелү тарихы тәфсилле һәм тулы бәян ителгән. Шулай ук биредәге язмалардан әдипнең вафатыннан соң аны хөрмәтләп күмү өчен төзелгән комиссияләр эше, аларның утырыш беркетмәләре, татарлар яшәгән төрле төбәкләрдән килгән кайгы уртаклашу телеграммаларының текстлары һәм башка мәгълүматлар белән танышырга мөмкин. Болар барысы бергә шул чорның тарихи атмосферасын, язучының аралашкан даирәсен, татар әдәбияты барышында һәм иҗтимагый-мәдәни тормышында тоткан урынын, 1930 елларда аның иҗатына мөнәсәбәтле фикер-бәяләрнең формалашу алшартларын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Моны көндәлекне язган Кәрим Сәгыйд тә яхшы төшенгән, шуңа Фатих Әмирхан тирәсендә барган һәм үзе дә актив катнашкан вакыйгаларны бөтен нечкәлеге һәм тулылыгы белән киләчәк буыннар өчен теркәп калдырырга омтылган.

Гомумән, истәлек эчтәлекле, бай мәгълүматлы. Биредә чыганак тексты гарәп графикасыннан кирилл хәрефләренә бернинди үзгәртүләрсез һәм тулысынча күчерелеп, автор пунктуациясен саклап, киңкатлам укучыларга беренче тапкыр тәкъдим ителә.

*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров*

## АТАКЛЫ ТАТАР ӘДИБЕ ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ АВЫРУЫ, ҮЛҮЕ, КҮМЕЛҮ МӘРАСИМЕ

**15 февраль – 12 март, 1926 ел**

*Авырый башлаган көнләрендән алыб каберге илтеб күмгәнчәгә чаклы даими рәвешдә диерлек янында булдым һәм күземдән үткәнләрнең күбесен ошбу дәфтәргә теркәдем. Исдәлек булып сакланырга тиеш.*

### [1 бит] Фатих Әмирханның ютәл авыруы

Фатих Әмирхан 1907 нче елның июль ахырларында паралич белән авырган. Шундан ике аягы да йөрергә яраксыз булыб калган. Русиядәге иң атаклы доктор, профессор һәм хирургларның берсе дә анның бу авыруын бетерә алмаганлар. Бары тик шул параличне бот уртасындан югары үткәрмичә туктатканлар гына.

Менә шул аяксыз калуындан башлаб ул үлгәнчәгә чаклы (19 елга якын) бөтенләйгә утырган килеш гомер итде. Урындан урынга күчкәндә үзенең гәүдәсен кешедән күтәртеб йөртде яки үзенең кечкенә арбасына утырыб йөрде. Шул вакытдан бирле яңадан бер кат аякка баса алмады. Шундан бирле ул, вакытлы рәвешдә йөреп кайтуларын алмаганда, бөтен гомерен Казанда үткәрде һәм бөтен эшләрен Казанда эшләде.

19 ел берөзлексез аягына баса алмыйча һаман утырыб яки ятыб кына яшәгән бер организмның таза була алмавы, билгеле, бик табигый бер хәл. Ләкин анның организмасы шушы паралич авыруына чыдаб аяксызлыкны йөкләгән көндән башлаб, акрын-акрын һәртөрле вак-төяк авыруларга каршы чыдамлык күрсәтергә, көрәшергә өйрәнеб киткән, чыныккан. Шуңар күрә, ул аяксыз хәлендә дә, үзенең гомерендә берничә мәртәбә нык-нык авырып алуларына карамасдан (мәсәлән, ул бик каты рәвешдә плеврит белән дә авырган имеш), соңгы елларга чаклы чибәр генә таза булыб килде. Бары тик 1925 нче елның язында гына начарлана төшде. Шул вакытда гына Атарда доктор Әбүбәкер Терегулов ютәл хәстәсе (туберкулез авыруы) **[2 бит]** барлыгын табды һәм анның киңәше буенча Фатих Әмирхан шул 1925 нче ел җәй ахырларында (15 нче августларда) даруланыр өчен Кырымга китде.

## Кырымда һәм андан кайткач

Фатих Әмирхан Казандан Кырымга киткән чагында мин Ялтада идем. Алдан сүз беркетеб куюыбыз буенча ул миңа үзенең 20 нче августда Симферопольдә булачагын телеграм белән хәбәр итде. Бу хәбәр килү белән мин Симферопольгә – Фатих Әмирханны белгән танышларга – аның киләчәген Ялтадан телефон белән әйтдем; ни көнне һәм кайсы поезд белән Симферопольгә төшәчәген, аны каршы алырга кирәклеген сөйләдем. Шуның өстенә Симферопольдә торучы Исмәгыйль Лиманов, Шакир Мөхәммәдияров һәм Кырым мөфтисе Хаҗи Мөслехеддинләргә мәхсус телеграм да бирдем. Үзем шул ук көнләрне Ялтадан Казанга кайтыб китдем һәм мәхсус рәвешдә юлны Симферополь аркылы алдым. Шунда очрашдык. Симферополь укымышлылары аны бик матурлаб каршы алганлар. Якуб һәм Илһамия Богдановичларның фатирына куйганлар. Мин Фатих белән сөйләшергә барганда шунда Кырым укымышлыларындан Озынбашлы белән Чабчакчы һәм югарыда әйткән кешеләр бар иде[1]. Берничә сәгатьләр буенча сөйләшеб утырдык. Фатих аларга бик матурлаб һәм тулы өмидле карашлар белән Татарстан хәлләрен сөйләде һәм Кырым татарларының хәлләрен сорашды. Байтак көлке сүзләр сөйләб бик күңелле хуш мәҗлес ясады.

**[3 бит]** Фатихның кәефе якшы, юлда вагонда уңайлы булганга, янындагы караучы бала[2] җитез һәм якшы карап килгәнгә артык ватылмаган, артык армаган иде. «Кырым миңа бик охшар төсле күренә. Симферопольдән үк һавасы безнең һавага караганда бөтенләй башка икән. Әле җингеләеп китдем» диб кәефләнеб сөйләде. «Монда килеб утыргач тазарыб киткән шикелле булдым, дәрт күтәрелде, абыеңны күрәсеңме ничек пан булыб утыра, без шул инде әфәндем авыруларны Кара диңгезгә ташлап калдырырга ният итдек. Йөзә бирсен әле шунда» диде. Менә бу җөмләләр – аның хәреф-хәреф минем күңелдә калган сүзләре.

Шундан соң Фатихны Ялта тирәсендә якшы бер дачага урынлашдыру турында, шундагы кырымлылар белән бераз сөйләшү

---

[1] *Озынбашлы – Кырымның укымышлы, игътибарлы, нуфузлы яшьләрендән берсе. Ул бу вакыт Кырымнаркомфинның урынбасары иде. Чабчакчы – Кырымның Наркомздравы. Партияле, укымышлы, милләтче. (Автор искәрмәсе).*

[2] *Бу сүзнең карандаш белән астына сызылган. Кулъязманың 2б битендә әлеге баланың исемен ачыклаган язу бар: Зәкәрия Әмирхани.*

булды. Алар Фатихны кадерләб кунак итәргә теләгәнлекләрен һәм Ялта янында Кырым Наркомздравына караган якшы бер санаторияда урынлашдырырга ниятләб торганлыкларын аңлатдылар. Шулай эшләячәкләренә вәгъдә бирделәр. (Фатихны якшы санаторияга урынлашдыруны үтенеб Татарстанның Наркомздравы Мөхәммәдияров Чабчакчкыга мәхсус хат да язган булган икән. Фатих миңа шуны сөйләб «Әлегә монда эшләр әйбәт бара» диде).

Мин Симферопольдә бер генә кич кундым. Фатих ышанычлы кешеләр кулында калды. Минем гаилә белән күрешергә һәм безне озатырга килгән танышлар һәм һәммәсе дә Фатихка кулларындан килгәнчә якшы хезмәт итәргә булдылар.

Фатих Әмирхан Казанга кайткандан соң да бу кешеләргә бик күп рәхмәтләр әйтде. Чөнки аны анда үзләренең вәгъдәләре буенча башда бик әйбәтләб кунак иткәнләр һәм Ялта янындагы «Гастрия» диелгән иң матур бер татар санаториясына куеб, Кырымның татар докторларындан **[4 бит]** Габделгаффар дигән бер доктор карамагына табшырганлар. Шулай итеб ул шушы санаторияда ике айдан артыграк торыб, даруланыб, 13 нче ноябрьләрдә Казанга әйләнеб кайтды. Бу вакыт аның үпкәләрендәге туберкулезасы (ютәле) үзенең әйтүенә караганда якшы ук төзәлгән, тәскә-биткә дә чибәр ук тазарган, кәефе дә нык кына күтәрелгән иде. Тәмәке тартуын бик сирәкләндергәнгә йөткерүе дә бик азайган иде.

Казанга кайткандан соң ул шушы Кырымга баруының уңышлы чыкканлыгы хосусый утырышларда һәрвакыт шатланыб сөйли, үзенең шушы торган урынын һәм санаториясын «Кырымның иң шәб җире» диб, шулай ук үзен караган докторны һәрвакыт мактый, киләчәк җәйдә дә шунда барачакмын диб әйтә торган иде. Ләкин аңарга Кырымдан кайткан чагында юлда тугры килгән бер уңайсызлык яңадан Кырымга барырга комачаулык итде. Шуның аркасында башка төрле авыруларга таб булыб шулардан терелә алмады. Мәсьәлә моннан гыйбарәт:

Аңарга Кырымдан кайткан чагында Мәскәү вокзалында бик озак (унбер сәгать чамасы) һичбер ял итмичә бер тоташдан утырыб Казан поездын көтеб торырга тугры килгән. Менә шушы аның биленә зур авырлык китергән. Һәм шуның аркасында аның элекдән булыб да тәмам төзәлүгә авышкан бил кимерчәге туберкулезасы кузгалган иде. Шул сәбәбле ул Казанга кайткандан соң бөтенләйгә диерлек утырыб тормады, тора алмады, һаман ятыб үткәрде (бары тик бер генә табкыр «Сания» операсына барыб шунда гына

утырыб торды). Менә шушы рәвешдә һаман ятыб тору аны тагын да ябыкдырды. Кырымда төзәлә башлаган туберкулезен яңадан кузгатды. Ләкин шулай да аның әле җәй башларына чаклы **[5 бит]** бик иркен Казанда торырлык хәле бар һәм яңадан Кырымга барып даруланганда тагын сәламәтләнүенә дә өмид бик зур иде. Үзе дә «Март җитеб көнләр йылына башлагач клиникага кереб билемне төзетеб чыгармын да Кырымга китәрмен» диб тора иде. Ләкин бөек бәхетсезлеккә каршы эш уйланганча булмады. Көтелмәгән икенче төрле авырулар белән кискәнәтдән[1] авырыб китде.

### Үлем авыруының башлануы

Фатихның үлем авыруы 1926 нчы ел 15–16 нчы февральләрдә башланган. Хәлсезлек, дәрмансызлык сәбәбле кичләрен тирли торган булганга күрә битен һәм тәнен юеш чүпрәк белән сөртеб алгалаган[2]. Шул вакыт аңарга суык тигән, яңадан тирләгән, яңадан сөртенгән. Шуның нәтиҗәсендә иртәгәләрен үк кызыша башлаган, температурасы күтәрелгән. Ләкин үзе моңарга игътибар итмәскә тырышкан. Гадәти инфлюэнция[3] диб кенә караган. Шуңар күрә доктор да чакыртмаган. Янындагы кардәшләрендән Разия һәм Гомәр Әмирханлар доктор чакырыйк диб кат-кат әйтеб карасалар да, ул боларга: «Андый инфлюэнцияләрне генә күб күрдек инде без, аны гына җиңәрлек хәлебез бар әле» диб үзенең авыруына һаман әһәмият бирмәскә тырышкан. Аның вакыт-вакыт температурасы күтәрелгәләб тору элекдән килгән бер гадәт булганга күрә кардәшләре дә доктор чакыру турында аны артык көчләмәгәнләр. Инфлюэнция үтмәгән. 25 нче февральдә тагын да кәефсезләнә төшкән. Шуңар күрә кардәшләре, үзен һәрвакыт **[6 бит]** карый торган Петр Васильевич Дезидериев дигән докторны чакыртканлар. Доктор Фатихда 16 нчы февральдән бирле үпкә шеше авыруы (воспаление легких[4]) башланган диб табкан һәм даруларга керешкән. 26 нчы февральгә чаклы Фатихның янында бары тик кардәшләре генә (Гомәр, Разия Әмирханлар һәм кода-

---

[1] Кискәнәтдән – көтмәгәндә.

[2] *Кырымга киткәнче башлаган һәм кайткач да дәвам кыла килгән спирт яки одеклонлы салкынча су белән иртә-кич сөртенә торган гадәте бар иде. Бик күб вак авырулардан шушы «обтирание» бөтенләй хилас (?) кыла диб тирги башлагач да ташламады. (Автор искәрмәсе).*

[3] Инфлюэнция – грипп.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

гыйсы Газизә абыстай Яушева гына) булганлар. 25 нче февральдә җизнәсе Габдулла мулла Әмирхани да килгән. Ләкин 26 нчы февральгә аның бу авыруын дустлары да, мөхлислары[1] да, якын танышлары да һичберәүсе дә белмәгәнләр. Яллар буенча бөтен төнләрен Фатихның өендә преферанс уйнаб үткәргән һәм шуның белән Фатихның хәятендә әллә ничаклы гайре табигый хәлләргә сәбәб булган кешеләрдән берәүсе дә килеб чыкмаганлар.

Мин үзем дә аның авырганлыгын шушы 26 нчы февральдә кодагый Газизә абыстай Яушеваны урамда очратыб сорашкач белдем. Ләкин ул миңа: «Фатих абыегыз бераз кәефсезләнеб ята әле» диб кенә әйтде. Шул көнне Ибраһим Бикколны очратыб аңарга: «Фатих абый кәефсез ята икән, нигә бер дә бармыйсың, хәлен белергә кирәк» дип әйтдем. Шул вакыт без аның белән бүген кич Фатих абый янына керергә вәгъдәләшдек. Ләкин мин аның болай ук авыр хәлдә икәнлеген белми идем. Шуңар күрә мин аңарга ашау-эчү бүләкләре алыб кердем. Миндән алда гына Ибраһим Биккол да килгән иде[2]. Бу вакыт Фатихның янында: җизнәсе Габдулла мулла Әмирхани белән кодагый Яушева һәм Разиялар бар иде. Соңындан Гомәр Әмирхан белән Фатима Апаковалар килделәр. Андан соң фельдшер Габдерахман Моратов чакырылды. Фельдшер тиз килде.

Кичә 25 нче февральдә Фатихның авыруы нык кына көчәеб температурасы **[7 бит]** 39 га күтәрелгән булган. Шул сәбәбле доктор Дезидериев иң зарур чараларны күреб шул фельдшерицаны чакырырга кушыб киткән һәм аңарга Фатихка банкалар салырга, камфаралар җибәрергә кушкан булган.

Бүген (26 нчы февраль, җомга көн) инде аның хәле тагын да авырая төшкән, температурасы 39,5 кә җиткән иде.

---

[1] Мөхлислары – якын дуслары.

[2] *Кулъязманың 5 б битендә карандаш белән түбәндәге текст бирелгән: «Фатих белән Биккол арасында шул рәвешдә сөйләшү булган:*

*Ибрай: Нихәл, Фатих?*

*Фатих: Менә каяндыр воспаления лёхки килеб чыкды. Үләргә булгач бер сәбәб кирәк бит, воспаленияме, бүтәнме? Үләсе булгач түшәкдә ятыб да берсен табасың инде аның. (Шундан бераз тынычлангач янә): Ни хәбәрләр бар, матбугат юбилейсы нишли? Анда тагын кемне сүгәргә хәзерләнәләр. Анда тагын минедер инде.*

*Матбугат юбилейсы тиз түгел әле, ул турыда хәбәрләр юк диб тынычландырдым».*

Безгә Фатих белән сөйләшеб утырырга мөмкин булмады. Бары тик йөзенә караб, берничә сүз белән юатыб кына икенче бүлмәгә чыкдык та, иң ашыгыч чаралар күрү киңәшенә керешдек. Габдулла мулла белән Гомәрне безгә хәбәр бирмәгәнлекләре өчен бераз орышыб алдык. Катгый рәвешдә иң ашыгыч чаралар күрергә, яңыз Дезидериев белән генә кәнәгатьләтмичә Казанның иң якшы профессорларын чакырыб ничек кенә булса да шушы авыруындан алып калу дәртен күрергә кисеб тәклиф[1] итдек. Бүген мәшһүр Казан математигы Лобачевскийның йөз еллык юбилее бәйрәме булганга күрә, профессорларны өйләрендән табу бик читен, чөнки һәммәсе дә диярлек шул эш артындан йөриләр иде. Шунда да без үзебезнең эшебезгә керешдек. Ибраһим Биккол Әбүбәкер Терегуловка китде. Аны өендә очрату яки очратмавындан миңа телефон бирергә булды. Мин икенче докторларны эзләргә китдем. Өйгә кереб Фатих Мөхәммәдияровка телефон белән «Үзеңнең Наркомздрав карамагындагы иң якшы профессорларыңдан берәресен шушы сәгатьдүк Фатих Әмирханга җибәрә күр, ул хәзер үпкә шеше белән бик авыр хәлдә ята, ничек булса да үлемдән алыб калырга кирәк» диб әйтдем. Аннары Мөхәммәдияровның **[8 бит]** киңәше буенча әлеге Лобачевскийның юбилейсе була торган фән ияләре клубына китдем. Анда әле берәү дә килеб җитмәгән, бары тик бер генә доктор бар иде. Ул миңа эчке авыруларны карауда мәшһүр булган доктор Якимовны күрсәтде. Аңарга бардым. Өендә очрамады. Шуңар күрә Наркомздрав Мөхәммәдияров исемендән сөйләб: «Татарларның зур әдибе Әмирхан авыр хәлдә ята, кайткач да шунда килсен» диб кушыб калдырдым. Анардан кайткач яңадан Мөхәммәдияровдан профессор сорадым. Ул озакламыйча берничә доктор җибәрергә вәгъдә итде. Бер сәгать чамасы үткәч Ибраһим Биккол белән безнең артдан озак та тормадылар: 1) Терегулов, 2) Якимов, 3) Шварцман дигән докторлар килделәр. Шулар өстенә авыруны ничек табканлыгын, ничек дарулаганлыгын сөйләтер өчен доктор Дезидериевне дә чакыртдык. Шул вакыт Гыйльми һәм Рәхимә Шәрәфләр хәл белә килделәр.

Докторлар җыйнаулашыб карадылар. Фатихның хәле авыр булса да, кәефе якшы иде. Шуңар күрә ул докторлар белән ачык

---

[1] Тәклиф – көчләп кушу, боеру.

сөйләшде. Миңа: «Кәрим, син ник болай дөнья кубтарыб йөрисең? Минем хәлем алай ук куркынычлы авыр түгел ич әле. Кешеләрне борчымаска кирәк иде. Синең шул медицина булыр инде» диде. Шуңар каршы Әбүбәкер Терегулов: «Фатих, бер дә борчылма, без сине карарга тиеш. Авыруың куркынычлы түгел шул. Үпкә шеше авыруы гына нәрсә булган ул. Аны гына төзәтә алырбыз әле», диде.

Фатих (медицинага бөтенләй үк ышаныб бетмәгәнлеген аңлатыб): **[9 бит]** «Караб карыйк инде» диде. Моңарга Әбүбәкер: «Юк, Фатих, мин бит сине бер тапкыр плевритләрдән алыб калган идем. Ул чагында да шулай әйткән идең дә, однако төзәлгән идең» диб илзам[1] кылды.

Докторлар авыруны бик ныклаб тикшергәндән соң, күрше зал бүлмәсенә чыгыб һәм яңыз үзләре генә калыб бер сәгать чамасы киңәшделәр. Нәтиҗәсендә һәммәсе дә бер төсле фикергә килгәнлекләрен безне чакырыб әйтделәр. Дезидериевнең дарулау тәртибен дөрест диб табтылар һәм мондан соң даими рәвешдә йөрүне аңарга табшырдылар. Һәммәсенең имзалары белән берничә төрле рецептлар яздылар. Шварцманга иртәгә Наркомздрав белән аңлашыб, Казанның иң яхшы профессорларындан консилиум ясату эшен табшырдылар.

Докторлар киткәндән соң Фатих абый миңа янәдән: «Кәрим, син нигә анда докторларны ду китереб, дөнья кубтарыб йөрисең? Синең медицинага бик исең китә шул. Караб карыйк инде нишләрләр икән докторларың! Карасыннар! Төзәтергә, терелетергә кулларындан килсә, моны эшләсеннәр. Әгәр дә булдыра алмасалар, медицинага төкерегез[2]. Әле бит моның расходлары да бардыр. Булмаса мин сиңа акча биреб куим әле» диде. Мин: «Фатих абый, анысы өчен кайгырма әле. Аны үзебез карарбыз. Безгә синең сәламәтләнүең генә кирәк» дидем. Ул «Алай булса Кәрим миндән сиңа йөз сумга чаклы расход тотарга рөхсәт, соңындан исәбләшербез» диде.

**[10 бит]** Докторлар киткәндән соң Ибраһим Биккол һәм Гомәр Әмирхан белән өчәүләб Фатих абыйны карар өчен үзебезгә һәм аның башка якыннарына, дустларына кизү төзедек. Бүген төнлә

---

[1] Илзам – бәхәстә җиңеп чыгу.

[2] *Бу сүзләрне ул берничә көнләр үткәч янында булган башка кешеләргә дә кат-кат әйтә башлады. (Автор искәрмәсе).*

саклауны фельдшер Габдерахман Моратов белән Габдулла мулла Әмирхан икәүсе үз өстләренә алдылар һәм шулай итделәр.

**Фатихны карар өчен төзелгән кизүлек**

Монда күрсәтелгән кешеләр һәммәсе дә кизүдә тордылар. Бары тик көнләрдә һәм алмашынуларда гына үзгәрешләр булды.

| | |
|---|---|
| Февраль 26 җомга төнлә белән | Габдерахман Моратов, Габдулла мулла Әмирхани |
| 27 шинбә көндез | Гомәр Әмирхан, Ибраһим Биккол |
| төнлә | Кәрим Сәгыйд, Габдерахман Моратов |
| 28 якшәнбе көндез | Гомәр, Биккол, Кәрим Сәгыйд |
| төнлә | Һарун Максудов, Садри Җәлал |
| 1 март дүшәнбе көндез | Гомәр Әмирхан, Хәсән Исхаков |
| төнлә | Бәдри Максудов, Вафа Бәхтияров |
| 2 сишәнбе көндез | Гомәр Әмирхан, Кәрим Сәгыйд |
| төнлә | Фатима Максудова, Кадыйр Хуҗаев |
| 3 чәршәнбе көндез | Гомәр Әмирхан, Хәсән Иҗаков, Кәрим Сәгыйд |
| төнлә | Габдерахман Моратов, М. Гали. |
| 4 кече атна көндез | Гомәр, Гәрәй Хәсәни |
| төнлә | Нәфисә Ваһапова, Разия Әмирхан |

**[11 бит]**

| | |
|---|---|
| Март 5 җомга көндез | Гомәр, Зыя Ваһапов |
| төнлә | Салих Корбангалиев, Сафа Хафизов. |
| 6 шинбә көндез | Гомәр, Биккол |
| төнлә | Сара Касыймова, Рәүф Шахмәмитов, Шиһаб Әхмеров |
| 7 якшәнбе көндез | Кәрим Сәгыйд, Ибраһим Биккол |
| төнлә | Рәбига Дивиниева, Габдерахман Моратов, Габдулла мулла һәм Каюм Мостакай |
| 8 дүшәнбе көндез | Гомәр, Биккол, кичен Кәрим Сәгыйд |
| төнлә | Фәйзуллин, Рәхимә Мөхтиева, Габдулла мулла |
| 9 сишәнбе иртә белән | Габдулла мулла, Кәрим Сәгыйд. |

27 нче февральдә кичә бирелгән карар буенча Казанның иң атаклы профессор һәм докторларыннан консилиум ясалды. Монда: 1) профессор Лурия, 2) профессор Зимницки, 3) доктор Терегулов, 4) доктор Шварцман һәм 5) Наркомздрав Фатих Мөхәммәдияровлар булдылар. Болар Фатихның хәле бик авыр; үпкә һәм бил туберкулезалары да, шулар өстенә пешеккән үпкә шеше – катаральное воспаление легких[1] авыруы да тагын да көчәя төшкән, ләкин шулай да әле терелүе өмидсез түгел – небезнадежно диделәр һәм медицинаның иң соңгы чараларыннан дарулар, киңәшләр бирделәр.

**[12 бит]** Шушы сәгатдән башлаб Фатихны карау, аны дарулау һәм һәрбер кирәкләре өчен хәзер торулар һәр якдан мөкәммәл[2] рәвешдә җитешдерелде. Доктор Дезидериев һәр көн ике килә. Кирәк булыб чакырылса төнлә дә килә. Башка докторлар да әледән әле хәл белә торалар. Шәфкать туташы яки фельдшер һәрвакыт бар. Яшь татар врачлары үзләре теләб төнләрен кизү торалар. Шуның өстенә якын дустларыннан, мөхлисләрендән һәм гомумән укымышлылардан билгеләнгән югарыгы җәдвәлдәге[3] кешеләр алмаш-тилмәш кизүләб көнләрен-төнләрен берөзлексез саклыйлар, саклыйбыз. Доктор биреб киткән тәгълимат дикъкать белән сәгатендә, минутында үтәлеб тора.

**Яшь татар врачларының үзләре куйган кизүләре**

| | |
|---|---|
| 28 февраль | Һарун Максудов |
| 1 март | Бәдри Максудов |
| 2 март | Фатима Максудова |
| 3 март | Сара Касыймова |
| 4 март | Рабига Дивиева |
| 5 март | Рәхимә Мөхтиева |
| 6 март | Рәүф Шахмәмитов |
| 7 март | Салих Корбангалиев |
| 8 март | Фәйзуллин |
| 9 март | Барый Биккинин. |

Бу тәртиб шушы көенчә үтәлмәсә дә, болар һәммәсе дә килделәр һәм кизү торыб Фатих Әмирханны карадылар, сакладылар.

**[13 бит]** Шушы 27 нче февральдә шинбә көн кич белән безнең чакыруыбыз буенча Фатихның якын дустларыннан һәм аны

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Мөкәммәл – камил.
[3] Җәдвәлдәге – исемлектәге.

ихтирам итүче укымышлылардан Кәрим Сәгыйд фатирында кечкенә генә бер җыелыш ясалды. Чакырылган кешеләрдән: 1) Фатих Мөхәммәдияров, 2) Ибраһим Биккол, 3) Кәрим Сәгыйд, 4) Гыйльми Шәрәф, 5) Гомәр Бикбулатов, 6) Ибраһим Аитов, 7) Шиһаб Әхмирев, 8) Гомәр Әмирхан, 9) Бениамин Әхтәмов һәм 10) Хәсән Исхаковлар хәзер булдылар.

Куелган мәсьәләләр: 1) Фатих Әмирханны якшылаб тәрбияләү, дарулау өчен бер үзәк төзү. 2) Терелгәндән соң Кырымга җибәрү чарасын күрү.

Беренче мәсьәлә тикшерелгәндә Фатих Мөхәммәдияровдан авыруның дәрәҗәсе һәм терелү өмиде барлыгы турында сорашкандан соң һәрбер йомышларны үтәб бару, шулай ук информация өчен үзәк итдерелеб өчле комиссия төзелде. Болар: 1) Фатих Мөхәммәдияров, 2) Ибраһим Биккол, 3) Кәрим Сәгыйдләр булдылар. Шулар арасындан Кәрим Сәгыйдкә авыру өчен кирәк булачак расходларны тоту эше йөкләтелде.

Икенче мәсьәләдә Фатихның материальный яклары тикшерелгәч, терелгәндән соң Кырымга җибәрергә булыр, әгәр дә үлеб китсә дәфенләре[1] өчен тотылыр диб иң азында биш йөз сум акча җыярга карар бирелде һәм бу акчаны Печән базары сәүдәгәрләреннән җыймыйча яңыз Фатихны якын күргән берничә кешеләрдән генә алырга карар ителде. Шуның өстенә әгәр дә партиясез укымышлылар үзләре теләб бирсәләр алардан да биргәнләре чаклы **[14 бит]** алынырга булынды. Бу эш Гыйльми Шәрәф, Шиһаб Әхмирев һәм Ибраһим Аитевләргә табшырылды. Утырышдан соң Биккол, Әхмирев һәм мин өчәүләб Фатихның хәлен белергә кердек. Башкалар кайтыб китделәр. Мин фельдшер Габдерахман Моратов белән икәүләб төн буенча сакларга калдым.

Төнлә Фатихның хәле җиңеләймәде. Ләкин кәефе ачык булды. Бары тик йоклый алмавындан гына зарланды. Шушы төнне ул миңа: «Кәрим син ник төнлә белән монда йөрисең? Әллә синең мине карый торган чиратыңмы? Әле сез шулай организоваться[2] итеб алыб мине чиратлаб керешдегезмени? Минем тик шул фактны белеб торасым һәм шуны констатировать итәсем генә килә» диде. Мин моңар каршы аңарга дару эчердем. Шуның белән сүз озаймады. Ул да бераз тынычланыб калды.

---

[1] Дәфенләре – күмүләре.

[2] Организоваться – оешып.

28 февраль бер килеш үтде. Кизү, куелган килеш барды. 1, 2, 3 нче март көнләре дә бер килеш үтделәр. Кизү торулар, дарулаулар, караулар мөкәммәл рәвешдә барды. Авыруның хәле көндән-көн якшырды. Ул инде хәзер бары тик камфара җибәргән урынларның авыртуындан гына зарлана башлады. Докторлар үпкә шеше авыруының төзәлә башлавындан хәбәр бирделәр. Шуңар күрә камфара җибәрүне дә азайтдылар. Хәтта «Фатих котылды» дигән шадлыклы өмид һәркемдә ныгый башлады. Шуңар күрә аны апрель башларындан калдырмыйча Кырымга җибәрү мәсьәләсе безнең арада бик нык сөйләнеб шуңарга планлар корылды. Ләкин 4 нче мартка каршы төнлә белән Фатихның хәле көтелмәгәндән янә начарланыб китде.

**[15 бит]** Бу төнне кизүдә торучы Нәфисә Ваһапова төнге сәгать 3 дә миңа килеб кереб: «Кәрим, нишлик инде? Фатихның сидеге тукталды, тышка чыга алмый. Үлеб китмәсә ярар иде диб куркабыз» диб бер сөаль[1] куйды. Бик кыска гына уйлашкандан соң телефон белән «ашыгыч тыйбби ярдәм станция»сендән бер врач чакырдык. Шуның өстенә Дезидериевне алырга китделәр. Ярты сәгатьдән соң һәммәсе дә авыру янына килделәр. Катетер куеб карадылар. Ләкин сидек чыкмады. Доктор, нервлар авыруы башланган һәм шуның беренче бәрелүе сидек юлына тугъры килгән диб табды. Яңадан консилиум ясаб нервлар авыруын карарга кирәк булачак, иртәгә шуны җыярбыз диб берничә киңәшләр биреб кайтыб китде.

4 нче март иртә белән сидек юлларында, почкада[2] авыру юклыгы мәгълүм булды. Шул көндүк яңадан консилиум ясалды. Бусында Фатих Мөхәммәдияров, Терегулов, Дезидериев, доктор Варашилов һәм Зимницкийлар катнашдылар. Болар: «Үпкә шеше авыруы тәмам бетеб бара икән дә, ләкин туберкулеза палочкалары фронтны кисеб чыгыб карынга, эчәкләргә һөҗүм иткәнләр. Шул сәбәбле эчәк һәм карын шеше (воспаление брюш. кишки[3]) авырулары килеб чыккан. Бусы инде теге авыруларына караганда бик күб куркынычлы» диделәр. Терелү өмиде барлыгын әйтмәделәр.

Шунда да әле Фатих, бу зур куркынычлы авыру белән дә нык-лаб көрәшергә, медицина биргән кораллар белән авыруына каршы бик ныклаб сугышырга керешде.

[1] Сөаль – сорау.

[2] Почкада – бөердә.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

**[16 бит]** Никадәр авыр азабланса да, һәммәсен дә эчендән тына, йөзенә чыгармый, кәефен һаман да якшы күрсәтә иде. Камфара, морфий кебек дарулар җибәргәндән соң берәр сәгать чамасы мәлҗерәб ятыб, андары кәефе ачылгач ара-тирә үткен сүзләр яки кыска гына мәзәкләр әйтеб сала иде. Үзен кадерләб караганга бик шадлана, үлемдән һичбер курыкмыйча аны көлә-көлә каршы алырга хәзер булуы белән бергә «Инде якшылаб карагач тереләм» диб өмид итә иде. Шушы көннәрдә ул: «Татарстанның мәгариф һәм матбугат эшләрендәге егетләре мине татар театрының 20 еллык юбилейсы булган көндә, күңел хатирәсе өчен генә дә бер кисәк кәгазь җибәреб чакырмаганлар да, хәтта шуның танта[на]лы мәҗелесендә мине һәм татар театрының нигезен салучы, аны гражданлык хокукын алырлык дәрәҗәгә күтәрүче Габдулла Кариевне сүккәнләр иде. Моны миңа “Таз” эшләде. Ләкин менә хәзер минем авыру чагымда миңа никадәр докторлар киләләр. Һәммәсе дә мине юаталар. Бу хезмәтне коммунистлар түгел, минем дустларым гына эшлиләр. Әгәр дә Наркомздравда Фатих Мөхәммәдияров булмыйча, анда да бер коммунист утырса, бу докторлар да, бу дарулар да килмәсләр иде» диб сөйләде.

Кизүдә торучы яшь врач Рәбига Дивиевага минем алдымда: «Әгәр дә миңа мондан егерме еллар элек син татарның зур мөхәррире булырсың, кулында реальный көч булган бер партия синең кешелек кадереңне төшереб изәргә тырышса да, каты авырган чагыңда сине олуглаб бик күб татар партиясез врачлары кизү торыб карарлар диб әйтсәләр, бу хәлнең булуына һичбер ышана алмас идем. Ләкин Ходай миңа шуны күрергә насыйб итде. Менә күрәсеңме Рәбига татарның хәяте нинди уңышлы **[17 бит]** производительно[1] бара. Шуны уйлагач ирексез терелəсем килә» диде. Шуны сөйләгәч мәлҗерәб арыб китде.

Докторлар Фатихның терелəчәген өмидсез күрсәткәч, мин, Биккол, Нуркин өчәүләб минем өйдә утырыб, үлә калса ничек итдереб күмү турыларында киңәшдек. Олуглаб ихтирам белән күмү планнарын, тәртибләрен чамалаб карадык. Күмү комиссияләре проектын төзедек. Аңарга дуст, якын таныш һәм мөхлис булган интеллегенцияне тикшереб, кемләрнең нинди эшләргә кирәкле, файдалы булачагын күздән үткәрдек.

---

[1] Производительно – җитеш, үсештә. *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Габдулла мулла Әмирхани белән Гомәр Әмирханлар ни өчендер Фатихның каты авыруы турында үзләренең читдәге кардәшләрендән Ибраһим Әмирхан һәм Мәхмүд Әмирханларга хәбәр бирергә ашыкмадылар. Бары тик без кат-кат басыб әйкәндән соң гына 27–28 февральләрдә Гомәр Мәскәүгә Мәхмүд Әмирханга хат язды һәм Җиддәдәге[1] Ибраһимгә: «Фатих үпкә шеше белән каты авырый, карау якшы куелды, авыруның кидешендән киләчәктә хәбәр бирербез» дигән мәфһүмдә[2] телеграмм бирде. Фатихның авыруы көчәйгәч тагын хәбәр җибәрергә әйтдек. Ләкин һаман да «әһәмияте юк» диб кичекдерделәр. Шунда Мәхмүдкә телеграм бирделәр. Ибраһим Әмирхан авруның барышындан һаман хәбәрсез калды. Аңарга үлгәндән соң гына телеграм бирелде. Үзендән үлгән көндә хәле ничек диб соралган телеграм килде.

[18 бит] 5 нче мартда кич белән Фатихны саклаб утырган чагында хәл белә килүчеләрдән Шиһаб Әхмирев, Зыя Ваһапов, Исхак Карташов, Ибраһим Аитовларны алыб калыб, шулар янына Габдулла мулла белән Гомәр Әмирханны да чакырыб, шул ук фатирның урта бүлмәсендә янә бер кат киңәшдек. Монда югарыда сөйләнгән Биккол һәм Нуркинлар белән өчәүләб хәзерләгән күмү проектларын сөйләб күрсәтдек. Яңа кешеләр проектка үзгәреш кертмәделәр, мәгъкульләделәр[3]. Аннары Фатихның «Шәфигулла абзый»сы, мемуарлары, хатлары турында да сөйләшдек. «Шәфигулла абзый»ны күчерергә, башка кулъязмаларына акт язарга булдык. Ләкин бу нәрсәләрнең һәммәсе дә Фатихның кровате янындагы сандыкда булганга, ул сандыкны үзе авырса да һаман караб ятканга алыб чыгу мөмкин булмаганлыкдан һәм шалтыратыб ачыб алу да бик уңайсыз табылганлыкдан бу эшләрнең һәммәсе дә кичекдерелде[4].

---

[1] *1924–26 елларда Фатих Әмирханның энесе Ибраһим Әмирхан Согуд Гарәбстанында Совет илчелегенең сәркятибе һәм тәрҗемәчесе вазыйфаларын башкара.*

[2] Мәфһүмдә – эчтәлектә.

[3] Мәгъкульләделәр – аңлаешлы, дөрес дип таптылар.

[4] *Хакыйкатьтә бу эш берникадәр соңрак башкарылган. ТӘһСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендәге Ф.Әмирхан фондында әдипнең васыйлары Галимҗан Шәрәф һәм Ибраһим Бикколов тарафыннан 1926 елның 17 октябрьендә төзелгән Актның төп нөсхәсе саклана (Ф. 16, тасвир. 1, с.б. 47). Биредә Фатих Әмирханның вафатыннан соң бүлмәсендә калган кулъязмалары, китаплары, документлары, шәхси әйберләре һ.б. исәпкә алынган.*

6 нчы март шинбә көн авыру тагын да көчәйде. Бу көн көндез без хезмәтдә чагында доктор Терегулов килеб караб киткән һәм Ибраһим Бикколовны очратыб «Инде хәзер күмәргә хәзерләнергә кирәк, дүшәнбе көн иртә беләндән дә соңга калмас өзелер диб уйлыйм» дигән. Доктор Дезидериев: «Инде безнең хәлдән килерлек түгел. Якшәнбе көн кичдән дә калмас, өзелер, үләр диб уйлыйм» дигән.

Безне соңга таба үләр алдындан иң күб борчыган нәрсә Фатихның кулы белән язган васыяте бармы, юкмы икәнлеген белү булды. **[19 бит]** Докторлар аның үләчәген тәмам кисеб, вәгъдәләб куеб киткәч бу мәсьәлә безне тагын да борчыды. Мондый васыятьнең барлыгын яки юклыгын үзенең якын кардәшләрендән һичберсе өзеб әйтә алмады. Кырымга китәр алдыннан бары тик Ибраһим Бикколовка телдән генә «Әгәр дә үлә калсам, мине Ислам дине кушканча, ләкин бидгатьсез[1] без обрядов[2], ягъни фидия[3], дәүр[4], яллаб Коръән чыгарту, җидемне уздыру кебек эшләрнең – җолаларның берсен дә үтәмичә күмәрсез. Шулай ук минем җеназама чәчәк һәм ленталар да куйдырмазсыз. Васыйларым – Галимҗан Шәрәф, син һәм җизни, өчәү булырсыз» диб әйткән булган. Башкаларын шушылары белән бергә Кырымдан әйләнеб кайткач үзем язармын әле дигән[5].

Шушы 6 нчы мартда кичен гадәтдәгечә камфа[ра]лар тәэсире белән Фатихның кәефе ачылыб китә. Гадәтдәгечә сөйләшеб ята башлый. Шул араларда Ибраһим Биккол Фатихның үзендән сораб, үз кулы белән язган васыятенең юклыгын белә. Ләкин язар-

[1] Бидгатьсез – йолаларсыз.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] Фидия – үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкауны сорап биргән мал, йолым.

[4] Дәүр – үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкауны сорап үткәрелгән дини йола.

[5] *Кулъязманың 18 б битендә карандаш белән түбәндәге текст бирелгән:*

*– Нихәл, Ибрай, эш минем начар бит.*

*– Начар түгел әле, профессорлар өмид бар әле дияләр.*

*– Алар әйтерләр инде.*

*Янә дәвам итеб.*

*– Син Ибрай беләсең инде, син, җизни, Галимҗан Шәрәф – васыйлар.*

*– Синең бит Фатих язган васыятең бардыр.*

*«Язган васыятем юк», диде. «Күмүне инде ислам дине буенча, без обрядов» диде.*

*– Соң алай булгач Фатих син аны шаһидләр алдында әйтер идең, яки языб калдырыр идең.*

*«Ярар, шаһидләр алдында да әйтермен һәм хәлем якшыргач язармын» диде.*

*Разия һәм Гомәр Әмирханлар шул вакыт сүз уртасында килеб керделәр.*

га тәклиф[1] итми һәм васыятьләреңне әйтеб калдыр диб әйтергә дә базмый[2]. Биккол миңа моны шул сәгатьдүк хәбәр итде. Яңадан бер кат уйлашыб карадык. Ләкин һичбер төрле юл таба алмадык. Хәле авыр булган Фатихны васыятьләр турында сүз кузгатыб борчырга батырчылык итә алмадык. Чөнки аны сөйләшдерү аңарга зарар булыб төшәчәк иде. Шуңар күрә без аны үзебез карый башлагандан бирле мөмкин кадәр сөйләшдермәскә һәм аны үзебезнең сөальләргә[3] җаваб бирдерү мәҗбүриятенә төшермәскә тырышдык. Үзенең иң кирәкле сүзләрен генә тотыб, авыруына бәйләнеше булмаган сүзләрен сөйләшдермәс өчен мөмкин кадәр җавабсыз калдыра идек. Докторлар да шулай кушалар, шуны бик нык **[20 бит]** тотарга әмер итәләр иде. Хәтта хәл белә килүчеләрнең кайсыберләрен, сөйләшдерүләрендән куркыб, аның янына кертмичә, үзебез генә кабул итәдер идек.

Шулай да булса җиденче мартда бугай, Габдулла мулла Әмирхани бер уңаен табыб Фатихның телендән васыятьләренең кайберләрен әйтдергән һәм шуны языб кайтадан үзенә укыб күрсәткән. Фатих һәммәсен дә мәгъкуль[4] табыб бераз кәефе күтәрелсә, имза итәргә дә булган. Ләкин ул инде шундан соң имза итәрлек хәлгә килә алмады. Габдулла мулла язган васыять шул көенчә имзасыз хәлдә аның кулында калды. Бу васыятьне Габдулла мулла безгә дә күрсәтде. Биккол белән икәүләб укыдык. Монда ул Ибраһим Бикколга әйткән васыятьләре өстенә: 1) үзенең туганы Ибраһим Әмирханга биш мең сум чамасы бирәчәге барлыгын, артдырыб шуны үзендән калган суммалардан бирергә кушкан; 2) үземне күмү расходларындан калган суммадан якынларымны укытырсыз, дигән. Башка сүзләр артдырмаган[5].

Шул рәвешчә Фатих Әмирханның үз кулы белән язган васыяте калмады. Ләкин моның ул чаклы зур әһәмияте дә юк. Чөнки аның телдән әйткән васыятьләре үзе исән чагында ышанычлы рәвешдә исбат ителенде. **[21 бит]** Фатихның тәрбиясен, әхлакын, фикерен, игътикадын[6], карашларын, әсәрләрен белгән кешеләр өчен аның

---

[1] Тәклиф – көчләп кушу, боеру.

[2] *Бу җөмлә карандаш белән сызылган.*

[3] Сөальләргә – сорауларга.

[4] Мәгкуль – акылга ярашлы.

[5] *Ибраһим Бикколовка әйткәнненчә өч васый күрсәткән һәм җизнәсе Габдулла мулла Әмирхани белән Галимҗан Шәрәф, Ибраһим Бикколовларны атаган. (Автор искәрмәсе).*

[6] Игътикаден – ышануын.

шул телдән генә әйткән сүзләре дә инанырлык һәм игътикадына муафикъ[1] булганлыгы күренеб тора.

7–8 нче мартлар һәм 9 нчы мартка каршы төн, 9 нчы мартның иртәсе – Фатихның иң авыр рәвешдә иң куркынычлы авыруларга каршы көрәшкән көнләре. Бу көнләрдә аның күз нурлары байтка сүнде, күз пәрдәләре томанланды, сакалы үсеб китде. Үзе бик нык ябыкды. Ләкин анарда искиткеч чыдамлык булган икән. Ул һичбер вакыт һәм үлгән көнләрендә дә кычкырыб ыңгырашмады, ай-вайламады. Һәммәсен эчендән тынды. Мин аның унике көн рәтдән бик күб вакыт янында булсам да, бер генә табкыр да кычкырыб ыңгырашканын да ишетмәдем. Ул иң авыр минутларында да, үләренә тәмам 10–15 минут калганчага чаклы үзенең аңын югалтмады. Хәл белә килгән яки үзен кизүләб карый торган кешеләрнең һәммәсен дә таныб, һәркайсы белән берәр генә сүз булса да сөйләшеб ятды. Иртәгә үләчәк булган 8 нче март кичендә без Рәхимә Мөхитова белән икәү аның янында саклаб утыра идек. Шул вакыт кулын Рәхимәнең итәгенә куеб, Рәхимәнең кулын кысмакчы булды. Ләкин бармакларда көч юк иде. Моңар каршы Рәхимә: **[22 бит]** «Фатих абзый көчеңез азрак шул», дигәч, «Юк, миндә анлык кына көч бар әле», диб җавабланды, көлдерде. Андан соң бераз торгач: «Рәхимә, беләсеңме без бит синең белән син кечкенә чагында бер вакыт пароходда очрашкан идек. Син әле ул чагында 14–15 ләрдә генә булгансың. Менә инде хәзер ничек дәү үсеб киткәнсең. Мин сине шундан бирле күргәнем юк иде. Инде доктор да булгансың икән» диб, Рәхимәне таң гаҗәбкә калдырды. Исән булган Рәхимә Фатихның шулчаклы авыр хәлдә дә шул вакыйганы исенә төшерә алуына тәмам абтыраб калды.

Шул сүзләрендән соң мин чыгыб китдем. Рәхимә белән Габдулла мулла төнен утырыб сакларга калдылар. Аларга төнлә белән сүз араларында үзенең иртәгәч (9 нчы март була) сәгать 8–9 араларында үләчәген әйткән. «Иртә белән сәгать 8–9 араларында китәрбез инде ахыры» дигән.

Мине 9 нчы март иртә белән сәгать алтыда Фатих начарланды диб чакырдылар. «Фатих абый хәлең ничек?» диб сорагач: «Кәрим, син икәнсең, әлегә ничава, шулай ятабыз менә» диде дә изерәп китде. Шул чаклы аңы булганга янындагы кешеләрнең һичберсе аны бөтенләй өмидсез диб табмады. Көндезен бәлки

[1] Муафикъ – ярашлы, туры килгән.

рәтләнеб дә китәр әле диб уйлаган булдык. Чөнки докторларның аңарга үләргә куйган сроклары да үтеб киткән иде инде. Шулай да булса мин бик тиз генә **[23 бит]** Биккол белән Нуркинны һәм Гомәр Әмирханны, Фатих Мөхәммәдияровны өйләрендән чакырыб китердем. Фатих аларны да таныды. Шуңар күрә Биккол белән Нуркин бераздан үзләренең хезмәтләренә китделәр. Рәхимә Мөхитованы шәфкать туташы (Серова) алмашдырды. Шулай итеб без берничә кеше Фатих янында калдык. Сәгать тугызынчы яртыда тагын начарланды. Шул вакыт университет медицина факультетының соңгы курсында укучы Фәхретдинов дигән студент килде. Алар шәфкать туташы белән икәүләб камфара, морфий җибәрделәр. Аннары кокаин җибәрделәр. Һәммәсе дә доктор кушканча эшләнде. Ләкин инде болар да тәэсир итми башладылар. Габдулла мулла ясин укыб чыкды. Минут саен хәле авырая барды. Минут саен диерлек үзен әйләндерергә кушды. Бераз саташкалады. Ләкин әле һаман да аңында иде. Сәгать нәкъ ун тулганда: «Әйдә, китдек инде булмаса, күңелем рәхәтләнсен бер, менә шулай, менә шулай» диде. Шул вакыт Фатих Мөхәммәдияров килде.

Шушы сүзләре аның актык сүзләре булды. Шундан соң һич бер сүз әйтмәде. Пульсы тәртибсезләнде. Кан тибү сирәкләнде. Сулу алуы да тирәнәйде. Берничә минутлар бик эчдән сулады. Аннары күкрәкдән, аннары бугаздан гына сулу ала башлады. Сулу бугазга күчкән чагында тәмам соңгы сулуына чаклы сәгатемдән караб тордым. Сулуы соңга таба шул дәрәҗәдә сирәкләнде, хәтта ярты минутка бер генә калды. Габдулла мулла ясин укуда дәвам итде. Яңа Бистәдән килгән Рокыя апалары Фатихның колагына «Аллаһ», «Аллаһ» диб торды.

Күңел сизүе белән төнлә әйткән сүзендә күб ялгышмады. Иртә белән сәгать ун тулыб нәкъ 10 минут киткәндә актык сулуын алды. Җан бирде. Үзе әйткәнчә күңелен рәхәтләндереб Аллага табшырылды. Бездән аерылды. «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун»[1] дидек.

**[24 бит]** Фатихның җан биргән минутларында өстендә караб торучылар: 1) Габдулла мулла Әмирхани, 2) Гомәр Әмирхани, 3) Кәрим Сәгыйд, 4) Фатих Мөхәммәдияров, 5) Разия Әмирхан, 6) Газизә Яушева, 7) Нәфисә Ваһапова, 8) Рокыя апалары, 9) студент Фәхретдинов, 10) шәфкать туташы Серова.

[1] Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун – Хакыйкатьтә без Аллаһныкы һәм Аңа әйләнеп кайтачакбыз.

Фатих үлгәндән ун минут чамасы үткәч Исхак Карташев килде. Мин аны Фатихның хәле авырайгач да чакырткан идем, ләкин үлгәнче килеб җитә алмады. Мөхәммәдияров белән шәфкать туташы китделәр. Без шунда калган кешеләр Фатихның гәүдәсен урыныннан алыб караватын чистартдык. Бүлмәсен юдыртдык. Бераз гына дезинфекция ясадык. Астындагы көрпәләрен алыб, пакь простыня җәеб, кыйблага аяклары белән яңадан караватына салдык. Аяклары элекдән катып калганга, үлгәч дә тез турындан бөтенләй тураеб бетмәделәр. Ярты җәя рәвешендә калдылар. Шуның соңында телефон белән үзенең якын күргән дустларына, танышларына, нәселдәшләренә, үзе белән мәдрәсәдә укыган ибдәшләренә һәм аны сөюче-ихтирам итүчеләргә, гәзит идарәләренә бер сәгать чамасы берәм-берәм әйтеб, хәбәр биреб чыкдык. Кайберләренә кеше җибәреб әйтдердек. Күб дә үтмәде, бу кешеләрнең һәммәсе дә берәм-берәм Фатихны тәне суынмаган актык мәртәбә күреб калырга агыла башладылар. Елашулар, сыкранулар китде. Бераздан күмү киңәшләре башланды. Бусы турында алдагырак битләргә кара.

### [25 бит] Фатих Әмирхан авырган чагында хәл белә килүчеләр

26.02

Ибраһим Биккол
Кәрим Сәгыйд
Гыйльми һәм Рәхимә Шәрәфләр
Ә[б]үбәкер Терегулов
Габдерахман Моратов

27.02

Касыйм хәзрәт
Гәрәй Хәсәни
Садри Җәлал
Зыя Ваһапов
Фатима Апакова
Ибраһим Кули
Кәрим Тинчурин
Хәдичә Хуҗаханова
Кәрим Сәгыйд
Халисә Сәгыйд
Г. Моратов
Ә[б]үбәкер Терегулов
Фатих Мөхәммәдияров
Сафа Хафизов

28.02

Г. Кәрәм
Ә. Хәсәни
Хәсән Исхаков
Зәйнәб Хәсәни
Шәһәр Шәрәф
М. Гали
Юсупов
Һарун Максудов
Әхмәджан Мостафа
Исхак Карташ
Ибраһим Аит

Разия Садыкова
Хәдичә Хуҗаханова
Шиһаб Әхмирев
Кәрим Сәгыйд
Г. Байки
Г. Моратов
Ибраһим Биккол

1.03

Ибраһим Биккол
Кәрим Сәгыйд
Гәрәй Хәсәни
Таһир Ильяс
Йосыф Яушев
Ә. Терегулов
Б. Максудов
Хәдичә Хуҗаханова белән Суфия
Газизә Баттал
Г. Байки
Ибраһим Аит
Шиһаб Әхмирев
Вафа Бәхтияров
Г. Моратов
Исхак Карташ
Җамал Вәлиди

**[26 бит]** 2.02.

Нәфисә Ваһапова
Кәрим Сәгыйд
Ибраһим Биккол
Борһан Шәрәф
Халисә Сәгыйд
Фатима Бәхти
Гәрәй Хәсәни
Шиһаб Әхмирев
Г. Моратов
Гаяс Байки
Шәфика Аитова
Кадир Хуҗаев
Зыя Ваһапов
Һарун Максудов

3.03

Хәсән Исхаков
Йосыф Яушев
Каюм Мостакай
Фатиха Аитова
Зәйнәб Хәсәни
Ибраһим Биккол
Кадир Хуҗаев
Фатих Мөхәммәдияров
Нәфисә Ваһапова
Халисә Сәгыйд
Фатима Апакова
Кәрим Сәгыйд
(Танылмады)
Садри Җәлал
Гомәр Бикбулатов
Фәтхи Борнаш

4.03.

Нәфисә Ваһапова
Фатима Бәхти
Кадир Хуҗаев
Б. Максудов
Г. Моратов
Сибгать Ягуш
Шиһаб Әхмирев
М. Бөдәйли
Мәриям Мөштәри
Хәмид Мөштәри
Ибраһим Биккол
Кәрим Сәгыйд
Зыя Ваһапов
Фатих Мөхәммәдияров

**[27 бит]** 5.03.

Кәрим Сәгыйд
Каюм Мостакай

Ибраһим Биккол
Гәрәй Хәсәни
(Танылмады)
Заһид Нуркин
Хәдичә Карташ
Ш. Байчура
Г. Моратов
Сафа Хафиз
Шәфика Аитова
Ибраһим Аит
Хәдичә Хуҗаханова
Хәсән Исхаков
Садри Җәлал
Ильяс Әхмирев

6.03.

Габдулла Агишев
Ибраһим Биккол
Фатима Бәхти
Ш. Мостакай
Йосыф Яушев
Маһисәрвәр Мәрҗания
М. Гали
Ә. Хәсәни
Хәдичә Хуҗаханова
Зәйнәб Хәсәни
Х. Апаков
Исхак Карташ
Кәрим Сәгыйд
Ибраһим Кули
Нәфисә Ваһапова
Ә. Терегулов
Халисә Сәгыйд
Ибраһим Аит
Шиһаб Әхмирев
Ильяс Әхмирев
Г. Байки
Зыя Ваһапов
Фатима Апакова
Рәбига Дивиева
Г. Моратов
Гыйльми Шәрәф
Рәхимә Шәрәф
Исхак Карташ
Ә[б]үбәкер Терегулов
Г. Аитов

**[28 бит]** 7.03.

Кәрим Сәгыйд
Ибраһим Биккол
Г. Кәрәм
М. Туминов
Әфтәх Тәрҗемани
Садыйк Иманколый
Ибраһим Аит
Рауза Апак
Шәмсевәли Тимергали
Заһид Нуркин
Сөләйман Яналиев
Шахмамитов
Касыйм хәзрәт
Бинеямин Әхтәмов
Гыйльми Шәрәф
Сара Касыймова
Халисә Сәгыйд
Зәйнәб Хәсәни
Гәрәй Хәсәни
Шәһәр Шәрәф
Хәдичә Танач
Вәлидхан Танач
Каюм Мостакай
Х. Зәбири
Нәфисә Ваһапова
Г. Моратов

8.03.

Ибраһим Биккол
Кәрим Сәгыйд
Х. Зәбири

Гәрәй Хәсәни
Касыйм мөәззин
Вафа Бәхтияр
Фатима Бәхти
Нәфисә Ваһапова
Һади Максудов
Исхак Карташ
Кадир Хуҗаев
Фатима Апакова
Заһид Нуркин
Шиһаб Әхмирев
Зыя Ваһапов
Сафа Рәйми
Фатих Мөхәммәдияров
Сафа Хафиз
Ильяс Әхмирев
Ибраһим Кули

Хәдичә Хуҗаханова
Фазыл Локманов
Рәхимә Мөхитова
Хәсән Исхаков
М. Гали

9.03.

Кәрим Сәгыйд
Ибраһим Биккол
Заһид Нуркин
Исмәгыйль Кугушев
Касыйм Фәхретдинов
Нәфисә Ваһапова
Ибраһим Кули
Касыйм мөәззин
Ибраһим Аит
Исхак Карташ

**[29 бит]** Фатих Әмирханның авырый башлаган көнендән (15 нче февральдән) 26 нчы февральгә чаклы хәлен белә килүчеләр арасында кардәшләрендән башка кешеләр юк[1]. Аның авырганлыгы бу вакыт дустларына, танышларына билгеле түгел. Фатихның авырыб ятканлыгы үзенең дустларындан иң элек Кәрим Сәгыйд белән Ибраһим Бикколга мәгълүм булды. Бу 26 нчы февральдә иде. Шул көндән башлаб Фатихның хәлен белә килүчеләрнең һәммәсенең дә диерлек исем-фамилияләре яздырыла барылды. (Югарыда шул исемлек күчерелеб куелды, ләкин монда кардәшләре кермиләр, алар язылудан тыш һәрвакыт шунда). Менә шул көндән башлаб үлгән көненә чаклы (ягъни 26 нчы февраль белән 9 нчы

---

[1] *Миңа мәгълүм булганлардан Галимҗан Шәрәф Бакудагы Тюркология съездына китәчәк төнне 18 нче февральдә кич белән кереб утырган. Шунда бераз кәефсезләнеб торуын сөйләгән. Ләкин ул вакытда әле ул бу авыруына әһәмият биреб карамаган. Күберәк Бакуда булачак съездда һәм хәреф мәсьәләләре турында сөйләшкән. «Съездның күбчелеге башына ат тибкән халыкдан тормаса, латин кабул итү кебек җүләрлеккә бармас» дигән. Бакудан үзе өчен 15–20 сумларга кадәр яңа әзербәйҗан әдәбиятындагы һәм булса госманлы әдәбияты китабларын алыб кайтырга үтенгән. Соңындан каты авырыб яткан көнләрендә дә ул миндән съездның барышын сорашкалаб алгалый. «Галимҗан Шәрәф анда барыб үзенең докладын ясадымы әле, шул турыда «Коммунист» гәзитендә ниләр бар?» диб белергә кызыксына иде. (Автор искәрмәсе).*

март арасында) 12 көн эчендә Фатихның хәлен белә килүчеләрнең барысы бу язу буенча 76 кеше булды. Боларның 55 се ир кешеләр, 21 се кыз хатыннар. Өчәүсе коммунистлар, калганлары партиясезләр. Килү исәбләре белән барлыгы 199 табкыр була. Шундан ирләр 152 табкыр, кыз хатыннар 47 табкыр килгәннәр. Исем-фамилияләре белән санаганда болай була (хәреф тәртибе белән):

Ә[б]үбәкер Терегулов – 5 табкыр
Әфтәх Тәрҗемани – 1 табкыр
Әхмәдҗан Мостафа – 1 табкыр
Ильяс Әхмирев – 3 табкыр
Ибраһим Биккол – 12 көн рәтдән һәм һәркөн берничә табкыр. Төнлә дә саклады.
Ибраһим Кули – 4 табкыр
Ибраһим Аит – 6 табкыр
Исхак Карташ – 5 табкыр. Берсендә төнен саклады.
Исмәгыйль Кугушев – 1 табкыр
**[30 бит]** Бәдри Максудов – 2 табкыр. Берсендә ярты төн саклады.
Борһан Шәрәф – 1 табкыр
Бениямин Әхтәмов – 1 табкыр
Танылмаган фамилияләр – 2 табкыр
Таһир Ильяс – 1 табкыр
Рабига Дивиева – 1 табкыр. Икенче табкыр төнен саклады.
Разия Садыкова – 1 табкыр
Рауза Апакова – 1 табкыр
Рәхимә Мөхитова – 1 табкыр. 9 нчы мартка каршы төнен саклады.
Рәхимә Шәрәф – 2 табкыр
Заһид Нуркин – 4 табкыр. Бер табкыр төнен саклаб кунды.
Зәйнәб Хәсәни – 4 табкыр
Зыя Ваһапов – 5 табкыр. Бер табкыр төнен саклаб кунды.
Җәмал Вәлиди – 1 табкыр
Халисә Сәгыйд – 5 табкыр
Хадичә Танач – 1 табкыр
Хәдичә Хуҗаханова – 6 табкыр
Хәдичә Карташ – 1 табкыр
Хәсән Исхаков – 4 табкыр. Бер табкыр төнен саклады.
Хәмид Апаков – 2 табкыр
Хәмид Мөштәриев – 1 табкыр

| | |
|---|---|
| Хәбибрахман Зәбири – | 2 табкыр |
| **[31 бит]** Садри Җәлал – | 3 табкыр. Бер табкыр төнен саклады. |
| Садыйк Иманколый – | 1 табкыр |
| Сара Касыймова – | 1 табкыр. Ярты төн саклады. |
| Сафа Хафиз – | 3 табкыр. Бер табкыр төнен саклады. |
| Сафа Рәйми – | 1 табкыр |
| Сөләйман Яналиев – | 1 табкыр |
| Суфия – | 1 табкыр |
| Сибгать Ягуш – | 1 табкыр |
| Шахмәмитов Рәүф – | 2 табкыр. Берсендә ярты төн саклады. |
| Шәриф Байчура – | 1 табкыр |
| Шәһәр Шәрәф – | 2 табкыр |
| Шәфика Аитова – | 2 табкыр |
| Шәмсевәли Тимергали – | 1 табкыр |
| Ш. Мостакай – | 1 табкыр |
| Шиһаб Әхмирев – | 6 табкыр. Берсендә төнен саклады. |
| Габдулла Агишев – | 1 табкыр |
| Габдерахман Моратов – | 9 табкыр. 3–4 мәртәбә төнен саклады. |
| Газизә Баттал – | 1 табкыр |
| Г. Кәрәм – | 2 табкыр |
| Гыйльми Шәрәф – | 3 табкыр |
| Гаяс Байки – | 4 табкыр. Үлгәч бер төн саклады. |
| Фатих Мөхәммәдияров – | 4 табкыр |
| Фатима Апакова – | 4 табкыр |
| Фатима Бәхтиева – | 4 табкыр |
| Фатиха Аитова – | 1 табкыр |
| **[32 бит]** Фәтхи Борнаш – | 1 табкыр |
| Фазыл Локманов – | 1 табкыр |
| Касыйм Фәхретдинов – | 1 табкыр |
| Касыйм хәзрәт – | 2 табкыр |
| Кадир Хуҗаев – | 4 табкыр |
| Каюм Мостакай – | 4 табкыр. Берсендә төнен саклады. |
| Кәрим Сәгыйд – | 12 көн беррәтдән һәм һәркөн берничә табкыр төнлә дә саклады. |
| Кәрим Тинчурин – | 2 табкыр |
| Гәрәй Хәсәни – | 8 табкыр |
| Мәхмүд Бөдәйли – | 1 табкыр |
| Мәриям Мөштәри – | 1 табкыр |
| Маһисәрвәр Мәрҗания – | 1 табкыр |

| | |
|---|---|
| М. Гали – | 3 табкыр. Берсендә төнен саклады. |
| Мостафа Туминов – | 1 табкыр |
| Вафа Бәхтияров – | 2 табкыр. Һәр икәвендә төнләрен саклады. |
| Вәлидхан Танач – | 1 табкыр |
| Һади Максудов – | 1 табкыр |
| Һарун Максудов – | 2 табкыр |
| Йосыф Яушев – | 3 табкыр |
| Юсупов – | 1 табкыр |
| Гомәр Бикбулатов – | 1 табкыр |

**[33, 34 битләр[1]]**

**[35 бит]** *углы Әмирханны дәвалату, карашу өчен һәм әгәр дә Ходаның әмере җитеб дөньядан кичә калса, тәкфин-тәҗһиз[2] эшләрен үтәшү, андан соң калдырган мирасларын, язуларын, кульязмаларын, төрле документ һәм сәнәдләрен[3] барлаб акт языб алу өчен җәмәгать вәкилләре сыйфаты белән сезне ярдәмче итеб чакырабыз һәм ошбу дәгъвәтебезне[4] кабул иткән көндән кардәшебез әдиб Фатих Әмирханга гаид булган югарыдагы мәсьәләләрне башкаруда сезгә безнең белән бер хокукдан эш күрергә рөхсәт итәбез».* Имзалары:

Габдулла Әмирхани
Гомәр Әмирхани
Разия Әмирхани
Газизә Яушева

Күмү мәрасименең[5] үзәк комиссиясе шушы чакырылган кешеләрдән гыйбарәт булды. Шул рәвешчә күмү мәрасиме киңәшләренә керешдек. Безнең киңәшкә Заһид Нуркин белән Шиһаб Әхмиревләр дә катнашдылар. Мәҗлес актыгындарак янә берничә кеше килде. Күмү мәрасименә хәзерләнү планы берничә көн элек хәзерләнгән проектка нигезләнеп ошбу рәвешдә төзелде:

I. Фатих Әмирхан үзенең васыяте буенча ислам кагыйдәсе белән күмелер.

---

[1] *Кульязманың 34, 35 битләр сакланмаган.*

[2] Тәкфин-тәҗһиз – кәфенләү-күмәргә хәзерләү.

[3] Сәнәд – документ.

[4] Дәгъвәтебезне – чакыруыбызны.

[5] Күмү мәрасиме – күмү эшләре, процессы.

II. Коръән тутырту, тәһлил әйтдерү, дәүр[1] кылдыру, фидия[2] бирү кебек дин исемендән эшләнә торган бидгатьләр, җолалар, шулай ук табутына чәчәкләр, ленталар кую кебек горефләр һич берсе дә эшләнмәс. Чәчәк, лента китерүчеләр булса, өендә калдырылыр. Чәчәк, лента алырга теләгән кешеләргә шул акчаларын Фатих Әмирхан фондына бирергә мөмкин булуы гәзитдә чыгарылачак тәгъзия игъланларында[3] әйтелер. Үзенең васыяте буенча һәүел намазы[4] укылырга тиешлек **[36 бит]** турында мәсҗедләргә хәбәр бирелер.

III. Җеназаны Казан мөхтәсибе Касыйм хәзрәт Салихи укыр.

IV. Күмү 12 нче февральдә[5] җомга көн булыр. Мәет шул көн көндез сәгать бердә өйдән чыгарылыр. Шул тугрыда гәзитләрдә игълан басдырылыр.

V. Күмү мәрасимләрен башкару өчен өч төрле комиссия төзелә. Болар шушы сәгатьдән үк үзләренең эшләренә керешәләр.

*1. Информация һәм нотык сөйләүләр комиссиясе*

Бу комиссиянең вазифалары, эшләре:

1. Фатихның чит шәһәр яки илләрдәге кардәшләренә, дустларына һәм мәтлуб[6] булган аерым кешеләргә Фатихның үлүендән ашыгыч хәбәр тарату.

2. Гәзитләргә игълан бирү. Рустага (?) хәбәр итү.

3. Фатихның үлүенә багышланган бер номер газет чыгару.

4. Татар укучы һәм укытучыларын, студентларын, укымышлыларын күмү мәрасименә катнашу өчен оешдыру.

5. Җеназа мәйданларында сөйләнәчәк нотыкларның мәүзугларын[7] һәм сөйләячәк кешеләрне алдан билгеләб кую.

Бу комиссиянең әгъзалары: Җәмал Вәлиди, Заһид Нуркин, Садри Җәлал, Бениямин Әхтәмов, Мостафа Туминов, Ф. Мөхәммәдияров һәм Гомәр Әмирхан.

**[37 бит[8]]**

---

[1] Дәүр – үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкауны сорап үткәрелгән дини йола.

[2] Фидия – үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкауны сорап биргән мал, йолым.

[3] Тәгъзия игъланнарында – некрологларда

[4] Һәүел намазы – кеше үлгәнен ишеткәч, ахшамнан соң укыла торган ике рәкәгатьле намаз.

[5] *Биредә хата киткән. Дөресе «мартта» булырга тиеш.*

[6] Мәтлуб – эзләнгән.

[7] Мәүзугларын – темаларын, эчтәлекләрен.

[8] *Кулъязмада 37 бит буш калдырылган.*

**[38 бит]** *2. Тәкфин-тәҗһиз*[1] *комиссиясе*

Әгзалары: Габдулла Әмирхани, Кәрим Сәгыйд, Исхак Карташ, Зыя Ваһапов, Гыйльми Шәрәф, Шиһаб Әхмиров, Вафа Бәхтияров, Ибраһим Аитов.

Комиссиянең эшләре: юдырту, кәфенләү, мәетне саклау, атлар хәзерләтү, җеназа һәм кабер урынларын билгеләү, кабер казыту, өйдә һәм мәетне алыб барганда тәртиб саклау, башкалар...

Бу комиссия үзенә аерым утырыш ясаб хезмәтләрне түбәндәгечә бүлде:

1. Тәкфин-тәжһиз өчен кирәкле булган материалларны, нәрсәләрне хәзерләү һәм күмү мәрасимендә лязем[2] булачак барча мәсарифне[3] тәртибле рәвешдә алыб бару – хәзинәдарлык итү Исхак Карташевта йөкләнә.

2. Мәслихәт табылган кешеләрдән кизү белән мәетне саклату, саклау (почетлы сакчы кую), исләндермичә тоту Кәрим Сәгыйдкә табшырыла. Хезмәтләрен гарыз итеб[4] килүче студентлар иң беренче нәүбәтдә шушы эшдә Кәрим Сәгыйдкә ярдәм итәрләр.

3. Кабергә күмү өчен «Загс»дан рәсми язу алу Гомәр Әмирханга табшырыла.

4. Мәет булган өй янында мәсьәләгә гаид[5] йомышлар белән даими рәвешдә ат тоту (9–10 мартларда бер ат, 11 дә ике ат тоту) күмү көнесенә күб итдереб җитәрлек кадәр атлар хәзерләү Зыя Ваһаповка йөкләнә.

5. Җеназа һәм кабер урынларын билгеләү, кабер казыту эшләре Габдулла мулла Әмирхани белән Шиһаб Әхмиревкә табшырыла.

6. Күмү көнендә өй янына җыелган халыкдан үзләре теләгән кешеләргә мәетне күрсәтү вакытында, мәетне җеназа урынына һәм кабергә алыб барганда һәм күмү вакытларында тәртиб саклау, башында Кәрим Сәгыйд торганы хәлдә **[39 бит]** Габдулла мулла Әмирхани, Ибраһим Биккол, Шиһаб Әхмирев, Каюм Мостакай, һәм Зыя Ваһаповларга йөкләнә. Әгәр дә кирәк булса болар үзләренә ярдәмчеләр чакыралар.

---

[1] Тәкфин-тәҗһиз – кәфенләү-күмәргә хәзерләү.
[2] Лязем – кирәкле.
[3] Мәсарифне – тотылган чыгымнарны.
[4] Гарыз итеп – танып, олылап-хөрмәтләп.
[5] Гаид – бәйләнешле, мөнәсәбәтле.

7. Мәетне юу, Габдулла хәзрәт Әмирхани белән Фасих мөәззингә табшырыла. Юыб кую 11 нче март иртә беләндән дә соңга калдырылмас.

8. Мәетне өендә күтәреб табутына чыгарыб кую Габдулла хәзрәт Әмирхани, Гомәр Әмирхан, Ибраһим Биккол, Габдулла мулла углы Мәхмүд Әмирхани, Вафа Бәхтияр, Зыя Ваһапов һәм Гәрәй Хәсәниләргә табшырыла. Шулар өстенә башка кешеләр артдырылмый.

9. Мәетне табутка салгач өй яныннан театр мәйданына кадәр күтәреб баручылар: Габдулла хәзрәт, Гомәр Әмирхан, Ибраһим Биккол, Кәрим Сәгыйд, Габдулла мулла углы Мәхмүд Әмирхани, Зәкәрия Әмирхани, Зәкәрия Садретдинев, Гәрәй Хәсәни, Вафа Бәхтияров, Заһид Нуркин, Кәрим Тинчурин, Ибраһим Аит, Фатих Мөхәммәдияров, Хәмид Апаков, Гомәр Бикбулатов, Һади Максудов, Гыйльми Шәрәф булырлар.

10. Театр мәйданындан каберенә чаклы күтәреб баручылар яңыз укучылар, студентлар, укытучылар, һәм укымышлылар гына булыр. Башка төрле сыйныф кешеләре катнашдырылмас.

11. Мәетне кабергә индерүчеләр: Җәмал Вәлиди, Фатих Мөхәммәдияров, Вафа Бәхтияров, Зәкәрия Садретдинев, Кәрим Сәгыйд, Зыя Ваһаповлар булырлар.

12. Каберенә алыб ләхедкә куючылар: Ибраһим Биккол, Габдулла хәзрәт Әмирхани һәм Гомәр Әмирханлар булырлар.

**[40 бит]** *3. Рәсем алдыру комиссиясе*

Әгъзалары: Кәрим Тинчурин, Хәсән Исхаков, М. Гали, Кадир Хуҗаев, Каюм Мостакай, Г. Кәрәм.

Вазифалары: Фатихның караватында яткан килеш рәсемен алдыру. Якын кардәшләре белән бергәләб рәсемен алдыру. Гипс белән маскасын алдыру һәм шуны балавызга эшләтү. Өендән каберенә илткәнче берничә урында җеназа мәрасимләрен һәм каберенә төшерү вакытларын рәсемгә алдыру. Җеназа мәрасимләрен киноматограф лентасына алдыру.

Бу өч төрле комиссиядән тыш янә Фатихны күмгәндән соң аны искә төшерү комиссиясе төзелергә тиешлеге дә сөйләнеб үтелде. Фатихның каберенә таш куйдыру, аңарга багышланган кичәләр ясау, мәҗмугасын[1] чыгару, рәсемләрен эшләтдереб тарату,

[1] Мәҗмугасын – әсәрләренең җыентыгын.

кайбер нәрсәләрен музейга бирү һәм гомумән, аның исемен мәңгеләштерү кебек эшләр шушы комиссиядә каралырга тиеш.

**[41 бит] Комиссияләрдә**

Югарыда сөйләнгән комиссияләр һәм аның аерым-аерым әгъзалары һәммәсе дә бик ныклаб торыб үзләренең эшләренә керешделәр. 11 нче март кич һәммә эшләр башкарылыб бетде. Шушы ике арада, Фатихның үлгән көнендән 11 нче март кичкә чаклы (өч көн эчендә) эш өстендә байтак сөйләшүләр, киңәшүләр булды. Ләкин шушы киңәшүләрдә татар коммунист укымышлылары, язучылары килеб һичберсе төбле рәвешдә катнашмадылар (бары тик үлгәнендән берничә сәгатьләр үткәч үк Мәхмүд Бөдәйли ибдәш кенә зыярәт итеб тәгъзия[1] кылыб чыкды).

Без үзебезнең Үзәк комиссия исемендән шушы вакытда дәвам итмәкдә булган Татарстан Советлары съездының президиумына Фатих Әмирханның үлүендән рәсми кәгазь җибәрдек. Күмелү көнен хәбәр итдек. Шуңар каршы һичбер җаваб булмады[2].

Фатих үлгәннең беренче көнендә үк яшь язучылардан кайберәүләре (Хәсән Исхаков, М. Гали, Садри Җәлаллар): «Әгәр дә гражданский күмү белән күмсәк, бәлки съезд да, хөкүмәт дә һәм коммунистлар да катнашырлар; күмү мәрасиме тагын да зурырак булыр иде» дигән мәфһүмдәрәк[3] бер фикер сөйләделәр. Шул көнне кичен һәм иртәгесен Үзәк комиссия әгъзасы Фатих Мөхәммәдия[р]ов да шушы фикерне куәтләде. Ләкин боларның һичберсе Үзәк күмү комиссиясенә төбле бер тәклиф[4] рәвешендә түгел, бәлки хосусый рәвешдә генә әйтелделәр. Шулай да булса Үзәк комиссия бу фикерне игътибарга **[42 бит]** алыб үз эчендә берничә кат сөйләшеб үтде һәм бу тугрыда Фатих Әмирханның кат-кат әйтеб калдырган васыяте булганга, аңарга ихтирам йөзендән һәм аның динле булуын күздә тотыб, үзе әйткәнчә Ислам кагыйдәсе буенча җеназа укыб күмәргә карар бирде.

---

[1] Тәгъзыя – үлгән кеше якыннарының кайгысын уртаклашу, юату.

[2] *Соңындан ишетелгән хосусый хәбәрләрдән, съезд президиумының безнең бу кәгазебезне, гомумән, Фатихның үлү хәбәрен съездда рәсми игълан итмәгәнлеге беленде. Руслардан берәү Фатихның вафаты турында сөйләшкәндә «Фатихның үлгәнен съездга хәбәр итеб җеназасын съезд утыра торган Комклуб бинасы алдына алыб барганлар имеш дә, съезддан берәү дә чыкмаган имеш, шул дөрестме?» диб сорады. Җавабда «Ул көн бәйрәм иде, бәлки съездның җыелышы булмагандыр» диб калдырырга гына туры килде.*

[3] Мәфһүмдәрәк – эчтәлектәрәк.

[4] Тәклиф – көчләп кушу, боеру.

Шул көнне кич белән сәгать унларда Фәтхи Борнаш килде. Без әле бу вакыт аерым-аерым рәвешдә һаман да күмү мәрасимләренә хәзерлек турында сөйләшеб утыра идек. Ул безгә янәдән ничек күмү мәсьәләсен кузгатды, безнең карарыбызга бәхәс итде: «Фатих Әмирхан сезнең карашда гына түгел, безнең карашда да зур язучы һәм әдиб, ул җәмәгать кешесе. Аны сезнең кебек иске дустлары гына түгел, һәммәбез дә ихтирам итәбез, коммунистлар да ихтирам итәләр. Без аның Печән[1] һәм чалмалы халык кулы белән күмелүен теләмибез. Гражданларча күмелү белән күмелсен. Без партияле укымышлылар әле бу турыда съездда да сүз кузгатырга уйлаб йөрибез» диб дау чыгарды. Безне орышды. Күңелендән ничек булгандыр, анысын белмим, ләкин тышындан үтә динсез киселергә маташды. «Фатих ул динсез иде. Аның бит җеназа укыб күмү турында шаһидләр алдында үз кулы белән язып калдырган васыяте юкдыр» диде.

Мөхәммәдияров үзенең әсасән[2] гражданларча күмү ягында икәнлеген сөйләб, әгәр дә васыяте буенча җеназа укырга теләүчеләр булса, анысын зыярәт янында гына эшләсенләр, диде.

Мин «Без Фатихны зур ихтирам белән олуглаб күмәчәкбез. Бөтен партиясез укымышлылар бу күмү мәрасименең уртасында булачаклар. Чалмалы халык белән Печән базары кулына бирергә уйлаганыбыз да юк. Фатихны татарның **[43 бит]** укымышлылары, укытучылары, укучылары, студентлары күмәчәк. Әгәр дә татар коммунист укымышлылары да Фатихны зур әдиб һәм җәмәгать кешесе диб танысалар, сез әйткәнчә ихтирам итсәләр, ни өчен исән чагында килмиләр иде? Ни өчен татар театрының 20 еллык юбилейсе вакытында аны игнорировать[3] итделәр, хәтта юбилей мәҗлесендә сүкделәр? Ни өчен ул авырган чагында хәлен белә килмәделәр? Ни өчен бөтен партиясез укымышлылар үзләренең барлык көчләре белән Фатихны үлемдән алыб калырга тырышыб йөргәндә булышлык күрсәтмәделәр? «Фатих Әмирхан каты авырый» дигән хәбәргә һич бертөрле әһәмият дә бирмәделәр? «Кызыл Татарстан» идарәсендәге Толымбайскиләрегез «Фатих Әмирхан каты авырый» дигән хәбәрне гәзиткә басыб чыгарырга да каршы килделәр? «Фатих Әмирхан безнең өчен әллә кайчан үлгән инде, андый чепухаларны басыб ма[та]шмыйбыз» диб әйтергә дә нахал-

[1] *Биредә Печән базары халкы, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр күз уңында тотыла.*
[2] Әсасән – нигездә.
[3] Игнорировать – күрмәмешкә салышу, читкә тибәрү.

лыклары җитде! Инде хәзер инициативаны үзегезнең кулга алырга телисез! Монда аңлашылмый торган бер мантыйк бар», дидем. Шуның өстенә «Әгәр дә чындан да аңар ихтирам күрсәтеб күмү мәрасимләрендә катнашырга телисез икән, сезнең катнашуга җеназа уку бер дә комачаулык итми. Без җеназа укудан дүнмибез[1]. Ләкин мин үзем җеназа уку фактына чаклы гражданларча мәрасим ясарга да каршы түгел» дидем.

Ибраһим Биккол «Без Фатихны үзенең васыятенә бинаән[2] Ислам кагыйдәсе буенча җеназа укыб күмәчәкбез. Әгәр дә сез аны ихтирам итсәгез, аның васыятенә каршы килмәскә тиешсез. Мәсьәлә бик җиңел, бары тик җеназа гына укымыйсыз, без укыган чагында читкәрәк китеб кенә торасыз. Без бит җеназадан башка дини бидгатьләрнең берсен дә эшләмибез. Шуңар күрә җеназа укудан башка күмү мәрасимләренә бик иркенләб катнаша аласыз. Әгәр дә без ихтирам иткән бер коммунист үлсә, аның **[44 бит]** җеназасыз күмелүенә һичбер каршы килмәс һәм күмелү мәрасименә катнашыр идек. Шулай ук әгәр дә без ихтирам иткән бер урыс булса, аның поплар белән күмелүенә, чиркәүгә кертелүенә һичбер каршы килмәс идек. Урыслар белән чиркәүгә дә керер һәм чукынганларын да караб торыр идек; без үзебез андый игътикадда[3] булмаганга, бу безнең иманыбызга да зарар китермәс һәм аны ихтирам йөзендән күмү мәрасименә катнашуыбызга да манигъ[4] булмас иде. Ни өчен сез дә бу мәсьәләгә шулай карый алмыйсыз?» ди.

Фәтхи Борнаш янган шәһәр театры мәйданында гражданларча мәрасим ясау фикерен куя. Җеназагызны зыярәт янында укырсыз, ди.

Ибраһим Биккол: «Без инде Фатихның гәүдәсен коммунистлар да ихтирам итсенләр диб мәйдандан мәйданга өстерәб йөрергә каршы киләбез. Әгәр дә ихтирам итсәгез, Фатихны үзегезгә китертмичә, үзегез Фатих янына килегез», ди.

Җәмал Вәлиди: «Гражданларча күмү мәрасиме ясау намына[5] җеназасын яшереб укыб, Фатихны керәшенләрчә күмүгә һичбер разый булырга ярамый», ди.

---

[1] Дүнмибез – кире чигенмибез, баш тартмыйбыз.

[2] Бинаән – нигезләп, таянып.

[3] Игътикад – инану, ышаныч.

[4] Манигъ – тыю, киртә.

[5] Намына – исеменә.

Моназарә[1] озынга китә. Башкалар да катнашалар. Комиссиянең карары бозылмый.

10 нчы март «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» гәзитләрендә Фатихның үлүе турында түбәндәге игъланлар чыгарылды.

1.

*9 нчы мартда сишәнбе көн иртә белән 10 сәгать 10 минутда атаклы олы татар язучысы*
*Фатих Әмирханның*
*дөньядан үткәнлеген якынларына, мөхибләренә тирән кайгы белән белдерәбез. Мәрхүмнең җәсаде җомга көн 12 нче мартда көндез сәгать бердә фатирындан чыгарылыб, Мулланур Вахидов мәйданына китереләчәк. Мәрхүмнең васыяте буенча өстенә чәчәкләр һәм ленталар куелмаячак. (Ихтирам йөзендән чәчәк, лента куярга уйлаган оешма һәм кешеләргә, шул эшләргә тотачак акчаларын мәрхүмнең хатирәсе фондына табшырырга мөмкин).*

*Күмү мәрасимен үткәрү комиссиясе*

**[45 бит]** 2. Шундый ук игълан. Фатихның якын кардәшләре исемендән.

3. Гәзитнең Казан хәбәрләре арасында. Редакциядән.

10 март. Күмү комиссияләре үзләренең эшләрендә. Казандагы партиясез татар укымышлылары, Фатихның дустлары, танышлары әледән-әле килеб булышлык күрсәтеб торалар. Коммунистлар да берәм-берәм килеб тәгъзия кылыб китәләр. Үзәк күмү комиссиясенә кичә Фәтхи Борнаш кузгаткан мәсьәлә турында бер рәсми тәклиф-фәлән юк.

11 март. «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» гәзитләрендә Фәтхи Борнашның Фатих Әмирханга багышланган мәкаләләре чыга. Ул үзенең бу мәкаләләрендә Фатих Әмирханга «Без аны инкыйлабчы мөхәррир, шагыйрьләр тезмәсенә кертергә тырышмыйбыз» диб бәя куя. Әйтерсең лә аңарга «зинһар, кертсәнә инде, Фәтхи ибдәш» диб ялынганлар диярсең.

Андан соң шул ук көнге гәзитдә: 1) «Кызыл Татарстан» һәм «Крестьян» гәзитләре язучыларның, 2) Гужур һәм «Шәрык матба-

[1] Моназарә – бәхәс.

гасы» эшчеләренең, 3) матбугат эшчеләре оешмасы белән Гыйльми үзәк һәм Дәүләт нәшриятының тәгъзия игъланлары чыга.

«Татарстан» гәзите тирәсендәге яшь язучылар һәм партияле укымышлылар берәм-берәм килеб «Фатихны гражданнарча мәрасим белән күмергә кирәк» диб сүз куертыб, комиссия әгъзаларын моназарага[1] чакырыб йөриләр. Комиссия әгъзалары боларга каршы: «Әгәр дә гражданларча мәрасим белән күмү ягында булучылар үзләренең күмү мәрасименә катнашырга, Фатихны ихтирам итәргә теләгәнлекләрен комиссиягә килеб **[46 бит]** төбле-җүнле рәвешдә әйтсәләр, бер тәклиф кертсәләр, без сөйләшүдән баш тартмыйбыз, сөйләшербез. Ләкин җеназа укудан дүнмәбез. Шунда да һәр ике як катнашырлык рәвешдә килешү ясаб, күмү мәрасиме планларын яңадан бер кат тикшереб караб чыгарбыз» диб җаваб бирәләр.

Көн урталарында Биккол белән мине телефондан обкомның агитпроп бүлегенә чакыралар. Барабыз. Анда утыручы Гыймранов «мин бернәрсә дә белмим» ди. Провакация булыб чыга.

Ниһаять кич сәгать җиделәрдә (иртәгә Фатих күмеләчәк дигән кичдә) гражданларча күмү ягында булучылардан рәсми рәвешдә кешеләр киләләр. Безгә күмү мәрасиме турында сөйләшер өчен катнаш утырыш ясарга гарыз итәләр[2]. Утырыш башлана. Ибраһим Биккол рәислек, Заһид Нуркин секретарьлек итә. Протоколы түбәндәгечә:

**Фатих Әмирханны күмү мәрасиме турында мәҗлес протоколы**

1926 ел. 11 март.

*Мәҗлесдә булучылар:* Фатих Сәйфи, Исхак Рәхмәтуллин, Фәтхи Борнаш, Латыйф Гомәров, Мәхмүд Бөдәйли, Фатих Мөхәммәдияров, Ибраһим Биккол, Кәрим Сәгыйд, Бениямин Әхтәмов, Гомәр Әмирхан, Габдулла мулла Әмирхани, Заһид Нуркин, Гомәр Бикбулатов, Гыйльми Шәрәф, Шиһаб Әхмирев, Зыя Ваһапов, Гәрәй Хәсәни, Садри Җәлал, Фатих Әмирхан II, Х.Зәбири, Исмәгыйль Рәмиев.

*Нәүбәтдә:* ничек күмү мәсьәләсе.

*Ибраһим Биккол:* Күмү мәрасиме үткәрү комиссияләренең карарларын игълан итде.

[1] Моназарага – бәхәскә.

[2] Гарыз итәләр – тәкъдим итәләр.

*Латыйф Гомәр:* Фатих абый барыбыз өчен дә кадерле. Ул үзенең гомерен искелек белән көрәшеб үткәрде. Яшь буынга тәэсире зур булды. Күмүне дә шундый итеб үткәрергә кирәк.

**[47 бит]** *Исхак Рәхмәтуллин:* Күмүгә без һәр хәлдә катнашачакбыз. Шулай да төб бер мәсьәләне чишәргә кирәк. Дини рәвешдә күмү буламы? Гражданскиймы? Безнең катнашуыбызның рәвеше шушы мәсьәлә белән чишеләчәк. Комиссия мәсьәләне «дини» диб кисеб куюы белән үзенең өстенә зур бер мәсьүлият[1] ала.

*Габдулла мулла Әмирхани:* Фатихның васыяте шулай ди.

*Ф. Мөхәммәдияров:* Комиссиянең күб әгъзалары гражданский күмү ягында булса да, Фатихның үз теләгенә ихтирам итеб, җеназа белән күмүгә разый булдылар[2].

*Фатих Сәйфи:* Ничек күмәргә дә мөмкин. Кеше үзенең якынын ничек күмсә дә ярый. Ләкин гәзитдә Фатихның васыятен төртеб күрсәтүнең ни өчен эшләнгәнен белмибез[3]. Фатихның языб калдырган әйбере юк икән. Мәрасимне театр мәйданында үткәрү сезнең өчен дә кабул ителерлекдер.

*Х. Зәбири:* Монда мәрасимне үткәреб, тегендә җеназа укырга мөмкин.

*Кәрим Сәгыйд:* Ни өчен Мулланур Вахидов мәйданында түгел дә, ни өчен бу мәйданда? Шуның төб сәбәбе нәрсә икән?

*Мәхмүд Бөдәйли:* Сәбәбләре: 1) Татарстан Советлар съездының шул мәйдан алдындагы Комклуб бинасында булуы. 2) Татар өчен эшләб торган Фатихның җеназасы барыбер шушы мәйдандан үткәреләчәк. 3) Шулай булгач җеназачылар шунда туктаб бераз сабыр итә алалар.

*Кәрим Сәгыйд:* Бу мәйдандагы митингда җыелган халык монсоң да мәет белән барачакלармы?

(Җаваб бирәләр: барачаклар).

*Г. Әмирхани:* Мулланур Вахидов мәйданы алга китсен, шушындый тантаналы эшләр шунда эшләнсен иде.

**[48 бит]** *Фәтхи Борнаш:* Мәрасимне тегендә ясаганда ихтирам булыб да, монда ясаганда ихтирам булмый диелсә самимият булмас иде. Халык монда да килә алыр һәм килгән кешеләр озатырлар да.

[1] Мәсьүлият – җаваплылык.

[2] *Комиссиянең күбчелеге гражданский күмү ягында булмады. (Автор искәрмәсе).*

[3] *Тәгъзия игъланындагы чәчәкләр, ленталар турында әйтелгән сүзләргә күрсәтә. (Автор искәрмәсе).*

*Исхак Рәхмәтуллин:* Сез артык мәсьүлиятле эш алгансыз. Татар мәгариф эшчеләренең туксан проценты безнең якда. Безнең теләк бик катгый. Без ихтирамыбызны дини мәрасим белән бер урында җыя алмыйбыз. Сез уступка[1] ясасагыз, без дә ясарбыз.

*Кәрим Сәгыйд:* Килешүгә якынлашу аңлашылды. Монда әледән-әле мәсьүлият алу белән куркытышырга урын юк. Без мәсьүлиятне бик ачык аңлаб үз өстебезгә алабыз. Җавабын биргәндә ярдәмгә сезгә барырга кирәк булмаса кирәк. Шулай да без мәслихәт булган эшкә каршы килмибез. Әгәр дә бу Театр мәйданында да мәрасим ясаганда халык икегә аерылыб таркалмаса, без Театр мәйданында ясаб үтәргә дә разый.

*Шиһаб Әхмирев:* Габдулла хәзрәт ихтирам күрсәтергә манигъ[2] юк, ди. Театр мәйданында мәрасим ясау тарафында кеше күб. Безнең аңарга каршы торырга хак юк.

*Ф. Сәйфи:* Без Татарстан Советлары съездындан вәкил түгел. Андагы кешеләрне мәрасимгә барырга көчләмибез. Митинганы теләсәк кайчан ясый алабыз. Җеназа артындан бармауда безне һичбер иҗтимагый совет (?) гаебләмәс.

*Г. Әмирхани:* Низагъ юк. Уңайсызлык чыкмасмы? Монда да мәрасим үткәрү озакка сузылмасмы?

*Латыйф Гомәров.* Тәкъдимләр кертә: 1) Фатих абыйның васыятен безнеңчә аңларгамы? Комиссиячәме? 2) Мәрасим театр мәйданында үткәреләме, әллә Вахидов мәйданындамы? Әллә икесендә дәме? Шуларны чишәргә кирәк. Шундан соң гамәли чараларын төзәрбез, ди.

Мәсьәлә бутала. Сөйләүчеләр күбәя.

*Ф. Мөхәммәдияров:* Күмүне монда фиксировать[3] итеб калырга кирәк, ди.

**[49 бит]** *Садри Җәлал:* Без партиясез зыялыны күмгәндә, һәммәбез бергә булырга тиешбез. Муллалар, пуркилар[4] катнашмасыннар иде, ди.

*Исхак Рәхмәтуллин:* Без мәгариф, мәдәният оешмалары вәкилләре Фатихны үзебез теләгәнчә хөрмәт итеб озатырга уйлыйбыз. Шуңарга разыймы?

---

[1] Уступка – юл кую.
[2] Манигъ – каршылык, киртә.
[3] Фиксировать – теркәп.
[4] Пурки – ялкау, иҗтиһадсыз шәкерт, укучы.

*Ибраһим Биккол:* Без Театр мәйданында гражданларча мәрасим үтәб үтәргә разый. Ләкин мин мәсьәләнең бу рәвешдә куелышына каршы булганга рәислекдән чыгам.

Фатих Мөхәммәдияров рәислек итә.

Ф. Сәйфи мәгариф, мәдәният оешмаларының белдермәсен игълан итә. Бу белдермә түбәндәге 4 маддәдән гыйбарәт:

1. Мәгариф һәм матбугат эшчеләренең оешмалары Фатих Әмирханны гражданларча күмү рәвеше белән үткәрергә (озатырга булса кирәк) тәкъдим итәләр.

2. Мәрхүмнең языб калдырган васыяте булмавын белсәк дә, ләкин васыйларының югарыда күрсәтелгән рәвешдә күмүгә риза булмавын искә алыб, Фатихны нинди мәрасим белән күмүне васыйларның үзләренә табшырырга.

3. Бу карарның икенче маддәсе белән риза булмаган киңәш мәҗлесенең әгъзалары Фатихны озаткан чакда Театр мәйданында туктаб хөрмәт итүне муафикъ диб таба.

4. Театр мәйданындагы җыелышның рәисе итеб Фәтхи Борнашны күрсәтә.

Бу белдермәне укыгандан соң мәсьәлә тагын бутала. Сөйләүчеләр артык күбәя. Фәтхи Борнаш урынына Фатих Мөхәммәдияровны тәкъдим итәләр. Партиялеләр моңарга разый булмыйлар. «Фәтхи Борнаш сезнең кеше ич» диб көләләр.

**[50 бит]** Шуннан соң киселеб әйтелгән, сүз берекдерелгән булмаса да, түбәндәге карар язылыб куела (ләкин бу карарга бик күб кешеләр разый булмыйлар).

*Карар:* Театр мәйданындагы митинг Гыйльми Үзәк, матбугат эшчеләре оешмасы, Дәүләт нәшрияты һәм гражданларча мәрасимдә хәзер булучылар исемендән Фәтхи Борнаш тарафындан ачылачак. (Аннары мәетне алыб бару йолалары).

Шуның белән гражданларча күмү тарафындагы кешеләр таралыб бетәләр. Аларча инде резолюция чыгарылгач, гүя һәммә нәрсә шуның белән тәмам булды.

Килгән халык таралыб беткәч, күмү мәрасимен үткәрү комиссиясе шундук үзенең утырышын ясаб яңадан бер кат элекдәге карарларын тасдыйк[1] кылыб үтде. Шуның белән бергә Театр мәйданында ясалачак мәрасимдә табутны туктатырга булды. Шунда Фатихның тәрҗемәи хәлен һәм аның ничек авыруын сөйләр өчен

[1] Тасдыйк – раслау.

комиссия әгъзаларындан Ибраһим Биккол белән Фатих Мөхәммәдияровларны билгеләде. Театр мәйданында мәрасим булачагын һәм табутның шунда туктатылачагын белдереб гәзитдә игълан чыгарырга булды.

12 март. «Кызыл Татарстан»да информация комиссиясенең, кичә идарә белән ясаган килешүе буенча, гәзитнең уртасына салынган ярты табак кәгазьдә ике яклы булыб, Фатих Әмирханга багышланган мәкаләләр һәм игъланлар һәм читдән килгән тәгъзия телеграмларның кайберләре басылыб чыкды.

**[51 бит]** Партиядәге укымышлы яки язучыларның, бигрәк дә сул канатда булганларының Фатих Әмирханны үлгәндән соң «Без дә аны тәкъдир һәм хөрмәт итәбез» диб йөрүләрен, күмү мәрасимләрендә катнашабыз диб митинг ясаб этәчләнүләрен «якшы түгел, читдәге эмигрантлар – дошманлар шуны истифадә[1] итәрләр, Әмирханның әдиблеген игътираф[2] итмәгәнләр диб битебезгә бәрерләр» дигән тактикалардан чыкканлар диб юрадылар, шулай диб сөйләделәр.

Фатих Әмирхан үлгәндән соң күмү мәрасимен үткәрү комиссиясенә үзләренең кайгыларын белдереб төрле оешма һәм аерым кешеләрдән түбәндәге телеграмлар килде:

1. *Мәскәү. 10 март. Бөек каләм остасы татар классигы Фатих Әмирханның үлә хәбәрен тирән кайгы белән каршы алдык. Бу югалтуга күңелебез сыкранганлыкны зур хәсрәт белән белдерәбез.*

Эшче редакциясе.

2. *Мәскәү. 10 март. Оста татар язучысы, татар матур әдәбиятын тудыручыларның берсе булган Фатих Әмирханның югалуына чын күңелдән кайгырабыз. Туган һәм дустларының хәсрәтләрен уртаклашабыз.*

Үзәк нәшриятның татар-башкорд,
казакъ, үзбәк, кыргыз, нугай, төркмән секцияләре.

3. *Мәскәү. 10 март. Үзебезнең бөек классик, матур әдәбиятыбызның энҗесе Фатих Әмирханның үлүенә тирән һәм чын, ихласдан кайгырабыз. Үзебезнең халкыбыз, мәрхүмнең туган һәм дустларының кайгыларын уртаклашабыз.*

Имзалар: Фатих Кәримев, Ф.Агиев, Суфия Агиева, Мәхмүд
Мәрҗани, Нәҗиб Гасрый, Шакир Мостаев.

---

[1] Истифадә – файдалану.
[2] Игътираф – тану.

**[52 бит]** 4. *Мәскәү. 10 март. Үзбәк әдәбияты, хәзерге художество ягыннан үсү чорында Фатих Әмирханны татар әдәбиятының оста художнигы сыйфаты белән чын ихласдан һәм чиксез ярата. Мин Фатих Әмирханның талантын хөрмәт итүчеләрдән булыб, сезнең кайгыгызга кушылам.*

Чулпан.

5. *Мәскәү. 10 март. Бөек әдиб Фатих Әмирханның үлү хәбәре безне кайгыга төшерде. Аның исеме, үсеб килә торган яшьләрнең йөрәгендә мәңгегә калыр.*

Үзәк наборщиклар мәктәбенең
татар өйрәнүчеләр группасы.

6. *Мәскәү. Классик Әмирханның вакытсыз үлеб китүенә кайгырганлыгыбызны белдерәбез.*

Хиҗаз Гали, Бикбулат, Кушаев, Уразмөхәммитев.

7. *Серпухов. 11 март. Тюркология съездының Татарстан вәкилләре татарның талантлы язучы һәм художникларындан берсе булган Фатих Әмирханның үлгәнлеген юлда ишетеб тирән кайгыда калды. Чын күңелебездән ошбу гомуми кайгыга без дә кушылабыз.*

Имзалар: Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Максудов,
Галимҗан Шәрәф, Гали Рәхим, Габдерахман Сәгъди,
Нигъмәт Хәким, Мөхәммидева.

8. *Ленинград. 10 март. Башкордстан студентлары оешмасы халык язучысы булган Фатих Әмирханның үлүе мөнәсәбәте белән үзенең тирән кайгырганлыгын белдерә.*

Рәис: Төхфәтуллин.

9. *Ленинград. 11 март. Кайгы аңлатыб бирелгән телеграм оешманың фикере түгел.*

Төхфәтуллин.

10. *Ленинград. 10 март. Ленинград яшьләре кыйммәтле язучы Фатих Әмирханның югалуына тирән кайгыра.*

Имза: Яшьләр.

**[53 бит]** 11. *Ленинград. 10 март. Сөекле язучыбыз Фатих Әмирханның үлүенә Ленинград мөселманларының кайгырганлыкларын белдерәбез.*

Мәсҗиде Җамигъ комитеты

12. *Әстерхан. 10 март. Чиксез хөрмәтле Фатих әфәнде Әмирханның үлү вакыйгасе белән гаять мөтәәссир*[1] *булганлыгымны белдерәм.*

Мулла Ниязи.

13. *Әстерхан. 9 март. Бәхил бул кадерле дуст, Фатих!*

Әлмөхәммәдев, Габәши.

14. *Әстерхан. 10 март. Безнең исемебездән Фатих Әмирханның табутына чәчәк куярсыз. 25 сум акча җибәрелде.*

Имзалар: Борһан Бадамшин, Гали Шәмиунов, Фатих Шахмазов, Гата Баһаветдинов, Гани Ниязов, Гыйлаҗеддин Яһудин.

15. *Әстерхан. 10 март. Татар күгенең йолдызларындан берсенең сүнүе белән тирән хәсрәт эченә чумган хәлдә, кадерле дуст һәм алмашдырылмый торган ибдәшне югалткан дустларыбызның бөек кайгыларын уртаклашабыз.*

Әлмөхәммәдев, Габәши, Һилалов.

16. *Әстерхан. 10 март. Кадерле язучы Әмирханның вакытсыз үлеб китүенә Әстерханның партиясез укучы яшьләре исеменнән чын ихласыбыздан сыкранганлыгыбызны аңлатабыз. Аның татар әдәбияты, татар иҗтимагыяте алдындагы хезмәтләрен таныганлыгыбызны әйтеб үтү белән бергә, үлем аның тәнен алыб китсә дә, татар яшьләренең аңарга һәм аның хезмәтләренә булган бөек ихтирамын алыб китә алмас дибез.*

Имзалар: Гомәрев, Шәмсетдинов, Камалетдинов, Хәсәнев һәм башкалар.

**[54 бит]** 17. *Әстерхан. 11 март. Татарның бөек язучысы һәм татар кызларының хокукларын яклаучы әдибләрнең беренчеләрендән булган Фатих Әмирханның үлүенә без Әстерханның укуы кызлары үзебезнең тирән кайгы белән йөрәкдән кайгырганлыгыбызны белдерәбез.*

Имзалар: Курамшина, Сайганова, Гомәрева һәм башкалар.

18. *Әстерхан. 10 март. Йөзләгән татар халкының әхвале рухиясен һәм тормышын сурәтләнереб бирүче шагыйрь, рәссам, сатирик һәм әдиб мәрхүм Фатих Әмирханга үзебезнең мәнгелек соңгы сәламебезне күндерәбез. Уяну дәверен зур осталык белән*

[1] Мөтәәссир – кайгы-хәсрәткән төшкән.

*матурлаб язган Фатихның каләме киләчәкдәге татар әдәбиятына мәнге нур чәчеб торсын! Без аның бөек таланты, фикерләре, сүзләре һәм әдәби хезмәтләре алдында баш иябез.*

Фатих Шахмазов, Яһудин, Галим Шакиров,
Гата Баһаветдинов, Гани Ниязи, Борһан Бадамшин.

19. *Әстерхан. Татар әдәбиятының ифтихары булган Фатих Әмирханның үлүенә тирән кайгырабыз. Аның үлүе турындагы бу зур кайгылы хәбәр аның хезмәтләренә булган безнең ихтирамыбызны тагын артдырачак һәм аның исеме безнең күңелләребездә мәңге сакланачак.*

Урта мәктәб укучылары: Шакировлар,
Гомәревләр, Әбүталиповлар һәм башкалар.

20. *Сарытау. 10 март. Кадерле ибдәш һәм дуст Фатих Әмирханның вакытсыз үлүенә тирән кайгы белән кайгырам һәм үземнең күмү мәрасименә хәзер була алмавыма чын күңелдән тәэссеф*[1] *итәм.*

Зыя Янгаличев

**[55 бит]** 21. *Симферополь. 10 март. Татарның зур язучыларындан Фатих Әмирханның үлү хәбәре аның талантын тәкъдир итүче яшь кырымлыларны тирән бер кайгыга салганлыгын белдерәбез.*

Шакир Мөхәммәдияров, Озынбашлы, Чапчакчы,
(Мөгыйнев) Җәлал, бородәран Адабаш һәм Бикинлар, Җәббар.

22. *Симферополь. 10 март. Бөек мөхәррир Фатихның үлүе безне тирән кайгыга төшерде. Аның якынларының һәм аны тәкъдир итүчеләрнең кайгыларына уртаклашабыз.*

Мөфти Хаҗи Мөслихеддин.

23. *Уфа. 10 март. Тебя уже нет Фатих ибдяш*
*Прими привет последний наш*[2].

Сүнчәләй, Гафури, Исәнбәт.

24. *Уфа. 11 март. Милләтнең талантлы мөхәррире Фатих Әмирханны югалтуга чын күңелемдән кайгыруымны белдерәм.*

Мөфти Ризаэддин Фәхреддин.

---

[1] Тәэссеф – кайгыга төшү, үкенү.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

25. *Оренбург. 10 март. Губерна мәгариф шөгъбәсенең*[1] *вак милләтләр бүлегенә караган Тәрбия-тәгълим техникумының татарлар һәйәте*[2]*, кыйммәтле классик язучы Әмирханның үлүен зур югалту диб карый һәм шуңарга үзенең тирән кайгы белән кайгырганлыгын белдерә.*

Алиев, Шәркый.

26. *Ташкенд. 10 март. Матур стиль тудыручы кыйммәтле дуст Фатих Әмирханның вакытсыз үлүенә чиксез хәсрәтләнәм. Фатих Әмирхан исеменә фонд өчен 200 сум җибәрәм.*

Кәбир Бәкер.

**[56 бит]** 27. *Ташкенд. 10 март. Октябрьгә чаклы булган татар әдәбиятына бик күб кыйммәтле әсәрләр биргән татар язучысы Әмирханның үлүенә кайгырабыз.*

Урта Азия вак милләтләр Комуниверситетында эшләүче татар группасы исемедән: Абызов, Борһан Хәбиб.

28. *Иске Бохара. 10 март. Без ерак Бохарада торучы татарлар, үзебезнең хезмәт иясе булган татар халкының кадерле язучысы Әмирханны югалту кайгыларына кушылабыз. Без Совет хезмәтендәге партияле татарлар кыйммәтле язучы ибдәш Әмирханның күмү мәрасимендә була алмавыбызга бик үкенәбез. Бәхил бул бездән, безнең өчен багышланган татар әдәбиятының атасы – Әмирхан!*

Имзалар: Әбүзәрев, Әлмәшев, Кәмалов, Каина, Зәетев, Гизаков, Хәсәнев, Фатих Сөләйманов, Гомәр Җанов, Мәрзыя Җанова, Даутов, Габбасов, Әбләзинләр, Бурлик, Ишмөхәмитов, Иблиев, Хәирев, Таһиров, Самад Кандани, Гайшә Сөләйманова, Сәгъдиев, Дибирдиев, Юсупов, Нагаев, Фәһимә Нагаева, Хөсәенев, Рабига, Кинукиев, Ситдыйков, Нугаев, Хаммадов, Ибраһимов, Якупов.

29. *Иске Бохара. 11 март. Азад Бохара идарәсе татар халкы күбчелегенең бу көнге кайгысына кушыла. Без Фатих Әмирханны бары тик татар җәмәгатьче язучысы итдереб кенә түгел, бәлки бөтен Союздагы шәрык халыклары әдәбиятының пионеры итдереб хөрмәт итәбез.*

30. *Петропаул. 11 март. Әмирханның талантын тәкъдир итүчеләр исемендән аның вакытсыз үлеб китүенә кайгырганлы-*

[1] Шөгъбә – тармак, бүлек.
[2] Һәйәт – төркеме.

*гыбызны белдерәбез. Исеме Татарстанның мәркәзендә* **[57 бит]** *мәнгеләшдерергә мөстәхикъ*[1] *булган бу талант иясенең бөтен әсәрләре мәҗмугәсенең тиздән басдырылыб чыгарылуын һәм киң халык күбчелеге арасына таратылуын телибез.*

Габделҗәлилов (Галим Акчурин булса кирәк).

31. *Омски. 10 март. Яшьләр арасында искелеккә каршы көрәшү фикерләре таратучы һәм татарның матур әдәбиятын тудыручылардан кыйммәтле Әмирханның үлүенә бик нык кайгырам.*

Искәндәрев.

32. *Омски. 10 март. Мәдрәсә реформасы өчен беренче булыб көрәшкә чыккан һәм мәктәбкә кыйммәтле әсәрләр биргән Әмирханның үлүенә кайгырабыз.*

Омски мәктәбендә укучылар.

Монда тәрҗемә итеб күчерелгәнләрдән тыш янә «Кызыл Татарстан» гәзите идарәсенә дә байтака тәгъзия телеграмлары килгән. Боларның кайберләре гәзитдә чыгарылсалар да, байтагысы ни өчендер басылмый калдылар. (Җеназа укыб күмгәнгә булса кирәк. Чөнки идарәнең шуңарга ачуы килгәнлеге күмү мәрасименең ничек үткәнлеген язган номерында да ачык күренеб тора. 12 март). Бу гәзитдә басылмыйча һәм безгә күренмичә калган телеграмлар арасында Сәмәрканд, Ялта, Полторацки[2], Баку, Касыйм һәм башка шәһәрләрдән килгән телеграмлар бар иде диб риваять итделәр. Хәерле булсын.

## [58 бит] Күмү мәрасиме

12 март. Бүген атаклы әдибләребезнең иң сөеклесе булган Фатих Әмирханның гәүдәсен дөньядан озатдык. Бөтен Казан бөек җәмәгать хезмәтчесе булган Фатих Әмирханның үлүенә матәм тотды. Казанның бөтен татар җәмәгате аңарга үзенең ихтирамын күрсәтеб, җеназасы өстендә олуглау мәрасимен ясады. Бүген, бөтен каләм ияләребез, матбугат әһелләребез, изелгән татар халкының әхвале рухиясен[3], аның тормышын сурәтләндереб бирүче шагыйрь, рәссам, сатирик һәм татар әдәбиятында яңа матур стиль тудыручы әдиб Фатих Әмирхандан аерылыб, аңарга үзләренең

---

[1] Мөстәхикъ – хаклы, лаеклы.

[2] *Полтарацк – Ашхабад шәһәренең 1919–1927 еллар арасындагы рәсми атамасы.*

[3] Әһвале рухиясен – рухи дөньясын.

мәнгелек соңгы сәламләрен әйтделәр. Татарның сәнәгате нәфисә[1] ияләре, артистлары, тормышның ямсез якларын оста тәнкыйд белән сәхнәгә кергән, сәхнәне яңа типлар белән баеткан драматург Фатих Әмирхандан аерылдылар. Бу көн бөтен татар хатын-кыз дөньясы, татар кызының иң каты изелгән бер вакытында аның хокукын яклаб чыккан көрәшче Фатих Әмирханны озатдылар. Татарның бөтен мәдрәсә җимешләре, шәкерддән җитешкән кешеләре үзләренең уяну, ислахәт[2] дәверендәге юлбашчысын югалтдылар, кордашларының алдынгысындан аерылдылар.

Бүген Русиядәге бөтен төрк-татар халыкларының аңлы сыйныфлары, Фатих Әмирханны олуглаб аның таланты, фикерләре, сүзләре һәм әдәби хезмәтләре алдында баш иделәр.

Менә шундый аң, шундый хиссият, шундый тәгъзияләр белән Фатих Әмирханның гәүдәсе дөньядан озатылды. Күмү мәрасимендәге меңләрчә халыклар шушы нокталарны аңлаб аның җеназасына җыелдылар. Гәүдәсен озатдылар.

**[59 бит]** 12 март иртә белән сәгать унларда Фатих Әмирханның фатиры тирәсенә халык җыела башлады. Өй эчендә үзенең кардәш-ыруглары, дустлары, якын танышлары тулыб калдылар. Сәгать 11ләрдә урамда төрле милләтләрдән, төрле сыйныфлардан, ирләрдән, кыз хатынлардан, картлардан-яшьләрдән, хәтта укучы балалардан җыелган халык меңләргә җитде. Дистәләрчә атлар җыелды.

Шундан соң төрле оешмаларның, мөәссәсәләрнең[3], сыйныфларның, милләтләрнең вәкилләре, мәктәб шәкердләре һәм аерым кешеләр Фатих яткан бүлмәгә кереб үзләренең соңгы сәламләрен әйтеб саубуллаша башладылар. Ике сәгать тоташдан шушы халык бертуктаусыз кизү белән агылыб торды. Фатихны өендән алыб чыгар минут җиткәндә дә бу агым бетмәде. Сәламләшүчеләрнең очы-кырые күренмәгәнгә туктатылды. Ишек төбләрендәге почетлы сакчылар авырлык белән тәртиб куя алдылар. Чөнки халык һаман да сәламләшергә сорады.

Мөхтәсиб Касыйм хәзрәт Коръән укыгандан соң, комиссия тарафындан билгеләнгән кешеләр Фатихның гәүдәсен өендән алыб чыгыб табутка салдылар. Фатихның дустлары, кардәшләре табутны күтәреб Театр мәйданына юл тотдылар. Юлда мәктәб шәкертләрендән, укучылардан ике яклаб бау тартылды. Иң беренче

[1] Сәнәгате нәфисә – матур сәнгать.
[2] Ислахәт – реформалар.
[3] Мөәссәсәләрнең – оешмаларның.

рәсем Жуковский урам[ын]да алынды. Грузинский (Карл Маркс) урамына чыккач трамбайлар тукталдылар. Театр мәйданында төрле мәгариф, мәдәният оешмаларындан килгән халыклар, төркем-төркем мәктәб шәкердләре каршы алдылар. Шулар өстенә һәр якдан аерым-аерым кешеләр агылыб килделәр. Мәйдан каршындагы Комклуб бинасындан, съездның оешкан хәлдә дә һәм аерым-аерым вәкилләренең дә[1] чыкканы күренмәде.

Алдан билгеләнеб куелган Фәтхи Борнаш, Татарстан матбугат эшчеләре **[60 бит]** оешмасы, Гыйльми үзәк, Гажур, Дәүләт нәшрияты һәм шундагы гражданларча күмү ягында булган кешеләр исемендән диб митингны ачды. Ләкин монда гражданларча күмүгә бөтенләй каршы булган кешеләр дә бик күб, бәлки, иң зур күбчелек алар ягында иде.

Барлык халык мең ярым – ике мең чамасында иде. Бу халык Фатихны фәлән яки төгән төрле күмү ягында булганлыгы өчен түгел, бәлки ничек булса да аны олуглаб ихтирам итеб озату өчен җыелганлар иде. Һәрхәлдә митинг ачылды. Фотографчылар, кинематографчылар төрле якдан рәсемләр алдылар. Төрле оешмаларның вәкилләре тарафындан Фатих Әмирханны үзләренчә тәкъдир итеб, аның үлүенә кайгырыб сөйләүләр башланды:

1. Митингны ачучы Фәтхи Борнаш («Кызыл Татарстан»ның 14 нче март номерында басылды).
2. Күмү комиссиясе әгъзасы Ибраһим Биккол (Фатихның тәрҗемәи хәле).
3. Наркомпрос исемендән Фатих Мөхетдинев урысча телдә (14 нче март, «Кызыл Татарстан»).
4. Күмү комиссиясе әгъзасы Фатих Мөхәммәдияров. Авыруы турында.
5. Каләм эшчеләре исемендән Фатих Сәйфи (14 нче март, «Кызыл Татарстан»).
6. Гыйльми үзәк һәм укытучылар исемендән Мөхетдин Корбангалиев.
7. Гаскәри укучылар исемендән Булатов.
8. Урта мәктәбләрдә укучылардан Хуҗа Рәфыйков.
9. Татар артистларындан Кәрим Тинчурин.
10. Башкорд яшьләрендән Нури Таһиров.

---

[1] *Текстның «һәм аерым-аерым вәкилләренең дә» дигән өлеше карандаш белән өстеннән сызылган.*

сөйләделәр[1]. Митинг шуның белән ябылды. Артдан меңләрчә халык ияргән хәлдә, җеназаны Казанның партиясез татар укымышлылары күтәреб Проломный урамга төшеб китделәр. Юлда ике якдан сузылган бау белән шулук **[61 бит]** кешеләр тәртиб саклаб бардылар. Проломныйга җиткәч җеназа килгәнне каршылаб көтеб торган тагын бер зур төркем халык килеб кушылды. Ике яклаб тәртиб саклаб барыр өчен атлы милиционерлар килделәр. Күренеш зур бер манифестация рәвешен алды. Җеназаны күтәреб баручылар Кәрим Сәгыйд идарәсендә һаман да алмашына тордылар һәм ялңыз укучылар (студентлар), укытучылар, укымышлылардан гына күтәртелде. Мещан һәм рухани сыйныф кешеләренә бөтенләй бирелмәде.

Проломныйдан университет урамына борылыб, андан Печән базары урамы буенча Тукай урамына – Ак мәсҗед почмагына җиткәч җеназаны исәбсез күб халык каршы алды. Мондагы халык мең генә түгел, ун меңләб бар иде. Тукай урамы белән Татарстан почмагындан алыб Юнусовлар мәйданын узыб киткәнчәгә чаклы бөтен юл халык белән лыгрым тулы иде. Алма ташласаң җиргә төшмәслек дәрәҗәдә иде. Шуның өстенә урамның ике як йорт түбәләре чебен баскан кебек халык белән кабланган иде. Шул рәвешчә җеназаны атлы милиционерларның ярдәме белән юл ачыб, Юнусовлар мәйданындагы җеназа намазы укыла торган урынга китереб куйдык. Алдан хәзерләнгән фотографчылар кат-кат рәсем алдылар.

Җеназа өстендә сөйләүләр башланды. Иң элек Фатихның якын дустларындан: 1) Ибраһим Биккол, 2) Кәрим Сәгыйд, 3) Гыйльми Шәрәфләр, аннары татар укымышлыларындан: 4) Мостафа Туминов, 5) Казан кустарларыннан[2] – Биккинин, 6) Әстерхан яшьләрендән – Кадир Хуҗаев, 7) матур сәнәгать эшчеләрендән – Кәрим Тинчурин, 8) руханилардан – Габдулла мулла Әмирхани, 9) фән эшчеләрендән – Салих Корбангалиев, 10) хатын-кызлардан – Зөһрә Салиховалар сөйләделәр[3].

**[62 бит]** 14 нче март «Кызыл Татарстан» гәзитендә Фатих Әмирханны күмү мәрасиме турында язылган мәкаләдәге «Мул-

---

[1] *Бу кешеләрнең сөйләгәнләрен үзләрендән яздырыб алыб мәҗмугага кертергә ярый.*

[2] Кустарларыннан – һөнәрчеләреннән.

[3] *Бу кешеләрнең сөйләгәнләрен языб бару М. Галигә табшырылган иде. Ул шуларны языб «Татарстан» гәзитенә биргән. Анда басмаганлар. Югалтканлар. Үзләрендән бер нәрсә оешдырганлар. Шуңар күрә мәҗмугага кертергә булганда бу кешеләрнең үзләрендән яздырырга кирәк булачак.*

лануp Вахидов мәйданында» һәм «Зыяратлыкда» дигән кисәкләр бөтенләй чебчи ялган.

Озату мәрасименең иң зурысы, иң көчлесе Мулланур Вахидов (элекке Юнусовлар) мәйданында булды. Сөйләүләр беткәндән соң да очы-кырые күренмәгән шул халык бер таралмады. Иң аз дигәндә алты-җиде мең халык җеназа укыды. Шул вакыт коммунистлар җеназа укучы халык арасындан аерылыб чыга алмыйча буталыб калдылар. Чөнки андан һичбер ерыб чыгарга мөмкин дә түгел иде.

Җеназа укыгандан соң табутны Казан университетының медицина факультетында укучы татар студентлары үз кулларына алдылар һәм, каберенә чаклы һичкемгә бирмичә, үзләре генә нәүбәтләб күтәреб бардылар. Вахидов мәйданындагы халыкның бер меңләбе (иң азында) җеназа артындан кабергә чаклы килде. Артда иң азында утыз-кырык ат бар иде. Яңа Бистәгә җиткәч җеназаны тагын бер зур төркем халык каршы алды һәм алар да кабергә чаклы бардылар. Кабергә баручылар арасында Фәтхи Борнаш, Фатих Сәйфи, Рәфыйков кебек дистәләрчә җаваблы коммунистлар да һәм партиясез мәсьүл[1] совет эшчеләре дә бар иде.

Сәгать 4 нче яртыда Фатих Әмирханның гәүдәсе кабергә индерелеб үзенең ләхеденә куелды. Кабергә индерүчеләр һәм ләхедкә куючылар комиссия тарафындан билгеләнгән кешеләр булдылар. Кабергә индергәндә янәдән рәсем алдырылды. Ләхед такталарын Габдулла мулла Әмирхани тезде. Каберне үзенең дустлары, якыннары, кардәшләре күмделәр. Күмелгәндән соң 1) Кәрим Сәгыйд, 2) Шәһәр Шәрәф, 3) Ибраһим Бикколлар тарафындан соңгы сәлам сүзләре сөйләнде. Фатихның үзе **[63 бит[2]]**

## [64 бит] Фатих Әмирхан үлү уңае белән гәзит-журналларда чыккан мәкаләләр

1. «Татарстан» гәзите. 11 март, 58 нче номер. Фәтхи Борнаш мәкаләсе.

2. «Красная Татария» гәзите. 11 март.

3. «Кызыл Татарстан». 12 март. 59 нчы номер. Җәмал Вәлиди һәм И. Биккол мәкаләләре.

4. «Кызыл Татарстан». 14 март. 60 нчы номер. Күмү мәрасиме турында. Хәбәрче.

---

[1] Мәсьүл – җаваплы.

[2] Кулъязманың 63 нче бите юк.

5. «Кызыл Татарстан». 18 март. 63 нче номер. «Васыятем». Гумер.

6. Мәскәү «Известия»се. 17 март. № 62. Мирсәид Солтангалиев мәкаләсе.

7. Саратов. «Ялкын» гәзите. 19 март. Номер 9.

8. «Башкордстан» гәзите. 12 март. 24 нче номер. Ризван Ибраһимов.

9. «Азад Бохара» гәзите. 14 март. 32 нче номер.

10. «Төрекмәнстан». 14 март. 51 нче номер. Зыя мәкаләсе.

11. «Зәрәфшан». 18 март. 345 нче номер.

12. «Яңа дөнья». 27 март. 70 нче номер. Г. Нури мәкаләсе.

13. «Белем» журналы. Уфа. Март. 2–3 нче номер. М. Гафури.

14. «Эшче» гәзите. Мәскәү.

15. «Азад Себер» гәзите. 27 март. 10 нчы номер. Сарим Фәхри мәкаләсе.

16. «Яңа авыл» гәзите. Уфа. 11 март. 29 нчы номер. Ризван Ибраһимов.

17. «Коммунист» гәзите. Баку. 12 март. 61 нче номер. Казаннан телеграмма.

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*җитәкчесе Илһам Гомәров*
*һәм Санкт-Петербургтагы Европа университетының*
*Россия ислам халыклары тарихы буенча ТАИФ профессурасы*
*профессоры Әлфрид Бустанов әзерләде*

# Ф. ӘМИРХАН ТУРЫНДА ФӘННИ-ТӘНКЫЙДИ МӘКАЛӘЛӘР

## Ф. Әмирхан иҗади мирасы – текстологик тикшеренүләрдә

Дөньядан кичкән һәр иҗади шәхеснең язганнары рәсми яктан нәселен дәвам итүчеләр кулына күчсә дә, ахыр чиктә ул үз халкының мәдәни мирасына әверелә. Шунлыктан цивилизацияле илләрдә аларны саклау һәм файдалану, идентификация бурычы да алга килеп баса.

Татар әдәбиятының классик дәвере – XX гасыр башы чоры әдипләре язма мирасын өйрәнүнең дә гаять әһәмиятле бер тармагы – текстологик тикшеренү нәтиҗәләре нәкъ менә шул бурычны үтәүгә хезмәт итә. Ә инде мондый төр тикшеренүләрдә үзәккә куелып хәл ителергә тиешле мәсьәләләрнең иң мөһимнәре булып, язучы иҗат иткән барлык төр әсәрләрнең текстларын табу, атрибуцияләү, текстларның авторлары ирек-ихтыярына туры килү дәрәҗәсен ачыклау, басмага әзерләгәндә аларның укучы тарафыннан адекват кабул ителүен булдыру максатында фәнни шәрехләүләр (аңлатма һәм искәрмәләр – комментарий) язу тора.

Прозаик, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан 1926 елның 9 мартында бакый дөньяга күчкәч тә, аның иҗат мирасын бөтен тулылыгында өйрәнүгә керешү мөмкин булырга тиеш иде. Әмма 1920–1940 елларда татар әдәбиятының барыннан да бигрәк яңа шартларда үсеше турында сүз алып барылганда, классик мирасны өйрәнү арткы планга күчкән иде, бу марксистик-ленинчыл идеология басымы Октябрьгә кадәрге әдәби мирасны бөтен байлыгында, катлаулылыгында өйрәнүне өнәмәде. Мисал өчен ерак китеп карыйсы юк, Ф. Әмирхан әсәрләре җыентыклары вафатыннан соңгы ун-унбиш ел эчендә бер генә мәртәбә дә басылмады. Тик вафатына унбиш тулуны искә алып булса кирәк, 1941 елда Татгосиздат аның совет чорында беренче мәртәбә «Сайланма әсәрләр»ен бастырып чыгарды (төзүчесе – Афзал Шамов). Кереш сүзне язган Хәсән Хәйри әдипнең «иң яхшы әсәрләре критик реализм белән сугарылганнар» дип санавы белән бергә,

бу реализмның буржуа реализмы булуын, «критикасы да эзлекле, тулы булмавы»н әйтә. Аныңча, Ф. Әмирхан реакция елларында, Беренче бөтендөнья сугышы чорында хәтта ки демократик әдәбиятка каршы позициядә дә торган. Ул сүзен җыентыкка «язучының иң характерлы, иң яхшы, хәзерге укучы масса өчен дә әһәмиятен югалтмаган әсәрләр» тупланыуын әйтеп тәмамлый. Җыентыкка төрле жанрларга караган 15 текст кертелгән: болар – повестьлар, хикәяләр, «Яшьләр» пьесасы. Һәр әсәр ахырына иҗат ителү датасы гына куелган. Аларның кайсы басмадан алынып басылуы әйтелми, әмма җыентык ахырындагы М. Бурнашева төзегән «Фатих Әмирхан әсәрләренең библиографиясе» бу мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертә. Анда әдипнең 33 китабы, вакытлы матбугатта басылган 27 хикәя һәм очеркы, 42 тәнкыйть мәкаләсе, рецензия һәм истәлегенең исемнәре, басылу урыннары күрсәтелә.

Ф. Әмирханның әдәбиятта чын-чынлап үз урынына кайтарылу факты итеп тагын унбиш-уналты елдан соң «Сайланма әсәрләр» рәвешендә генә булса да басылып чыккан ике томлыгы бәяләнергә тиеш. Аның беренчесен Афзал Шамов, икенчесен Хәй Хисмәтуллин төзегән иде. Аларда Әмирханның төп проза һәм драма әсәрләре беренче мәртәбә аңлатма һәм искәрмәләр белән бирелә. Әмма кайбер текстларга кыскартулар ясала. Шулай да бу ике томлык утыз ел чамасы укучылар, галимнәр өстәлендә булып, аның иҗаты белән кызыксынуны шактый дәрәҗәдә канәгатьләндереп килде.

1976 елда Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында текстология төркеме оештырылганнан соң, классикларыбызның мирас басмаларын фәнни-текстологик принципларны кулланып әзерләү җайга салына башлады. Олы юбилейлары якынлашуны да истә тотып, Мәҗит Гафуриның дүрттомлы, Һади Такташ һәм Галиәсгар Камалларның өчәр, Габдулла Тукайның биштомлы басмаларын матбугатка әзерләү эшен берничә ел алдан ук хезмәткәрләрнең фәнни-тикшеренү планнарына кертергә мөмкин булды. Нәкъ шул вакытларда чиратта торган эшләрнең берсе рәвешендә Фатих Әмирхан мирасын барлау мәсьәләсе дә алга килеп баскан иде. Ниһаять, хәтерем ялгышмаса, 1981 елда Фатыйма Ибраһимова, Наҗия Садыйкова, Зөфәр Рәмиев һәм Марсель Әхмәтҗановлар бу әдипнең күптомлыгын төзергә керește. Беренче томына хикәяләрен һәм тәрҗемәләрен, икенчесенә – повесть, роман һәм драмаларын, өченче томга – публицистикасын, соңгысына тәнкыйть мәкаләләрен, автобиографик язмаларын һәм хатларын

урнаштыру планлаштырылган иде. Әйтергә кирәк, бу юлы Әмирханның Институт мирасханәсендә (хәзер: Язма һәм музыкаль мирас үзәге) саклана торган шактый бай шәхси архивына зур игътибар бирелде, нечкәләп өйрәнү нәтиҗәсендә кайбер тәмамланмаган әсәрләр, фрагментлар да томнарда урын алырга лаек дип табылды. Текстларга язылган аңлатма һәм искәрмәләр дә шактый баеды. Алар аеруча 3 нче һәм Марсель Әхмәтҗанов төзегән 4 нче томда зур күләм алып тора. Әмма шулай да совет чорында хакимлек иткән идеология басымы астында эшләнде бу мөһим эш. Текстларның кайбер урыннарын кыскартырга, «Шәфигулла агай» кебек әсәрләрен читтә калдырырга туры килде, 1921–1926 елларда язып барган гаять кызыклы көндәлекләре дә тулысынча кертелмәде. Кыскасы, Ф. Әмирханның бу дүрттомлыгы, бүгенге күзлектән чыгып караганда, шактый дәрәҗәдә кимчелекле. Ул Фатих Әмирхан дигән феноменны бүгенге укучыга бөтен байлыгында ачып бирә алмый[1]. Чыгуына инде утыз ел чамасы вакыт узып киткән, без инде бөтенләй башка иҗтимагый тормышта, демократия шартларында яшибез. Әмма әдипнең 120 еллыгы да, быелгы олы юбилеен да әсәрләренең яңа, тулыландырылган басмасы белән билгеләп үтелми.

Быел Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галим-текстологлары Габдулла Тукайның 130 еллыгына зур фәнни эшне төгәлләп каршыладылар: Татарстан китап нәшрияты бөек шагыйребезнең алар тарафыннан текстология фәне принципларын эзлекле һәм төгәл кулланып төзелгән алты томлы «Әсәрләр. Академик басма»сын бастырып чыгарды (2011–2016). Институтның текстология бүлегендә 2013 елдан бирле Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең дә унбиш томлы академик басмасы әзерләнүе дә күпләргә мәгълүм. Аз санлы, алты-җиде кеше составында гына гаять зур эшләр башкарып килгән текстологлар коллективы, аны төзүне якындагы өч-дүрт елда тәмамлый алса, минемчә, ниһаять дип әйтергәдер, Фатих Әмирхан әдәби мирасын тулысы белән, нәкъ менә академик басма тибында (рәвешендә) әзерләүгә дә керешергә тиештер. Әйтергә кирәк, Гаяз Исхакый унбиш томлыгын әзерләгәндәге кебек, бу очракта да аны төзү җиңел бармас. Бәлкем, кабатлана торганмындыр да, әдипләребезнең фәнни библиографияләре төзелмәгән хәлдә эшкә тотынабыз. Беренче авырлык – шунда. Ф. Әмирханның башлыча «Әл-ислах», «Кояш» га-

[1] Бу турыда Равил Әмирхановның «Классик мирас тирәсендә уйланулар» исемле мәкаләсендә тәфсиллерәк әйтелә [Әмирхан, 1997, б. 332–345].

зеталарында еш басылган, һәрвакытта да иясе инде мәгълүм, ачык имза белән генә түгел, аноним рәвештә дә. Хәзергә аның ике дистәгә якын яшерен имза кулланганы билгеле. Бу сан да үзгәрергә мөмкин, ул җигелеп эшләгән газеталарны җентекләп тикшереп, өйрәнеп чыкканда, аның әлегәчә мәгълүм булмаган башка имзалары да, имзасыз басылган текстлары да табылачак. 1986 елда Казан педагогия институтында узган, Ф. Әмирханның 100 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференциядә Уфа профессоры Үзбәк Гыймадиев Ф. Әмирханның «Ялт-йолт» журналларында «Имгәк», «Әүлияуллаһтан бер залим» һәм «Хәсрәт» псевдонимнары белән дә еш язышканын сөйләгән иде. Әмма мин конференциядә аларны Әмирханныкы итеп санауга шик белдердем һәм соңрак, үземчә дәлилләп, бу турыда мәкалә дә чыгардым. Кыскасы, псевдонимнарны ачканда нык ышанычлы дәлилләргә генә таянырга кирәк. Югыйсә, бездә кайчак моңа кадәр авторы ачыкланмаган теге яки бу текстны «бөтен стиле фәләннеке» дип кенә томнарга кертеп җибәрү очраклары да бар.

Мәгълүм дүрттомлыкның өченче томын мин төзегән идем. Ул вакытка миндә Ф. Әмирхан авторлыгы шикләндерми торган материал шактый җыелган иде. Әмма әлеге дә баягы, совет идеологиясе басымын тоеп тору, җитмәсә, томның күләме һәм аны әзерләүгә бирелгән вакытның чикләнгәнлеге аркасында байтак мәкалә һәм фельетонны читтә калдырырга туры килде... [бу турыда: Рәмиев, 1987, б. 46–53; З. Рәмиев доклады].

Озак еллар эшләнеп килгән, 2300 мәкалә һәм белешмәне эченә алган Тукай энциклопедиясе, ниһаять, быел басылып чыгып дөнья күрәчәк. Азмы-күпме тәҗрибә дә тупланды. Ә бит мондый типтагы хезмәтләр Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, М. Җәлилләр турында да булырга тиешледер. Һәм беренче чиратта Фатих Әмирханга багышланганы төзелсен иде.

**Әдәбият**

*Әмирхан Р.* Иманга тугрылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

З. Рәмиев доклады: Ф. Әмирхан һәм «Кояш» газетасы. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтының 1883 елгы йомгаклау конференциясе. 1984 ел. 16 январь.

*Рәмиев З.* Ф. Әмирхан публицистикасын текстологик өйрәнү юлында / Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш. Казан, 1987. Б. 46–53.

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

## И. Нуруллин тәнкыйтендә Фатих Әмирханның проза әсәрләренә бәйле карашлар

Әдәби тәнкыйтьтә Тукайның замандашы, дусты Фатих Әмирхан иҗатына тиешле күләмдә игътибар бирелми. Ике бөекнең 1907–1913 еллардагы яшәешләре бер-берсенә нык бәйләнгән, аралашкан кешеләре, уй-фикерләре уртак булу сәбәпле, Ибраһим Нуруллин, Тукайның тормышын өйрәнгәндә үк, Әмирхан турында да мәгълүматлар туплый. Ул әдипне белүчеләр, туганнары белән очрашып, истәлекләр, фоторәсемнәр җыя (Әмирханның сөйгән кызы Шәмсенисаның да рәсемен таба), архивларда утыра, Ялтага барып Фатих Әмирхан дәваланган шифаханәне күреп, әдипкә хезмәт күрсәткән шәфкать туташларының берсенә тап була. Ф. Әмирхан турында хезмәтне язуга галим 1980 елда керешә. И. Нуруллинның «Фатих Әмирхан» китабы 1988 елда татар телендә чыга һәм «Прометей из Ново-Татарской слободы» (1991) исеме астында рус теленә дә тәрҗемә ителә. Әлеге китаплары өчен галим Гаяз Исхакый премиясе белән бүләкләнә.

И. Нуруллинның «Фатих Әмирхан» хезмәтендә әдипнең күп кенә әсәрләре бәяләнә, анализлана, уңышлы яклары, әдәбиятка алып килгән яңалыклары күрсәтелә. Галим Фатих Әмирханның һәр әсәренә аерым туктала, үз фикерләрен дәлилләр белән нигезли.

Әйтик, Ф. Әмирханның «Кадерле минутлар» әсәре турында игътибарга лаеклы фикерләр бар. Хикәянең эчтәлеге студент Рәшат авызыннан сөйләнгән өч мәхәббәт тарихыннан гыйбарәт. И. Нуруллин соңгысының Серноводск белән бәйле булуын әйтеп уза.

Тәнкыйтьче әсәрдә урын алган вакыйгаларны, мәхәббәт маҗараларын Ф. Әмирханның үз тормышыннан алынган дип нигезли. Яңа гына өлгергәнлек аттестатына имтихан биреп бетергән Рәшат, аяклары авырта торган әбисенә юлдаш һәм ярдәмче сыйфатында, Самара ягындагы күкертле су санаториена килә һәм электән таныш булган Хәерниса карчык, аның ике кызы – Разия белән Мәрьямне очрата. Үсмер чакларында аралашкан Разиянең зифа гәүдәле, чибәр кыз булып өлгерүе Рәшатта матур хисләр уята. И. Нуруллин озын кара керфекле коңгырт күзле сылу Разияне Ф. Әмирхан тормышында билгеле урын алып торган Шәмсенисага охшаш дип таба. Шәкерт чакта Фатих аның белән аралаша, шаярыша, үчекләшә торган була.

Шулай да әсәрдәге вакыйга-хәлләрне, мәхәббәт тарихларын тормыштан гына алынган дип уйларга ярамый, язучы фантазиясе белән тудырылган, үзгәртелгән өлешләр дә бар, дигән фикер җиткерә тәнкыйтьче. Коляскадагы Фатих белән яшьлектән, саулыктан, гимназия тәмамлау куанычыннан канатланган Рәшат арасына тигезлек билгесе куеп булмаган кебек, Разияне дә Шәмсенисаның күчерелмәсе итеп карарга ярамый. Аларның Серноводскидагы аралашулары, билгеле, нәкъ хикәядәгечә була алмаган. Тулып, пешеп җиткән Шәмсенисаны кабат күргәч, Фатихның гаҗәпләнү катыш соклануы, таң калуы, кызның тышкы матурлыгына тиң эчке матурлыгын да абайлап алгач, башын җуяр дәрәҗәдә гашыйк булуы исә хак. И. Нуруллин Рәшатның күп кенә кичерешләре, һичшиксез, Фатихның үзенеке булуын ассызыклый.

Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» хикәясен галим язучының беренче оригиналь иҗат җимеше булуын искәртә. Әлеге әсәрнең, хикәя булудан бигрәк, әдәби чаралар кулланып язылган публицистика икәнлеген дә билгели. Без хәзерге вакытта еш кына очраклы куелган формалар белән очрашабыз, И. Нуруллин тамгалаган жанр формалары һәрвакыт ышандырырлык итеп дәлилләнә бара.

И. Нуруллин монда буржуаз милләтчелек, татар милләтен бүтән милләтләргә каршы кую юкмы, дигән сорау да куя. Шул сорауларга җавап та бирә: *«Бу вакытттагы дөньяга карашын яхшы белгәнгә, кистереп җавап бирә алабыз: юк, һич юк! Беренчедән, болар яңа гына күзе ачылган шәкерт хыяллары. Икенчедән, яшь автор, героеның уй-тойгыларын беркадәр уртаклашса да, милләтне милләткә каршы куймый, мәгърифәтче буларак (әйе, ул мәгърифәтче дә бит әле), татарларны алга киткән милләтләр дәрәҗәсенә күтәрү турында хыяллана* [Нуруллин, б. 120].

Ф. Әмирхан сурәтләү объекты итеп иске тип татар сәүдә буржуазиясенең арурак вәкилен сайлап алган, бик үк карага буямый гына үзенчә яшәргә, үзенчә гамәл кылырга юл куйган, героена карата антипатиясен сиздерми генә, акрынлап эчке дөньясын ачып биргән, дипраслый тәнкыйтьче. И. Нуруллинның һәр бәяләмәсе, һәр мөнәсәбәте гадәттән тыш төгәллеге белән истә кала.

Ф. Әмирханның сатирик әсәрләрен дә аерып күрсәтә, бәя бирә И. Нуруллин. «Замана хикәяләре»нең беренчесендә без эчкә яшерелгән сатира булуын; «Милләт тәрәккый иттерү»нең ачыктан-ачык сатира икәнлеген; «Танымаганлыктан таныштык»

хикәясендә дә тышы яңа, эче иске булган байбәтчәнең колоритлы сатирик образлары өстенлек алуына басым ясый. Моннан соң тагын берничә яхшы сатирик хикәя язу белән бергә, «Фәтхулла хәзрәт» дип исемләнгән сатирик повестен дөньяга чыгарып дан казанды, дип билгели галим. «Фәтхулла хәзрәт» повестьтындагы Фәтхулла хәзрәт образының да тормыштан алынганлыгы, аның прототибы Йосыф хәзрәт булуын да язып үтә Ибраһим ага. Бер яктан, мажаралылыгы, уйдырма күренешләре белән укучыны тартып торган, икенче яктан, яшәп килгән җәмгыятькә тәнкыйди караш та ташлаткан әлеге әсәрнең формасын башкача билгеләп тә булмый. Галим, Ф.Әмирхан әсәрләренең формасын атау-дәлилләү белән генә чикләнми, беррәттән, аларга карата бәяләмәле җөмләләр дә язып үтә. Шунысы игътибарга ташлана: И. Нуруллин Ф. Әмирхан прозасыннан тулаем канәгать һәм аның һәрбер әсәрен камиллек үрнәге буларак бәяли.

Галим Ф. Әмирхан иҗатында юмор һәм сатираның ни өчен шундый зур урын тотуын да дәлилле, төгәл ачыклый. Бу иң элек, әдипнең табигате, характеры белән бәйле, дигән фикергә туктала. «*Тумыштан зирәк, үткен һәм тапкыр; гыйлем-мәгълүматы тиз арту белән бәрабәр рухи яктан да тиз өлгерде; болай да үчекләүгә, ирештерергә, мыскыл итүгә һәвәс яшүсмер, тора-бара үзенең өстенлеген тоеп, искелек күренешләренә, аның тәрәкләренә ачы көлү, ирония белән карарга күнегеп китте. Икенчедән, тормыш үзе, тарихи барыш аны сатира каләмен эшкә җигәргә кушты»,* [Нуруллин, б. 125] – дип яза галим.

И. Нуруллин типик характерлар иҗат итеп, аларны типик хәлгә куеп күрсәтү, мәгълүм булганча, җитлеккән реализмның төп сыйфаты дип билгели.

И. Нуруллин Фатих Әмирханның «Татар кызы», «Хәят», «Рәхәт көн», «Кадерле минутлар» әсәрләрен аеруча игътибар үзәгенә алып тикшерә. «Фатих Әмирхан» китабының «Кояшлы һәм болытлы көннәр» дип аталган бүлегеN галим тулысынча әдип иҗатындагы татар кызы образын анализлауга багышлый. Әлеге бүлектә хатын-кыз иреге проблемасы күтәрелә. «Татар кызы» әсәренең жанрына карата да тәнкыйтьче үз фикерен әйтә. «Татар кызы», автор үзе «хикәя» дип атаса да, чынлыкта хикәя дә, повесть та түгел. Чөнки анда индивидуальләштерелгән персонажлар булмаган кебек, бер вакыйгага нигезләнгән сюжет юк. Әсәрдә Татар кызы һәм Кара көч, Биктимер образлары хәрәкәт итә. Соңгы-

сы – «татар кешесе» дигән мәгънәне аңлата торган җыелма образ буларак анализлана.

Әлеге әсәрнең жанр үзенчәлекләренә дә туктала галим: *«Талантлы каләм белән көчле язылган публицистик нәсер бу. Анда ике зур проблема – татар хатын кызларының гасырлардан килә торган аянычлы язмышы һәм реализмның үзәк мәсьәләсе, ягъни шәхеснең уй-тойгысын һәм эш-гамәлен иҗтимагый тирәлек билгели дигән мәсьәлә күтәрелгән. Формасындагы яңалыктан тыш, әнә шундый күп сыйдырышлыгы әсәрне, күрәсең, авторның күңеленә якын иткән»* [Нуруллин, б. 142].

Татар хатын-кызының аяныч хәле үзәк мәсьәлә булып формалаша. Ф. Әмирханның күп кенә хикәя, повестьларында Татар кызы үзенә генә хас гадәт-фигыле булган шәхес рәвешендә хәрәкәт итә. И. Нуруллин Ф. Әмирхан әсәрләрендәге хатын-кыз образларын үзәк бер «җепкә тезеп», аларның ни рәвешле үстерелә бару тәртибен ачыклый: «Рәхәт көн» (1910) хикәясендә кызның дүрт стена эчендә ир көтеп утырган чагы. Кара көч Гайнижамалның фикер даирәсен шулкадәр зурайткан һәм зәвыгын тупасландырган, укымышлы Закирга күңеле төшкән булса да, татлы телле приказчикны ир булырга кулайрак саный. «Кадерле минутлар» хикәясендә (1912) аны яңа гына ир йортына бикләп куйганнар. Элек сөеп йөргән егете белән көрешергә үзендә көч тапкан Хөршид җанлы курчакка әле әверелеп җитә алмаган. Әмма бу соңгы тыпырчыну гына. «Яшьләр» пьесасында инде фәрештәдәй Фәхернисаның, еллар үткәч, надан, зәһәр һәм килделе-киттеле хатынга әверелүен билгели тәнкыйтьче.

Галим «Хәят» әсәрендәге Хәят образына да характеристика биреп китә, «Татар кызы» әсәрендәге героиня белән чагыштыра. Беренче карашка, Хәят без белгән Татар кызына охшамый. Ул, татарлар аз яши торган шәһәрдә, рус купецлары һәм чиновниклары белән эш йөртә торган сәүдәгәр гаиләсендә туып, чагыштырмача иркен үскән. Европача киенә, русча чиста сөйләшә, алты ай дәвамында русча да укыган. Лиза исемле рус кызы белән дус. Рус егетләре белән аралашудан, дачада күңел ачудан, театрга һәм танцыга йөрүдән дә аны тыймыйлар.

Нәсердәге Татар кызына бик үк охшамаган Хәятны да иҗтимагый тирәлек, ягъни феодаль-патриархаль яшәеш кагыйдәләре һәм буржуаз исәп-хисап, «җанлы курчак» ясарга әзерли. Моның өчен ул аның акылын, фикерен, карашын аңлап, бәхет өчен көрәшергә сәләтсез иткән, үз белдегенчә яшәр өчен хыял дөньясын

гына калдырган. Татар кызлары бәхетле булсын, кешечә яшәсен өчен, димәк, җәмгыятьне тамырыннан үзгәртеп корырга кирәк. Повесть әнә шундый тәнкыйди реализм әсәреннән генә чыга ала торган нәтиҗәгә китерә. Безнең карашыбызча, галимнең әлеге фикере белән килешмәскә дә мөмкин. Бүгенге көнбатышка йөз тоткан, фән-техника үсеше чорында нәкъ менә милли, рухи байлыкларга кытлык булган заманда әлеге әсәрне бүтән яссылыктан анализлап карау ихтыяҗы килеп туа.

И. Нуруллин тәнкыйтенең бүгенге көн тәнкыйте белән чагыштырып карыйк. Мәсәлән, «Хәят» повестен Д.Ф. Заһидуллина да бәяли: «*Язучы XIX–XX гасыр чиге татар дөньясында үз идеалын чагылдырган тормыш таба алмаячагын белә, шуңа күрә бик бай татар гаиләсе Рәхимовларның да кызлары сайлау хокукыннан мәхрүм икәнлекне ассызыклый. Шулай итеп, татар яшьләре хәятның ахыр чиктә иске җәмгыять кануннарына, йорт кысаларына, ямьсезлек эченә кереп бикләнергә мәҗбүрлеген белдерә, йортның тарлыгына, берьяклылыгына борчыла һәм моны үзгәртү – башка, идеаль тормышка ирешү мөмкин икәнлекне искәртә*» [Заһидуллина һ.б., б. 111].

И. Нуруллин «Хәят»нең икенче кисәге язылу-язылмау хакында тикшеренү эшләре алып барган. Ул чынлап та язылган икән, кульязмасы 1926 елга кадәр исән-имин булган, дип яза галим. Икенче кисәк язылып бетмәгәне хак, ни өчен ахыргача язылмавы билгесез. «*Ф. Әмирханның алдан сызган планы буенча, Хәят каен энесенә гашыйк булырга һәм аның белән берлектә атасы йортына качып китәргә тиеш*» [Нуруллин, б. 149] була.

И. Нуруллин Ф. Әмирханның әлеге әсәренә карата басылган тәнкыйть мәкаләләрен дә барлый. Мәсәлән, М. Укмасиның «Хәят» әсәренә кагылышлы тәнкыйте белән килешмәвен белдерә.

Г. Ибраһимовның рецензиясе дә төгәл түгел дип бәяләнә Ибраһим ага тарафыннан: «*Г. Ибраһимов рецензиясе болай зарарсыз. Ф. Әмирхан, ди ул, татар тормышының моңарчы өртүле хәлдә калган ягын күрсәтеп бирә, әдәбиятта яңа хәдисә ача, каһарманнары турында үзе сөйләү белән мавыкмыйча, холык-табигатьләре кушканча яшәргә, гамәл кылырга ирек бирә, тасвиры җиңел һәм ләззәтле. Әнә шулай мактап килә дә, мичкәдәге балга бер кашык дегет тондыра:*

*– Әсәргә «милли хикәя» диелгән. Мин моның яңлышлыгы хакында кул кисеп бәхәсләшә алам.*

*– Хәят тибының табигый икәнлеге хакында да бик зур шөбһә бар* [Нуруллин, б. 150].

Фатих Әмирханның «Габделбасыйр гыйшкы» хикәясен (кечерәк повесть дисәң дә ярый) кайчан кәгазьгә төшерә башлагандыр, әйтеп булмый, соңгы нокта куелган көне 31 июль дип билгеләнә автор тарафыннан.

Әлеге әсәргә И. Нуруллин үз бәясен бирә: ашык-пошык язылуына, басмага кисәкләп тапшырылуына һәм кабат эшкәртелмәвенә карамастан, «Габделбасыйр гыйшкы» повесте шедевр булып саналуын әйтеп китә.

Галим Габделбасыйрның социаль тип кына түгел, бәлки психологик тип та булуына игътибар итә һәм әлеге образны Хлестаков белән Обломов, шулай ук бүтән төргә караган Молчанин, Манилов, Гамлет, Тартюф, Июдушка, Головлев һ.б. кебек үк, гомумкешелек тибы буларак та тиңләштереп була дип саный.

Фатих Әмирханның «Урталыкта» романынын да тәнкыйтьче әдипнең тормышы белән бәйле дип таба, уртак якларны ачыклый. Әйтик, әсәргә Сергей Николаевич Гассар дигән чиновник гаиләсендә туып, гимназия тәмамлаган шәхес кертелгән булуы ассызыклана. Ф. Әмирхан аннан рус теле дәресләре алган. «Урталыкта» романында Гассар турында беркадәр мәгълүмат бар. Галим Ф. Әмирхан әсәрләренең «каһарманы» Хәсән Арслановны аттестатка әзерләүче студентның исемен дә үзгәртүне кирәк тапмаганлыгын искәртә.

И. Нуруллин Ф. Әмирханның «Сүнгәч» хикәясенең финал өлешенең гаҗәеп мәгънәле булуын билгели. Тәнкыйтьче трамвайда бергә туры килгән Шакир белән Әсманың ерак танышлар кебек кенә сөйләшеп, берни булмагандай аерылуларын гаҗәп дип таба. Хикәянең «яза башлап ташланган бер хикәядән» дигән искәрмә белән басылуы да галим тарафыннан әсәрнең тагын бер уңай ягы дип күрсәтә. Димәк, бу язма – ниндидер әсәрнең тик башламы, әйтик, экспозициясе.

И. Нуруллин югарыда саналган әсәрләрнең һәркайсына кагылышлы фикер әйтә, анализ ясый. Әсәрләрнең тарихи җирлеге, нинди шартларда язылуы да ачыклана.

Ибраһим Нуруллин әдипнең биографиясен өйрәнеп, иҗатын тикшереп, беркем дә игътибар итмәгән яңа якларны ача, үзенчә бәя бирә, нәтиҗәләрен һәрвакыт һәр кеше ышанырлык итеп фәнни мисалларга таянып дәлилли. XX гасыр башы әдәбиятында

күренекле урын тоткан Фатих Әмирханның прозасын берьяклы гына анализламый, ул аны биографиясе, җәмгыятьтәге урыны, дәрәҗәсе, кешеләргә булган мөнәсәбәте белән берлектә өйрәнә һәм сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә чагылдыра.

**Әдәбият**

*Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р.* Әдәби әсәргә анализ ясау. Казан: Мәгариф, 2005. 111 б.

*Нуруллин И.* Фатих Әмирхан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 280 б.

*Л.М. Тимерова,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

## XX йөз башы төрек-татар әдәби багланышлары яссылыгында Ф. Әмирхан иҗатын өйрәнү

XXI гасыр башында – Татарстан белән Төркия арасындагы сәяси, икътисади, мәдәни, әдәби мөнәсәбәтләр тагы да ныгый төшкәч, татар әдипләренең иҗатларында төрек әдәбиятының тәэсирен киңрәк һәм тулырак өйрәнү мөмкинлеге туды. 1990 нчы еллардан башлап төрек галимнәренең да аеруча XX йөз башы төрек-татар әдәби багланышларын өйрәнүгә кызыксынулары көчәйде. Шуның бер мисалы буларак, 2015 елда дөнья күргән галим Хөсәен Барганның «Яңарыш дәвере төрек әдәбиятының Идел-Урал өлкәсендәге татар әдәбиятына тәэсире» хезмәтен күрсәтергә мөмкин [1]. Әлеге докторлык диссертациясендә галим XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар әдипләре Йосыф Акчура, Фатих Кәрими, Габдулла Тукай, Закир Рәмиев, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал кебек әдипләр белән беррәттән, Фатих Әмирхан иҗатын да төрек әдәбияты яссылыгында тикшерүгә аерым бер бүлекчә багышлый. Хезмәттә Ф. Әмирхан әсәрләре Тәнзимат әдәбиятының гареб, аерым алганда француз мәдәнияте белән мавыккан сәрвәти-фөнүн (гыйлемнәр бакчасы) чоры әдипләренең иҗатлары янәшәсендә яктыртыла. Татар әдибенең ауропалашуга йөз тоткан «Гарәфә кич төшемдә» (1907), «Картайдым» (1909), «Татар кызы» (1909), «Хәят» (1911), «Кадерле минутлар» (1912) кебек әсәрләрен XIX йөз ахыры төрек әдәбияты тәэсирендә язылуына ишарә итә.

Чыннан да, XX йөз башы татар әдипләре госманлы вакытлы матбугатын алдырып, кардәш милләтләрнең иҗтимагый-сәяси вәзгыяте белән даими танышып барганнар, төрек әдәбиятын

кызыксынып укыганнар һәм татар теленә тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнгәннәр. Чоры өчен табигый булган әлеге күренеш Ф. Әмирхан каләменә дә тәэсир итми калмаган. Әдип үз иҗатының беренче елларында ук төрек темасына мөрәҗәгать итә. Аның «Тәрбиятел этфаль» («Балалар тәрбиясе») журналында Хәйдәр паша (госманлы вәзире) сурәте, Айя-Суфия, Солтан Әхмәт мәчетләре, Босфор бугазы күренешләре белән бизәлгән «Истанбул шәһәре» (1907) исемле публицистик мәкаләсе дөнья күрә [2]. Алга таба да язучының публицистик эшчәнлегендә Төркия темасы даими чагылыш таба. «Турецкий сборник» (1909), «Төрек милләтчелеге вә Русия Советлар власте» һ.б. мәкаләләре шул турыда сөйли. Төрек галиме, Ф. Әмирханның публицистикасына гомуми күзәтү ясаганнан соң, язучының хикәяләрендә төрек Тәнзимат әдәбияты белән уртак мотивларның еш очравына аерым тукталып, мисаллар ярдәмендә исбатлауга ирешә. Аның фикеренчә, Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» (1907) сатирик хикәясе XIX йөз азагы төрек мәгърифәтчесе, язучы Нәмык Кәмалның «Руя» («Төш», 1869) әсәренә нигезләнеп иҗат ителгән. Төрек әсәре 1907 елда Зыя Насыйри тарафыннан татарчага тәрҗемә ителеп, Казанда «Мәгариф» көтепханәсе, И.В. Ермолаева лито-типографиясендә басылып чыга [3]. Шул ук елда Ф. Әмирханның төрек әсәрендә күтәрелгән тема, проблеманы яктырткан «Гарәфә кич төшемдә» хикәясе дөнья күрә. Бу фактлар төрек галименең фикерен ныгытуга бер дәлил булып тора. Төрек хикәясендә төп геройның төшендә күктән фәрештәдәй сылу кыз төшә һәм халыкны ачык күз белән йоклап йөрүләре – аң-белемгә битарафлыклары, изелүгә каршы тормаулары, хөрлек өчен көрәшмәүләренә рәнҗеш белдерә, сүгә, милләтнең артта калуын мәгърифәтсез булуда күрсәтә, халыкны куркаклыкта гаепли: «Йоклаңыз! Йоклаңыз! Хәят вә гафләтне үлем йокысына алмашдырыр өчен мондый ансат юл юкдыр», – ди. Ә Ф. Әмирхан героеның төше (идеалы) реаль татар милли җирлегенә каршы куела. Төштә автор милли тормышның алга киткән чорын күзалдына бастыра, татар зыялыларын бергә җыя; газета-журналларда татар галимнәренең һәм сәнгать әһелләренең зур уңышлары турында мәкаләләр укыла. Татар язучысы төрек әсәренә сукырларча иярми, бары «төш» символы ярдәмендә ике милләт өчен дә хас кимчелекле иҗтимагый-мәдәни вәзгыятьләр яктыртыла. Н. Кәмал һәм Ф. Әмирхан хикәяләрендә укучыны милли уянуга чакыру алгы сызыкка чыга.

Шулай ук Х. Барган «Чәчәкләр китерегез миңа (тәгъзия)» (1920) белән төрек әдибе Халид Зыяның «Мәзардән сесләр» хикәясе арасында параллельлек уздыра. 1912 елда Габдрахман Сәгъди төрек әсәрен «Кабердән тавышлар» исеме белән татарчага тәрҗемә итеп, Уфада «Шәрекъ» матбагасында бастыра [4]. Соңрак Ф. Әмирхан хикәясе дөнья күргәч, Г. Сәгъди ике әсәрнең сәнгатьчә эшләнелеше, символлар кулланылышында уртаклыкларын билгели һәм «Символизм турында» хезмәтендә бу хакта язып та чыга [5]. Төрек галиме, әлеге хезмәткә таянып, ике әсәрдә дә кулланылган зират, каберлек символларының, үлеләргә мөрәҗәгать итү, рухлары белән сөйләшү алымнарының бер үк функция башкаруын, кеше гомеренең фанилыгы, үлгәннән соң дә яшәү барлыгына инандыруга омтылуга игътибар итә.

Ф. Әмирханның төрек Тәнзимат әдәбияты белән якыннан таныш булуы турында замандашларының истәлекләреннән чыгып та билгеләргә була. Дусты Миргазиз Укмасыйга бүләк итеп тапшырган фотосы кырына Ф. Әмирхан атаклы госманлы әдибе Зыя Пашаның (Габделхәмид Зыяэддин; 1829–1880) шигырь юлларын язган була: «Җисмү зарым хакта пинһан уланча эстәрем, / Сурәтем бу рәсем илә калсын җиһанда ядкәр» [6]. Төрек язучысының «Руя» («Төш»; Н. Кәмал һәм З. Пашаның бер үк исемдә ике әсәре) романы китабы автор фотосы белән ачыла һәм фото астына түбәндәге дүртьюллык урнаштырыла:

Cism-i zârım hâkte pinhan olunca isterim
Bir zaman olsun, Ziya ğâlemde namım payidar.
Siretim âsar-ı hamemden kılınsın içtihat,
Suretim bu resm ile kalsın cihanda yadgâr... [7].

Зәгыйфь тәнем туфракка күмелгәнчегә кадәр,
Бер заман якты галәмдә исемемнең мәңгегә калуын телим.
Тормышым каләмемнән (әсәрләремнән) иҗтиһад кылынсын,
Сурәтем бу рәсем белән калсын җиһанда ядкяр.

Димәк Ф. Әмирхан Зыя Пашаның беренче һәм дүртенче юлларын дустына истәлеккә сурәтен биргәндә файдаланган.

Х. Барган «Төрек йорды» журналының 1912 елгы 7 нче санында басылган «Казаннан» исемле хат-хәбәрне дә Ф. Әмирханга нисбәт итә. Билгеле, ул бу фактны татар галиме Мәсгуть Гайнетдинов мәкаләсенә нигезләнеп әйтә. Диссертацияне язу барышында Х. Барган даими М. Гайнетдинов белән фикерләшеп торган,

хезмәтенең кереш өлешендә ул татар галименә ярдәме өчен чиксез рәхмәтен белдергән. Төрек матбугатында басылган хат астына «Ф. бәк Хан» дигән имза куелган. М. Гайнетдинов «әмир» сүзенең төрекчәдә «бәк» булуын искә алып, Ф. Бәкханның Әмирхан булуын фаразлый. Хатны 1996 елда, татарчалаштырып, «Казан утлары» журналында «Фатих Әмирхан иҗатының бер яфрагы» исемле кереш мәкалә белән бергә бастыра [8]. Хат-язма Казан татарларының Италия-төрек сугышына мөнәсәбәте – төрекләргә хәерһахлык, италиялергә рәнҗү, дошманлык хисләрен яктырту белән башлана: «Бөтен урта Русия төрекләре яшәешенең үзәге урынындагы Казан Госманлы – Итальян сугышыннан бик мөтәэссир (тәэсирле) вә мөтәһәйеж (хисле) улды... Казанлыларның җөмләсенең калебендә хакны таптаган итальяннарга каршы тирән бер хис, нәфрәт бар» [9]. Ерактагы кардәшләрне Казан татарларының иҗтимагый-мәдәни тормышыннан хәбәрдар итәр өчен язылган әлеге басмада Шәрекъ клубының эшчәнлеге, шулай ук яңа басма китаплар, Россия төрекләренең сарыф вә нәхүенә бәйле яңа чыккан хезмәтләр, Коръәни Кәримнең шималь төрекчәсенә – татарчага тәрҗемә ителә башлавы турында мәгълүматлар китерелә. Шуны да искәртеп үтү кирәк, хатта Ф. Әмирханның башка әсәрләрендә урын алган проблемалар да күтәрелә. Мисалга, татар сабыйлары өчен милли бәйрәмнәрнең булмавы турында ачынып язылган «Балаларга бәйрәм» мәкаләсендә күтәрелгән мәсьәләләр Төркиягә җибәргән хатта да яктыртыла. «Безнең кошчыкларыбыз сабый дәверләрен суык вә коры кичериюрлар», – ди ул бу хакта.

Х. Барган хезмәтендә Ф. Әмирхан иҗатын төрек дөньясына таныткан «Татар кызы» (1909) хикәясенә аерым игътибар һәм хөрмәт ачык сизелә. 1913 елда «Кояш» газетасының 30 нчы август санында әлеге әсәрнең төрекчә, русча һәм гарәпчәгә тәрҗемә ителүе турында мәгълүмат басылган була. Ләкин Фатих Әмирхан «Әсәрләр»енең 4 томлыгы искәрмәләрендә әлеге фактлар ачыкланмады дип билгеләнә [10]. Хикәя 1922 елда Истанбулда Нури Кая тарафыннан «Төрек кызы – җанлы бәбәк» исеме белән төрек укучысына тәкъдим ителүе турында диссертациядә әйтелә. Н. Каяның керешендә түбәндәге сүзләр язылган: «Хөр туып та, дингә артык дәрәҗәдә буйсынып, тере-тере күмелгән ислам хатын-кызын “җанлы курчак” буларак унике-унөч ел элек “Татар кызы” исемле әсәрендә тасвир иткән шималь Русия төрек мөселман кардәшләребезнең милли әдибе Фатих Әмирханны укучы егет-кызларыбызга

танытмак өчен, “Татар кызы”н “Төрек кызы” исеме белән төрекчәбезгә күчердем. Мөхтәрәм укучыларның “Төрек кызы”н бөек бер ләззәт белән укаячакларыннан, дөресен әйткәндә, бик горурланам». Ф. Әмирхан XX йөз башында мөселман хатын-кызының җәмгыятьтәге урынын «кара көч» образы ярдәмендә уңышлы яктырта. К. Бәкер әсәрне «әдәбиятыбыз өчен яңа булган бер нәүгъ инша (стиль)» дип күрсәтсә, Г. Ибраһимов исә «татар кызы хәятенең авыр якларын укучының күз алдында тәҗәссем иттереп (гәүдәләндереп), укучының хис вә хыялына тәэсир вә шул хәлгә нәфрәт хисе бирергә тырыша», – дип, үзенең югары бәясен бирә.

Х. Барган, татар хезмәтләре нигезендә, Ф. Әмирхан каләменә төрек Тәнзимат әдәбиятының уңышлы тәэсир итүен дәлилләүгә ирешә. Бу исә үз чиратында XX йөз башы татар әдипләре иҗатын төрек-татар багланышлары яссылыгында монографик тикшеренүләр зарурлыгы турында сөйли.

**Әдәбият**

1. Bargan H. Yenileşme dönemi Türk edebiyatı’nın İdil-Ural bölgesi Tatar edebiyatı’na etkisi. İstanbul. 2015. S. 452.

2. Әмирхан Ф. Истанбул шәһәре // Тәрбиятел этфаль. 1907. № 1. Б. 9–10.

3. Кәмал Н. Руя-Төш. Казан: «Мәгариф» көтепханәсе, И.В. Ермолаева лито-типографиясе, 1907. 45 б. (Мөтәрҗиме – Зыя Насыйри).

4. Зыя Х. Кабердән тавышлар. Уфа: «Шәрекъ» матбагасы, 1912. 31 б. (Мөтәрҗиме – Габдрахман Сәгъди).

5. Сәгъди Г. Символизм турында. М.: Центриздат, 1932. 117 б.

6. Укмасый М. Фатих Әмирхан турында истәлекләр // Казан утлары. 1996. № 1. Б. 163.

7. Зыя Паша. Руя. Дерсаадет: «Касбар» матбагасы, 1326/1910. 39 б.

8. Гайнетдинов М. Фатих Әмирхан иҗатының бер яфрагы // Казан утлары. 1996. № 1. Б. 151–152.

9. Бәкхан Ф. Казаннан // Казан утлары. 1996. № 1. Б. 152.

10. Фатих Әмирхан. Әсәрләр: 4 томда. Т. IV. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 426.

*А.Р. Мөбарәкшина,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

## Фатих Амирхан и музыка

В художественной прозе и публицистике, эпистолярном наследии писателя Ф. Амирхана обращают на себя внимание ситуации, наблюдения и заметки, касающиеся различных явлений музыкального искусства. Его современники в своих воспоминаниях

свидетельствуют об увлеченности писателя музыкой: посещении концертов в Казани и Уфе, оперных спектаклей, наличии в доме старого пианино. Фрагменты арий из любимых им опер «Фауст» Гуно и «Демон» Рубинштейна он включил в канву повествования некоторых своих художественных произведений. Среди них рассказы «Счастливые минуты» («Кадерле минутлар»), в котором в переводе на татарский язык и с растягиванием по ходу напева гласных звучит отрывок арии Зибеля, а также «Мулла пришел поучать» («Хәзрәт үгетләргә килде...») с фрагментом арии Демона, но уже на русском языке. Ф. Амирхан завоевал авторитет среди музыкантов своим интересом к этому виду искусства, познаниями в данной области и суждениями о ней. Поэтому, видимо, его назначили председателем комиссии по подготовке оперы «Сания», поставленной в 1925 году, авторами которой стали С. Габаши, Г. Альмухаметов и В. Виноградов. Мандолинист Х. Илялов вспоминал, что два первых упомянутых музыканта довольно часто приходили в дом к Ф. Амирхану для показа и обсуждения не только либретто, но и музыкального материала. Не случайно, клавир данной оперы хранится не только в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, но и в личном фонде писателя в Национальном музее РТ. Ф. Амирхан оказал влияние на сюжетное завершение оперы. Писатель считал, что она не может заканчиваться гибелью главной героини: представители трудового народа должны оказаться выше богачей. Счастливая развязка в результате и была принята как итоговая. Отметим также, что в публикациях о Ф. Амирхане указывали на давние дружеские отношения, сложившиеся между ним и композитором С. Габаши, которые с детства знали друг друга. Возможно название песни «Томление» («Сагыну»), встречающееся в повести «Фатхулла мулла» («Фәтхулла хәзрәт») навеяно одноименной фортепьянной пьесой С. Габаши.

Все три указанные области литературного наследия писателя как бы дополняют друг друга в плане музыкального искусства. Но полное освещение темы «Фатих Амирхан и музыка» с привлечением всех материалов писателя в рамках одной статьи не удастся. Требуется книжный формат. Только пересказ фрагментов из художественных произведений и других работ Ф. Амирхана, имеющих отношение к музыке, занимает очень большое место. А ведь необходимо рассмотрение их в контексте эпохи, ее музыкальной

культуры и биографии писателя. Попутно отметим, что, к сожалению, музыковеды Татарстана обошли вниманием создание монографий под названием «литератор и музыка». Есть только брошюра Р. Исхаковой-Вамбы – «Тукай и татарская музыка», в то время как у других народов, например, в русском музыкознании эта тема нашла отражение в многочисленных исследованиях и указателях.

Ф. Амирхан на страницах своих изданий рассказывал о музыке, связанной с религиозной и светской жизнью. Не конфессиональные произведения представлены в них композиторскими и фольклорными образцами разных народов. В данной статье внимание уделено преимущественно светской авторской музыке, нашедшей отражение в литературном творчестве писателя. Апелляция к отдельным материалам из его публицистического и эпистолярного наследия, сведениям из записной книжки происходит эпизодически. Тем не менее, поскольку предпринята первая попытка освещения вопроса «Ф.Амирхан о музыке и музыкантах», хотя бы укажем некоторые статьи и письма писателя из четырехтомного собрания его сочинений, имеющие отношение к этой теме. Образцы его музыкально-критической и публицистической деятельности по содержанию представляют собой рецензии («Җырчыларымыз», «Әдәбият кичәсе») и сообщения («Беренче татар операсы язылып бетү мөнәсәбәте белән»). В эпистолярном же наследии вопросы, касающиеся музыки, затронуты в письмах к его друзьям – И. Аитову и учителю Р. Алуши.

Можно с полным правом утверждать, что музыка в том или ином своем виде присутствует в жизни героев большинства произведений Ф. Амирхана. В своих литературных сочинениях он показывает преимущественно картины городского быта татарского общества начала XX века с присущей ей музыкальной культурой. В этом плане они могли бы послужить своеобразным источником по музыкальному искусству данного времени. Но до сих пор музыковеды ими не воспользовались. В их трудах встречается лишь цитата из рассказа Ф. Амирхана «Сон в канун праздника», которую приводят обычно в связи с постулатом об отсутствии национальной музыки и исполнительских кадров в этот период и соответствующих мечтах по данному поводу представителей передовой татарской интеллигенции. Напомним, что в этом самом раннем произведении писателя, написанном в 1907 году, писатель повествует, в частности, о выступлении на сцене некоего клуба пиа-

нистки, скрипача и певцов-солистов, исполнивших арию из оперы «Ради человечности» («Инсаният өчен»), романс «Забыл ли эти вечера?» («Оныттыңмыни ул кичләрне? ») и сонату, принадлежащих перу безымянных татарских композиторов. Скрипач же исполнил собственное сочинение под названием «Горе» («Кайгы»). Но и в последующих других своих литературных произведениях Ф. Амирхан нередко показывает такие же музыкальные ситуации. В связи с этим возникает вопрос: являются ли они художественным вымыслом автора или все же отражением музыкальных реалий того времени? Обращаться ли к ним как к еще одному достоверному источнику информации по музыкальной (прежде всего городской) культуре татар XX века? Ответ можно дать, пожалуй положительный. Его подтверждают воспоминания людей, знавших Ф. Амирхана, факты его биографии и публицистические работы, отчеты различных обществ и учебных заведений (хотя занятия могли вестись и на дому), хроникальные известия периодической печати той эпохи. Таким образом, речь идет о музыке окружающего мира в восприятии татарского писателя. В его литературных произведениях, созданных после рассказа «Сон в канун праздника», добавилась конкретизация некоторых моментов. В частности, уточнено место проведения концертов. Названы клубы: Купеческий, Восточный, Дворянское собрание и другие. Согласно газетным и журнальным сообщениям концертные выступления в них действительно проводились, начиная с 1907 года. Что же касается учебных музыкальных заведений Казани, то в городе начали функционировать музыкальные школы, созданные впервые в 70-е годы XIX века. А в 1904 году на базе одной из них, а именно – школы А. Гуммерта – открылось Казанское музыкальное училище. Сохранились отчеты этого учебного учреждения со списком воспитанников. Первые единичные фамилии татарских учащихся появляются в них в 1907 году. В дальнейшем их количество заметно возрастает. Возможно, что не всех отметили в этих списках, т.к. многие (это касается прежде всего девушек) учились для себя, а не для приобретения диплома, получить который можно было, сдав определенные экзамены, что делали лишь отдельные личности. Владение навыками музицирования считалось желательным для представителей женского пола, чтобы они успешно поддерживали семейный уклад и вели домашнее воспитание. Примерно такой же норматив знаний и умений, видимо, установился и для татарок. Так героиня

рассказа «Познакомились от того, что не были знакомы» («Танымаганлыктан таныштык») сообщает спутнику о своем обучении некоторым предметам: русскому и французскому языкам, игре на рояле, пению, а также рукоделию. Аттестат учебного музыкального заведения стремились получить те, кто планировал работать учительницей музыки. Преобладающее большинство учащихся в Казанском музыкальном училище составляли девушки (разных национальностей, но преимущественно русские). Именно молодые представительницы татарского народа чаще всего фигурируют и в произведениях Ф. Амирхана в качестве к сольных исполнительниц на различных инструментах – рояле, гитаре, а также как аккомпаниаторов вокалистам. Вероятно, писатель акцентировал в своих произведениях внимание на девушках-музыкантах по причине того, что он знал о гендерном составе учащихся музыкальных учебных учреждений Казани и хотел видеть также и татарок музыкально образованными и, к тому же посещающими различные концерты. Так в некоторых своих рецензиях, например, в статье «Литературный вечер» («Әдәбият кичәсе (1)») он высказал сожаление об отсутствии среди татарских зрителей литературно-музыкального вечера представителей женского пола. В отчетах Казанского музыкального училища начала XX века напечатаны фамилии таких учащихся-татар, которые проявили себя на музыкальном поприще. Это Халима Терегулова, Вали Апанаев. Безусловно, татарская музыка не входила в программу изучения в учебных заведениях, т.к. первые фактически самодеятельные композиторы только еще начинали создавать свои опусы. А народная музыка педагогов не интересовала. Можно предположить, что в результате этого горожанки из татарских семей, умевшие музицировать, не знали свои национальные мелодии. Такие факты, вероятно, имели место в быту Казани начала XX века и по этой причине, видимо, они нашли отражение в творчестве Ф. Амирхана, в частности, в рассказе «Познакомились от того, что не были знакомы» («Танымаганлыктан таныштык»). Его героиня умела играть только мелодию песни «Тафтиляу». Остальной ее репертуар составляли русские романсы и танцы.

Ф. Амирхан продемонстрировал в своих литературных произведениях неплохую осведомленность в области музыкального искусства, например, знание его жанров, конкретных опусов, инструментов, типов голосов и их характеристик. Она проявилась не только в текстах его сочинений, но и в прилагаемых к ним

сносках. В своих произведениях Ф. Амирхан использовал слова арабско-персидского происхождения, которые уже не встречаются в современном языке татар. Но как татарские термины, например, обозначающие различные музыкальные понятия в начале XX века, они до сих пор представляют интерес. Вот некоторые из них: «мизмар» – инструмент; «мусикави» – музыка; «мөкәммәл тәрбияи мусикави» («тулы музыкаль белем тәрбиясе») – полное музыкальное воспитание; «нәгъмә» – («көй, моң») – напев, задушевность. Но сочетание «музыка нәгъмәләре» сам Ф. Амирхан в сноске перевел как «музыка парчалары» – музыкальные отрывки. К понятиям, связанных с разговором о религиозных песнопениях, относится «тәгании» («җыр, музыка») – песня, музыка. Это слово иногда всплывает в современной жизни Казани, например, при перепечатке книжной продукции некоторых восточных народов. Обращался Ф. Амирхан и к традиционным классическим музыкальным терминам особенно в связи с танцами.

Пожалуй, особое внимание Ф. Амирхан уделил в своих произведениях вокальному исполнительству. Его отличает разнообразие эпитетов, которыми он характеризует голоса, оттенки исполнения. Иногда писатель таким же образом описывал звучание инструментов: «Гитара в руках Фахрии плачет, подобно ангелу с золотым голосом, задушевным голосом плачет» («Гитара Фәхриянең кулында җылый, алтын тавышлы фәрештә җылаган шикелле, моң вә хәят катыш тавыш белән җылый») [1]. Вокальные голоса звучат в произведениях Ф. Амирхана не только в «живом» исполнении, но и в записях с пластинок. В отрицательной оценке этих музыкальных номеров писатель был единодушен с Г. Тукаем, который тоже негативно отзывался о них. В романе «Посередине» («Урталыкта») Ф. Амирхана в одном из эпизодов повествуется о том, как в одном из домов завели граммофон. Один из персонажей произведения принялся искать среди пластинок записи фрагментов каких-нибудь опер, однако вся имеющаяся музыка была безликой, неважной. Не оказалось ни одной значительной песни. Большинство из них, представленное татарскими такмаками, было спето плохим и испорченным голосом. Надо заметить, что при прослушивании в концертах татарских певцов, Ф. Амирхан также не мог удержаться от критики. Это касалось, например, выступлений К. Мотыгый. В статье «Наши певцы» («Җырчыларымыз. Театр вә музыка») он оценивает пение четырех исполнителей: уже упомянутого Камиля

Мотыгый, Фаттаха Латыпова, Фатимы Ихсановой и Сатиры Ахмадеевой. Ему не понравился сам голос и «кричащая» манера пения К. Мотыгый. Но больше всего писателя раздражало то, что начало татарских песен было у К. Мотыгый таким, как должно им и быть, но затем он «вбивал» их в русло русских мелодий, исполняя в чужеродном стиле. Исключением явилась только песня «Кара урман» («Дремучий лес»), которую певец, по выражению Ф. Амирхана, не стал портить, ломать и «европеизировать». Подытоживая разговор о К. Мотыгый, писатель заметил, что тому не хватает музыкального воспитания. Ф. Ихсанову Ф. Амирхан вообще посчитал плохой певицей, находящейся ниже всякой критики. А вот Ф. Латыпов и С. Ахмадеева удостоились от него похвал. Отметим прозорливость Ф. Амирхана. Эти последние указанные им певцы, а также Х. Чамаева, упомянутая в позитивных тонах в статье «Весенний праздник – сабантуй» («Яз бәйрәме – сабан туе»), М. Рахманкулова и впоследствии – в советское время – продолжили певческую карьеру в отличии от раскритикованных им других исполнителей. Очень благодарна была Ф. Амирхану певица и композитор Сара Садыкова. Она познакомилась с ним в годы учебы в педагогическом техникуме. С. Габаши, преподававший там ботанику, организовал также хоровой кружок, с участниками которого разучивал созданные им музыкальные номера к пьесам «Тагир-Зухра» («Таһир-Зөһрә») и «Молодой парень» («Бүз егет»). Композитор хотел знать мнение Ф. Амирхана о своих сочинениях. С этой целью он несколько раз приходил к писателю домой, приводя с собой и С. Садыкову для показа этих номеров. Как-то раз Ф. Амирхан напутствовал юную Сару Садыкову следующими словами: «Сара, сестренка, природа дала тебе задушевный, красивый голос. Учителем может быть и человек с некрасивым голосом. А ты пение не бросай» [2]. Значительно позже, уже состоявшись на музыкальном поприще, С. Садыкова, удивлялась провидческому дару писателя. Ведь свое счастье она нашла именно в этой области искусства. Поэтому воспоминания о Ф. Амирхане певица назвала: «Указатель моего пути» («Юл күрсәтүчем»).

Большое место в быту казанских горожан начала XX века занимала танцевальная музыка. Она оказала значительное влияние на репертуар татарских певцов. Литературно-музыкальные мероприятия очень часто завершали различными играми и плясками. Устраивали также отдельно и самостоятельные танцевальные ве-

чера. Их описание Ф. Амирхан включил в некоторые свои художественные произведения: «Сон в канун праздника», «Когда погасло пламя» («Сүнгәч»), «Танцевальный вечер» («Танс кичәсе»), «Хаят».Самым популярным танцем был вальс. Кроме него в прозаическом наследии писателя встречаются названия таких плясовых номеров как казачок, па-д’эспань, а также военные маршы «Тоска по родине», «Встречный марш» («Каршылау маршы»). Во время поездки на пароходе в Астрахань Ф. Амирхан, вероятно, слышал популярный в Европе и Америки в конце XIX века и по 30-е годы XX века бразильский танец «Матчиш». Поэтому он включил описание его мелодии в один из своих рассказов, действие которого происходит как раз во время плавания на пароходе («Танымаганлыктан таныштык»). Интересно, что хореографические па матчиша вошли в современный танец под названием «Ламбада». Движения же танцоров, увиденные Ф. Амирханом в Казани, нередко получали в его произведениях негативную характеристику.

Еще многое предстоит осуществить в плане открытия музыкальной составляющей в художественных произведениях и других работах Ф. Амирхана. Хотелось, чтобы такое исследование, как и некоторые другие в отношении наследия Ф. Амирхана нашли свое продолжение и не заканчивались с проведением юбилейных мероприятий.

ПРИМЕЧАНИЯ

1. Бер хәрабәдә // Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. Казан, 1984. 1 т. Б. 154.
2. Садыйкова С. Юл күрсәтүчем // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан, 2005. Б. 118.

*Г.Ф. Юнусова, старший научный сотрудник*
*Центра письменного и музыкального наследия*
*Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

## Неизвестная фотография писателя Фатиха Амирхана

Вниманию читателей журнала предлагаем фотографию, представляющую несомненный интерес, в особенности, для дальнейшего исследования богатой и многовековой истории татарской литературы. Документ публикуется впервые.

Этот снимок группы татарских религиозных деятелей, представителей интеллигенции, учащихся рубежа XIX–XX вв. Хроно-

логически документ относится к январю 1906 года (первым дням первой российской революции).

В историю общественно-политической жизни татар эти дни вошли как время работы второго мусульманского съезда в Санкт-Петербурге.

Юноша в очках и каляпуше во втором ряду, первый справа – молодой Фатих Амирхан. В отличие от других мужчин и юношей занявших второй ряд – он не стоит, а сидит. Как известно он был делегатом данного форума мусульман Российской империи. Кроме него на форуме учащихся г. Казани представляли еще двое юношей: Шакир Рахимов и Мубин Садиров [1]. Возможно, они так же на снимке. Юноши шакирдовского возраста действительно зафиксированы на снимке.

На фото мы узнаем еще одного человека. Это известный общественный деятель, юрист, депутат IV Государственной Думы России от Уфимской губернии Ибниамин Абуссугудович Ахтямов (1877–1941). О нем можно сказать следующее. Он один из издателей газеты «Миллят», и, один из организаторов IV съезда «Иттифак». В мае 1927 года И. Ахтямов подписал обращение татарской интеллигенции И. Сталину и III пленуму Татарского обкома партии известное как «письмо 82-х», где было выражено сомнение в необходимости перевода татарской графики на латынь.

Ко времени же появления фотоснимка за его плечами были: учеба (с 1898 г.) и изгнание (1899 г.) из физико-математического факультета Санкт-Петербургского университета за участие в студенческих волнениях, аресты в столице (1901 г. по делу «Комитет рабочей организации») и в Уфе, ссылка.

На момент фотографирования он был студентом факультета естествознания, который окончил в 1907 году. В 1910 г он окончил и юридический факультет столичного высшего учебного заведения. Свидетельство об окончании названного вуза он получил 15 декабря 1910 года. Ибниамин был связан с революционным движением. С 1903 г он стал членом партии и социалистов-революционеров Уфе [2; 3].

Заметим, к этому моменту фотографирования (к началу 1906 года) Ибниамин Ахтямов и Фатих Амирхан скорее всего были знакомы лично или знали друг друга заочно. Они были связаны по социал-демократическому движению в Казани. В частности, Ф. Амирхан занимался написанием прокламаций [4].

На этой же фотографии мы видим известного татарского писателя Гаяза Исхаки. Он во втором ряду через одного человека от Ф. Амирхана.

При сравнении выявленной фотографии с известным, получившим широкое распространение снимком участников съезда в Санкт-Петербурге в январе 1906 года создается видимость того, что они сделаны примерно в одно и тоже время. Это можно проиллюстрировать и на примере образа молодого Ф. Амирхана, которого мы видим на обоих снимках.

Возрастная характеристика (измерение) людей известных нам выглядела следующим образом: Фатиху Амирхану – 20 лет, Гаязу Исхаки – 28 лет, Ибниамину Ахтямову – 29 лет. Фотоизображения названных людей татарского мира подтверждают их возрастное состояние.

Судя по своеобразной наклейке приклеенной на обороте фото, багетную раму для этого снимка сделали в С.-Петербурге по Садовой, между Сенной площадью и Гороховой улице, в доме № 33.

В настоящее время существует мнение и о месте проживания Ф. Амирхана в С.-Петербурге. По утверждению исследователей, составителей книги «Фатих Әмирхан турында истәлекләр» (Казан, 2005) Фатимы Ибрагимовой и Равиля Амирхана писатель во время пребывания в столице скорее всего останавливался у Исмагила Аитова [5]. При этом они опираются на письмо Ф. Амирхана Ризвану Алуши от 5 ноября 1905 года. В письме приводится и адрес проживания последнего «С.Петербург, Астраханская ул д № 28, кв № 3. Измаилу Аитову» [6].

В качестве вывода можно сказать следующее. Данное фото станет хорошим подарком для почитателей многогранного творчества классика татарской литературы Ф. Амирхана. На наш взгляд, вновь опубликованное фото поможет исследователям еще полнее и всестороннее осветить биографию и неповторимое творчество ровесника, друга и единомышленника Габдуллы Тукая Фатиха Амирхана. Исследование данной находки поможет сделать еще один шаг в освещение жизни и деятельности как Фатиха Амирхана, так и других людей зафиксированных на снимке. В частности, фотодокумент поможет показать тех людей, с которыми встречался и общался писатель. Возможно, что писатель симпатизировал некоторым из них. Исследователям предстоит дальнейшая расшифровка фотографии. Поиск продолжается.

**Литература**

1. *Сенюткина О.Н.* Тюркизм как историческое явление (на материалах истории Российской империи 1905–1916 гг.): Монография. Нижний Новгород: Издательский дом «Медина». 2007. С. 263.

2. *Айнутдинова Л.М., Усманова Д.М.* Ахтямов // Татарская энциклопедия. Т. 1. С. 249–250.

3. *Таиров Н.И.* Дальнейшая судьба Ибниамина Ахтямова // Эхо веков = Гасырлар авазы. 2000. № 3/4, С. 239–243.

4. *Ибраһим Бикколов.* Бөек язучы Фатих Зариф углы Әмирхан // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 17–18, 193.

5. Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар кит нәшр., 2005. Б. 108, 212.

6. *Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. Т. 4. Б. 229, 319.

*Н.И. Таиров, доктор исторических наук,*
*профессор Казанского государственного*
*института культуры (г. Казань)*

## Милли музей фондында Фатих Әмирхан мирасы

Татарстан Республикасы Милли музеенда татар мәдәнияте һәм әдәбияты әһелләренең бай җыелмалары саклана. Фондның нигезен татар зыялыларының архивлары, китапханәләре һәм шәхси әйберләре тәшкил итә. Алар арасында күренекле прозаик, драматург, публицист, әдәби тәнкыйтьче һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан (1886–1926) мирасы әһәмиятле урын алып тора.

Фатих Әмирхан фондына материаллар 1950 елларда туплана башлый. Шушы елларда язучының шәхси әйберләре кабул ителә: барлыгы 15 предмет. Алар арасында берничә күлмәк, сюртук, эшләпә, кепка, яка, манжет һәм башка ир-ат киемнәре бар. Иң кыйммәтле яркярләрнең берсе – Ф. Әмирханның үлгәннән соң алынган битлеге (посмертная маска) башка берничә татар язучыларыныкы белән берлектә 1950 елның 30 май акты нигезендә музейга тапшырыла.

1958 елда музей фондлары Ф. Әмирханның туганы (апасының кызы) Разия Габдулла кызы Әмирхановадан (1904–1968) кергән предметлар – әдипнең шәхси альбомында сакланган гаилә фотосы һәм почта открыткалары белән байый. Фото «Рембрандть» салонында 1906 елда төшерелгән. Анда Ф. Әмирхан, әнисе Рабига, энесе Ибраһим, апасы Сәгадәт һәм аның кызы Разия сурәтләнгән. Открыткалар Казан, Оренбург, Петербург, Ростов-Дон шәһәрләреннән Ф. Әмирханга юлланган. Текстлар гарәп графикасында

һәм кириллицада язылган. Алар арасында әдипнең таныш кызы Лёлядан килгәннәре игътибарга лаек. Разия Әмирханова бу кыз турында «Абыем турында истәлекләр»ендә түбәндәгечә искә ала: «Фатих абый авырып ята. Аны караучы шәкерт, «Фатих абый бик каты кызышып ята, саташа» дип сөйли. Шул вакыт дәү әнинең кемгәдер бик каты ачуланып кычкырганы ишетелә. Ишегалдына йөгереп чыксак, парадный ишеге төбендә урта буйлы яшь кенә рус хатыны һәм кулларын ике якка җәеп, ишекне каплап басып торучы дәү әнине күрдек. Ул, бик гасабиланып: «Үләргә яткан балам янына имансыз марҗаны кертмәм», – дип кычкыра, ә теге «марҗа», күз яше белән, Фатих абый янына кертегез, дип ялына иде. Мине бик нык тетрәткән бу хәлнең нәрсә белән тәмам булганын белмим. Тик кич белән Фатих абыйны карый торган шәкерт Хөсниҗамалга Фатих абыйның ниндидер Лёляны яратуын, дәү әнинең «күземә күренмәсен» дип, кызны өйгә кертмәвен, Фатих абыйның авырганда шул Лёля белән саташуын шыпыртлап сөйләп утырганы исемдә» [6, б. 57]. Бер открыткада кызның үз фотосы бирелгән, икесе әдипне бәйрәм белән тәбрикләп язылган, Лёля һәм Рыбуся исемнәре белән имзаланган. Анда Лёляның эчке хисләре чагылыш таба, аларның «өченче ел таныш булу»лары турында да хәбәр ителә. Открыткалар 1914 ел белән даталанган. Кызганыч, Лёля хакында мәгълүматыбыз юк.

Ф. Әмирханның үз кулы белән язылган открыткалар да игътибарны җәлеп итә. Алар Гает, Корбан, Раштуа бәйрәмнәре белән котлап кириллица һәм гарәп графикасында язылган. Зөләйха туташка (Зөләйха Хәсәновна Мөхәммәдова) адресланганы бик кызыклы. Язучы туташны Корбан бәйрәме белән котлар өчен фәрештәләр рәсеме төшерелгән открытка сайлый. Түбәндәге текстны китерә: «Зөләйха туташ! Сезне Корбан бәйрәме белән тәбрик итәр өчен менә шушы музыка өчен фәрештәләр җибәрәм. Җырчылары җырлап, уйнаучылары уйнап торган хәлдә, сезне алар тәбрик итәләр. Ф. Әмирхан». Ахырда исә тагын «сезне әни бәйрәмдә көтә» дип өсти. Чыннан да, туганнарының һәм замандашларының истәлекләрендә «Ф. Әмирхан гомере буе хатын-кызга фәрештәгә караган кебек карады, алиһәгә табынган кебек табынды» [6, б. 95] дигән сүзләр аның хатын-кызга мөнәсәбәтенең ни кадәр нәзакәтле булуын тагын бер кат раслый.

1980 елларда Ф. Әмирхан белән бәйле предметларны музей фондына туплау аеруча актив башкарыла. Бу вакытта Казанда

Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулу уңае белән шагыйрьнең музее оештырыла башлый һәм экспонатлар җыю эше алып барыла. Г. Тукай мирасы белән бергә аның тирәлеге (дуслары, танышлары, хезмәттәшләре, туганнары) турындагы материаллар музейга кабул ителә.

Бу елларда Ф. Әмирханның әдәби мирасын туплауга да зур игътибар бирелә. Бу мирас 1907–1926 елларда иҗат ителгән әсәрләрне үз эченә ала һәм жанр төрлелеге белән аерылып тора: балалар өчен әсәрләр, роман-повестьлар, драмалар, хикәяләр, публицистик мәкаләләр, әдәбият-сәнгать тәнкыйте һ.б.

Музей фондында Ф. Әмирханның үзе исән чагында Казан һәм Уфада нәшер ителгән китаплары саклана. Мәсәлән, 1918 елда Уфада «Восточная печать» электро-типографиясендә дөнья күргән хикәяләр җыентыгы. Казанда 1909 елда аерым китаплар булып чыккан «Татар кызы» һәм «Танымаганлыктан таныштык» хикәяләре, «Фәтхулла хәзрәт»нең төрле елларда нәшер ителгән басмалары, 1912 елда чыккан «Урталыкта» романы зур кызыксыну уята. Драма әсәрләреннән 1910 елда «Үрнәк» матбагасында чыккан «Яшьләр»ен һәм 1915 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан аерым китап итеп бастырылган «Тигезсезләр»ен атарга була. Соңгы китапта урын алган өч фотоның – спектакльдән сәхнә күренешләренең төп нөсхәләре Милли музей фондында саклана. Билгеле булганча, «Тигезсезләр» пьесасы 1915 елның февралендә «Новый клуб» сәхнәсендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан уйнала [3, б. 482]. Газетада аның турында анонс бирелә. Бу документ та музей фондында бар. Пьеса тиз арада популяр булып китә, күрәсең, ул төрле шәһәрләрдә уйнала башлый. Оренбург, Ташкент шәһәрләрендә куелган бу спектакльнең афишалары кызыксыну тудыра. Анда Ф. Әмирханның 3 күренештән торган «Тигезсезләр» пьесасы Оренбургта – 1915 елның 30 июлендә, Ташкентта 1918 елның 16 сентябрендә куелуы хәбәр ителә.

1984 елда Ф. Әмирхан белән бәйле материалларны язучының ерак туганы Х. Шамкин Милли музей фондына тапшыра. Алар арасында әдипнең үзе исән чагында нәшер ителгән басмалары, XX гасыр башы язучыларының китаплары һәм гаилә фотолары бар. Шул ук елны С. Ибәтуллинадан 122 саклану берәмлегеннән торган Ф. Әмирхан гаиләсе белән бәйле тормыш-көнкүреш әйберләре һәм документлар сатып алына.

«1926 елда Ф. Әмирхан вафат булганнан соң җеназаны өйдән чыгарганда һәм ике мәйданда, юлда барганда һәм кабергә төшергәндә фотография алына» [6, б. 167]. Музей фондында әлеге фотоларның икесенең төп нөсхәсе сакланып калган. Беренче фотода Ф. Әмирханның җеназасы янында Фатыйма Апакова, Разия Әмирханова, Габдулла Әмирханов, Гомәр Әмирханов, Газизә Яушева, Зәкәрия Әмирханов, Мәхмүт Әмирханов, Габделхәмит Апаков сурәтләнгән. Икенче фотода Яңа татар бистәсе зиратында мәетне кабергә төшерү күренеше чагылыш таба.

Ф. Әмирхан мирасының иң кадерле, әһәмиятле өлеше, һичшиксез, – аның кулъязмалары. Аларның күп өлеше ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. ТР Милли музеенда исә язучының «Хәят» повестеның кулъязмалары бар. Алар барлыгы 22 дәфтәрдән гыйбарәт. Бу кадерле мирас музейга 2001 елда тел галиме Галимҗан Шәрәфнең (1896–1950) улы Арслан Шәрәфтән сатып алына. Кабул итү документларында дәфтәрләр «Татар әдәбияты классигы Ф. Әмирханның «Хәят» повесте кулъязмасы» буларак теркәлгән. Галимнәр тарафыннан бүгенге көнгә кадәр «Хәят» повестеның кулъязмалары югалган дип расланды. Тарихка күз салсак, Ф. Әмирхан вафат булганнан соң, фатирында калган әйберләрен барлау өчен махсус комиссия оештырыла. Әлеге комиссия вәкилләре тел белгече Галимҗан Шәрәф, журналист Ибраһим Биккулов (1884–1938), язучының фатирында калган кулъязмалар, хатлар, тәрҗемәи хәленә бәйләнешле материаллар, китаплар, рәсемнәр, кием-салым, йорт җиһазларының һәммәсен барлап, исемлеген төзиләр [2, б. 453]. Анда «Хәят» повестеның кулъязмалары да теркәлгән. Бу исемлекне һәм язучының сакланып калган кулъязмаларын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына язучының ерак туганы Хәким Гали улы Шамкин тапшыра. Ләкин ул кулъязмаларның барысы да институт архивына кермәгән булып чыга.

Кулъязмалар укучы дәфтәренә язылган. 14 дәфтәр бербөтен әсәрне тәшкил итә, бит саннары дәфтәрдән дәфтәргә дәвам итеп барыла. Мәсәлән, 1 дәфтәр – 1–10 бит, 2 дәфтәр – 11–18, 3 дәфтәр – 19–26 һәм шул тәртиптә 14 дәфтәр 127–136 битләр белән тәмамлана. 1926 елда төзелгән исемлектә «Хәят»нең беренче бүлеге ундүрт дәфтәрдән, 136 биттән торуы турында мәгълүмат бар [5, б. 148]. Димәк, бу дәфтәрләр «Хәят»нең беренче бүлегенең кулъязмалары.

Калган алты дәфтәргә рим цифрлары сугылган. Титул битләре рәсемле. Бит саннары күрсәтелмәгән. Беренче һәм икенче дәфтәрнең тышлыгында гарәп имлясе белән «икенче җөзье», өченче, дүртенчедә «Часть 2-ая романъ», бишенче һәм алтынчыда «Село Неклюдово (Симбирской губернии)» дигән язулар бар. Беренче дәфтәрдә – «15 август, 1912», өченче дәфтәрдә – «1912–1913», 4 дәфтәрдә – «10 октябрь 1912», биштә – «24 сентябрь 1913» һәм алтынчы дәфтәрдә «10 октябрь 1913» даталары күрсәтелгән. Димәк, бу дәфтәрләр 1912 елның августыннан 1913 елның октябренә кадәр вакыт аралыгында язылган. Ф. Әмирханның 1913 елның сентябрендә Сембер губернасында булуына нигезләнеп, бишенче һәм алтынчы дәфтәрләр шунда язылган дигән нәтиҗәгә киләбез. Тагын бер кызыклы факт – бу ике дәфтәрнең титул битенә Г. Тукайның 1908 елгы сурәте төшерелгән (мондый дәфтәрләр Г. Тукай үлгәннән соң чыгарылырга мөмкин). Алда искә алынган исемлектә «Хәят»нең икенче бүлегенең 10 дәфтәр булуы хәбәр ителә [5, б. 148]. Димәк, «Хәят»нең икенче кисәге язылган ун дәфтәр Ф. Әмирханның үзендә сакланган. Кызганыч, Милли музей фондына ун кулъязма дәфтәрнең алтысы гына кергән.

Чираттагы ике дәфтәргә игътибар итик. Аларның тышлыкларында рим цифрлары белән унынчы-унберенче дәфтәр дип күрсәтелгән. Унынчы дәфтәр 106–113 нче битләрне үз эченә ала һәм 1911 елның 28 гыйнвар – 15 февраль даталары белән билгеләнә. Соңгы биткә «15 февраль 1911 ел, төнге 12 сәгать» датасы куелып, хәтта сәгате язылу әдипнең иҗат лабораториясен төгәлрәк ачарга мөмкинлек бирә. 114–119 нче битләрдән торган унберенче дәфтәр шушы ук дата белән башланып китә. Дәфтәрләр караламага охшаган, бик күп төзәтүләр бар, кайбер битләре ертып алынган. Күренгәнчә, бу Ф. Әмирханның әсәрне камилләштерүен, аның өстендә эшләвен дәлилли.

Милли музей фондларында саклана торган тагын бер экспонат зур кызыксыну уята. Ул – Ф. Әмирханның «Эсперанто теленең кагыйдәләре» исемле китабы. Эсперанто – халыкара аралашу өчен 1887 елда Варшава врачы Л. Заменгоф (1859–1917) тарафыннан эшләнгән ясалма тел [2, б. 429]. Бу тел белән кызыксынган Ф. Әмирханда Л. Заменгофның «Эсперанто» исемле китабы да булган [6, б. 84]. Шулай ук «әл-Ислах»ның 1907 елгы 10 декабрь санында Дамелла имзасы белән «Эсперанто теле» исемле мәкалә бастыруы да билгеле [2, б. 429]. Ф. Әмирхан музейда са-

кланган «Эсперанто теленең кагыйдәләре» китабын дусты Г. Тукайга бүләк иткән. Титул битендә язылган автографында түбәндәге сүзләр укыла: «Иптәшем Г. Тукаевка тәскирә. Ф. Әмирхан. 16 март 1909 ел».

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Милли музее фондында саклана торган Фатих Әмирхан мирасы документлар, шәхси әйберләре, язучының үзе исән чагында дөнья күргән китаплары, хатлар, фотосурәтләр, почта открыткалары, кульъязмалар һәм гаиләсе белән бәйле тормыш-көнкүреш предметларыннан торган фондны тәшкил итә. Мәкаләне С. Сүнчәләйнең Ф. Әмирхан вафатыннан соң аңа багышлап язган шигъри юллары белән тәмамлыйм. Шигырьнең кульъязмасы С. Сүнчәләй архивында Милли музей фондында саклана.

Татарның бар иде хәят әдибе
Әдипләрнең дә иң шады, нәҗибе
Хәятнең иң шаян, назлы баласы,
Фәләкнең әмма мазлуме, гарибе.
Шәкертләр вожде, ислахы каһарман
Хатын-кызга бәхет итеп аһ орган
Хәким сөхбәтче
Шагыйрьләр дусты һәм – Фатих Әмирхан.

**Әдәбият**

1. *Әмирханов Р.* Әмирханнар. Казан: Мәгариф, 2005. 223 б.

2. *Әмирхан Ф.* Әсәрләр. Дүрт томда. 1 том. Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

3. *Әмирхан Ф.* Әсәрләр. Дүрт томда. 2 том. Повестьлар, роман һәм драма әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 488 б.

4. *Әхмәтҗанов М.* Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. Казан, 2005. – 224 б.

5. *Нуруллин И.* Фатих Әмирхан: Атаклы кешеләр тормышы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 279 б.

6. Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 255 б.

*Л.Ә. Медведева,*
*Габдулла Тукай әдәби музее өлкән фәнни хезмәткәре*

## ЭЧТӘЛЕК

**Кереш** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
**Әдип публицистикасын барлаганда** . . . . . . . . . . . . . . 11
Сәясәт галәмендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Беренче Дума әгъзаларына хөкем . . . . . . . . . . . . . . 12
Гаспринский юбилее . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Мәдрәсәләр берләштерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Мәдрәсәләр берләштерү (28 номердагы мәкаләгә гыйлавә) . . . . 18
«Әлислах»тан ни көтәргә ярый? . . . . . . . . . . . . . . . 20
Гыйбадәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Минем тәрҗемәи хәлем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Балаларга бәйрәм *(Мәүлүд мөнәсәбәте илә)* . . . . . . . . . 32
Муса әфәндегә җавап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Идарәгә мәктүпләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Мәхмүд Әсгадь әфәнде хәзрәтләре белән «Кояш» сайфиясендә мөсахәбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Хыял галәмендән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Кызганыч бу тәнасеб . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Дини мәктәп һәм мәдрәсәләр хакындагы истифсарга даир . . . . 43
Коръән бозу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Харитонов җавабы мөнәсәбәте белән . . . . . . . . . . . 47
Мөфти хәзрәткә бердәнбер юл . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Бездә вә кардәшләремездә сөтрә мәсьәләсе . . . . . . . . 54
Мәгънәсез тәкълид . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Наилбәк һәм иптәше белән мөсахәбә . . . . . . . . . . . . 58
Беренче шәүвәл, шинбә көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
«Йолдыз»га җавап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Олуг милләтче тугрысында кечкенә бер хатирә . . . . . . 66
Хурлык сәнәде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Хәррәфуль кәлям ган мәвазыйгиһи . . . . . . . . . . . . . 69
Инкыйлаб вә без . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Вакытлы мөфти . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Корылтайда хатын-кыз мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . 106
Оят булды! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
*Аңлатмалар һәм искәрмәләр* . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
**Фатих Әмирханга язылган хатлар** . . . . . . . . . . . . . . 116
Борһан Шәрәф хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Кәбир Бәкер хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Вафа Бәхтияров хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Борһан Шәрәф хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Исмәгыйль Аитов хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Әхмәд Исхак хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Исмәгыйль Аитов хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Хәлил Әбелханов хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Йосыф Казаков хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Ибраһим Бикколов хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Камил Мотыйгый хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Фәхрелислам Агиев хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

Ләбибә Хөсәения хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Ризван Алуши хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Борһан Шәрәф хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Ризван Алуши хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Борһан Шәрәф хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Ризван Алуши хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Билгесез мөселман хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Әфтәхетдин Габдуллин хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Ибраһим Бикколов хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Ризван Алуши хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Фәхрислам Агиев хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Габдрахман Гомәров хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Кояш Җәббәрова хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Таһир Ильяси хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Шәһид Гайфи хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Фәрханә Алуши хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Фәрханә Алуши хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Зәкәрия Сәдретдинев хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Зариф Бәшири хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Муса Бигиев хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
**Фатих Әмирхан – замандашлары истәлекләрендә**. . . . . . . 185
Миргазиз Укмасыйның Ф. Әмирхан турындагы истәлеге . . . . 187
Разия Бәхтиярова истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Габделбари Баттал-Таймас истәлеге . . . . . . . . . . . . . 205
Хәбибрахман Рәфыйков истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . 212
**Фатих Әмирханның соңгы көннәре турында**
**яңа табылган чыганак: Кәрим Сәгыйд көндәлеге** . . . . . . . 220
Атаклы татар әдибе Фатих Әмирханның
авыруы, үлүе, күмелү мәрасиме. . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Фатих Әмирханның ютәл авыруы . . . . . . . . . . . . . . . 222
Кырымда һәм андан кайткач . . . . . . . . . . . . . . . . . . 223
Үлем авыруының башлануы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
Фатихны карар өчен төзелгән кизүлек . . . . . . . . . . . . 229
Яшь татар врачларының үзләре куйган кизүләре . . . . . 230
Фатих Әмирхан авырган чагында хәл белә килүчеләр . . . . . 239
Комиссияләрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
Ф. Әмирханны күмү мәрасиме турында мәҗлес протоколы . . . 253
Күмү мәрасиме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 262
Ф. Әмирхан үлү уңае белән гәзит-журналларда чыккан мәкаләләр . 266
**Ф. Әмирхан турында фәнни-тәнкыйди мәкаләләр** . . . . . 268
*З.З. Рәмиев.* И. Ф. Әмирхан иҗади мирасы – текстологик
тикшеренүләрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268
*Л.М. Тимерова.* И. Нуруллин тәнкыйтендә Фатих
Әмирханның проза әсәрләренә бәйле карашлар . . . . . . . . 272
*А.Р. Мөбарәкшина.* XX йөз башы төрек-татар әдәби
багланышлары яссылыгында Ф. Әмирхан иҗатын өйрәнү . . . . 278
*Г.Ф. Юнусова.* Фатих Амирхан и музыка . . . . . . . . . . . 282
*Н.И. Таиров.* Неизвестная фотография писателя Фатиха Амирхана . 289
*Л.Ә. Медведева.* Милли музей фондында Фатих Әмирхан мирасы . 292

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**

Выпуск 2

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *К.В. Кормушина*

Подписано в печать: 18.11.2016 г.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 17,4. Уч-изд. л. 14,2. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12